# КАЗАН УТЛАРЫ

6.1997



# 1997 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында УКАЗ



А. Абзгильдин



В. Ганиева



Р. Харис

Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, **карар бирәм:**

1997 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен:

1. **Абзгильдин Абрек Әмир улына,** «Г. Тукай», «Дәрдмәнд», «Б. Урманче» триптихы әсәрләре сериясе өчен;

2. **Ганиева Венера Әхәт кызына,** Дж. Вердиның «Риголетто» операсында Джильда, «Травиата» операсында Виолетта, Дж. Россининың «Севилья чәчтарашы» операсында Розина, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партияләрен башкарганы өчен;

3. **Ренат Хариска (Харисов Ренат Мәгъсүм улына),** «Хисемнең исеме» дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 1996 ел) өчен бирергә.

*Казан, Кремль.*
*1997 ел, 24 апрель*

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. ШӘЙМИЕВ**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**6**

**(896)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

РУХТА, ҖАНДА БЕЗНЕҢ — САБАНТУЙ!

С. ХӘКИМ. Ходайдан мин сорыйм... *Шигырь* ... 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Элмәк. *Роман* ... 4
З. ХӘКИМ. Гөнаһ. *Роман* ... 49
Р. РАХМАН. Каенлы җыр. *Шигырьләр* ... 125

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ

ЗӨЛФӘТ. Күңел агымының сере ... 36
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Кайда синең йөрәк турын. *Шигырьләр* ... 37

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Г. АХУНОВ. «Сагышларым Агыйделдә чайкадым...» ... 42
К. АРАЛБАЙ. Ак тирмә. *Шигырьләр* ... 43

ФАРСИЛ ЗЫЯТДИНГА 60 ЯШЬ

Ш. МАННАП. Туган җирдән күч алып... ... 106
Ф. ЗЫЯТДИН. Кайту. *Шигырьләр* ... 108

КАВИ ЛАТЫЙПКА 70 ЯШЬ

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. «Һәркем җирдә бер бизәк...» ... 111
К. ЛАТЫЙП. Серле култамгалар ... 114

ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. УРАЗАЕВ. Фаҗигале мизгел ... 128

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

С. ГОБӘЙДУЛЛИН. Онытылмас әтием ... 132

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ә. БАЯН. Проза турында сөйләшү ... 153

ХӘТЕР

Н. НӘҖМИ. Истәлекләр ... 156

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Р. НӘФЫЙКОВ. Шагыйрьне өйрәнү юлында. ... 164

ӘДӘБИ МИРАС

Гаяз Исхакый хатлары ... 167

СӘНГАТЬ

Т. ӘЙДИ. Рухы нык — үргә менә ... 175

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**



Б е з н е ң а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.


# В НАШЕМ НОМЕРЕ


«Проза и поэзия»: продолжение романа Т. ГАЛИУЛЛИНА «Петля», продолжение романа З. ХАКИМА «Грех»; стихи Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, К. АРАЛБАЯ, Ф. ЗИЯТДИНОВА, Р. РАХМАН.
«К 70-летию Кави Латыйпа»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА посвящена творчеству юбиляра; статья К. ЛАТЫЙПА «Таинственные автографы».
«Публицистика»: статья Ф. УРАЗАЕВА «Трагический миг». «К 110-летию Газиза Губайдуллина»: воспоминания об отце С. ГУБАЙДУЛЛИНА.
«Литературная критика»: статья А. БАЯНА о проблемах современной прозы.
«Память»: воспоминания Н. НАДЖМИ.
«К истории литературы»: статья Р. НАФИГОВА «На пути изучения поэта».
«Литературное наследие»: письма Г. ИСХАКИ.
«Искусство»: статья Т. АЙДИ посвящена к 60-летию композитора Р. Еникеева.
В номере отмечаются юбилеи Э. Шарифуллиной, Ф. Зиятдинова, Н. Каримовой.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Дердменд» — триптих лауреата Государственной премии имени Г. Тукая, художника А. Абзгильдина; известный поэт Назар Наджми.


# In our issue


«Prose and poetry»: the seguel of T. Galiullin's novel «Loop», the seguel of Z. Khakim's novel «Sin»; the verses of E. Shariphullina, K. Aralbai, Ph. Ziyatdinov, R. Rakhman.
«Commemorating the 70 th anniversary of Kavi Latip»: R. Phaizullin's article devoted to the creabive-work of Kavi Latip; K. Latip's article «Mysterious autographs».
«Publicism: Ph. Urazaev's article «The tragic moment».
«Commemorating the 110 th anniversary of Gaziz Gubaidullin»: recollections about S. Gubaidullin's fathev.
«Literary critigue: A. Bayan's article about ptoblems of modern prose.
«Memory»: N. Nadjmi's recollection.
«To the ristory of literature»: R. Naphigov's article «Studying the poet».
«Literary heritage»: G. Iskhaki's letters.
«Art»: T. Aidi's article devoted to the 60 th anniversary of composer R. Enikeev.
Anniversaries of E. Shariphullina, Ph. Siyatdinov, N. Karimova are celebrated.
«Remark»: M. Akhmetzyanov. «What are facts telling?»
The diary of social and cultural life.
In our covers: Dardmand» — the trip tych of Tukai prize winner, an artist A. Abgildin, well-rnown poet Nazar Nadjmi.



● **Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.**

● **Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**

● **Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.**



*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев, Тәүфикъ Әйди**

*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.



Производствога бирелде 30.04.97 ел. Басарга кул куелды 10.06.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 12 660. Заказ Н-216.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1997 ел.

## Сибгат Хәким

* * *

Ходайдан мин сорыйм: алданрак,
Яки соңрак, димен, ал җаным,
Тимә миңа, тимә син миңа
Сабан туе көнне Арчаның.

Мин мәйданда... Мәйдан таралгач,
Бүтән төштән мине син эзлә.
Минем өчен дөнья рәхәте —
Кайту шул көн кичке поездда.

Кала болын артта чәчәктә,
Кала кырлар, кала су-инеш;
Тыгыз, кыен, керә вагонга,
Килеп керә мәйдан шул килеш.

Гармун керә, төшкән салынып
Гармуннардан арып кул башы;
Тыңлыйм шул кич халкым моңнарын
Җаным тәмам гарык булганчы.

Кешеләрнең ачык йөзеннән
Бар уйларын шунда укыдым;
Рельслардан өскә күтәреп,
Бөек көче шулар рухының.

Каяндыр бик ерак-еракка
Илтә сыман: узып Казаннан,
Барам, барам, мин бу поездан
Теләсәм дә төшеп калалмам.

Телем, рухым шушы поездда,
Әллә нинди үзенә бер поезд;
Саклап барлык изге хисләрен,
Тигез торсын иде йортыбыз.

Ходайдан мин үтенәм: кичектер,
Халәтемнең үлчәп бар ягын,
Тимә миңа, тимә син миңа
Сабан туе көнне Арчаның.

## Тәлгат Галиуллин

# ЭЛМӘК

РОМАН

### 9

Сакманов магаданлы энесен сакчы штатына утыртты. Җитдирәк эш бирергә иртәрәк дигән фикергә килде. Башында — солы боламыгы. Әлегә аның фатирына күз-колак булып торсын, яңа мохиткә өйрәнсен.

Үзе яз-җәй айларында Матюшинода сатып алган агач йортында яши торган булып китте. Халык теленә «охотник» кушаматы белән кереп калган, элеккеге фирка өлкә комитетының җаваплы хезмәткәре сеңелесенең йортын сатып алган иде. «Дотация» туктагач, ялгыз карчыкка шактый олы биләмәне тәртиптә тотуы кыенлаша. Сәет шундый бер тыныч, саклаулы, карап торылган юллы урынны күптәннән эзли иде, бу юлы хәбәрдарлык аңа ярдәм итте. Дөрес, бакчасында бикләнеп кенә ята алмый. Төркия, Кипр, Балтика илләрендә еш булырга туры килә. Бүрене — аяклары туйдыра.

Вильсурның башкисәрләре «Игелек» хуҗасының шәһәрдәге фатирын күз уңыннан төшермиләр, заманында Шөреп Мансур Мәүлетовны каравыллаган дәрәҗәдә үк саклыйлар. Сакманов үзе генә белми бу хакта. «Рәхмәтле» булыр иде.

Көзге җепшек көннәрнең берсендә Вильсур колагына яраннары сөенечле, көтеп алынган хәбәр ирештерәләр: Сәет Ярулла улы Сакманов инде өченче атна трамвайда йөри. Машинасы өенә килми диярлек. Дөрес, фатирыннан чыгып китү, кайтып керү вакытын тәгаен билгеләве кыен. Төрлечә кыландыра. Бер көнне оясыннан сәгать сигездә үк чыгып китсә, икенче вакытта төшкә чаклы өендә кала. Әйләнеп кайтуы да вакыт кысаларына сыймый. Алманнар төгәллеге юк үзендә. Тагын бер өметле күзәтү: сирәк-мирәк булса да, подъездына чайкала-чайкала кереп киткән кичләре дә булгалый.

Бу яңалыкны зиһененә үткәргәч, Вильсур усал, тантаналы, җиңүле елмаюын яшерә алмый. Иреннәре каз канатларыдай як-якка җәелә. «Әһә, киеренке тормышка түзә алмыйча, гөнаһлы тәнеңнең тиздән сары балчык эченә керәсен сизеп, эчүгә сабыштыңмы? Халык арасына кереп югалып, трамвайда йөреп котылырга хыялланасыңмы? Үз-үзенә гашыйк, эре, тәкәббер, ваемсыз рәхәт тормыш гаменә кереп баткан, хатын-кыз итәге колы Мансур белән бил алышу түгел бу сиңа, абзыкай. Капкынга килеп керүеңне сизми дә калырсың! Үзеңне үле кешегә сана!»

---

Дәвамы. Башы 5 санда.

«Өеннән чыкканда яисә соңрак, салмыш хәлендә кайтканда мүшкәгә, пычакка алырга»,— дигән тәкъдимне кабул итмәде Вильсур. Юк, мондый алым артык гадәти бер криминал гына булыр иде. Аны җәзалап үтерергә кирәк. Миендә Остап Бендер, Саламторханнарны көнләштерә алырлык, һөҗүмчән хыялый манзара туды... Башкаручыларын җиз иләк аша уздырып, сайлап алды, үтәлешнең вак-төягенә чаклы үзе төпченде. Аның кебек акылга муафыйк кешеләр аз, дигән фикердә ныгыган иде ул күптәннән. Әлләҗем буласы кеше иде дә, вакытында күреп, бәяләп җиткермәделәр...

Көн яктысы караңгылык шәүләсен эретә алмаган, салкынча яңгырлы иртәләрнең берсе иде. Трамвайга салкының ни, эссең ни, аңа барыбер. Ул — берәүдән дә курыкмый, бер шәйгә дә ашыкмый. Кешеләргә мәрхәмәтле, юллары туры килсә, кирәк җиргә илтә дә куя.

Магаданнан алып килгән иске биштәрен тоткан Рафаэльне да тимер сандык үз эченә алды. Аңа чаклы, үзгә тукталышларда, шактый кешегә мәрхәмәтлелек күрсәткән булып чыкты трамвай иптәш.

Буш урыннар юк иде. Сакмаров уртагарак үтеп, уң кулы белән югарыдагы тимер сузымга тотынды. Янында ике яшь кыз утыра. Кара чәчле, калку яңаклысы мөмкин булганча кыска тегелгән итәкле, йомры тезле, аксыл сары чәчле, нечкә борынлы сердәшенә ашыга-ашыга нидер сөйли. Ахири кызлар, араларына ир-ат заты кереп «кәртләрен бутаганчы», беркайчан да сөйләшеп, серләшеп туя алмыйлар. Аек акыл яссылыгыннан килеп бәяләгәндә, юк кына нәрсәләр турында, көлешә-көлешә сәгатьләр буенча ләчтит сатуны шөгыльгә дә санамыйлар.

Рафаэльнең күзләре бер генә мизгелгә, аның ягында утырган кызның аякларына төште. Йомры тез башларын алдагы утыргычның артына ук терәп куйган. Үтә күренмәле йон оек, теләр-теләмәс кенә тар итәк астына кереп китә. Башка вакытта Сәетнең туганы да күзләре белән кызларның аягын озаклап иркәләп барырга, «минем аркага терәлеп утырсаң иде, матурым, салкын урындык шундый нәфис ботларның җылы, йомшак, назлы икәнен бәяли алмый, кадерен белми, ханымнарның бөтен матурлыгы, күрке, мактанычы аяктыр»,— дип хыялланып, ләззәтләнеп барырга ярата иде. Ә бүген ул бу гүзәллеккә исе китми, бәяләми. Аның бөтен барлыгын башка хәсрәт биләгән. Сул кулы белән пинжәгенең сәдәфкә каптырылган эчке кесәсен кысып бара. Анда аның бар байлыгы — алтын коелмасы. Хәзер аны ломбардка илтеп тапшыра да, самолетка билет алып, Магаданга оча. Кайтмыйча булдыра алмый, инде өченче көн, диңгез суыдай зәңгәрсу күзле, су анасы кебек ап-ак чәчле кызы Лариса төшенә керә. «Әтием, кайт, сине сагынудан чирләдем»,— дип, кычкырып-кычкырып елый, ап-ак тиреле кечкенә куллары белән муеныннан кочаклый. Кызы аны сагынган, ул аның янында булырга тиеш. Бәлки, кире кайтыр әле Казанга. Кызын да алып килер. Сәет абыйсының өйдә булмавы начар. Күпме изгелек эшләде. Ул аңа барысын да аңлатып, озын итеп хат язып, рәхмәтләрен әйтеп калдырыр. Акчаны күбрәк бирсәләр, берәр бүләк алып калдырыр...

Шунда Рафаэль кемнеңдер терсәге белән янтавына каты итеп төрткәнен тойды. Уйларыннан аерылырга мәҗбүр булды. Борынына аракы, суган, сарымсак «дуслыгы» җимеше — сасы, әшәке ис килеп бәрелде. Күңеле болганып, косасылары килеп китте. Чит ир гәүдәсе белән Сакмаровның пинҗәк өстеннән киелгән күн курткасына сыланган, кайнар кулы учына ук терәлгән. Махмыр дулкыны шул тарафлардан иңә икән.

Магаданлы артына борылып карамыйча, матур аякларга моңсу карашын да төшермичә, алгарак күчте. Кемгәдер урын җитми, күрәсең. Сасы исле бәндә дә аңа иярде. Тагын терәлеп басты. Берни аңламаган Рафаэль гаҗизләнеп артына борылып карады: кемсәгә тыгыз икән анда. Бакса, янында иске, таушалган бүрек, тар якалы, кыска зәңгәрсу пальто кигән, таушалган йөзле, бәрәңге борынының бер урында тиресе кубарылып,

кызыл ите күренеп торган ир боргалана икән. Яшен тәгаен билгеләве кыен. Иллеләр тирәсендә булыр.

«Бу агай-эне үзен-үзе белештермәс дәрәҗәдә исерек бугай, бәйләнә күрмәсен тагын,— дип, Әхсән абзый улы алгарак күчүне мәслихәт күрде. Яралы борын аңа иярде. Магнит белән бәйләп куйганнармени? Рафаэль янәдән бер-ике рәт утыргычны артта калдырды. Теге ир янәдән янына килеп басты, ышкылырга тотынды. Егет уң кулын курткасы кесәсенә тыгып, терсәген тырпайтып, тегенең корсагына терәде, «иске бүрек» аның белән «аралашырга» теләүче юклыкны аңлап, тынычланасы, нәтиҗә ясыйсы урынга, басымны, эзәрлекләүне көчәйтә барды. Берәр таныш-мазар шаярта торгандыр, дип фараз кылып, борылып, йөзенә игътибар беләнрәк карады. Эзәрлекләүченең бик исе китми үзен өйрәнүгә. Күзләрен тәрәзәгә текәгән дә, арзанлы аракы сасысы артыннан гәүдәсен юнәлтә бирә. Танк кебек өстенә бара магаданлының. Ике-өч тукталыш түздә Рафаэль. Инде тәкате корыгач: «Әйдә, абзый, уз, мин хатын-кыз түгел, сыланып барырга»,— дип әйтеп салды. Артык исе китмәде махмырлының. Җавабы әзер иде.

— Син үзең миңа хут бирмисең, терсәгең белән эчемне кара яндырып, тишеп бетердең, ярдәм итегез, хулиган,— дип кычкырына ук башлады салмыш агай.

Оештырылган әшәкелекне сизгер күңеле чамалаган Рафаэль алгы ишеккә таба атлый. Беренче тукталышта ук төшеп калу иде нияте. Теге бәндә йөгерә-атлый килеп, Сакмаровның җиңенә ябыша.

— Ярдәм итегез, ул мине рәнҗетте, сволочь,— дип, кычкырынуын дәвам итә.

Дөреслек яклы кешеләре дә табыла шул ук трамвайда. Ике әзмәвердәй таза егет Рафаэль янына килеп, ике яктан култыклап алып, күтәреп диярлек трамвайдан төшерәләр. Башкалар битараф кына, күзәтеп тора, ике чибәр кыз сүзләрен дәвам итә. «Рәнҗетелгән» кеше үз аягы белән җиргә сикерә. Милициясе дә килеп чыга, будкага алып кереп, беркетмә тутыралар, шаһитлардан, табигый ки, шул ук егетләрдән дәгъва-аңлатмалар яздырып, Рафаэльны бүлекчәгә озаталар. Санаулы дәкыйка эчендә бу сөенечле хәбәр телефон төбендә утырган Вильсурга ирешә. Ул яраннарына әзер әмер төшерә: «Сакмановны КПЗда озак тотмаслар, ментовкада дус-ишләре күп. Өенә үк озатып куймагайлары. Шул тирәдә саклап торыгыз, бернечә машина белән. Милиция бүлегеннән чыгуга, автоматтан урталай кисегез. «Тегеләр» атып үтергән дип хәбәр таратырлык урын, мөмкинлек калсын. Урлап китә алсагыз... өчләтә артык түлим».

Чыннан да Вильсур Садыйков фаразы раска килә. Аркасын, тез асларын, йомшак җирләрен иҗтимагый урында тәртип бозган, вак хулиганлык өчен резина таяк белән «иркәләп», тиешле сумманы түләткәч, мәхбүсне чыгарып та җибәрәләр. Шул ук көйсез, яңгырлы көн торса да, урамда рәхәтрәк, иркенрәк икән. Ни өчен үзенә трамвайда бәйләнгәнне, хөкем оешмасына сөйрәп алып кереп, әллә нинди кәгазьләргә кул куйдырып, каршы әйткән өчен, сүгенә-сүгенә кыйнарга керешкәннәрен аңламаган шикелле, шулай тиз котылуына да ышанмыйча, тагын кире чакырып алмасыннар дип, егет чантасын селки-селки, олы юлга таба ашыга. Иншалла алтыны кесәсендә. «Тәрбияләгәндә» курткасын, пинжәген салдырдылар, биштәрен тикшерделәр, ә кесәләрен тентергә башлары җитмәде. Күпме мәшәкать, аңлашу, ышану-ышанмау китәр иде шул сары шайтан тирәсендә. Тизрәк-тизрәк илтеп тапшырырга кирәк бу металл кисәген. Бераз авызны чылатып, халәтне иркәләп алсаң да ярар иде шундый зәхмәттән соң. Шулай икеләнеп, уйланып атлаганда, янына шып итеп, чит илдә эшләнгән, адәм баласы акылының казанышы — спай җиңел машина килеп туктады. Арткы ишекнең тәрәзәсе ачылды, урта яшьләрдәге мыеклы ир кулы белән ишарә ясап, үзе янына утырырга чакырды. Рафаэль берни аңламый. Башы гөжли, тәне авырта. Абыйсы бу

хәл турыда ишетеп, артыннан машина җибәргән дияр идең, ул өйдә юк, гомумән Казанда түгел.

Алгы рәттә утырган адәм, төзәтеп булмаслык хата ясап, Рафаэльне айнытып җибәрде.

— Сәет Яруллович, утырыгыз, без сезнең дусларыгыз. Теләсә кая җилфердәтеп илтеп куярбыз.

Баш миендәге җыерчыклары тартышып, йөрәге чәнчешеп куйды. Рафаэль ул чаклы ук дивана түгел, барысын да аңлады. Аны абыйсы белән бутаганнар түгелме соң? Йа хода! Артта утыручыларның берсе таныш тоелды аңа. Туктале, трамвайдан күтәреп төшергән адәм түгелме соң? Беләгеннән авырттырып, чеметеп тоткач, ул егеткә ачу белән карап алган иде. Сыны, эчкә баткан күзләре, ике бармак чаклы гына тар маңгае хәтер казанында ныклап урнашып калган.

Рафаэльнең бөтен барлыгын курку, өркү, шикләнү биләде, бизгәк тоткандай калтырана башлап, бу таза җаналырлардан еракка, җәһәннәмгә булса да качып китәргә, дигән фикер зиһенен бораулады. Әмма аяклары хуҗаларын тыңламас хәлдә иде. Әйтерсең лә, сөяген, сеңерләрен, канын суырып алып, бөтен бәдәненә йомычка чүбе тутырганнар. Кәмит күреп, авызын ачып катып калган тиле-миле кебек, урам чатында тәк басып тора. «Вольво»ның беренче рәтендә утырганы «Ат!» — дип кычкырды. Нәкъ шул мәлдә Рафаэль янында бер ишекле кечкенә автобус пәйда булды. Ачык ишектән аңа мәрхәмәтле куллар үрелде. Сакманов шунда сикерде, лып итеп яндагы утыргычка сеңде. Аның башкага хәле калмаган иде. Ату тавышы ишетелмәде. Автобус, ашыкмыйча гына борылды да, баягы җилбәзәк машинага иярде. Магаданлы юлдашларына күтәрелеп карады һәм тынсыз-өнсез калды, Казанга килеп төшкән көнне, абыйсының таш баскычында сугып еккан, күн аяк киеме белән изгән бәндәне таныды. Ул — Гөмбә кушаматлы имансыз зат Роман Кусаматов иде. Магаданлы бүген үзен исән калдырмасларын аңлады. Трамвайда баргандагы шикелле, сул кулы белән алтынын кальбенә кысып, елап җибәрде. Күз алдында үз кызы булмаса да, аның өчен иң якын, иң газиз җан иясе Ларисасы тора. Аның өчен тырышканые.

Кеше язмышына битараф шәһәр шау-шулы, гөнаһлы тормышы белән яши бирде...

Бәхет эзләп, Магаданнан ата-бабасы җиренә аяк баскан Рафаэль Әхсән улы Сакмаровның үле гәүдәсен Коры Елгадан ерак түгел бер урманда, агачка асып куелган рәвештә табалар. Гөмбәнең корбанын гөмбә җыючылар күреп ала. Тәненнән вак калибрлы унбиш пуля табалар. Күрәсең, җан алучылар Рафаэльне тере килеш агачка элеп куеп, төз ату буенча мәргәнлек ярышлары уздырганнар. Берәүгә дә аңлы рәвештә начарлык эшләмәгән, явызлык кылмаган, болгавыр замана агышына җайлаша алмаган, күк тормышы өчен яратылган изге кан янында явыз каннар да аккан дигән фикергә килгәннәр тикшерүчеләр. Үтерүчеләр арасында авыр аңлашулар булганга охшый. Сәет Сакманов белән йөртүчесе Замир атышуга, һәрхәлдә кан коешуга барып җиткән низагъның серенә тиз төшенделәр. Сәбәбе: берәүгә дә бәхет бирмәгән Магаданнан килгән алтын коелмасы булырга тиеш. Байтак кешенең башына җитәрлек көч бар иде ул табылдыкта.

Көндәш ширкәт җитәкчесе Вильсур берничә көннән соң, җирле газитә битләреннән түбәндәге хәбәрне зиһененә алды: «Коры Елга янындагы урманда, беркая да эшләми торган, Магаданнан килгән Р. А. Сакмаровның үле гәүдәсе табылды. Җинаятьчеләрне эзләү башланды».

Бу көннәрдә бәйрәм халәтендә яшәгән, катыйльларына акчаның шактый өлешен түләп өлгергән Вильсур Мәгъсүм улы ошбу белешмә белән танышкач, өянәге тоткан кеше көненә төште, телсез, өнсез калды. Димәк, Сәет Сакманов исән, значит, сугыш дәвам итәчәк. Энесе өчен аңа, Вильсур Садыйковка түләргә туры киләчәк. Гафу итеп булмаслык ахмаклыклры өчен кыйммәтле киллерларын, Гөмбәдән башкаларын, куып

чыгарды. Бу адымы дошман тегерменәнә агызылган шифалы су булды. Алар бар гаепне, энесен үтерүне Гөмбә белән Вильсурга сылап калдырып, Сакманов белән якынаю юлларын эзли башладылар. «Эдельвейс» корылмасында үтәли җилләр уйнаганда Сәет кальгасы ныгый, көчәя барды.

Трамвайда Рафаэльгә бәйләнгән, яралы борынлы салмыш карт та табылды, көтмәгәндә кесәсенә килеп кергән акча бәрабәренә, ул үзен ничек эзләп табуларын, яллауларын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бу төр кешеләрнең иманы да, ватаны да була алмый. Хәмер атлы шайтанга коллыкка төшкән бәндә, тамагы хакына теләсә кемне сата алып, янәдән ваклап сата ала.

Вильсур ширкәтенең икътисадый хәле шактый хөртиләнде. Мансурның энесе Ленар Динмөхәмметов та, аның өметен аклау турында җитди уйланмыйча, үз теләге белән диярлек, тәненә кургаш «сорап» алып, абыйсы янына кереп ятты. «Акчаң булганда бар да дус, акчаң бетүгә, бар да яныңнан таяр», дип белмичә язмагандыр бер шагыйрь. Килер мал кимегәндә, китәр чыгымнар арта бара икән. Мәгәр нәтиҗә ясарга иртә әле. Арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче кала, диләр.

## 10

Сакмановның терелүе шактый озакка сузылды, аңына килеп, мәненә кайтып, тамагына каба башлагач та, аягына басып, мөстәкыйль хәрәкәт иткәнче шактый вакыт узды. Җәрәхәтләре санап бетергесез иде. Шәфкать туташы да арыды, йончыды. Аны аеруча киләчәгенең, караватта егетләнеп яткан кеше белән мөнәсәбәтләренең, әллә ничек кенә, бернинди шартнамә белән беркетелмәгән булуы борчыды. «Гомерлек ярым шул чирләшкә булырмы икән?» — кебек шаян-моңсу гамен ачылышлысы алыштырды: «Өч ай яныннан китмичә, интегә-янтыга аякка бастырырсың да, «мин синнән ярдәм сорамадым»,— дип, шамбы балыгы кебек, кулыңнан шуар да чыгар. Машинасының төтенен иснәп, өч юл чатында, әкияттәге күзле бүкәндәй, чәчләреңне тузгытып басып калырсың».

Шул ук вакытта ап-ак чырайлы, яра эзләре ямалып бетмәгән, сакалмыек баскан ир белән күңел уртаклыгын, җан якынлыгын тоеп яшәү аңа дәрт, дәрман өсти. Соңыннан Сәет белән борчаклары пешмәсә дә, ул карават янында уздырган көннәре өчен үкенмәс кебек. Ир-ат белән буталгаласа да, аның сыктанып, әрнеп яраткан кешесе булмаган икән әлегә кадәр. Аның өчен иң кыены арага Җирәннең килеп керүе иде. Аны яратмый Фәридә. Мәгәр кискен рәвештә бүрәнәләрен дә бүлеп куя алмый. Шөлли. Теге үзен айга сикергән азгын арысландай тота.

Эчке күлмәк өстенә генә киелгән яңа халаты җайсызрак булды, бөгелгәндә, иелгәндә гел шуышып төшә, шул мәлдә җитешеп тулган күкрәкләр ачылып, биешеп алалар. Ханым өзелеп төшәргә әзер алмаларны каплап куйгандай итә. Терелеп килгән ирнең аның һәр хәрәкәтен күзәтеп ятканын сиземли. Сызлаулары, тән әрнүләре иргә ачылып китәргә бирми. Яшен чыбыркысыдай елмаеп ала да, тагын кырыслана.

Куллары хәрәкәтләнә, кашыкны үзе тота башлагач, Сәет гомерендә беренче кат, кызамык белән чирләгәндәге шикелле, кайнар учына Фәридәнең бармакларын алды. Ханым кулга кергән тере балыктай бөтен гәүдәсе белән калтыранып куйды. Рәнҗетмәслек итеп кенә кулын бушатты.— Сезгә, Сәет Яруллович, шаярырга ярамый. Врачлардан андый рөхсәт юк.

— Ни өчен?

— Хәлегез авыр. Аннан, сез бит җитди кеше. Бала-чага түгел!

— Кем мине, суръюзный, ди?

Фәридә икеләнеп торды да, ярым шаярткан булып, әйтеп салды.

— Үзем беләм. Сез коедан үле бала эзлисез: хатын-кыз башын өтермәгә тыгу хыялы белән яшисез. Моннан да явыз кеше була аламы соң җир йөзендә?

Бер тын белән көнләшүне... 

Бер тын белән күңелендәге кысып чыгарды да тынып калды. Үзенә дә уңайсыз булып китте. Бармакларын туфлие кысамы диярсең. Озак еллар күңелендә ачулы нөктә булып яшәгән үпкәсен әйтмичә калдыра алмады. Килен коймагындагы төер генә түгел шул йөрәк ярасы. Кул белән алып ташлап, авызга эләксә, төкереп котылып булмый.

Сәет йөзен читкә бормады, үпкәләмәде. Оста шахматчы төсле, иң дөрес юлны тапты. Күңелендәгесен чište...

— Ул дивана чорымда, синең шундый изге кеше икәнеңне, язгы чәчәк төсле матураеп ачылып китәсеңне күз алдыма да китерә алмадым. Ахмак булынган. Хәзер терсәкне тешләп булмый. Ачуланмавыңны, соңарган тәүбәмне кабул кылуыңны гына сорый алам.

Фикер сөрешенең икенче өлешенә Фәридә юри дикъкать салмады. Бу хакта аңлашу бер тапкыр гына булмас әле.

— Матурлык бер көнлек байлык. Аңысын әти-әни биргән. Минем бу эшкә катнашым юк диярлек.

— Ни өчен «диярлек»?

— Үземне саклап тота белдем. Өлешләп вакларга ирек куймадым.

— Һмм... Кызык. Дөньяга китерүчеләрең табигый чибәрлегеңә әдәп-әхлак якларын да өстәгән булсаларчы? — дип, ычкындырганын сизми дә калды Сәет. Соңыннан, Су Анасының тарагын урлаган малайдан да ныграк үкенде шул җөмләсе өчен. Әйткән сүз — аткан ук. Аның ни хакы бар Фәридәне шулай битәрләп, тәнкыйть итеп утырырга. Үзең фәрештә булсаң бер хәл иде.

Иплe генә башланган сөйләшү барышында ханымның алсулык типкән бит алмаларына рәнҗү катыш үпкә, әрнү тимгелләре бәреп чыкты. Күзләре тирән упкындай эчкә батты. Кискен торып басты.

— Гафу ит, Фәридә! Зинһар дим.

— Минем белән шулай сөйләшергә ни хаккыгыз бар? Көне-төне янызызда утыруның рәхмәте шул булдымы?

— Булдыра алсаң, Фәридәкәй, рәнҗемә инде. Минем шундый гадәтем бар. Әүвәл әйтәм, соңра уйлана башлыйм. Бернинди явыз ниятем юк иде.

— Сез бит чынында берни белмисез! Вакыйганың тышкы ягын гына күрдегез. Милисәдә эшләгәндә дә, тирәнгә кереп, тикшереп, өйрәнеп тормадыгыз. Максатыгыз: фактны раслап, мине этапка озатып, иңбашыгызга яңа йолдыз тагу иде. Кеше, аның язмышы, шул фаҗигага этәргән сәбәпләр берегезне дә борчымады. Их сез, җаваплы ирләр.

Сәет дус-ишләре белән аралашкандагыдай җиңеллек белән ычкынган сүзләре өчен чын күңелдән, ихлас җаннан үкенде. Үзенә тау хәтле яхшылык эшләгән, өзелеп төшәргә әзер җимештәй чибәр хатынны ни пычагыма дип шулай рәнҗетә соң әле ул! Эгоист первой гильдии. Хаталанган, булган, беткән. Базар хатыны кебек, сасы мичкәдә күәс әчетәсең! Кайдадыр укыган иде: «Әшәке хатыннан үзең котыл, яхшысы үзе ташлап китәр». Хатын-кыз гадәттә изгелекне онытмый, начарлыкка шул ук көмеш белән түли.

Фәридәнең ифрат четерекле, катлаулы хис-тойгылар өермәсе эчендә калганын аңлады Сакманов. Чын-чынлап үпкәле генә күрмәсен иде. Иманеп китте.

Өлгергән карлыгандай кара, сизгәк күзле, өлгергән гәүдәле ханымның үзенә кадерле җан икәнен җаны, тәне, яралы күзәнәкләре белән тойды Сәет шул мизгелдә.

Ханым чыгып китмәде. Күзендәге яңгыр тамчыларын кечтеки ак яулыгы белән сөртте дә сөйләп китте:

— Сез бит берни белмисез. Минем әнием (мин аңардан бик яшьли калдым): «Адәм язмышы, агым су кебек, борылмалы, сыгылмалы,

чоңгыллы»,— ди торгание. Сәет Яруллович, дөресен әйтәм, сез миңа якын булып киттегез. Абыем кебек димме. Киләчәктә араларыбыз ничек булып бетәр, күрәзәлек итә алмыйм, миннән генә тормый. Сез тышкы дөнья мәшәкатьләрен кабул итә алырлык хәлгә килгәч, тормыш юлымны түкми-чәчми, бигрәк тә «теге хәлне» бәйнә-бәйнә сөйләп бирермен дигән нәзерем бар. Хәлегез шәпләнә бара. Шаярта, төрттерә, хәтта чәнчи башладыгыз.

Бер авызы пешкәч, салкын суны да өреп кабу хәленә төшкән Сәет: «Күңелеңә яра аласы булсаң, сөйләмә, Фәридә. Узган эшкә салаватулла. Тем более, мин хәзер хөкем оешмасында эшләмим!» — дип, чигенүне мәгъкульрәк күрде. «Синең аркада милициядән куып чыгардылар»,— дигән, тел очына килгән җөмләне аска, үт куыгына төртеп төшерде. Акыл теше чыгарга вакыт иде абзыйга.

— Ничек булганын мин үзем сөйләп бирә алам. Телисеңме? — дип әтәчләнде «Игелек» хуҗасы.

— Йәле,— диде табигый хәленә кайткан ханым, сакаллы сабыйның уенына тартылып.

— Тәк. Училище тәмамлап, медсестра булып эшли башлаган, авыллыгы чыкмаган мөлаем кызый, чыкылдап торган шәһәр компаниесенә, тусовкага эләгә. Үрнәкләр күрсәтә-күрсәтә, мактый-мактый, үз шәхси мисаллары белән котырта-үрти шәраб эчерәләр. Кызыл хәмергә спирт кушылган була. Шайтан пары кызның миенә үрмәли, акыл күзәнәкләрен томалый. Озын буйлы, нечкә иренле, очлы борынлы, аксыл бөдрә сачле егет аны тансыга ала. Кочаклашып, җылыга тарган сары майдай эреп биегән арада бүлмәдә икәүдән-икәү генә калганны яшь шәфкать туташы, гомерләр узган шикелле, сизми дә кала. Ловелас эссе кулын нечкә билдән алмыйча гына, кызны тәрәзә янына алып килә, урамда торган «Мерседес»ка төртеп күрсәтә: «Бу — синеке». Шуннан теленә салына башлый: «Күзләрең ошый миңа, йомшак күкрәгеңә гөнаһлы башымны салып, мәңгегә йокыга таласым килә. Минеке бул. Теге дөньяда, хәтта, случайно, оҗмахка эләксәң дә, җенси тормыш, сөешү юк. Чал тарих белән чагыштырганда, кешенең гомере, вай-вай, кыска. Күбәләкнеке кебек кенә. Санаулы рәхәт мизгелләрне әләктереп калырга кирәк».

Куллары, табигый ки, тик тормый, тегендә керә, моннан чыга, кызның кызышуы җитә һәм, шул татлы ширбәт басымына түзә алмыйча, Агыйдел камышыдай бөгелеп төшә. Карышырлык тәкате калмый... Тагын һәм тагын очрашасыз. «Колга», биленнен нечкәлеге юкка чыгуын күргән көнне үк, кояш нурлары куып тараткан иртәнге томан кебек, юкка чыга.

Фәридә авыруның илһамланып сөйләгән хыялый хикәятен бүлдермичә тыңлады. Көянтәдәй кашлары гаҗәпләнүдән бер өскә менде, бер аска төште. Каен күмередәй кара, шыр ачылган күзләрендә серле тирәнлек. Шунда кереп югаласы, эрисе килеп китте Сәетнең. Өсте турсаеп торган тулы иреннәренең читенә елмаю кунды. Очып чыгарга әзер тутый кош төсле. Сәетнең хыял уенынамы, әллә шул чаклы матур сөйләвенә шаклар катыпмы, ул кадәресен кистереп әйтүе кыен. Фәридә кычкырып көлеп җибәрде. Тәмәке тартырга чыккан җирән яугир ишекне ачып карап алды.

— Дөрес уйламыйсыз. Уйдырмагыз раска чыкмый. Әйтсәм әйтим: әгәр шундый яшь, иләс-миләс чагымда сезне очраткан булсам, бәлки, мерседесыгызга утырып киткән булыр да идем. Но, увы. Гомер узды, чабата тузды...

— Чыны менә болай,— дип, бирешмәде Сәет.— Хастаханәнең өченче катында катлаулы операция бара. Баш врач яисә баш хирург син биргән сөлгегә маңгаендагы тирен сөртә дә, җилкәңә кулын сала. Син тыйнаклыгың аркасындамы, югалып калыпмы, аяк табаныңнан күтәрелгән шатлык хисенә бирелепме, йонлы кулга шап иттереп сукмыйсың. Шул гына кирәк тегеңә. Йомран мәсле әрсезләнә. Оҗмахлар вәгъдә итеп, шул

исәптән хатыны белән аерылышып, өйләнергә антлар эчеп, синең белән йоклауга ирешә. Мондый якынлык, өлгергән карбыз кебек шартларга җиткән, шуны таләп иткән тыгыз тәнеңә охшап китә. Бала тугач, коты алынып, сине әлеге юлга этәрә.

— Бу гөманыгыз да туры килми, әфәндем. Кино сөйләвегезне дәвам иттерә аласызмы? Әүвәл менә бу эремчекне йотып җибәрик, йөрәкне тазарта, башны эшләтә торган ризык бу, менә шулай.

Тыңлаучан балага әверелә барган Сәет, эремчекне җылы чәй белән тамагыннан төртеп төшергәч, лыкылдавын дәвам иттерде.

— Хуш. Хәзер иң дөресен сөйлим. Фал китабын ачтым. Авылыңа кайткач, алдынгы, орденлы комбайнчы сине озата килә. Синең печәнлектә берүзең йоклаганыңны белеп китә, төнге сәгать бердә, син җәелеп, изрәп, кул-аякларыңны як-якка ташлап, мәрткә киткәнеңне күтеп ала да, ач бүредәй өстеңә сикерә, көчли. Үзең дә принципиаль каршылык күрсәтмисең. Чуаш кардәшләр әйтмешли, «рәкәт пулып» китә. Беркем белми дә кала. Кулыңны сорап килә. Яктыда тегенең йөзен күргәч, никахтан баш тартасың.

Сәетнең шаярткан булып, Фәридәнең үткәне турында күбрәк беләсе килүен аңлады ханым. Значитсы, битараф түгел.

— Бөтенләй башкача булды шул минем хәлләр, Сәет Яруллович. Мең дә бер вариант уйлап тапсагыз да, туры китерә алмассыз, дип куркам. Иң мөһиме: мине көчләүче дә, алдаучы да булмады. Үз ихтыярым, үз теләгем белән...

— Әһә, аңыштым. Ләйлә белән Мәҗнүн, Таһир белән Зөһрә, Ромео-Джульетталар мәхәббәте... Олы шашыну... Җир Күккә тоташа... Тик замана баласы — Таһир подлец булып чыга. Срочно «үлеп» китә. Шулай ук адым саен очрый торган тәварих.

Фәридә авырлык белән икеләнүен йотты, иренендә, кош мамыгыдай утырып калган елмаюын саклап, сүзен башлады.

— Әйткән идем: мин әни рәхәтен күрмәдем.

— Ташлап киттеме?

— Вафат булды. Мине әткәй белән олы апам үстерде. Медучилищены бетергәч, эшкә Казанда калырга рөхсәт иттеләр. Миннән кала энекәшем — Искәндәр бар әле. Быел химико-технология университетын тәмамлады. Мисхәт, Гриша, Замирлар арыгач, берничә төн сакта да торды.

— Минем әле кайниш тә бар икән. Үземдә эшләр.

— Муены булгач, камыты табылыр. Аны дустыгыз Нургали абзый үз цехына алды инде.

— Кара син аны карт төлкене. Минем белән туган-тумача уйнамакчы.

— Ярый. Бүлдермәгез! Бу фаҗигале хәл хакында бик сөйлисем килеп тормый. Безнең арада яткан тумранны атлап булмый. Аны утынга турыйсы...

Апам безнең аркада утырып калды. Күкесе бушка кычкырды. Аның белән аулак өйгә йөргәннәрнең балалары урта мәктәптә укый. Сайланырлык хуты юк иде, өлешенә тигән көмешең дигәндәй, күрше авылдан хатыны куып чыгарган бер ирне алып кайта бу безгә. Үзегезгә мәгълүм: яхшы ир белән акыллы этне йорттан куып чыгармыйлар. Алкаш булып чыга. Һәрдаим тавыш, гауга, җәнҗал... Әткәйне үз өеннән куа башлыйлар. Кыерсытуга, рәнҗетүгә түзә алмыйча, биштәрен аркасына сала да, минем кырга, тулай торакка килеп төшә бу. Бүлмәдә миннән өлкәнрәк, сиңа таныш Сәлимә апа кебек үк, холыксыз, карт кыз белән икәү яшибез.

Әтине кабул иттем, урнаштырдым, караватымны бирдем. Үзем идәндә йоклыйм. Өйдәшем, төннәрен бәдрәфкә чыккан булып, туфлие белән аякка, кулга баса, янтауга тибеп үтә. Чыдамлылык бизләремне соң чиккәчә киереп түзәм.

Атна-ун көн шул тәмугта яшәп, тәмам чыгырымнан чыгып, киттем үзебезнең терапия бүлеге мөдире Кәүсәрия Фатыховна янына. Дөньяны күп күргән, абруйлы, бик күп каста начальствоны аякка бастырган ханым. Тәненең алтын-көмеш тагылмаган җирен табуы кыен. Балдакларының һәркайсы кыйммәтле таш белән бизәлгән. Кыскасы, безнең ише ачкүз хәчтерүшләрнең бәбәге тискәре якка әйләнеп чыгарлык.

Җылый-җылый, нарасый яшьләремне агыза-агыза, хәл-әхвәлемне бәян иттем. Әйткәнемчә, бик чая, үткен, тоткан җирендә теләсә нәрсәне өзеп ала торган хатын иде. Мине тыңлагач, энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгән, сосиска кебек бармакларын пумала башына батырып, бик озак уйланып утыргандай итте. Кыскасы, шартын килештерде.

Йөренеп алды. Ишекне келәгә салды. Соравы һаман колагымда чыңлап тора.

— Ирләр белән йоклаганың бармы?

Мин берни аңламыйм. Ялганларга ярамаганны беләм. Безнең якта аулак өйдә егетләр белән куну гадәте бар. Тирәнгә китеш юк. Көлтәгә куелган башаклар кебек, тәне-тәнгә сыланып, кызышып, шаярышып ятасың да, миңгерәгән балыктай торып китәсең йә берәрсенең әти-әнисе килеп, шайканы куып тарата. Шул хакта сөйләп бирдем.

Калын пыялалы күзлеген кулына алып, Кәүсәрия Фатыховна кылчыктай карашларын миңа текәде. Тәнем аша көчле рентген нурлары узды диярсең.

— Мине бала чакта кем белән әп итешеп йөрүең борчымый. Сән кызмы, хатынмы? Йоклау белән йоклауның аермасы бар. Сән медик, шуны гына беләсеңдер шәт?

Мин — сарыкбаш һаман берни аңламыйм.

— Кыз кеше мин, Кәүсәрия апа,— дим, үрсәләнеп, нинди җавап ишетергә теләгәнен белмичә.

— Шылай булуың начар да, яхшы да,— дигән нәтиҗә ясый ханым.

Алтын тешләрен елтыратып, яңа сорауны авызыннан төшерә.

— Фатирлы буласың киләме?

— Кая миңа ул хакта хыялланырга. Тулай торактан әткәй белән торырдай бүлмә сорап килүем, Кәүсәрия Фатыховна.

Күзләрем ат дагасы хәтле алтын алкаларында. Яшьлек — яшьлек инде. «Ханымның кулларындагы, колагындагы, муенындагы алтыны, тешләренә тимәсәң дә, әткәй белән икебезгә бер фатирга артыгы белән җитәр иде»,— дигән тиле фикер уза сыек фикерле башымнан.

Ханымның холкын беләбез. Өч нарат арасында адашып кала торганнардан түгел. Сүзен маңгайга бәреп әйтер.

— Бер карт, юк, ялгыш атьәм, өлкәнрәк яшьтәге дәдәй белән йокларга риза булсаң, язын, ояларына очып кайткан карлыгачлар белән бергә, менә дигән фатирга кереп утырырсың.

Авыллыгым, мокытлыгым чыкмаган һәм мин мондый «җитди» әңгәмәгә әзер түгел идем. Авызымны ачтым да, тилебәрән орлыгы ашаган тинтәк төсле катып калдым.

— Авызың хөрмәдә булыр.

Соңгы җөмләдән зиһенем ачылып, яктырып киткәндәй булды. Әһә, апаем шаярта, мине тикшерә, тиле-миле авыл кызында тәҗрибә уздыра.

— Хөрмә яратмыйм мин. Ул авызны бөрештерә.

— Арзанлысы, зарплатка сатып алганы гына мәми авызны бөрештерә, тешне камаштыра,— дигән җавап алдым, уңышсыз дип табылган шаяртуыма.

Аның җитди сөйләшкәнен, хәлемнең мөшкеллегеннән файдаланып, мине кемгәдер тапшырырга, сатарга җыенганын аңлап, камчы ашарга әзер чыгымчы аттай, аякларымны бусагага терәдем.

— Юк, юк, булмаганны. Сез нәрсә сөйлисез, мин кыз кеше, оят...— дип, мыгырдана, кычкырына, пырдымсызлана башлаган идем, Кәүсәрия Фатыховнам калын пыялалы, әлбәттә инде хакыйкый алтын кысалы күзлеген борынына элде дә, усал, явыз, тәкәббер тавыш белән:

«Чыгып кит моннан, дура, күземә күренәсе булма. Олы башымны мыскыл итеп, мин але аның белән сөйләшеп торам. Учына кысып ят».— диде, Наполеон ишарәсе белән ишеккә күрсәтеп.

Җәядән ычкынган агулы уктай атылып чыгып киттем. Урамдагы эскәмиягә ятып, гарык булганчы, күзләремнең карасы кат-кат юылганчы җыладым. Көтүче чыбыркысы төсле сөйрәлеп бүлмәмә киттем. Өйдәшем әтинең кием-салымын, биштәрен, чантасын коридорга ташлап ята. Дөнья бетереп акыра. Азгын кәҗәне суялармыни: «Мажик сасысына түзәрлегем калмады. Чыгып китегез моннан. Хәзер үк главныйга барам. Икегезне дә общагадан кудыртмасам, исемем Фильсинә булмасын!»

Югалып, мескенләнеп, кечерәеп калган әткәйне кочаклап, янәдән диңгез суын агыздым да, Кәүсәрия Фатыховнага: «Мин риза»,— дип кереп әйттем.

— Бер исерек башка арәм китәриең, наным. Син медик кеше. Үзең чамаларсың, үзем дә үрәтермен. Сизми дә калыр. Фатирлы хатын иргә аптырап тормый безнең заманда. Шәкәргә килгән умарта кортларыдай артыңнан улап йөрерләр әле, Кәүсәрия апа атьте диярсең...

Минем язмыш абзам безнең балниста, япан хәтле люкста миниаль, мануаль массажлар алып, кыскасы, гомерен озайтып, хәл җыеп ята икән. Кан басымын төшерү өчен яшь ханым кирәк икән аңа. Бу хәтлесенә соңрак барып җиттем.

Минем тәүге «ирем» билгән урыны, дәрәҗәсе, абруе белән мәмләкәтебезнең иң олы кешеләреннән берсе булып чыкты. Мөдир апа миңа, тулы инструктаж биреп, энә кадарга кертеп җибәрде аның бүлмәсенә. Мин бөтен тәнемне һөҗүмгә, вату, сыту, изүгә әзерләп, кычкыра калсам дип, авызга тыгарга чүпрәкләр алып, өркетелгән болан баласыдай колакларымны тырпайтып, аяк очына басып кына палатага кердем. Гаҗәбе: ул миңа ач бүредәй ташланмады. Бик гади итеп, аталарча хәл-әхвәлемне сорашты, әллә ничаклы мәзәк хәлләр сөйләп ташлады. Мин аңа ияләшә башладым. Якыннан танышып, муен-маңгаендагы сырларга, күз төпләрендәге кара уемнарга күнеккәч, ул миңа артык карт күренми башлады. Түгәрәк йөзе, тулы, елмаючан иреннәре, арыган, акыллы күзләре тулы, олы гәүдәсенә ятышып тора. Кыскасы, кешегә ияләшеп була икән... ихтыяҗ чыкканда. Мине итәгенә утыртып үбүдән артыкка бармады. Кулын алып куйганда да, ачуланмады, үпкәләмәде.

Бальнистан, делегация җитәкчесе булып, чит илгә китте. Миңа алтын алка, көмеш балдаклар алып кайтты. Йөзекнең иң күркәме, ханшалар кия торган алтын кашбау кебек, ялт-йолт килеп торганы Кәүсәрия Фатыховнага насыйп булды.

Тын алмыйча тыңлап яткан Сакманов көйсезләнеп куйды.

— Онытылып киттең, Фәридә. Торак мәсьәләсен хәл иттеме, хет?

— Кәүсәрия Фатыховна бабамның бүлмәсенә алып кереп, мин беренче уколны кадаган көнне, безне тулай торакта аерым, зуррак бүлмәгә күчерделәр. Дөрес, анысы сезнең якын дустыгыз, шымчыгыз Сәлимә апа кырында булып чыкты, гөнаһ шомлыгына каршы...

— Ә... ә... бабаң бүлмәңдә булгаладымы? — диде Сәет, үзе яшь кеше мәсле, «бабаң» сүзенә көчле мәгънәви басым төшереп.

Ирнең гасабилануына ханымның ияге дә селкенмәде.

— Юк диярлек. Главврач белән, обход ясаган булып, кереп чыккан булдылар. Шул визиттан соң, серле таяктан суыткыч, япон телевизоры, кием-салым шүрлеге төште бүлмәбезгә.

— Син аңа... бабаңа, ничек, кем дип мөрәҗәгать итеп яшәдең?

Сәет күңелендә көнләшүгә якын үҗәт, тырнаклы усал хиснең куеруын тойды. Күбрәк беләсе килде. Бит, тән төзелеше, тире төсе тарафларыннан Зөлфиясе урыс фильмнарында күрсәтелгән татарларга бөтенләй охшамаган иде. Фәридә исә, кыпчак-болгар хатын-кызларына хас күркәле сыйфатларны үзенә җыеп алган. Бер караганда кучкыл, икенче бакканда, өлгергән, юеш эре карлыгандай чем-кара күзләре, салмак

борылышлы кашлары, тойгылы иреннәре, гәүдәсе һәйкәлгә куярлык мәһабәт. Сәет сокланып карап туя алмый. Күзләре матурлык белән иләсләнгән, илһамланган саен, билгесез көчкә ачуы уяна, саруы кайный. Билгесез дип...

— Исеме, отчествосы белән мөрәҗәгать иттем,— дип, дәвам итте язмышы, тормышы, күтәрелүе һәм төшүе турындагы хикәяне Фәридә, ирнең яралы тәнендә кабынган утлы көнчелек ялкыны дөрләвен сизмичә. Хәер, Сәет күңелендәге зилзилә, туфан өермәсе турында тәгаен хәбәрдар булса, шатланыр гына иде. Бәлки, булган-беткән хәлләрнең кайбер бөҗраларын, тыкырыклы борылышларын төшереп тә калдырыр иде сөйләмнән.

— Үзе юкта «бабам» дип йөрттем. Әткәмнән берничә яшькә олы булса да, гел тәрбиядә, затлы ризыкны вакытында ашап яшәгәч, шактый яшь күренә иде.

Форсаттан файдаланып, «сезнең кебек», дип өстәмәкче иде дә, шырпысын урынында калдырырга акылы җитте.

— Әтиең синең белән яшәдеме?

— Юк. Теге мәлгунь апамны ташлап, балалары, беренче хатыны янына кайтып китте. Әтине авылга озатып куйдык.

Бу сөален сүз, җөмлә тукымасын күчереп, дөньяга очырып чыгарырга хаккы юклыгын аңлый Сәет. Самолет, һава упкынына төшеп алгандагыдай, йөрәгенең бер күтәрелеп, бер түбәнгә тәгәрәп алуы буенча ялгышын сизенде. Мәгәр соң иде. Ак мендәреннән өскәрәк күтәрелде. Үз тавышын ишетмәде.

— Ул сиңа... сиңа укол кадаганда кызганмадымы? Авырттырмадымы?

Фәридә сорауны аңлады. Ул инде Кәүсәрия Фатыховна кулына килеп кергән тәҗрибәсез, хәйләсез, саф күңелле, беркатлы кызчык түгел иде. «Көнчелек галәмәте — бәйләнү башланды»,— дип уйлап алды ханым.

Үзен тыеп кала алган булса, Сакманов ак сакаллы картлар рәтендә йөрисе иде дә, шайтан коткысына бирелде. Аһ ул, каһәр суккан, тиктормас, сөяксез телне... Күпме кешенең башына җитте, яшьли гүргә кертте.

Эндәшми, теле кычытса да сорауны бирми кала торган акыллы дәүләт ирләре була. Читтән күзәтеп торучылар берни аңламый. Акыл шәрифләре дә чамалы кебек. Ә үзен һаман үстерәләр, күтәрәләр. Иң хәйләкәр хатыннар өчен дә алар табышмак.

Сәетҗанның эчендәгесе — тышында. Ханымга, аның сөйләгәннәренә битарафлык саклый алмавы, кызулыгы, дуамал тәвәккәллеге чак кына араларын чәлперәмә китермәде. Якынлык хисе, саклап тота белсәң генә дәвамлы була, озакка җитә, диләр шул.

Вакланып төпченүен яратмаса да, Фәридә чын-чынлап терелә килгән иргә үпкәләмәде, киресенчә, күңелендә аңа галәкәдә җылы мөнәсәбәтнең уяна килүен тойды. Сәет чын иргә охшаган. Ә аларның күп түгеллеге шәфкать туташына мәгълүм. Шуңа күрә, күңеленнән рәнҗесә дә, эчтән бүселгән канәгатьсезлеген тышка чыгармады, сиздермәде. Аралары тирәнгә китеп, кое бурасын өйгәнче, араларын ачыклау, кемнең кем икәнен тәгаенләү хәерлерәктер.

— Әүвәл шактый интекте... тирләде, пеште, мине дә бимазалады. Аннан соң хөкүмәт мунчасына алып барды. Голливуд журналларын күрсәтте. Соңгы мода буенча киендерергә тырышты. Саран һәм куркак кеше түгел иде. Мин аңа барыбер рәхмәтле.

Көндәшенең кемлеген чамаласа да, беткән баш беткән инде дип, ачыклауны кирәк тапты.

— Ни өчен «иде»?

— Тукай абыебыз әйтмешли, җәсәден туфрак алды... Кстати, әтием дә фани дөньяны ташлап китте.

Мотыйгуллинаның ике бүлмәле фатиры барын белсә дә, башын юләргә салып, сорап куйды.

— Синең тору һаман шул тулай торактамы?

— Мин сезгә, Сәет Яруллович, терелә башлауга әйткән идем инде. Квартирам бик яхшы.

— Ачуланма инде. Минем зиһен ниерәк... Үзең генә яшисеңме?

— Әнем миндә тора... Фатирны алу җиңел генә булмады,— дип өстәп куюны кирәк тапты ханым.

«Алтын-көмешкә, чүпрәк-чапракка алдап, төп байлыгын алганнан соң, бабай койрыкны сыртка салу ягын карагандыр әле. Хатын-кыз төп мәсьәләләрен до того хәл итеп куярга тиеш шул»,— дип нәтиҗә ясады «Игелек» сәрвәре. Үзеннән беләдер иде.

— Бабаң шомартырга тырышып карадымы?— диде, беренче сүзгә бу юлы да каһкаһәле төртмә төшереп. Соңрак, үзенең дә кырык бишне ваклаганы, чәчләренең бәскә манчылганлыгы исенә төште. Алдында олы көзге тормаганда, ир-ат үзен гел яшь саный. Янәсе, аны гына вакыт алмый, ул гына саклана.

— Илгә яңартып кору дигән зәхмәт килгәч, аның әмерен үтәми башладылар. Бабам да артык кабаланмый. Минем бала табар вакытым җитте.

— Ул бу вариантка ничегрәк карады?

— Аңа үстерәсе түгел. Кешенең бу дөньяда бер көнлек кунак кына икәнен чамалый иде. «Теләсәң тап, мин разый»,— диде. Мин квартира ягын каердым. Корсагымны күтәреп, эшенә киләм, ярдәмчеләренә әйтәм, хатыныңа җитүе дә бар, дигәч, чакырган җиренә бармый башлагач (ул мине яратты), үзе генә белгән төймәләргә басты...

— Мин арыдым,— диде Сәет, иркәләнеп. Вакыйганың үзе катнашачак өлеше аны бик кызыксындырмый иде шикелле.

Фәридә кыйссасын дәвам иттерде. Аның кемгәдер серен чишәсе, күңел сандыкларын бушатасы килүе табигый иде. Газиз башын чүт кенә зинданга илтеп тыкмаган абзый дөреслекне белергә тиеш.

— Үзем дә баланы табып, үстерү фикерендә тупланеп җиткән идем. Фамилиясен куярга курыкса да, исемен аталыкка алырга рөхсәт бирде. Ә нигә үстермәскә... Торыр урыным бар.

— Ә ни өчен... ташладың?

— Балам гарип булып туды. Аның уң аягының бармаклары сул ботының чәлтеренә береккән иде.

— Берүзең таптыңмы? Өеңдә?

— Юк. Кәүсәрия Фатыховна ярдәм итте. Мин зәгыйфь баладан котылуны мәгъкуль күрдем. Хәзер дә дөрес эшләдем, дип уйлыйм. Гарип баланы гомере буена интектергәнче...

— Бабаң, Кәүсәрия апаң белделәрме?

— Кәүсәрия Фатыховнага: «Балам үлде, авылга алып кайтып күмдем»,— дидем. Баланың атасына дөресен әйттем.

— Ул ничек бәяләде җинаятеңне?

«Кешенең гомере ялгышлар һәм аларны төзәтүләр чылбырыннан тора, юкка хафаланма, дүрт аяклы ат та абына»,— дип тынычландыру ягын карады. Аңа яшь бала кирәкми иде.

Фәридә, башыннан узганнарны кабат кичереп, хисләнде, янган күмер кисәгедәй күзләреннән әрнүле, тозлы яшь бәреп чыкты. Урыныннан торып, читкәрәк китеп, кулъяулыгы белән үтә күренмәле тамчыларны җыеп алды. Сәет хатынның өмсендергеч, ак халатын төртеп торган артына, биек үкчәле туфли белән аеруча төз күренгән аякларына, йомры иңбашларына сөеп караудан үзен тыя алмады. Калтыранып алган туры аркасы, кечкенә, үтә күренмәле колаклары, бөдрәләткән куе кара чәчләре якын вә газиз иде аңа бу мизгелдә.

— Утыр әле, Фәридә, яныма!

Ханым буйсынды. Сәетнең караваты янына килеп чүгәләде. Ир аның җилкәсеннән алып, дымлы күзеннән үпте, иреннәренә телен тидерде. Тозлы каен суыдай тоелды аңа Фәридәнең күз яше. Сәет әрсезләнеп,

хатынны үзенә тартты. Җирән сакчыга кулын селтәде: «чыгып тор, йәисә борыл».

Үбешүне җитди гамәлгә санамаган яугир урыныннан кузгалмады, тораташ булып катып тора бирде. Эчендә ничә баллы дулкын котырынганын үзе генә белә иде. Кичерешләрен тышка чыгармаска тырышса да, ул да ана тапкан кеше иде, зәңгәрсу күзләренә боз менде, яңаклары бүртенеп чыкты.

Иреннәре кыска бер мизгелгә генә кушылып алса да, Сәетнең сәламәтләнә барган йөрәге, хуҗасының ниятен хуплап, читлеген бәреп чыгардай булып шашынып, дагалы ат тавышлары чыгарып типте, дөньялар түгәрәкләнеп китте, күктә йолдызлар кабынды. Ханымның зиһене чуалып алса да, җаваплылык, курку, оялу хисе җиңде. Авыруны көчле куллары белән үзеннән аерып алды. Ишек төбендәге киң җилкәле, аерылы авыр иякле адәмгә үзләре генә аңлаган ым какты.

Мотыгуллина башлаган дастанын дәвам итүне кирәк тапты.

— Бала белән шулай итеп чыгып, сезнең галиҗәнәб минем шәхес белән кызыксына башлагач, бабамны катыштырырга мәҗбүр булдым. Төрмәгә башымны тыгып куярга бик тырыштыгыз. Барып чыкмады. Нәтиҗәдә икебез дә нәрсәдер югалттык. Мин РКБдан китәргә мәҗбүр булдым. Хәзерге балниска күчтем. Үземне эзәрлекләгән, почмакка китереп кыскан, җәза бирү турында хыялый шашынып йөргән адәмгә тап булдым. Аны аякка бастырам.

— Ничек килеп эләктем мин бирегә?

— Егетләрең алып килде. Кичке сәгать җиделәр иде. Баш врач кабул итмәскә маташты, үзәккә озатырга тырышты. Бер сакчың наган күрсәтте, менә бу җирән сакчының хуҗасы — Ваһапов абый бик күп яшел акчалар төртте.

— Ә син мине таныдыңмы?

— Юк. «Сез иң тәҗрибәле сестра-хирург»,— дип, миңа операциядә катнашырга куштылар. Танымадым. Кәгазьләрне тутырганда, исем, фамилияң буенча кем икәнеңне белдем. Сине онытып буламы? Бавырда, бөердә утырдың. Ә хәзер йөрәктә калдың.

Ул Сәетне дәвалауга алынуга бәйле шактый буыннарны төшереп калдырды. Һәммә нәрсәне акчага гына күчереп булмый шул. Әле табигать кануннары бар. Үзе балалар врачы, йөзеп йөри торган күзле, итләч борынлы баш табиб: «Кем авыруны үзенә ала?»,— дип сорагач, шәфкать туташларының берсе дә сикереп тормады. Бу чаклы яра-җәрәхәт белән аның исән-имин калуына берәү дә чын-чынлап ышанмады. Көчең, вакытың гына исраф китүе ихтимал. Сакта торачак бандитлары, рәхмәт әйтәсе урынга, җәһәннәмгә олактырырга озак сорап тормаслар. Йөзләрендә иманның мунча себеркесе яфрагы хәтле кечтеки генә кисәге дә калмаган. Күзләрендә покрау бозы. Терелсә, үзе, мәрхәмәтен, шәфкатен күрсәтә белерме? Бер язучының герое әйтмешли, «едвали».

Фәридә бүгенгедәй хәтерли: Сакмановны операция өстәленнән алып чыгып, караватка салдылар. Күзләре, иреннәре ябык. Гәүдәсе ап-ак чүпрәктә, кан тибеше көчкә сизелә. Күңелендә ике «мин» тартыша: үч алу һәм кызгану. Бәлки, теге вакытта кыланганнары, кирза итеге астына салып, җир суалчанын таптагандай изәргә, юкка чыгарырга тырышканы өчен, бер укол кадарга да, вәссаләм, мулла кушкан исеме Сәет иде дияргә генә булгандыр.

Шунда Фәридәнең йөзенә, татар карчыкларының баш яулыгы кебек, ап-ак төсле оят менде. «Ярым үле кеше белән үчләшү нинди әхлак тәртәсенә, әдәп бизмәненә сыяр икән? Син аны әүвәл терелт, аякка бастыр, шуннан аңа мөнәсәбәтеңне, ахыр дәгъваңны белдер! Шәфкать туташы вазифаларың үтәлгән булыр. Намусың чистарыр. Үлгән балаң намына терелт син аны!» — диде эчке бер көч.

Күңеленең түрендә, җанының иң серле кыйтгасында үзгә хис тә яши иде. Бала үлеменә бәйле вакыйгалар куерып киткәч, Сәет аңардан сора-

улар алган, кәгазьләр тутырган, шаһит-шымчылар эзләгән, прокурор бүлмәсендә этләшкән арада аңа участковый милиционер ошап куйган иде. Дошманыңа да бәя биреп була, ул да кайсы сыйфаты беләндер күңелдә калырга мөмкин ич әле. Фәридә бу хакта үзенә танырга базмаса да, чынында аны Сакмановның караваты янына, нөктәле үпкәсеннән битәр, кабына, ачыла алмый калган яшерен ярату хисе утыртып куйды. Ул Сәетне аякка бастырырга дигән карарны күңеленә беркетте. Җиң сызганып эшкә керешге.

Шунда бер кыенлыгы да килеп чыкты. Хастаханә хирургы Фәләх Сабиров Фәридәне күптәннән комсыз күзләре белән капшап, озатып йөри иде. Җае чыкканда култыклап ала, бармак очларыннан җенси нурлар җибәрә, кайнар учларын аркасында онытып калдырырга ярата. Ямьсез дип булмый үзен. Олы гәүдәле, киң күкрәкле, яше утыз бишләр тирәсендә булыр. Алга чыгып торган күкерт төсле күзләрендә һәрвакыт теләк эңгере... Эреләнеп алырга ярата. Җиһанында аңардан зур һәм кирәкле кишер яфрагы юк диярсең. Гәүдәсе, көчле куллары ханыма ошаса да, артык тәкәббер тотуы, борынын чөеп йөрүе гайрәтен чигерә. Һәрьяктан килгән кешеләр сирәк була дип, инде байтактан ир-ат белән йокламаган Фәридә Фәләх Сабировның бәйләнүләренә риза булыр дәрәҗәгә җиткән иде.

Аның олпат адымнарын ишетүгә, ир-ат кулын сагынган күкрәгенең иңрәп, ыңгырашып куюын тоя, бар ихтыярын, әхлагын җиксә дә, чыдамының «шигрин күне» кебек кими, эри баруын, табигате белән көрәшкә көче җитмәвен, көннәрнең берендә Фәләхнең үзен кулына алып, караватка салса, карышырлык тәкате калмасын сизеп яши.

Хастаханәгә шул үләтне китереп ташламасалар, якын арада кисеп ямаучы табиб Сабиров Фәридә куенында фани дөньяда иң рәхәт, иң ләззәтле көннәрен кичерәчәк иде. Сакмановка берничә көн соңрак аткан булсалар соң инде шунда.

Ханымның аңа нисбәтән йомшаруын, назлау-иркәләүләрен кабул итеп, елмаеп исәнләшүен яхшыга юрап, җиденче күк томанында йөзгән хирург, хастаханәгә каты авыру килеп керүне яхшыга юрады. Бик тырышып ярдәм итте үзәктән чакырылган профессорга: «Каты җәрәхәт белән мафия башлыгын салдылар, берничә көн биредә кунарга туры киләчәк, югалтмагыз»,— дип, шылтыратып, кисәтеп куйды хатынын да. Көне буена рухланып, учын-учка ышкып йөрде. Күрше бүлмәне бушатты. Коньяк, затлы конфет-шоколадлар алып кайтып куйды.

Кич тә җитте. Сәет янында утырган Фәридә янына керде.

— Хәлләр ничек?

— Пульсы көчкә-көчкә тибә. Начар.

— Тагын бер операция ясарга туры килмәгәе,— диде хирург, Фәридәнең кулын алып.

Хатынның күзләрендә курку, өркү галәмәте күрде.

— Сезнең танышыгызмы әллә?

Ни өчен хәзер шулай җавап биргәнен кешегә түгел, үзенә дә әйтә, аңлата алмас иде ханым.

— Минем бик якын кешем ул, Фәләх Сабирович.

— Кем инде?

— Не важно.

— Мин күршедә бүлмә әзерләдем. Чәе дә, мәе дә бар... Бергә кунарбыз.

Фәридә аның күкерт күзләрендә тупас теләк элпәсеннән башка нәрсә күрмәде. Шул мәлдә авыр итеп ыңгырашып, сыктаныпкуйга Сәет коткарды аны. «Юк, юк, ул беркая да керми. Үлем түшәгендә яткан чирлене ташлап китәргә аның хакы юк. Сөрмә күзгә нәрсә кирәген ул яхшы белә. Фәридә кеше, шәхес буларак аны кызыксындырмый...»

— Рәхмәт, Фәләх Сабирович, мин ирем яныннан беркая да китә алмыйм. Аның янында утырачакмын.

— Ирең? Син бит кияүдә түгел.

— Ярәшкән, вәгъдәләшкән кешем. Без бер айдан язылышырга тиеш идек. Так что...

Өметеңне өз, нәфсеңне бастыр дию иде ханымның. Әле шуннан соң да Фәләх шактый бәйләнеп йөрде. Хыялы тормышка ашмагач, ул да гадәти адәм баласы булып калды. Фәридәгә һәм аның карый торган кешесенә суынды. Суынуы бозга әйләнгәч, аяк чала башлады. Шактый мәшәкать, бәла, артык сүз тудырды. Кайсы вакыт хатын-кызга ир-ат белән бер йоклап алуы арзанракка төшә, диләр. Фәридә бу юлны сайлый алмады. Дарулар, дәвалау бирдертми башлаган иде дә, барып чыкмады, Фәридә бу хакта Сакмановның ярдәмчесе Гришага — Григорий Степановичка сиздерде. Хирургны өенә озата бардылар. Тынычланды. Ярдәмгә ашкынып тормаса да, аяк чалудан туктады.

Шәфкать туташының җылы кулын күкрәгенә алып яткан Сәет бу хәлләрнең берсеннән дә хәбәрдар түгел, карлыган күзле фәрештәнең үзенә җир йөзендәге иң зур үлчәү дә күтәрә алмаслык фидакарьлек эшләгәнен, чынында шул бизмәнгә киләчәген салганын белми иде.

Сакманов тормыш баскычларын барлап ята. Тилереп, хакыйкать эзләп, алданган, дөресе, яшь хатынны батырырга йөреп, җитәкчелек белән әчелешле булып, күпер башында тәкә сөзештереп йөргән елларын кызгана. Берәүгә дә хаҗәте булмаган ялган дөреслек куалап, Фәридә кебек асыл затны зинданга тыгып куюга ирешсә, ул ни нәрсә отар иде. Милициядән халык хуҗалыгына озатмасалар, бәлки, хәзер майор дәрәҗәсенә ирешеп, кителенең сәдәфләре өзелеп төшәрлек итеп күкрәк киереп, борын чөереп йөрер идеме? Торып тор. Аның холкы белән капитаннан уздырмаслар иде барыбер.

Фәридә төрмәдән рухи имгәнеп чыгар иде. Хәзер аны — гарип-горабәне армый-талмый, җирәнми, үзен кызганмый карый алырлык кешесе дә булмас иде. Күптәннән инде, «товарищ янарал», гөнаһлы тәнеңне сары балчык үзенә кабул иткән булыр иде, бисмилласын әйтеп. Шыр тиле булгансың. Советский политработник. Агачтан ясалган флик. Безнең илдә адәм баласы шундый хәлгә куелган. Шәхес иреге... Демократия дибез... Чуртым...

Шулай ук, үзенә генә мәгълүм истәлек-хатирә болытлары арасында йөзгән ханымның нурланып киткән битенә сөеп карап: «Фәридә, син кемгә охшаган?» — дип сорап куйды.

— Нәрсә дисез?

Яңгыр тамчылары кибеп өлгергән кара күзләр Сәеткә текәлде:

— Әтиеңәме, әниеңәме охшагансың, дип сорамакчы идем. Чирләшкәнең шул хакта белешергә хокукы булса?

Сәетнең сүзләрен аңлаудан бигрәк, эчке сиземләве белән бәяләде ханым.

— Мөгаен, әнкәйгәдер, нигә сорыйсыз? Барыбер түгелмени? Кайсысы шундый җиңел холыклы булган икән, дип ачыкларга итәсезме?

— Кемнәргә ошап шундый ләтыйф, олы җанлы, кешелекле булганыңны беләсем килгән иде. Дәүләт сере булмаса.

Чыннан да, Фәридә табигать могҗизаларының күп мөмкинлекләрен үзенә «җыеп» алган иде. Бирмеш түгәрәк ияген җәя кебек бөгелеп, күтәрелеп торган өске ирене бизи. Аскы ирене астында, сул почмакта күптәннән төзәлгән яра эземе, чуан зәхмәте калдыгымы сизелеп тора. Анысы да килешле. Сәетнең бу җөйгә игътибар иткәне юк иде. «Бу нәрсә, Фәридәкәй, нindидер,— сүз таба алмыйча торды,— ямау күрәм иренең кырында. Нәрсә ул?»

Кечтеки калкулыкны бармагы белән сыйпап алды ханым.

— Моны әйтәсезме? Пычак эзе.

— Пычак эзе?

— Сезгә генә яралы йөрергә димәгән. Безнең дә, акылга утырганчы, мафия чаклар бар иде.

Ак, дымлы, тигез тешләрен күрсәтеп, көлемсерәп алды.

— Бер сөйләрмен әле. Артык кызык история түгел.

Сәеткә бу вакыйга турында беркайчан да сөйләмәячәген Фәридә тәгаен белә. Аз сөйләмәк — акыллылык, күп сөйләмәк — наданлык галәмәте икәнне чамалый иде ул. Әле дә очы күренеп торган бу тәварих Фәридәнең күз алдыннан китми. Шаһиты ишек төбендә генә.

«Бабасының» йөртүчесе Айдарның үзен күзе белән ашап йөрүен сиземли иде Фәридә. Яшь, таза егет. Хуҗалардан артканы, тамганы, һич югында сөяге, шоферларга кала.

Җәйге матур көннәрнең берсендә, эңгер алынып яткан вакытларда Мотыйгуллинаның фатирына шакый егет. Фәридәнең квартирага күчеп йөргән сөенечле көннәре. Айдарның күзләренә кызыллык иңгән. Әйбәт кенә салганлыгы күренеп тора.

— Сине срочно алып килергә куштылар. Киттек!

Фәридә ни әйтергә дә белми. Алдан сөйләшми, килешми, бухтыбарахты кылана торган гадәте юк иде. Шоферын җибәргәч, кирәктер инде. Тиз генә киенә дә, машинаның арткы утыргычына кереп утыра. Айдар музыка куя, ялт-йолт карана, бер дә юктан көлеп җибәрә. Бөтенләй, икенче, таныш булмаган якка баруларын сизенгән Фәридә курыкмаса да, шикләнеп, сорап куя.

— Айдар, кая юл тотабыз?

— Фәридәкәй, бер дә борчылма. Мин сине пикникка алып барам. Андагы күңеллелекне күрсәң...

Бер урман аланлыгына килеп туктадылар. Куе яшеллек, кояш кыздыра. Мөһерле сәрвәрләрне йөртүче биш-алты «Волга» тора. Ышыкта, киң яшел брезент өстендә ашамлыклар, эчемлекләр... Һәр шофер үзенең ахирәтен алып килгән. Кайсыныңдыр туган көнен билгеләргә җыенганнар икән.

Айдар ишекне ачты, Фәридәгә кулын бирде һәм, кызның бармакларын учыннан җибәрмичә, мәҗлестәшләре янына алып килде.

— Таныш булыгыз! Минем кызым Фәридә булыр.

Кунак ханым эндәшмәскә, баш күтәрмәскә булды. Кызы — так кызы. Өстәлләр әгъләдән, нигә кемнәрнеңдер исәбенә сыйланып алмаска. Ашадылар, эчтеләр, тостлар әйттеләр һәм һәркайсы үзенең парын алып, төрле якка таралыша башладылар. Фәридә бабасының килмәсен, үзенең капкынга эләккәнен, һич югында дуслары каршында Айдарның абруен күтәрергә тиеш икәнен аңлады. Ул чаклысына да каршы булмады. Тик егетнең хыяллары зурдан, Бонопартча булып чыкты.

— Әйдә, без дә әйләнеп килик,— дип, шактый тупас кына терсәгеннән алып, чакырулы кунагын аягына бастырды. Көчле кулларын иңбаш аша төшеп, нечкә биленә батырды, иреннәрен эзли башлады. Әрсез тинтәкнең ниятен чамалаган Фәридә, чүгәләп, Айдарның кочагыннан тук балык мәсле шуып чыга да, авырулар күтәреп, уколлар кадап ныгыган кулы белән йөртүченең яңагына сылый. Кызарынган битендә биш бармак эзләре калгандай була. Чапылдау тавышының кайтавазы каен, нарат, артыш, шомырт, гөлҗимеш агачларын урап кайтып җиткәч кенә, дәгъвачы аңына килде. Җирсенгән карасу күзләрен як-якка йөртеп алды. Аның өчен иң аянычы — ошбу мәсхәрәне берәрсенең күреп калуы иде. Мондый хурлыкның шаһиты булса — иртәгә үк башка җирдән эш эзлә яисә муеныңны элмәккә тык.

Фәридә дә кызып җиткән иде. Аны теләсә кем белән йоклап йөрүче кәнтәйләр рәтендә алып килгәннәр бирегә! Шампан шәрабы белән тулы стаканны, кызыгырлык җитезлек белән, югалып калган ирнең битенә сипте. Гарьләнүе соң чиккәчә куерган Айдар, кулына ике ягы да үткен пычак алып, Фәридәнең өстенә китте.

— Син нәрсә, хайван, шулай кыланасың? Үзеңнән фәрештә ясыйсың! Алтмыш яшьлек карт белән йоклап йөрүче сөйрәлчек. Хәзер изге булып кыйланган буласың. Күргән без синең ише шлюхаларны. Барыгыз да минем кул аша үтәсез — иртәме, соңмы...

Хатынны куркып качар, урманда барыбер куып тотармын, дип уйлагандыр, бәлки, таза, чибәр шофер. Фәридә, дошман амбразурасын күкрәге белән япкан батыр сәвит сугышчысы кебек, пычак өстенә китте.

— Нәрсә әйттең, йәле кабатла, хәзер үк.

Айдар салкын коралын читкә алып өлгермәдеме, әллә чыннан да көенеченнән шашынып, ярсып, үзен онытырлык дәрәҗәгә җиткән идеме, мәгәр ике арадагы низагны хәл итүгә салкын коралның өлеше керде. Хатынның ирене астыннан шарлап кан китте.

Шул мизгелдә тамаша барышында алдан каралмаган гаҗәеп хәл булды. «Күктән төшкән» көчле йодрык әрсезнең иягенә килеп сыланды. «Батыр» пычагы-ние белән ике-өч аршынга читкә, куаклар арасына барып төште. Коткаручы, төсле кульяулыгына аракы салып, бер кулы белән Фәридәне кочып, икенчесе белән канны сөртә башлый. Иң гаҗәбе шунда иде. Ыржыктай таза Айдар үзен пәрәвезгә уралган урмәкүчтәй тыныч тота. Шыпырт кына «арба»сына кереп утыра. Җиңүче ханымны шул ук машинаның арткы кәнәфиенә утырта, үзе дә янәшә кереп оялый.

— Киттек. Тиз бул,— дип әмер төшерә дә, юл буенча канны туктаткан, битендәге, муенындагы тапларны сөрткән булып, Фәридәне тынычландырып, иркәләп кайта.

Куркудан агарынып, тәмам сөмсере коелып, югалып калган, мыегы чыланып та, авызына бал эләкмәгән Айдар, тукмаучысы күрмәгән арада гына, көзгедән арткы рәтне күзәтеп барса да, ләм-мим сүз катмый. Мотыйгуллинаның өенә кайтып җиткәч, «урман джентльмены» кисәтеп үк куя: «Ханым теләсә, гариза язса, сиңа өч ел химия обеспечена».

Шөлләве соң чиккә җиткән ирне, инде кайтып төшкән, риясыз Фәридә тынычландырырга ашыга.

— Эшне судка җибәрмәбез. Айдар ни әйтсәң дә үз кеше. Яра төзәлер, эзе яшьлек истәлеге булып калыр.

Коткаручы ханымны фатирына озата менә. Яралы кешенең берүзен ташлап калдырырга базмыйча, бик гадәти генә кунарга ук кала. Урман аланында ничек килеп чыккан булса, шулай ук юкка да чыга.

Сакманов палатасының ишек катында торучы, Ваһаповның «яһүдме, нимесме» дип йөргән, «телсез» җирән яугире Фәридәнең коткаручысы иде. Шул чорда аның ханымның «бабасының» рәсми, яшертен сакчысы булып хезмәт иткәнен сирәк кеше белә иде.

Сакмановны күтәрешеп алып кергәч, иске танышы Фәридәне ак халаттан күргәч, күзләрен чакма ташыдай уйнатып ала да, гел күрешеп торган кешеләр кыяфәтендә, ханымны читкә алып китеп, колагына саф татарча пышылдый: «Фәридәкәй, без аны исән калдырыйк. Кирәк булыр әле ул. Чын-чынлап гашыйк була күрмә бу байбәтчәгә. Яшь ханымнарны илләм ярата, яраттыра да белә. Сак бул».

Сөаленә җавап ала алмаган Сәет Фәридәне янына утыртты, кулларын учына алды. Тулы, кояшта кызынгандай матур, шома беләкләрендә, бармакларында көч сизелеп тора. Яклаучысыз, көчсез, гаҗиз Сакмановны ничәмә-ничә тапкыр күтәргәнен, астын алыштырганын куллар үзләре генә белә. Алар — сүзсез. Алар — акыл, зиһен, хис куллары.

— Фәридәкәй, мең рәхмәтләр инде сиңа.

Кулын тыгыз, сыгылмалы, калтыранып торган билгә төшерде.

— Ошыйсың син миңа, кызый!

— Бик хәйләкәр дә, мәкерле дә кеше икәнсез, Сәет агай.

## 11

Нонса-Наилә судагы балыктай «гаип» булып, эзләү-тикшерүләр, табигый ки, бернинди нәтиҗә бирмәгәч, «Игелек»кә яңа баш хисапчы эзли башладылар. Сакманов ир-ат кавеменнән баш тартты. Тоташ утырып эшли торган шөгыль бу нәселгә батмый. Аларның бер ишесе чүлмәкнең каймагы тышына чыкканчы урлый, йә борыны чөгендер төсенә кергәнче эчә торган булып чыга һәм инде, иң әшәкесе, карыша, үзфикерле булырга тырыша. Иң яманы: кул астында эшләүче чибәркәйгә кул суза, бу хәл шунда ук аның хәләл җефетенә мәгълүм була, тавыш, гауга чыга, тәмсез сүзләр китә. Һәр очракта да нәтиҗә бер үк: ширкәтнең абруена күләгә төшә.

Хатын-кыз кулайрак. Дөрес, аларның да бармагы ирләрнекедәй үз ягына бөгелә анысы. Мәгәр алар чама хисен югалтмый, тәртәгә типми, артыгын кыланмый, җылы бүлмәнең, вакытында уртланган хезмәт хакының кадерен белә, рәхмәтле. Үз фикерен хуҗасына тагарга тырышмый.

Булачак ярдәмчесенең рәсми ирдә, кече баласына кимендә үз аягы белән бәдрәфкә йөрерлек яшьтә булуын шарт итеп куйды Сәет. Күргәч косасы килерлек ямьсез дә, азгын ирләр кигәвеннәр кебек артыннан ияреп йөрерлек чибәр дә булмасын. Табак битне бәрәңге борын «бизәп», берсе икенчесе өстенә атланган теш авызын тулы итеп ачарга ирек бирмәсә дә зарар юк, төп вазифасы белән шөгыльләнергә вакыты күбрәк калыр.

Фирая Симатованы аңа дәүләт оешмасыннан тәкъдим иттеләр. Булачак «финанс министры» курач гәүдәле, биле бөгелеп-сыгылып, уемланып, эчкә кереп торасы, ирләр кулы ятасы урынга «кар сыланып», аяклары бәдәненә караганда кыскарак булса да, Фирая ачык, мөлаем, зыялы, әмма куркытылган күзле ханым иде. Кабарынкы яңаклары елмаеп тора, җыерчыклары тирәнгә китмәгән. Яшьлек ямен еллар ашаса да, акыл шәрифләре сакланган. Кешенең язмышында кискен көчәнеш, шартлау, авыр югалту булмаса, гакылы озакка җитә икән.

Симатованы Сәет ошатты. Аның акчаларын, табыш-югалтуларын

шөкер, чибәркәйләр бәйгесендә катнашасы юк. Минем башкисәрләрдән өлкән, алар кармагына эләкмәс. Ире бар, баласы икенче класста укый»,— дип уйлап алды, ханымның симерүгә бирешә торган гәүдәсен, ясалма чәчен хуплап. Өч сәгатьләп аның белән утырды, эш рәтенә кертте, үзенең таләпләрен катгый итеп куйды.

«Игелек»тә хезмәт хакы алган дәвердә сезнең хуҗагыз берәү генә. Ул — Сакманов булыр. Аның сүзе бәхәссез үтәлергә тиешле. Рәсми кәгазьгә ике тапкыр кул кую, карышу безнең оешмада кабул ителмәгән. Шул ук вакытта робот та кирәк түгел миңа. Вакытында киңәш бирү, эшне яхшырту буенча тәкъдимнәр кирәкле шәйдер. Һәм соңгысы. Хуҗага турылыклы булу, күргән-белгәннәрне, чатаклыкларны вакытында аның колагына җиткерү — бирелгәнлек билгесе саналыр, алыначак премиягә тәэсир итәр,— дип Сәет, алыпсатарларга хас булганча, бик озаклап вәгазь укыды. «Картаям, картаям, озын-озак сөйли башладым»,— дип, үзен битәрләп алырга да онытмады. Өченче заттан аңлашу аңа ошап китте, борчакны сипте генә. Кеше исеменнән сөйләү җиңелрәк икән.

Яшьли юанайган хатын-кыз гадәттә олы сәясәт белән кызыксынмый. Аларның рухына ашау-эчү, базар бәяләре, көнитеш, гаилә мәсьәләләре якынрак. Кагыйдәдән чыгарма, ак карга булмаса да, Фирая акыллы, зирәк вә сизгер ханым булып чыкты. Тормыш ләмкәсен үзе тартып барырга өйрәнгәнлеге күренеп тора. Күрәсең, ире аңа салынган. Кыскасы, үзеннән ни нәрсә таләп ителгәнне төгәенләрлек, мәүзүгълы хисапчы эләкте «Игелек» ширкәтенә.

Берничә ай эчендә Симатова үз хезмәтенең бөтен нечкәлекләренә кереп җитте. Эшнең җаен алып, көндәлек мәшәкатьләре үз агымына төшеп ятканда, бер четерекле мәсьәлә кабыргасы илә килеп басмасынмы? Бер караганда, гадәти хәл. Ике кыз атасы Хәлил Газиз улы баш хисапчыга «кармак» сала башлый.

Бу хакта, рәсми кәгазьләргә имза салдырганнан соң, рәсемләнмичә, гадәти генә итеп, Симатова үзе әйтеп салды.

— Сәет Яруллович, эшкә карамаган бер нәрсә бар иде. Мөмкинме?

— Йәле, нәрсә борчый үзеңне?— ди-ди Сәет, кулларын бер-берсенә ышкып, канын уятты. Кәефе яхшы. Ул хәзер теләсә нинди табышмакны, диңгез төенен чишәргә әзер.

— Мәсьәлә дип инде... Сездән бернәрсәне дә яшермәскә куштыгыз.

«Игелек» хуҗасы бөтен шартын китереп, кычкырып көлеп җибәрде.

— Хатын-кыз соңгы серен ачса, чирләп ястыкка авар, диләр түгелме? Барыбер иң тирән эч сереңне әйтмәячәксең. Башымны бүкәнгә куям.

Баш хисапчы хуҗасының тел шомартуына мөкиббән китмичә, йомышын ярып салды.

— Ярдәмчегез, Хәлил Газизович минем белән үзен... ничектер сәер тота.

Сәет вакыйга-хәлләрне бик тиз күз алдына китерде. Үгезне җиргә егарлык ихтыяр көче белән генә тигез тешләрен елтыратып, көлүен дәвам итүдән тыелып калды. Башын җүләргә салырга булды.

— Аңышмадым? Урлашу, хәрәмләшү, керемне кысып калу юлына этәрәме? Карагыз аны, тотсам, икегезне дә Гаяз Исхакый утырган Чистай зинданында черетәм. Чәй дә бирдертмим. Исемем Сәетхан булмасын.

— Юк ла, Сәет Яруллович, сүз бөтенләй башка нәрсә турында бара,— диде Фирая, үзен ялгыш аңлаулары өчен үрсәләнеп, гасабиланып. Ничек инде аның турында шулай әшәке уйларга мөмкин. Маңгаена тир типте.

— Күрешкәндә кулны җибәрмичә, озак итеп тота. Кигән киемемне, үземне, гадәти ручкамны мактый. Ул гына да түгел... Каядыр чыгып керергә, ресторанда утырып алырга чакыра.

Тәртәнең кайсы тарафларга борыласын күптән сизенгән Сәет, җитди кыяфәт белән, сорашкан булды.

— Хуш, синең фикерең ничегрәк инде? Хатын-кыз игътибар ярата. Бәйләнүләре күңеләңә сарымай булып яткандыр әле?— дип, шаяртуын дәвам итте хуҗа? — Кем түли, көйне шул сайлый.

— Ошамый миңа ул абзый. Таза, пеләш, хатын-кыз кебек кыланчык ирләрне җенем сөйми.

— Ул үзе турында башкарак фикердә.

— Керпе дә үз баласын йомшагым, дип иркәли. Сезнең бик якын, ышанычлы, җан дустыгыз, диләр аны. Әйтегез, ничек тотыйм үземне аның белән? Кулына сугыйммы, тәкъдимен кабул итимме?

Сәетнең көлү бизләре басылды. Җитди сорау калкытты ханым. «Симатованың эч серләре белән уртаклашуы тугрылык, бирелгәнлек, ихласлык билгесе, шулай булырга тиеш, беренче очрашуда ук үзем шундый нәзер-установка биргән идем»,— дип, эченнән хуплап, чынында, кәмит табып, авызын ерып, елмаеп-көлеп утырса да, әңгәмә барышында ул исәп-хисап буенча ярдәмчесенең җаваплылыкны үз өстеннән төшерүен, ул-бу була калса, гөнаһсын урталай бүлешергә чамалавын аңлады. «Җитди бәйгедә йомшак дошманнар катнашмый»,— ди торган иде Симферополь училищесында самбо буенча тренеры. Бу фикернең хаклыгына ничәмә катлар инанды инде гомер агышында. Аңа әйтмичә, мәчеләр кебек, буран чыккач, караңгы төшкәч, шыпырт кына йоклап йөрсәләр ни булган... Хәлилнең «эше» беренче борылышта ук барып чыкса, «коймак майсыз табада янмыйча пешсә», Сәет белми дә калыр иде. Хәзер хисапчының ирләр белән кайчан һәм ничек җәелеп ятуы өчен дә җавапны йолдызсыз җилкәңә алырга тиеш буласыңмы? Ханым соргылт күзләрен җемелдәтеп тәк тора җавап көтеп. Нинди киңәш бирергә соң аңа? Үзең шундый юнәлеш биргәч, түз, абзыкай.

— Фирая Вагизовна, бу мәсьәлә четерекле инде. Һәркем аны үзенчә хәл итә. Нинди киңәш бирергә дә белмим. Мин сезнең урында булсам (аллам сакласын!), кулына да сукмас, тезне чүгәргә дә ашыкмас идем.

— Ярый, шулай кыйландырырга тырышырмын, барып чыкса. Рәхмәт.

Бухгалтер бүлмәне бушатуга, бусагада Хәлилнең яртысы чәчсез башы, тулылыкка дәгъва итәрлек гәүдәсе һәм башы очлы чем- кара туфлиләре пәйда булды. Симатованың чыгып китүен күреп калган йә көтеп торган булса кирәк, сүз ялгавычы итеп аны алды.

— Кадрларны сайлый беләсең, молодец.

— Ресторан ишеген саклаганда үзең өйрәттең чын алкашны просто исеректән аерырга.

— Һәр чорның үз мәзәге була, малай. Мин Фирая Вагизовна турында әйтәм.

— Аңа ни булган?

— Кызыклы хатын.

Сәет бу «клиент» илә дә башын җүләргә салырга булды. Андыйлар рәхәт яши.

— «Кызыклы хатын» дигән гыйбарәң, аяктан асып куйсаң да, миңа барып җитми. Котелок пешерми. Хатын-кыз матур, ямьсез, акыллы, шыр тиле, пырдымсыз, бозык, азгын, салкын, кайнар, явыз, шәфкатьле, озын телле, йомык һ. б. булырга мөмкин дип, укыганым һәм ишеткәнем бар. Ә менә «кызыклы» нинди бәяләмәдер, ниткән тәмләткечтер... Билләһи, белмим.

Хәлил хуҗасының үзен ирештерүен аңламыйча, шундый гади нәрсәгә төшенмәвеннән чарасыз калып, наданлыгына шаклар катып, карап торды да, күзлеген кулына алып, ихластан аңлатырга кереште.

— Эшне дә алып бара. Хатын-кызга тиешле мөлаемлеге бар. Кыскасы, барча әгъзасы үз урынында диюем.

— Тикшереп, экспертиза ясап карарга өлгердеңме, мент калдыгы, азгын тәре, карт шайтан.

Уйланып торган кыяфәт оештырды йөзендә. Япон байлары яратып кия торган куе карасу зәңгәр пинжәгенең якасыннан чүп алып, читкә ташлаган булды. Сүзен ялгап китте.

— Табигать-анабыз тиеш тапкан һәр әгъзасы булмаса, ул башка зат, үзгә җенес була торгандыр?

Хәлил, ниһаять, Сәетнең мыскыллы көлүен, ирештерүен аңлады. Юкка-барга үпкәләү бүген аңа файдалы түгел иде. Күңелендәген ярып салды.

— Миңа ошый ул хатын. Синнән яшерен-батырын түгел.

— Дебет-кредитны алып баруы күңелеңә хуш килдеме?

— Юк ла, гәүдәсе, үзен тотышы, йөри белүе...

— Минем күңелемә дә хуш килә ул,— дип, алдашырга булды Сәет.

— Син аны үзеңә аласыңмы?— диде Хәлил, борчылуын яшерә алмыйча.

— Ничек инде «алам». Өченче ай миндә эшли бит инде. Алынган.

— Гаҗәпләндерәсең, Сәет, мине соңгы вакытта. Не поймешь. Шаярып сөйлисеңме син, әллә чын күңелдәнме?

Хуҗа уенны туктатырга булды. Урынбасары белән башка, җитдирәк сүзе дә бар иде аның. Телне чарладык — җитте.

— Мине мәхәббәт маҗаралары борчымый. Ишетүемчә, акыллы кеше сөяркәне үз хезмәткәрләре арасыннан эзләми. Ул аны читтән, Багам утрауларыннан таба. Шәхси дөньяга тыкшынасым килми. Тик бу шөгылең гомуми эшкә зарар китерергә тиеш түгел.

Хәлил тәнкыйтьнең бер кисмәк балга эләккән бер кашыгын да яратмый, кабул итми. Чөнки ул үзен һәр җәһәттән килгән, алланың кашка тәкәседәй хезмәткәр, дип саный. Шул ышанычыннан тәм вә ләззәт таба.

— Мине һаман үз вазифаларымны эленке-салынкы үти дип санамсыңмы?

Хәлилнең соңгы вакытта бик нык үзгәрүен күздә тотты Сәет. Сәнәктән көрәк булган кешеләргә хас эрелек, кәперәюлек, тәкәбберлек кебек сыйфатларны, ясалма мунчала кебек, үзенә тиз сеңдерде. Җае чыкканда, үзеннән түбәннәрне кыерсыта, рәнҗетә. Бу кыланышларына артык игътибар итмәс иде Сәет. Урам ташын таптап йөргәндә ярдәм кулын сузган өчен ул Хәлилгә бурычлы. Бер яхшылыкка мең изгелек белән җавап бирергә әзер кешеләрнең берсе иде. Төлке куышын күзәткән арслан кебек, тешен кысып булса да түзде, ризасызлыгын, ачуын тышка чыгармады, сүндерә килде Сакманов.

Дилбегәне бушатырга ярамый икән шул. Хәлил аңа һәрнәрсә ярый, гафу ителә, үзен алыштыргысыз кешегә санап, Сәет тарафына да: «Хаталар ясый, малны тигез бүлми. Үз ягын күбрәк каера»,— кебек җөмләләр ычкындыргалый. Чит-ят кешеләр булганда да авызын тезгендә тоту ихтыяҗы турында оныта урынбасар. Дус-иш, кызыклы хәбәрне мулрак алу нияте белән, «Игелек» синең җилкәдә тора, син булмасаң, ул кызыл балчыктан өелгән чүлмәк төсле уалып, убылып төшәр иде,— дип, котырталар һәм, табигый ки, нәтиҗәне читкәрәк китеп көтеп торалар. Нигъмәтуллин сабын куыгына алдана.

Бүген Сәетне иң гаҗәпләндергәне, хәтта аптыраштa калдырганы шул булды. Хәлил җитешсезлекләре, телен бастырыкка куя белмәве, чама хисен югалта баруы турындагы сүзләрне бик җиңел кабул итте.

— Барысы да дошман сүзе, Сәетҗан. Безнең араны бозарга, талаштырырга йөриләр.

— Соң синең кыланмышларыңны үзем күреп торам. Бер мәсьәләне хәл итүгә дә алынмыйсың. Каравылчы төсле, бүлмә саклап утырасың.

Җавабы белән Сакмановны телсез калдыра язды иптәш Нигъмәтуллин.

— Усал булып кыланма, Сәет, синнән катыйль чыкмаячак,— дип, әйтеп ташламасынмы.

Утны-суны кичкән, ничә кат үлемнән калган Сәет коелып төште: «Ни өчен шулай уйлыйсың?»,— дип сораганын сизми дә калды. Бу инде

авырлык белән алган киеренке биеклекне югалта бару дигән сүз иде. Хәлил өчен авыр сызык үтелгән иде.

— Усал булып туарга кирәк. Синең күңелең йомшак, җаның балавызлы.

— Хәлил әфәнде, комагайланма, юкка маташма. Әйтәсен әйттем. Миенә киртләп куй. Эшемне кылган кешедәй, кыланып йөрүдән уза алганың юк соңгы мәлдә.

Хәлил Сәет Сакмановның холкын-фигылен яхшы белә. Күпме генә нәгърәләр орып, дуласа, котырынса да, ул аны эшеннән куып чыгармаячак. Шелтә чәпәсен, ят кешеләр алдында ачулансын. Әрләү СПИД түгел, аңардан үлмиләр, алтынга нәҗес ябышмый.

Нигъмәтуллин Фираягә чын-чынлап гашыйк булган, дип раслау бик үк дөрес булмас иде. Баш хисапчының гәүдәсе, тән борылышлары, аяк атлавы ошый Хәлилгә. Төшләрендә аны кочагында эретә. Фирочкага якынаерга, аны ышанычлы кешесе ясарга тырышуының икенче, бик тирәндә яткан, үзенә дә әйтергә курыккан сере бар. Сәеткә каршы берләшү дисәк — артык каты әйтелгән булыр иде. «Игелек»нең акча, банк серләрен, алыш-биреш мөмкинлекләрен, Сакмановның килемнән үз исәбенә күпмесен күчерә баруын белү Хәлилнең эчен тишмәс иде. Баш бухгалтер һәммә нәрсәдән дә хәбәрдар дип уйлап, Нигъмәтуллин бер ялгышса, кочаклашып йоклаганнан соң, хатын-кыз һәммә нәрсәне ачып, серен актарып сала, дип уйлап, икенче хата ясады. Мәңге яшә, мәңге өйрән, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән борынгылар.

Урынбасарының Фирая белән «аулакта» очрашулары турында Сакманов белми дә калды. Хәлил бер кунакханәдән бүлмә алып, хисапчы ханымны сөйләшеп утырырга, ял итәргә чакыра. Ашау-эчү якларын җиренә җиткерә. Юк-бар турында сөйләшеп, әйбәтләп сыйланалар. Хәлил ничек кенә тырышмасын, Симатова: «Бүген эш турында сөйләшмибез»,— дип, көткән «ачышларны» ясамый. Ике сәгать чамасы утыргач, ханым, абзый ялап алган иннек-кершәннәрне иреннәренә, битенә төшерә башлый.

— Гафу итегез, Хәлил Газизович, мин ашыгам. Ирем театрга билет алганые.

— Кызганыч,— ди Хәлил. Бармаклары белән чәч калдыкларын сыйпап алганнан соң, өстәп куя.— Мин сиңа тимәдем. Мин нинди әдәпле кеше.

— Мин шуннан курыккан да идем, Хәлил абый,— ди хисапчы, асылма чантасын җилкәсенә ташлап.

Нигъмәтуллинның ялвару, очрашу безнең арада гына калсын кебек, буш аклану сүзләрен ишек белән кисә.

Илләм гарьләнә Хәлил. Ирлегенә тия бу. Алып килгән эчемлекләрен эчеп бетереп, үзен хәтерләмәс хәлгә килеп, ачык тәрәзә белән ятып йоклый. Икенче көнне «бәй»нең хатыны Сакманов конторасының ишеген шакый.

Сәет, Хәлил белән әвәрә килеп, гел аралашып яшәсә дә, дустының хатынын күрү бәхетенә берничә тапкыр гына ирешкән иде. Махсус өйрәтелгән этләр мәсле, ресторан ишеген саклаган, «әби патша» заманында булды тәүге очрашу-танышулары. Әллә сагынып, әллә берчак тикшереп килеп кергән идеме инде аларның эш урынына ханым, анысын үзе белгәндер. Сырлы агач бусагада хәләл нәзбереген күрүгә, Хәлил әүвәл, кабыгыннан яңа тазартылган юкә агачы төсенә керде. Хәер, үзен тиз кулга алды.

— Таныш бул, Сәет, минем хатыным — бердәнберем Мәйсәрәм,— дип, уңышсыз чыкса да, шаярткандай итте.

Никахлы ирен ташлап, нарасыен үги ата көненә калдырып, алама участковый ментка, тасма тел Нигъмәтуллинга ябышып чыккан хатынны

Сакманов игътибар белән «өйрәнде». Өлеш тәлинкәседәй кечкенә, түгәрәк йөзле, саргылт карасу тиреле, уртача буйлы, аякларыннан бәдәне озынрак, саф татар баласы икән Хәлилнең җефете. «Мәрхүм иреннән суырып алмаса, мондый гына матурлыктагы кыз-хатын тапкан булыр иде инде. Нәфесләренә хуҗа була алмыйча, кешене харап иткәннәр»,— дип, «изгеләнеп» уйлап алганы бүгенгедәй хәтер яньчегендә саклана. Акылына бәйсез рәвештә, әллә каян, астан күтәрелгән кабул итмәү, гаепләү, өнәмәү хисен бастырыкка утырта алмыйча интеккән иде шул мәлдә. Башка очрашканнары булмады. Зөлфия белән туйларына чакырулы булса да, килмәде. Хәлил түр башында, башкода урынында, берүзе кукраеп утырды.

Бүген менә Мәйсәрә ханым Сәетне үзе эзләп тапкан. Кирәкле кишер яфрагы икән әле ул. Ишек төбендә утыручы кыз кереп: «Сезне Мәйсәрә Нигъмәтуллина дигән ханым сорый. Хәлил Газизовичның хатыны түгелме икән? Үзе эшкә килеп җитмәгән»,— дип, кереп әйтүгә, бүлмәдәге белгечләрен вакытлыча чыгарып җибәреп, ханымны аягүрә басып кабул итте. Хәлилнең бүген эшкә чыкмавыннан хәбәрдар иде инде. Күрәсең, абзый эштә артыгын «тырышып» ташлап, чирләп киткәндер, «сөенчене алырга хатынын җибәргәндер»,— кебегрәк фикер узды башыннан. «Әллә, тормыш тоткасына шикаять белән килгәнме? Белмәссең, хатын-кыз фигыле — төпсез кое».

— Түрдән узыгыз, утырыгыз, Мәйсәрә. Атагызның исемен белмим. Сезне күрүгә бик шатмын.

Берничә ел эчендә, Газиз улы Хәлилнең «талап» алган хатыны шактый бирешкән, картайган. Муен, маңгай тирәсенә, күз төпләренә әрсез җыерчыклар үрләгән, тиресе сәлперәйгән, йомшаган. Уймак хәтле генә күзләре, кемнәндер оялган, курыккан кебек, алга чыгыбрак торган маңгае астына, тирәнгә кереп киткәннәр. Бу юлы да урынбасарының хатынында сөйкемлелек бизәкләре тапмады «Игелек» хуҗасы. «Син кешегә алдан әзер мөһерең, бәяң белән киләсең»,— дип, үзен юл уңаенда гына битәрләп алды да, янә бер рәт «кизү» сораулар тезеп куйды.

— Ни йомышлар китерде сезне мондый җилле көнне? Хәлил бәй зарплатасын өенә алып кайтмыймы әллә? Бүген эштә дә күренми диләр, чирләп китмәгәндер?

Сакманов тәкъдим иткән сөальләргә тискәре җавап алынды.

— Юк ла. Акчасын да, әйберен дә алып кайта. Бу яктан тәртип.

— Кызларын рәнҗетәме әллә?

Бу сорау да кабул ителмәде. Кыйммәтле балдаклары җемелдәп торган бармакларын аралаштырып, ханым эчке дулкынлануын басарга тырышты. Ник килгәненә үкенүе дә сизелә. Кеше психологиясенә хас гадәти хәл.

— Соң, ни йомыш алайса? Чәй куйдырыйммы?

— Авыз тутырып әйтерлек йомышым юк, Сәет Яруллович. Бик кызуланып килгән идем, хәзер югалып калдым. Сүзем бик четерекле. Башка барыр кешем булмагач, килдем инде. Хәлил турында сөйләшмәкче идем. Бик нык бозылды. Сез дә боздыгыз бугай! Артыгын үсендереп.

Берни аңышмый утырган, үзен гаепләү сүзләре колагына иңгәч, тәмам өммәтсез калган Сәет: «Менә сиңа мә, милли пәрәмәч»,— дип кенә уйлап өлгерә алды.

— Зурдан кубып килгәч, күңелегезне бушатып китегез инде. Үз ялгыш-йолгышымны белү дә киләчәк тормышымда бер таяныч булыр иде,— ди-ди Сәет, сөйләшүгә җиңелрәк төсмер бирергә тырышты. Үз җенесенең башка вәкилләре төсле үк, ул хатын-кыз белән бу төр аңлашуны бер дә өнәми иде.

— Гафу, гафу, Сәет Яруллович, сезне гаепләргә җыенмыйм. Хакым да юк. Хикмәт башкада. Хәлил бик нык бозылды, дидем. Арка тирәге нык булганда, яшәп тә, теләсә нинди дәрәҗәле эшне дә башкарып була.

Сәет «мәсьәләгә якынрак килик»,— дип бүлдерүдән чак-чак тыелып калды.

— Хәлилнең гаять көнче кеше булуын беләсезме икән? Шул гадәте белән тенкәләремә тия, вакытсыз гүрләргә илтеп тыга инде... Ашына, чәенә, яшертен генә төрле дарулар салып, тоз, җиләк-җимешләрне имчетомчы әбиләрдән өшкертеп, ашатып карадым. Файдасы юк. Һаман котырына.

— Соң, берәр сәбәбе бардыр? Үзегез хата ясагансыздыр? Гаеп аңарда гынамы?

Ханымны бигүк өнәп, яратып бетермәве теленә бәреп чыкты:

— Берәр ир белән тоттымы? Бу очракта, мин ярдәмчегез була алмам, дип куркам.

Мәйсәрә ханымның сусыз кое төсле тирәнгә баткан караҗимеш күзләренә сәерсенү, гаҗәпләнү, үпкәләү, гаҗизлек чалымнары бәреп чыкты.

Йөзе кызыл шәфәкътәй кабынды, беләк тиреләренә чаклы, кайнап торган суга тыгып алынган кысла төсенә керде.

— Алладан оялыгыз, Сәет Яруллович. Миңа сөяркә генә җитмәгән. Болай да, уттан качкан таракан кебек, кеше күзенә күренергә куркып, почмагымда посып кына яшим. Кемгә кирәк ди мин? Беренче иремнән көнләшә. Һәр кичне: «Кайсыбызны күбрәк яратасың, кайсыбыз көчлерәк?»,— дип, миемне черетә. Үзенә кулай җавапны алмыйча, туктамый. «Сине ныграк яратам, башкача, беренче никахымны бозып, син хәчтерүшкә кияүгә чыкмаган булыр идем»,— дип, кат-кат әйтәм, ышанмый, тумыштан елак бала төсле, һаман саен бәйләнә.

Ханым кул аркасы белән генә күзләрен сөртеп алды.

— Сез безнең тарихны беләсез ич инде?

— Үткән эшкә салават, диләрме әле. Булган беткән. Адәм баласы киләчәк белән яшәргә тиеш.

— Ул гына да түгел,— дип, фикерен ялгап алып китте кунакбикә.— Урамда, бергә барганда, яшьрәк иргә күз төшереп алсам,— мин бит сукыр түгел,— шунда ук гауга чыгара. Янәсе, минем күңелемдә ирләр һәм җенси азгынлык кына.

— Кызык та, сәер дә. Хәлил Газизович турында, шундый көнче дип, һич тә уйламассың. Көнчелеге өзелеп яратуы билгеседер, бәлки?

— Бер дә кызык түгел шул, Сәет Яруллович. Телевизордан җыр тыңлаганда моңсуланып, ямансулап китсәм: «Син беренче иреңне исеңә төшердең, аның тез башында утыргандай онытылып киттең»,— дип, тиләрә башлый. Үземне ничек тотарга да белмим.

Сакмановка бу низагка шәхси мөнәсәбәтен билгеләү җиңел түгел иде. Дөньяда ир белән хатын арасына керүдән дә куркынычрак албастының юклыгын белә иде ул. «Бу мәсьәләдә аның вазифасы нидән гыйбарәт соң? Ул Хәлилне ирләргә, тәнкыйть утында көйдерергә тиешме? Ханым, һәрхәлдә, яклау эзләп килгәндер инде? Кеше олыгайган саен бозыла, әшәкелек белән дыңгычлана бара икән».

— Мин сезнең хәлегезне аңлыйм. Бер-береңә тулы ышаныч булмаганда, яшәве кыендыр,— кебегрәк гомуми сүз боткасы куертты. Мәйсәрәнең янәдән борыны, күзләре йомшап китте. Дулкынлануы гәүдәсенә чыкты.

— Белүемчә, сез яратышып, киртә-диварларны ватып-җимереп өйләнештегез. Ике кызыгыз бар. Хәзер соң инде... Җир җиләге ачы диеп, балан ашар хәлем юк, диләр түгелме соң? Өлешегезгә чыккан тәңкәгез.

Ханым бүлмә хуҗасының йомры сүзләренә игътибар итмичә, үз йомгагын сүтүне дәвам итте.

— Безнең историяне беләсездер инде? Гайре табигый хәлләр, җепшек кар йомарламы кебек, күп тапкырларга үстерелеп җиткерелә, тиз тарала.

— Хәлил үзе сөйләгән иде,— дигән булды Сәет.

Ханым күңелендәгеп бушатмыйча, хәсрәтен ахыргача чыгармыйча, туктап калырлык хәлдә түгел иде инде.

— Шул милиционер аркасында нинди изге кешене югалттым. Рәнҗеп ята торгандыр инде. Миһербансызлыгым өчен бер түлисе булыр. Ялганга, хәрәмгә батып беттем. Мәңге тәмугта дөрләп янарга язгандыр инде миңа.

— Хәзер үкенүдән ни файда?

Хатын-кыз, олыгая барган саен, теге дөнья турында ешрак уйлый, кылган гөнаһлары өчен үкенү хисенә бирелүчән була икән. Тик Хәлилгә ябышып чыккан (димәк ки, үлепләр яратып) Мәйсәрә ханымнан Сәет мондый тәүбәне көтмәгән иде.

— Мин гөнаһларны ярлыкый белмим,— дип, сүз кыстырырга тырышып караса да, барып чыкмады. Хәлил хатыны су тулы чиләкне бушатып бетермичә туктасы түгел иде.

— Төннәрен, җилдә селкенеп утырган көзге яфрак төсле, калтыранып уянам. Төшләремә кереп йөдәтә беренче ирем. Җитмәсә, Хәлиле кара кайрак белән бәгырьне кайрый.

Кунакбикә хисләр көчәнешенең чигенә житте. Сәет аны чын күңелдән кызгана ук башлады.

— Минем язмышым турында чынын беркем белми. Ул мине куркытып, алдап, шантаж белән, көчләп диярлек алды.

Менә монда инде Сәет ханымга ышанмады. Хатын-кыз, теләмәсә, карышуы, үзен әтәч куа килгән тавыкның, «бик каты йөгермимме икән»,— дип, артына борылып, карап-карап алганы кебек, сүз-исем өчен генә булмаса, аны «алуы» мөмкин түгеллекне белә иде. Аны көчләргә, кыйнарга, типкәләргә, борынын канатырга, үтерергә мөмкин... Мәгәр яраттырып булмый. Хәлил яңачарак алымнар тапкан күрәсең?

— Безнең яшерен очрашу турындагы хәбәрне үзе үк иремә җиткергән. Кара йөзләр кебек тотылдык. Спектакльнең соңгы өлеше сезгә мәгълүм.

Елмаерга тырышып карады. Күзләре тирәнгәрәк керде. Кырыс һәм кайгылы иде аның кечкенә йөзе.

— Димәк, ул сезне яраткан.

— Бәлки... Аның белән йокларга тиз генә ризалашмыйча, терсәгемне күкрәгенә терәп карышкан өчен генә булмаса... Хәзер күңелемә уйларның төрлесе килә. Аның теле, куянны тартып китергән еланныкы төсле, алдаучан булып чыкты.

«Укытучы кеше шул. Иренмичә, ышандырып, җиренә җиткереп сөйли»,— дип, уйлап алды Сәет, аптыраганнан, хатынның күңелен рәнҗетмәс, канатын сындырмас өчен үзен кыстырып куярга булды.

— Соң, безнең яшь бара инде!

— Үзем дә шул хакта әйтеп торам. Илле яшенә җитеп килгән хатынга кем күз салсын. Әнә нинди өлгер яшьләр үсеп килә. Үзләре ирләр өстенә сикерергә торалар.

Сакманов урыныннан торып, йөренеп алгандай булды.

— Эт тилерсә хуҗасын талый, диләр. Аны артык иркәләп, гел кубызына биеп, өрмәгән җиргә утыртмыйча, үзегез үк бозып бетермәдегезме икән?

Сәет, тәмам рольгә кереп, рәхәтләнеп, тәмләп, әхлак темаларына сайрап алды. Әйтерсең лә, алдында утны-суны кичкән мәктәп укытучысы утырмый, ә борын асты да кипмәгән укучы басып тора.

Тышкы шелтәү аша иңгән эчке, яшертен мактануны ханым бик теләп, җаны-тәне белән кабул итте, аз-маз тынычланды.

— Үземдә дә гаеп бардыр инде, Сәет Яруллович. Болай бит Хәлил начар кеше түгел.

— Әшәке кеше турында болай сүз куертып утырмас та идек. Артык вакытым минем дә юк, җыелышны бүлеп кабул иттем сезне.

Сәет шунда, тыны кысылган кешедәй тукталыш ясады, һәм тавыш тембрын үзгәртеп, дөресе, кырыслык өстәп, сорап куйды.

— Мин нишләргә тиеш? Абзыкай, иптәш Нигъмәтуллин, череп таркалган капитализмнан инглән көнчелек чирене дәвала, тиле дәртене тышауга сал, хатыныңа больше тегеләй-болай дип, бәйләнәсе булма, иначе эшеннән куам дип, җитди кисәтү ясарга мәҗбүр буламмы?

— Юк, юк, минем монда булганны зинһар әйтә күрмәгез. Җене котырыр.

— Шулай булгач, нигә дип миңа бу хикмәтләрне сөйләдегез? Бу хәбәрдән башка, миңа яшәве күңелсез булыр иде, дип уйлыйсызмы?

Мәйсәрә аптырап калды. Күңелендә эчке, җилле-давыллы көрәш барганы сизелеп тора.

— Минем белән бер-бер хәл булса, белеп торыгыз, дип килдем. Һәм... Мин сезгә бөтенләй башка сәбәп уңаеннан килгәнием. Кичә Хәлил өйдә кунмады. Иртәгесен генә кайтты. Айнып та җитмәгән иде. Бер стакан тутырып аракы эчте дә, йокы бүлмәсенә кереп ятты. Минем белән сөйләшми дә...

Мәйсәрә ханымны озаткач, вакыйга-хәлләр агышын чамалаган Сәет бөтенләй башка йомыш белән баш хисапчысын чакыртты. Шактый озак сөйләштереп утырды. Әмма Фирая авызыннан кичәге хәл-әхвәлләр хакында ләм-мим сүз төшмәде. Сакманов мондый йомыклык, килешүне бозуы өчен үпкәләргә тиеш иде шикелле. Мәгәр, киресенчә, алдында табигый халәтендә утырган, тулы гәүдәле, тыныч табигатьле, үз бәясен үзе белгән ханымга ихтирамы артты: «Сата торган нәселдән түгел икән. Аңа ышанып, чалышаерга була». Шулай да, Симатова инде кулын ишек тоткасына куйгач, тавышына битарафлык төсмере салырга тырышып: «Бүген Хәлил Газизович эшкә чыкмаган. Конторада ямь юк»,— дип, әйтеп салды.

Фирая тыныч. «Причем монда мин», дигәндәй, җилкәләрен сикертте дә, чыгып та китте. Иреннәрендәге шаян елмаю Сәетнең күзендә калды. «Игелек» хуҗасы барысын да аңлады.

Фирая-Хәлил-Мәйсәрә өчпочмагының очына чыгарга насыйп булмады ул көнне Сәеткә. Чынында анда эләктереп алырлык вакыйга да юк иде. «Роман» тәки язылмыйча калды...

## 12

Авыруның халәтен аңлап, уйланып ятуын, елмаеп куюын күреп, янында шыпырт кына утырган Фәридә җаен китереп сүз катты:

— Сәет Яруллович, уегызны бүләм инде, әлегәчә әйтергә базмыйча йөрдем. Өч көннән сез бальнисны үзегездән азат итәргә тиеш буласыз. Баш табиб та, хирург та ашыктыралар. Бу көннәрне дә мин генә сорап алдым.

Ханымның соңгы җөмләсе, йөрәгенә сөт өсте булып ятса да, якланып алырга булды.

— Ни өчен мине бередә тагын шул чаклы тоту кирәк булды? Әллә иләшеп җитүең булдымы ятим үрдәк баласына?

— Сезнең бередән тәпи-тәпи атлап, ук аягыгыз белән чыгып китүегезне телим. Өч айлык гомер кисәгемнең нәтиҗәсен күрәсем килә.

Шунда ук элеккеге фикеренә әйләнеп кайтты.

— Бу палатада элек, сезгә чаклы, биш-алты кеше ята иде. Чирле эшчеләр, бакча сезоны беткәч, һәр елны ял итәргә кереп ятучы пенсионерлар шаулый, диләр.

— Барысы өчен дә түләрмен, Фәридәкәй. Әйт хуҗаларыңа. Тулы ремонт ясатып бирермен. Түбәне яматырмын, теге «хулиган» калайны

алыштырырмын. Сиңа мин... мәңгегә бурычлы. Бу изгелекнең бер өлешен генә түләү өчен дә, минем гомерем дә, байлыгым да җитмәячәк,— дип, пафоска кереп киткән иде дә, Фәридәнең игътибары башкада икәнлекне аңлап, тынды.

Ханымның зиһенен ниндедер башка, мөһимрәк нәрсәнең талкыганы күренеп тора. Бармаклары белән халат читен бөгәрли. Кечкенә туп төсле, йомры тез башының ачылганын, Сәетнең шуны күреп, кытыгы килгәнне дә сизми. Эчке каршылыгын, оялуын, тарсынуын җиңеп, ханым җанын бимазалаган фикерен әйтеп салды.

— Бальнистан чыккач, сезгә чын-чынлап аякка басканчы, ярдәмчеме, булышучымы, караучымы кирәк булыр; ишетүемчә, хатыныгыз юк.

— Берсе ташлап китте, икенчесен үтерделәр.

— Нинди шыксыз, иләмсез сүз. Туфрагы мамыклы мендәр, урыны оҗмахта булсын.

— Рәхмәт инде. Җылы сүзең өчен.

— Мин барча җәрәхәтегезне, кан басымын, йөрәк тибешен, сулыш алу үзенчәлеген һәм... башка якларыгызны да, яхшы беләм, дип уйлыйм. Ахыргача ярдәм итәргә ризамын. Кирәк дип тапсагыз, әлбәттә. Көчләп сыланмыйм.

Бу хакта Сәет сүзне үзе башларга тиеш иде. Нәрсәдер тотып торды. Зөлфия белән яшәгән фатирлары буш тора, Матюшинодагы йортында кыш көне дә яшәп була. Әхмәдиша карт белән Хәерниса апа да, «үзләренә» чакырып киттеләр. «Барып сыеныр, кайтып керер урыннар бинаһая анысы» — дип, рухын күтәрергә тырышса да, әлегә чаклы тәгаен бер карарга килә алганы юк иде. Фәридәнең бүген башлаган фикере тирәндә, аң төпкеле түрендә, әле үзе дә танымаслык хәлдә бөреләнеп яткан хыялы түгелме соң? Сәетнең хәл-әхвәлен, өч ай берөзлексез диярлек янында утырган, астын, өстен җыештырган Фәридәдән яхшырак белүче кеше юктыр бу олы җиһанда? Чынында гүр иясен аякка ул бастырды. Тыз-быз кереп-чыгып йөргән табиблар, төп эшне барыбер шәфкать туташларына тапшыралар. Ханым алдау-хәйләсез, ихластан күренә бу мизгелдә. Элеккеге хатасы өчен дә гафу итәргә була. Замана әхлагы, чор, тормыш көйсезлеге аны шул юлга этәргән. Ханым, алтабан да аңа ярдәмен үзе үк тәкъдим иткәч, һәрнәрсәгә шикләнеп, төрле яклап бәяләп кабул итәргә өйрәнгән Сәетнең күңелендә икеләнү шытты. Ни өчен аны, нәкъ менә ул рәнҗеткән Фәридә Мотыйгуллина үз канаты астына алган? Аңа кемдер югарыдан кушканмы, түләгәнме? Өстән, болытлар арьягыннан килгән фәрман гына да аздыр бу чаклы хезмәт, киң күңеллелек, хәтта бирелгәнлек өчен. Ошбу шәфкатьне кемнеңдер кушуы, үтенече буенча гына башкару мөмкинме? Юктыр, булмастыр. Мондый саф мөнәсәбәтне акчага, байлыкка сатып алып буламы? Юктыр, булмастыр. Сәет аңлап җитми торган шәйләр җитәрлек иде биредә.

Фәридәнең үз-үзен тотышында, дөресе, аңа шәхси карашында сәерлекләр тулып ята. Сәет эч серләрен ачып сала башлауга, мәхәббәте, йөрәгенең парә-парә килүе хакында кәлимә катуга, ханым сүзне җәһәт кенә икенчегә күчерә. Тыштан миһербанлы,гадәти бер шәфкать туташы булып күренсә дә, Мотыйгуллина үзен сыртка салдыра, арзанлы җимгә алдана торганнардан түгел икән. Бер авызы пешкән, салкын суны да өреп кабар, диләр. Чынбарлыкның ачы дәресләре бушка китмәгән.

«Фәридә аны, димәк ки, үлем тырнагыннан йолып алып, аякка бастырган. Теге вакытта үзе үз таныганча, ул аңа нисбәтән битараф була алмый бит инде. Бу хакта турыдан-туры әйтергә базмаса да, бәлки, шәфкать туташы Сәетне ярата да торгандыр. Ир кирәк булган өчен генә

болай тырышмас иде. Беткәнмени тирә-юньдә, көчен, куәтен, дәртен, гаурәтен кая куярга белми интегеп йөргән, арысландай таза әзмәверләр, сәнәктән көрәк булган, чикләвек белән шоколад кына ашап яшәүче яңа байлар. Сәтнең ирлеге дә, яхшы чәй булмаганда, мәтрүшкә чәчәген яисә кишер яфрагын болгатып эчүдән ерак китә алмый торгандыр әле. Кем белә?»

Ханымның соравына, киңәшенә, тәкъдименә җавап бирергә кирәк иде. Һәрхәлдә, тынлыкны бозарга ул җөрьәт итте. Сорау бәгыреннән төште.

— Фәридә, тел яшермичә, тирәли йөрмичә генә, минем өчен мөһим сорауга туры җавап бир әле! Минем янда төннәрен вә көннәрен интегеп утырырга, мине шулай тәрбияләргә кем кушты? Милиционер иптәш тыңлата алдымы? Әллә минем егетләр үтенечен тыңладыңмы? Зур акча вәгъдә иттеләрме?

— Анысы да хак. То есть, сораучы-үтенүчеләр аз булмады. Абруегыз бар икән. Баш табибка хөкүмәттән дә әйттеләр. Гаяровмы,Таяровмы, Саяровмы дигән полковник, баш табибка, әллә ничә кат шалтыратты, соңгысында: «Аның исәнлеге өчен башың белән җавап бирәсең»,— дип, кычкырынды диләр. Әмма мин сезне дәвалауга кемнеңдер кушуы буенча түгел, үзем алындым. Әүвәл чираттагы отпускамны файдаландым, ике аен үз исәбемә...

— Соң син, Фәридәкәй, эштә саналмыйсыңмы? — диде, гаҗәпләнүдән күзләре ачылып киткән Сәет.

— Безнең хезмәт хакын алдың ни, алмадың ни. Берничә җирдә эшләмәсәң, кече телнең күңелен күрергә дә җитми.

— Башка урында да эшеңне ташладыңмы, минем өчен? — дип, ахмак сорау бирде ир. Көне-төне аның ятагын каравыллаган кеше тагын нинди хезмәткә бара алсын, ди.

— Бер чирлегә бер медсестра тота алмый шул әлегә безнең демократик хөкүмәтебез, абзыкай. Ачка интекмәдем. Егетләрегез матди ярдәм күрсәтеп тордылар. Бераз запасым да бар иде.

Чирле кешенең күңел дәрьясы тулуга күп кирәкме? Сәет караватыннан күтәрелебрәк, Фәридәнең кайнар бармакларын учына алды. Кара күзләрдә үз чагылышын күргәндәй булып, ханымның кулын үпте.

— Ни өчен шундый корбанга бардың, сеңелем? Мин бит сиңа гомергә онытылмаслык рухи җәрәхәт ясаган адәм. Кем син?

— Фәридә Мотыйгуллина булам мин, паспортым буенча,— диде, ханым ирне күзләренең энҗе-мәрҗән нурларында коендырып.

— Кайрысы алынган черек колганың ни пычагыма кирәге бар иде сиңа? Минем исән калуыма ышаныч юк иде, диләр.

— Үзем өчен исән калдырырга булдым, Сәет Яруллович, рөхсәт булса. Теге вакытта... фатихагызны алып булмады,— диде ханым, гадәти генә итеп.

— Соңыннан үч алыр өченме? — дип сораганын сизми дә калды Сәет.

— Безнең бу хакта сүз булгание. Күрәсең, киләчәктә дә бу шеш калкып чыккалар әле. Ракка гына күчә күрмәсен. Хатын-кызны, Сәет абый, ирләр барыбер аңламый икән. Үзләрен акыллы дип йөргәннәре дә... череп баеганнары да... Ходай тәгалә без мәхлукъларны шулай яраткан инде. Ачу аласы... Ә без гашыйк булабыз. Иске коега төкерергә ярамый, күрәсең.

Сәетнең бөтен барлыгын сөенечле, шатлыклы, шул ук вакытта төерле, кантарлы дулкынлану биләде. Рухи халәтен яшерә алмыйча, Фәридәнең тыгыз гәүдәсенә сыланды. Ханым көчле куллары белән, назлы саклык илә, ирне урынына яткырды.

— Тагын бер серле сандыкны ачыйм инде. Бу адымга хакым бар идеме, юкмы, терелгәч, үзегез бәяләрсез. Шулай килеп чыкты... Мин барысына да сезне ирем дип ялганладым. Башкача булмый иде.

— Бик дөрес әйткәнсең, Фәридәкәй. Синең ялганны без хакка чыгарырбыз, дип уйлыйм,— диде Сәет күтәренке, көр, ихлас тавыш белән. Озак сөйләшүдән, хисләнүдән арыса да, ул үзен ифрат яхшы, бәхетле хис итте бу дәкыйкадә.

Шул мәлне бүлмәгә тәмәке тартырга чыккан Җирән яугир килеп керде. Шәфкать туташы читкәрәк күчеп утырып, Сәетнең кан тибешен саный башлады.

Ханымның үзенә битараф булмавына, бәллүр савытны саклагандай иркәләп тотуына, аңына кайтып, үзен белә башлагач, бер кызыклы күзәтүгә аша инанды ир-зат. Фәридәне ара-тирә, күбрәк төнлә, чирле йоклаган вакытларда, кизүдә башка шәфкать туташлары алыштыргалый икән.

Сакманов ул ак халатлы алиһәләрне бер-берсеннән аера, таный башлады. Үзе өчен яңа кешеләр ачты. Сәламәтләнә башлау галәмәте иде бу. Берсе — буй-сыны матур булуы өстенә, серле күренде ир-затка. Аңа игътибар беләнрәк баккач, ирләрчә сокланып, калтыранып куюын тойды. Мәңгегә, ахыргача, яшертен-орынтынлыгын ачмас куе яшел, зөбәрҗәт күзләрдә, яфрак аша төшкән кояш нурлары уйнагандай тоелды. Иң кыйммәтле фирүзә ташың бер якта торсын. Аклы кием өстенә, тыелгысыз иркенлек белән сибелгән аксыл-җирән чәчләр, хатын-кызда сирәк була торган киң маңгай, тойгылы иреннәр үзара килешеп урнашканнар. «Маңгае бер аршын, авызы чирек аршынлап булыр, мондый ходай бирмешләр белән кайгы-хәсрәтсез яшәп була торгандыр»,— дип күңеленнән, үзенчә шаяртып та алды чирле. Тиресе шикәр төсле ап-ак. Бәлки, татлыдадыр әле ул кем өчендер?

Беркөнне сөйләшеп-гәпләшеп тә алдылар.

— Үлгәнче, исемегезне беләсем килгәние. Үкенечкә калмасын,— дигән булды палата хуҗасы, чытыкланып.

Кыз житди җавап бирде.

— Бу хәлгә житкәч, озак яшәячәксез инде, Сәет Яруллович. Организмыгыз үзе өчен көрәшергә өйрәнеп житте. Һәрдаим һөҗүмгә әзер ерткыч шикелле...

— Миңа мондың чагыштыру ошый.

— Гафу итегез, медицинада шундый тиңләү яши... Исемем минем Лениза. Төннәрен, Фәридә хәлдән тайган вакытларда, янызда күп утырдым. Сез ул хакта белмәсәгез дә...

Яшел күзләрендә аҗаган уйнап алды. Катнаш никах җимеше икән кызый.

— Әнием татар хатыны булса да, аның туган телен белмим диярлек. Әтиемнең кайсы милләт вәкиле икәнен тәгаенли алмыйм. Хохолмы, белорусмы шунда. Күптәннән ташлап киткән. Мать-одиночка үстерде мине.

— Минем хакта нәрсәләр беләсез, ниләр сөйлиләр?

— Безгә пациентлар турында мәгълүматлар бирелми. Без аның чирен, ярасын, терелүгә барышын гына күз уңында тотарга тиешбез. Дәвалау алымнары бездән тора. Дөресе, без врач кушканны җиренә житкерүчеләр.

— Ягъни, кешенең әҗәл белән көрәшәсе көнен, үлем сәгатен сез белгеләргә тиеш буласыз түгелме?

— Анысы ходай тәгалә кулында. Бу дөньяда барыбыз да вакытлы кунак кына,— диде Лениза, көрсенеп. Җитди, хәтта үкенечле аһәң белән өстәп куйды: — Бездән генә тормый шул, хәлебездән килсә, һәммәгезне дә, үзегез яшәүдән туйганчы, сулатыр идек. Безгә үпкәләүдән файда юк.

Җитди итеп сөйләргә тырышса да, чибәр кызга катгыйлык, әхлакый тон килешми икән. Киңәеп, иркенәеп киткән авызы рәнҗүенең җитди булмавын сатып тора.

— Әгәренки, берәү дә бу фани җиһанны, үз чиратында ташлап китмәсә, җир шарында алма төшәрлек тә урын калмас иде.

Буын бүленешләре чокырчыкланып, эчкә батып торган матур бармаклы кулын гына селкеде бу юлы шәфкать туташы, гасабиланып.

— Ул хакта сүз бармый, Сәет Яруллович. Кеше үзенә табигатьтән бирелгән тиешленең өчтән берен генә яши. Карга, бөркет, ташбакалар фәлән-фәлән ел тереклек итә. Ә акыллы зат, табигатьнең таҗы — кеше алардан күпкә калыша. Ни өчен?

Сакманов кызның дөнья, тормыш, яшәеш турында җитди фикер йөртүен күңеленә бөркетеп куйды. Һәр шәхес үзенчә акыллы, үзенчә матур. Без ак халатлы туташларны укол кадарга, кан басымын үлчәргә генә өйрәтелгән манекеннар, гади үтәүчеләр, дип кенә кабул итәбез. Ә алар үз хезмәтләренә фәлсәфи яссылыктан килә беләләр икән.

Шулай да Сәетнең артык рәсми, авыр нәтиҗәле сөйләшүгә кереп китәсе килми иде.

— Ә мин беләм,— ди-ди Сәет, мендәреннән башын күтәрде. Аккош мамыгыдай йомшак кулын Лениза авыруның маңгаена куйды. «Игелек» хуҗасының бөтен тәненә тымызык җылылык йөгерде, рәхәт дулкын аның йөрәгенә, бавырына, бөеренә, чәнчи бармакларына барып җитте.

— Нәрсәне беләсез?

— Урыс теленең килешләрен төрләндерә беләм, компастан җылы якны таба алам. Кирәк булса... маймыл итеннән пылау пешереп бирәм.

Сакманов янында утырган затның төпсез яшел күзләрендә иркәләүле канәгатьлек чалымнары күрде. Мәгәр, авызы тагын да киңәеп китсә дә, ул көткән пырхылдап көлү булмады. Сөйләшергә яратса да, арзанлы юморны кабул итеп, мәмиләнеп, изрәп төшә торганнардан түгел икән Лениза туташ. Сәеткә җылы мөнәсәбәтен яшермәсә дә, артык ачылып, туарылып китмәскә тырышуы сизелә. Бик үк барып чыкмаса да, үзен кырыс вә тәкәббер тота; болай да җәелеп китте бүген, янәсе. Бу сәер тотышның сәбәбе Фәридәдә икәнлекне авыру соңрак белде, анысын икенче кизү кыз — Гөлчәчәк үзенең гадилеге белән ачып салды. Чая ханым, үзенә ярдәмгә бирелгән ике туташка да, Сакманов кара сызыкны исән-имин узып, яшәү билгеләре күрсәтә башлауга, артык аңлатып, ачыкламыш сүзләр кулланып тормыйча, заяга вакыт уздырмыйча: «Кызлар, ул — минеке, нәфсегезне сузмагыз»,— дип ярып сала, чирләшкә кырында үзен хуҗаларча тота. Сөйләшергә, аралашырга яраткан, энә белән дару сәдәфләреннән гарык булган кызларның киеренке халәтләре шуннан килә икән.

— Мин, кеше ни өчен шулай аз яши дигән, мәңгелек сорау турында гына сүз алып барам,— диде Лениза, ишеккә карана-карана.— Сезнең һөнәрләрегез күптер анысы. Шикләнмим...

Язгы әрсез үлән кебек тернәкләнеп килгән Сәетнең шаяртасы, үчекләшәсе килә.

— Җавапсыз, уңышсыз мәхәббәт, томаулы гыйшык кыра адәм баласын, Лениза, бик беләсең килсә.

Туташ, мул чәчләрен талкып, башын килешмәүчәнлек белдереп селкеде.

— Тәртипле, итагатьле яши белмәү. Күп ашау, чама белми эчү, тәмәке... Бер-беребезнең кадерен белмәү иртә картайта безне.

Кизүдәге кызның, дөньясын онытып, мавыгып сөйләнүен бүлмәгә Фәридәнең балкып килеп керүе бүлдерде. Лениза шып туктады. Хәтта, ялгышып тотылган кешедәй, уңайсызланып китте. Сүз — ләззәт бакчасына юл өзелде. Сакманов күпме генә тырышса да, кызый башкача үзен мондый иркен фикер алышуга тартып кертергә ирек бирмәде. Күрәсең, сизгер Фәридәдән янә бер җаваплы кисәтү алгандыр.

Икенче шәфкать туташына Сәет шулай ук рәхмәтле. Анысы тулы түгәрәк йөзле, йөгерек кара күзле, уймак хәтле генә кечкенә авызлы, кабарып торган иренле, уртача буйлы, кыскасы, татар-башкорт «җәйләвендә» туып-үскән кыз иде. Гөлчәчәк үзен табигать тарафыннан кимсетелгән, рәнҗетелгән, килбәтсез, ямьсез дип санаса да (әнә Ленизаның күзләре урман күле кебек матур, авызы колагына җиткән, маңгае Сократ бабаңныкы хәтле), ир-ат халкына ошамаслык түгел иде шәфкать туташы. Тәнен кояшта кыздырып торуның ихтыяҗы юк. Шоколад төсендәге, ходай биргән загары, кышкы әче суыкларга да, эссе мунчада юкә мунчаласына да бирешә торган түгел. Гәүдәсенә караганда кыскарак булса да, тулы аяклары читкә чыгып торган янтауларын, уемлы билен, югары, тыгыз, калку күкрәген ким-хур итмиләр. Күз төпләрендәге нәселдән килгән кара тимгелләре дә килешеп тора үзенә.

Кыскасы, авыл ипиен, бәрәңгесен ашап үскән кызның үз күрке, үз сөенече бар. Гөлчәчәк белән Сәет бөтенләй диярлек аралаша алмый калды. Әмма үзенең самими беркатлылыгы, табигый гадилеге белән кызый чирлегә күп нәрсәне үз урынына куярга, аңларга ярдәм итте. Больнистан чыгарга берничә көн калгач булды бу хәл.

— Сеңелем, мин сине бөтенләй хәтерләмим. Миңа беренче укол ясавыңмы бүген?

— Авырттырдыммы әллә?

— Юк ла! Минем арт сан хәзер шөшле белән кадасаң да, чыраен да сытмый. Күргәнем юк шикелле сине, бер дә?

— Сезнең янда инде... Күпмеләп булыр. Икенче ай сезне карыйм. Атнасына ике тапкыр дежурить итәм. Әүвәл Никишина Валя дигән хатын дежурда торды. Ул пенсиягә киткәч, миңа куштылар.

— Ни өчен сине бөтенләй хәтерләмим. Гөлчәчәк исемле икәнеңне беләм анысы. Лениза әйтте. Шул гына.

Шәфкать туташы, болай да кечкенә авызын бөрештереп, үйланып алды. Күңелендәге шөбһә-икеләнүен бастырыкка утырткач, түгәрәк кара күзләренә шаян чаткылар кунды.

— Кая ул сезгә мине хәтерләү. Әүвәл бик авыр идегез. Аннан Фәридә апа, дежурны безгә тапшырганда, «абыебыз ял итсен, хәл җыйсын» дип, йоклата торган укол биреп китә торганые. Мин яныгызда утырганда, сез, яңа туган сабый баладай, йокладыгыз да йокладыгыз. Шуңар тиз терелдегез. Фәридә апага әйтә күрмәгез, йәме.

Борынгылар хаклы булган: мәхәббәт янында мәкергә урын табыла. Мәкер өстенлек алган җирдә мәхәббәт сүнә, үлә...

Үзе өчен сөенечле ачыш ясаган кызның кәефен күтәреп җибәрәсе килде чирленең. Тәмле тел — яз кебек ямьле, яман тел — көз кебек пычрак.

— Синең турында язылган бер шигырь беләм мин,— дип, кызыктырды кызны Сәет.

Укырга ярый башлагач, Сәеткә Мисхәт Әлфиясе урыс шагыйрьләренең антологиясен алып килгән иде. Шуннан Сергей Наровчатовның бер шигыре исенә төште, Гөлчәчәк белән сөйләшеп утырганда.

А девушка сидит едва жива,
И лишь порой на срывах и откосах
Мелькает озорная татарва
В ее глазах, по-волжски раскосых.

Ул аны җыентыктан табып, укып күрсәтте. Чия төсле, тук иреннәргә үпкә чыкты. Күзләре тагын да кысыла төште.

— Бездән, миннән көлә түгелме соң? — дип сорады шәфкать туташы.

— Анысы инде шагыйрь намусында. Татар кызларының үткенлеге, чаялыгы турында яза бугай ул.

— Бәлки, шулайдыр,— ди-ди, Гөлчәчәк урыныннан күтәрелде.

— Сез инде терелеп беттегез дияргә була, Сәет Яруллович. Шрамнар да акрынлап ябылыр,— диде моңсу гына.

— Ат үләр — дагасы калыр, батыр терелер — ярасы калыр,— диләрме әле.

— Исән-сау яшәгез,— диде дә, тиз-тиз атлап, бүлмәдән чыгып та китте.

Шәфкать туташлары белән болай гына шаяртуы иде. Үзләренә игътибар бирмәгән ирне хатын-кыз гафу итми. Шәхси дошманы булып китүең дә бар. Сәеткә, аның хәлендә, шул гына җитмәгән иде!

*Дәвамы киләсе санда*

## ШИГЪРИЯТ

### ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНАГА 50 ЯШЬ



# КҮҢЕЛ АГЫМЫНЫҢ СЕРЕ

**Кеше күңелендәге тойгыларның агышын елга агышына охшатып була микән? Мөгаен, буладыр. Күңел агымының да ярсып шаулаган дәһшәтле бусагалары, җәелеп аккан тугайлары, шомлы чоңгыллары һәм чит күзләргә күренмичә генә, сабыр һәм тын гына гомерлек уйга талган яр куеннары була...**

**Аларны газиз күк йөзе генә күрә дә үзе генә аңлый. Кешегә табигать биргән талантны — күңел агымнарының барлык серләренә шаһит тирән күккә охшатасым килә. Әлбәттә, һәркемнең күңел агышы үзенчә, күге үзенчә.**

**Шигырьләр укыганда күңелгә шундый уйлар килә... Бармы соң бу шигъри тәртипкә салынган юлларда күңелнең әнә шундый көтелмәгән, сәер капризлары, серле борылышлары? Бармы аларда шатлык һәм кайгыларның бергә кушылып дулавыннан хасил булган ярсу шарламалар? Шуларның барысын да тоясы, күрәсе, үзеңнеке итеп кичерәсе килә.**

**Яңгыр җиле... Табигатьнең гаять серле халәте... Капылт кына исеп куйган бу җилдә барысы да бар: яңгыр көткән тереклекнең ымсынып кузгалуы да, өмет тә, шом да...**

**Шигъри хис тә күңелдә табигатьнең шундый бер халәте буларак туа.**

**Гомер сукмагында аллы-гөлле чәчәкләр генә балкып утырмый. Әлеге сукмакта кешене зур югалтулар, көенечләр дә сагалап тора. Ләкин барыбер яшәү — бәхет, бүтән берни белән дә тиңли алмаслык бәхет!**

**Күңеленә дөньяның яңгыр җиле килеп кагылган икән, син гамьсез генә яши алмыйсың. Яшәешнең һәр мизгеле каныңда Олы Гамь тойгысы булып сулкылдый. Ул тойгы сүзләргә күчә, шигырьгә әверелә.**

**Эльмира Шәрифуллина шигырьләренең нәкъ шулай дөньяга килгәнлеген тойдым мин. Аларда — ана хисләре, дуслык тойгылары. Балалар һәм ата-бабалар язмышы, Ил-Ватан киләчәге, җиребез киләчәге, дөнья иминлеге... һәм һәрберсенә үзенчә тирән моң сеңгән...**

**Аларда шагыйрәнең әйтергә теләгәне ахырынача әйтеп бетерелгән, яшерен берни дә калмаган кебек. Күңел талпынышларын беренче укуда ук тоясың, аңлыйсың, үз итәсең. Кичерешләр сине берьюлы бөтереп ала. Шагыйрә: «Мине шушы килеш, шушы барлыгым белән аңла, үзем килеш аңла»,— ди сыман.**

**Шигырь шулай ук ачыктан-ачык булырга тиеш микән? Күрәсең, алай да була. Югыйсә, үз халәте белән укучыны үзенә буйсындыра алыр идемени ул? Буйсындырган икән, димәк,**

шигырь бар, шигърият бар! Катлам-катлам итеп язылганмы ул, әллә якты күлдәй үтә күренмәле итепме,— мәсьәлә анда түгел. Катламнары кичерешләрендә ачыла.

Шигырьләрнең тел агышында да шундый ук эчкерсезлек, ихласлылык. Сокланулы, куанычлы шигырьме ул, әллә авыр газаптан соң бер сыкрану, бер омтылыш булып дөньяга килгән шигырьме — гади тел белән, табигый агыш белән язылган. Күтәрелеп бәрелмичә, чамасыз аһ ормыйча, татар хатын-кызларына хас сабырлык һәм тыйнаклык саклап әйтелгән.

Эльмира Шәрифуллинаның иҗатында без нәкъ хатын-кызларга гына хас тыйнак күңел, сизгер моң, серле уйчанлык, ярсу шарламалар белән очрашабыз. Хатын-кызны күңел нәфислеге өчен яратабыз лабаса! Яклауга мохтаҗ, сак күңелле булуы белән матур бит әле ул хатын-кыз! Бу — тормышта гына түгел, шигъриятттә дә шулай булырга тиештер, дип әйтәсе килә.

Әхлакый пакълеге, рухи бөтенлеге белән күңелемә хуш килә аның серләре. Сабырлыгы һәм якты моңы белән, риясызлыгы һәм эчкерсезлеге белән яраттырды алар...

Эльмираның «Янгыр җиле» исемле беренче китабы 1984 елда чыккан иде.

Аннан соң шагыйрә балаларга да, өлкәннәргә дә атап шактый китаплар чыгарырга өлгерде. Аның повестьлары, поэмалары халыкка барып иреште, яңадан-яңа җырлары яңгырады.

Өлкәнәя барган саен шагыйрә тәрбия мәсьәләләренә, халкыбызның гореф-гадәтенә, йола-кануннарына игътибар беләнрәк карый, шулар хакында уйлана.

Кыскасы, шагыйрәбез үзенең түгәрәк бәйрәменә лаеклы иҗат белән килә.

Болыныңда яңгыр җилләре тынмасын, Эльмира ханым!

ЗӨЛФӘТ.

*

# Эльмира Шәрифуллина

## КАЙДА СИНЕҢ ЙӨРӘК ТУРЫҢ?

### Күзләремнең карасында

Шәһәр белән авыл арасында,
Ике күзкәемнең карасында,
Йөгерепләр йөри балачагым —
Күңелемә уелып калачагым.

Йөгерепләр йөргән балачагым,
Ялкыннарга илтеп салачагым,
Мин яшәгән утлы гомерләрнең
Юлларында түгелеп калачагы.

Йөгерепләр йөргән балачагым,
Гомер буе озата барачагым,
Картлыгымда ишек кагачагым,
Бәлзәм булып җанга тамачагым.

Ике күзкәемнең карасында,
Шәһәр белән авыл арасында —
Күңелемнең сагыш-ярасында,
Уйларымның иске, яңасында

Йөгерепләр йөргән балачагым —
Көннәремнең агы, карасында...
...Безнең җаннар гомер буе юлда,
Шәһәр белән авыл арасында!

*1996*

## Синдә һәрбер көн яңа

Яшен булып балкыйммы,
Сагыш булып саркыйммы?
Туган ягым күгендә
Йолдыз булып калкыйммы?

Мәхәббәт эчкән җаным,
Тәнемә кучкән таңым,
Күздә нур булып кабын,
Телдә моң булып кагын.

Сиңа кирәк булганга
Бәхетле мин дөньяда.
Синдә генә, авылым,
Һәр төн, һәрбер көн яңа.

Җырла туган ягыма
Багышланган җырымны.
Сөйлә алтынга төреп
Сурәтләгән кырымны.

Яңгыр булып кайтырмын
Син сусаган көннәрдә.
Чәчәк булып шытармын
Сабый салган эзләрдә.

Синдә генә, авылым,
Һәр төн, һәрбер көн яңа.
Сиңа кирәк булганга
Бәхетле мин дөньяда!

*1996*

## Сөю таңы

Керфекләремә кагылып
Кабына сөю таңы.
Аллы-гөлле балкышларга
Бизәлгән кояш ягы.

Иртәләремнең нурланып,
Җанга сер тулган чагы.
Киртә-пәрдәләрне үтеп
Килсен хәләле-хагы.

Килсен, керсен күңелемнең
Биксез ишеген ачып.
Сөю хисем йөгереп чыксын
Яшерен җиреннән качып.

...Чәчләремнең карасына
Сибелгән картлык агы.
Бер картлыкта, бер яшьлектә
Җемелди сөю таңы.

*1995*

## Хозур дөнья

Чыга җилләр,
Таша силләр,
Кысыла билләр —
Сызланам.
Ава куыш,
Буа сулыш,
Тула күңел —
Уйланам.

Язда — тамчы,
Яшен — камчы,
Туктат,
Килсә хәлеңнән.
Тамчы — ачыш,
Камчы — качыш,—
Хозурлан
Һәр мәленнән.

Туган җирем,
Торган илем —
И газиз,
Нурлы төбәк.
Йорт-нигезне,
Пар-тигезне
Сөймәгән җаннар
Сирәк.

*1997*

## Елмайган иреннән үпсеннәр

Күтәреп күңелем пәрдәсен
Җил түгел, син кердең, сөюем:
Бу минем мәңгегә булсын дип,
Чын итеп, зур итеп сөюем.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр.

Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Юлларга түшәлсен гөлбизәк.
Тизрәк кайт, син, минем сөюем,
Калдым мин озатып, кул изәп.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Ихластан әйтелсен ярату.
Иң олы гөнаһ ул кемнеңдер
Ялганлап йөрәген канату.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Илһамы күзләргә күчсеннәр.
Мәхәббәт күтәрә, үстерә:
Парлылар сөелеп үссеннәр.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр.
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр!

*1996*

## Кайчан гына

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Шау чәчәктә иде гөлләрем.
Синең белән генә булган икән
Мәңге сагыначак көннәрем.

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Кыш ташланган иде ташуга.
Ап-ак карлар качып китте бугай
Түзә алмый язгы шау-шуга.

Әле кайчан гына яз башланган иде,
Яшь кыз идем мин дә ул чакта.
Инде менә алтын көзгә кереп,
Оныгыма сөйлим шул хакта.

*1996*

## Оныгым биргән бәхет

Балалык бирдең, табигать,
Үсмер чагым да булды.
Житү кыз идем,
Ә аннан...
Башым уй белән тулды.

Ана булдым.
Кызым туды...
Әби булдым бүгеннән!
Бар йолдызлар Кояш булып
Карый кебек күгемнән.

Кодрәтең зур, әй табигать
Шәфкать чыганагың киң.
Бер оныгым биргән бәхет —
Мең кояш назына тиң!

*1997*

## Йолдызымны калдыр

Җил кагылган саен сискәнәмен,
Ай кабынган саен үкенәм.
Кояшымны алдың,
Йолдызымны калдыр,
Миһербанлы бул, дип үтенәм.

Шәфкать-назны ахры кайберәүгә
Мыскал белән генә биргәннәр.
Гүя безнең яшәү рәвешен
Кара җепләр белән үргәннәр.

Авырткан җир гел сызлаучан була,
Нечкә күңел, никтер, тиз тула.
Болай да бит авыр безнең тормыш,
Ни шәригать илдә, ни йола.

Тыныч кына хәтта гүрләрендә
Ята алмый сыман үлгәннәр.
Ләхетемә вакытыннан алда
Гөрзи белән гүя кергәннәр...

Җил кагылган саен сискәнәмен,
Ай күренгән саен үкенәм.
Кояшымны алдың,
Йолдызымны калдыр,
Миһербанлы бул, дип, үтенәм!

*1990*

## Кайда синең йөрәк турың?

Катлам-катлам кара күз эчендә
Уралыплар аккан моңлы җырым,
Башларымны ташка салыр идем,
Шунда булса әгәр йөрәк турың.

Язмышыма күптән язылганны
Үзгәртмәкче булып никләр йөрим?
Кара күзләр теләр хатынмы мин,
Мин нишләп соң кара күзне телим?


Күмер булып көйгән елларымның
Канлы яшем юган борма юлын.
Онытkандыр, дияр шунда берсе,
Суырыплар өзәр йөрәк кылын...

Карадагынай кара күз эчендә
Яшеренеп калган якты язым,
Яшел генә яфракларын чиртеп,
Бер дәртләндер әле күңел сазын.

Кара күзләр кавыштырыр, бәлки,
Гел эндәшәм шуңа кара күзгә.
Шул күзләрнең чиксез киңлегендә
Без мәхрүм калган бәхет йөзә...

*1996*

## ДУСЛАР ЖЫРЫ



# «САГЫШЛАРЫМ АГЫЙДЕЛДӘ ЧАЙКАДЫМ...»

Кадим Аралбайның бер шигырендә шундый юллар бар. Мин моны сокланып укыдым. Бу — өр-яңа. Аның шигырьләре турында фикерләремне әйткәнче, журнал укучыларын автор белән таныштырып китим әле. Кадим Аралбай — башкорт шагыйре. Дөресен дөрес итеп әйтергә кирәк — башкортларның күренекле шагыйре. Мин аны бик күптән беләм инде: Башкортстан партия өлкә комитетында инструктор булып эшләде, мәктәптә укытучы булды, «Агыйдел» журналында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы сәркатип, Башкортстан Язучылар оешмасы рәисенең урынбасары булды, инде менә Уфадагы «Китап» нәшриятының директоры. Беркайчан да масаймады, гомер буе тыйнак һәм ихлас булды. Укучы дуслар игътибар итсен, Кадим каләмдәшебезнең «Ирлек» дигән шигырендә ихласлык турында бик тә төгәл бәяләмә бирелгән: «Ихлас күңел битлек кия белми»,— ди ул. Шуннан да төгәлрәк итеп әйтеп карасыннар шагыйрьләр. Кадим Аралбай беркайчан да буш сүз сөйләми, аның шигырьләре гел метафоралардан, ачышлардан тора. «Агыйдел» исемле гаять затлы шигырендә ул куплет саен ачыш ясый: Идел булып еллар ага; сагындым йөрәккә утлар ягарлык агышыңны; һәм, ниһаять, шигъри ачышларның иң биек ноктасы әсәрнең бетемендә:

Ишелеп-ишелеп ага
Сайлыкларда Агыйдел...
Халкым күңелендә шулай
Ак юл сал да ак иден!..

Казанда Кадим Аралбайның «Ак тирмәләр иле» дигән шигырьләр һәм поэмалар китабы дөнья күрде (1996). Аны татарчага авторның үзе кебек үк танылган шагыйребез Харрас Әюп тәрҗемә иткән, шагыйрьнең иҗатына сокланып, кыска гына, әмма үтә дә шигъри кереш сүз язган.

Татарстан белән Башкортстан арасында, дуслык килешүе нигезендә, әдәби китаплар алмашу бара. Әмма шушы изге эшне әле бер генә тәнкыйтьченең дә зурлап язып чыкканы юк. Кирәк иде. Аралбай кебек талантлы, шигырьдә үз юлын тапкан, рифмаларында да, Тукай әйтмешли, «такмак» сүзенә «шакмак» эзләп мич астына керми торган, метафораларга һәм ачышларга юмарт булган шагыйрьне, китабы чыгу белән үк, тәнкыйтьче-галимнәребез күреп алырга тиешләр иде. Ни хәл итмәк кирәк, заманалар үзгәрде, затлылык бетеп бара дирлек, капитализм дөньясындагы кебек, байлык артыннан, акча артыннан куу чоры башланды. Кайчан без табигый, дустанә яшәешебезгә күчәрбез, бер Ходай гына белә.

«Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы буларак, ут күршебез Башкортстанның талантлы шагыйре Кадим Аралбайның шигырьләр бәйләмен сөенеп һәм сокланып, укучыларыбыз карамагына тәкъдим итәм. Алар да әйбәт, затлы шигырьләр укып сөенсеннәр әле.

Гариф АХУНОВ
1997 ел, апрель.

# Кадим Аралбай

## Ак тирмә

Башкортстан — ак тирмәләр иле,
Бар Ватанга тора күренеп.
Якты моңга, наз-сагышка тулы
Ак тирмәле халкым күңеле.

Мең газаплы халкым,
Күпме ялкын
Йөрәгеңне өтеп купканда,
Ак тирмәңне,
Әманәтең итеп,
Саклагансың, калкып калкандай!

Ханнарыннан, тархан, баскаклардан
Көн иткәнсең, күпме изелеп!
Әмма җиргә сеңгән күз яшь, каннан
Шытып чыккан бер мәл игелек.

Күтәргәнсең җирдә ак тирмәңне —
Өметеңне — ялгап йөз җөйдән.
Йөрәк маең сызып яктырткансың
Юлларыңны кара төннәрдә.

Ак киездән булган өчен генә
Әйтмәгәннәр бит ак тирмә дип,
Биләү итеп башкорт ак күңелен,
Хак язмышын тапкан тирбәтеп...

Күккә ашкан мәгърур күк Уралдан
Алган башкорт чая горурлык,
Гасыр-гасыр яуга күтәрелгән
Даулап ирек, яклап хозурлык.

Уралына тамыр җәйгәнгә дә
Яшәмәгән халкым бөгелеп.
Ак тирмәне күргән хыялында
Һәм баглаган аңа өметен.

Урал-батыр кигән җиләнкәйнең
Чабуына баскан ахактай,
Җемелдәшеп ята авылларым,
Тәрәз ачып иман-хаклыкка...

Ак тирмә — ул безгә дәвернамә,
Күңелләрне нурлар ак китап;
Намусына кер кунмаган халык
Тарихына бирер хак хисап.

---

Кадим Аралбай — *башкорт шагыйре. 1941 елда туган. «Утлы кичүләр», «Батыр ярасы», «Сөюем йолдызы», «Рух язуы» һ. б. шигырь китаплары авторы. 1996 елда Казанда «Ак тирмәләр иле» исемле сайланма китабы дөнья күрде. Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

Ак тирмә — ул синең якты дөньяң,
Замандашым, синең күңелең.
Китмәсен ул
Байлык сазга батып,
Битарафлык белән күмелеп!

Учагыңда кайчак утың сүнсә,
Хафаларга калып: «Аһ!» — димә.
Кабыныр ул утың —
Күңелеңдә
Гел корулы торса ак тирмә.

Шуңадыр да
Әй җилкенә күңел
Вакыт тарлыкларын җиңәргә.
Мәңгелек сер,
Моң бишеге булган
Ак тирмәне ачып керергә...

## Таналыгым

Туган елгам, дала багы — Таналыгым,
Ерак-ерак торып калган балалыгым,
Ятимсерәп, үги кебек ятасыңчы,
Боек кына, оеп кына агасыңчы...
Тавышыңда шатлык та юк, көмеш тә юк,
Агышыңда сафлык та юк, өмет тә юк.

Пычратылган, җимерелгән ярларың да,
Сындырылган, яндырылган талларың да.
Кешеләрдәй үзгәргәнсең, картайгансың,
Үлән баскан, саекkансың, тартылгансың.

Атам киявү, анам килен булган җирдә,
Тирләр түккән, калкан булган туган җирдә,
Тәм-ямь биргән, җан да бераз тынган җирдә
Син ятимме, мин ятимме, Таналыгым,
Без кем: үги баласымы замананың?

Михнәтләрне юып бетерә алырсыңмы,
Гел җәберле, гел кадерсез калырсыңмы?..
Туган елгам, дала багы — Таналыгым,—
Балалыгым, балигълыгым, бәхиллегем...

## Җиләкле тугай

Бала чагымда иң башлап бугай
Әнкәм табышты җиләкле тугай.
Җиләкле тугай!
Җирем үстергән әзер җимешне
Җыеп алырга миндер тиешле.
Җиләкле тугай!
Ямь-тәм алдым мин шушы тугайдан,
Сут-нур чөмердем җыйган уңайга.

Җиләкле тугай!..
Җиләкләр шиңде, тугайлар бөлде,
«Әзергә — бәзер» йөрер чак үтте.
Җиләкле тугай!
Хәтергә төшә юк-юк та болай
Әнкәм табышкан җиләкле тугай.
Җиләкле тугай!
Баксаң, миңа бит бердәнбер булган
Әнкәм күңеле — җиләкле тугай.
Җиләкле тугай!..
Бизи алдыммы туган җиремне,
Нәрсә үстердем, түгеп тиремне?
Җиләкле тугай?
Язмыш — юлларым булдымы уңай,
Таптыммы үзем җиләкле тугай?
Җиләкле тугай!
Була алырмы минем җыр-догам
Балаларыма — җиләкле тугай?
Җиләкле тугай?
Җиләкле тугай!..

## Агыйдел

Ишелеп-ишелеп ага
Сайлыкларда Агыйдел...
Гомер дәрьясында шулай
Бертуктамый ак иДең...
    Кушылып ага дулкынга
    Секундлар, минут, сәгать...
    Бу тынгысыз агышта юк
    Кире кайтырдай гадәт.
Елларым шулай акканнар
Вакыт иделе булып:
Уңышлардан шатлык тукып,
Хатадан сабак алып...
    Идел булып еллар ага,
    Салып ярга пичәтен.
    Бу үзгәреш, бу яңару —
    Безгә бит ул кисәтү.
Уята якты истәлек
Иделгә койган инеш.
Син су алган шул ук басма,
Шул чыгыш, шул су кереш.
Менә син керләр чайкаган
Зур ак таш ята ярда.
Кайнар кояш,
Ярсу ташкын
Йөзенә уйган ярга.
    Сагындым йөрәккә утлар
    Ягарлык агышыңны!
    Иделем, сиңа килдем дә
    Чайкадым сагышымны...
Ишелеп-ишелеп ага
Сайлыкларда Агыйдел...
Халкым күңелендә шулай
Ак юл сал да ак иДең!..

## Моң

*Гыйльман Сәфәргалинга*

Бу чаклы ла көйне каян алдың? —
Озынлыгы булыр Уралдай:
Гүя торып Бозлы океаннан
Уятасың кебек Аралны.

Бу чаклы ла моңны каян алдың? —
Халкың тарихыдай борынгы.
Әйтерсең ил аны тыңлап барган,
Булган чакта юлы караңгы.

Каян килә бу моң? —
Дала иңләп,
Туфан суы гүя таралмыш.
«Диңгез тубыктан!» — дип кичәр батыр
Урал түбәсендә яралмыш.

Сызылып үтә җырда Зөлхиҗәнең
Тоткындагы кара көннәре,
Ерак Балтикадан килеп җиткән
Салаватның курай өннәре.

Каян килә бу моң? —
Тойгыларны
Шау моңсызлык басып барганда,
Бишек янындагы анаң кебек,
Тыны белән тартып алгандай.

Каян килә бу моң? —
Уралтаудан
Ишелеп-ишелеп ага
Моң-сагыш.

Тик табигать баласына гына
Табигатьтән бүләк бу тавыш.
Әй шул моңың!
Кабатланмас моңың
Җанкайларны ала көйрәтеп...
Җырга мөмкин әле өйрәтергә,
Моңга гына булмый өйрәтеп.

## Ирлек

Сабыр булсаң,
Томан таралыр да,
Кояш көләр,
Дөнья ямьләнер...
Батыр булсаң,
Кыюлыгың артыр,
Тотынырсың эшкә дәртләнеп...

Сабырлыклар — гомер тәҗрибәсе,
Батырлыклар — заман үрнәге.

Һәрнәрсәгә бәя биргәндә дә
Әйтәбез бит: «Вакыт күрсәтер...»

Вакыт бизмәненә баса кеше
Соңгы сулышларын алганда.
Бер табакка ята хаклыклары,
Бер табакка ята ялганнар.

Бер ягына ята алганнары,
Бер ягына ята биргәне.
Бер ягына ята чәчкәннәре,
Бер ягына ята тиргәне.

Бәгъзе берәү сөрән сала, әмма
Күз алдында эше юк була;
Капкан ризыклары күп булса да,
Җыйган энҗеләре чүп була.

Рәхәтлекләр баштан ашканда да
Дөнья малын ташыр күтәреп...
Ул адәмне ил җыелып күмми,
Килеп җыеп кына китәләр.

Ихлас күңел битлек кия белми,
Ярамсак җан әүвәл көлдерә.
Иң хак юлны Намус эзләп таба,
Язык үзе килә йөгереп...

Ирлек җирдә ятып калмагандай,
Ирләр күрке — күңел бизәге:
Дөньялыкта чәчкән игелеге
Шытып чыгар, ярып үзәген.

Ирлек гомере — ярларына сыймый
Ярсып ташкан дәрья шикелле:
Вакыт бизмәннәрен аска басар,
Гөнаһлары төшәр ишелеп...

## Көз

Тагын бер көз килде.
Кинәт килде —
Капкаларны кагып тормады.
Кызыл яфракларны йолка җилләр —
Козгын чукый гүя корбанын.

Җиремдә көз — уңыш, хисап мәле,
Кемдер — җиңә,
Кемдер — сыната.
Берәүләрне шатлык күккә чөя,
Берәүләрне хата елата.

Оя ташлап очкан кошлар шавын
Күмә яшьлек — туйлар үткәрә.

Кыңгыраулар чыңын тыңласа да,
Олыларның күзе — күкләрдә:

Чыңгыр-чыңгыр килеп,
Чәңгелдәшеп,
Кошлар сүтә җептәй көннәрне.
Әнкәйләрнең йөзе моңсулана
Ишеткәндә шушы өннәрне...

Гомеремнең алтын көзе алда —
Ут-яшелдән әле тирәгем.
Мул җимешле алтын көзен көтми,
Иҗат җимешләрен өзәмен.

Беләмәсен мине буш өметләр,
Чолгамасын кысыр хыяллар.
Күзем кызып, асыл аккошларны
Атып алмам, нәфесем тыялмый.

Капканнарым булмас гел бал да май,
Тапканнарым булмас хәзинә.
Оясына кайткан кошлар кебек,
Кайтам тынгы белмәс языма.

Алда әле минем «алтын көзем» —
«Аккош җырым» чыңы алдарак.
Илем бүген хисап сорамас та,
Ә намусны булмый алдалап...

Көзләр килә,
Аны борып булмый —
Табигатьнең төгәл кануны.
Бар бәхетем —
Таң җиледәй ачу
Офыкларның зәңгәр ябуын.

Мизгелләр шау яздан тормагандай,
Күңелемне бармам туйлатып.
Гомер яфракларын йолка-йолка,
Көз дуласын, гамем уятып...



## Чәчмә әсәрләр

### Зөлфәт Хәким

# ГӨНАҺ

Роман

## 11

Трошкин тиз арада, үзләренең каналлары буенча, рядовой Сибгатуллинның туып-үскән шәһәренә, детдомга, Казандагы эшенә һәм тормышына кагылышлы мәгълүматлар сорап запрос ясады. Сәерлекләре шактый булуга карамастан, гомумән алганда, рядовой Сибгатуллинны үз белгечлеге буенча ракеталар гаскәрендә, үз расчетында калдырырга мөмкин дип тапты. Шулай да, ул һәрвакыт күзәтү астында булырга тиеш, бәлки күңелендәге чатырларда адашып йөрмәсен өчен бераз рухи ярдәм итәргә дә кирәктер, дип уйлады Трошкин. Агент, шикаятьләр язучы яисә ярдәмче булалмый, әлбәттә, рядовой Сибгатуллин. Ул яктан уңай кеше түгел. Ләкин аның КПда хезмәт итүен искә алганда, кайчан да, ничек тә бер кирәге чыгуы ихтимал иде.

Өченче рота дежурдан кайтып ике көн узгач, бөтен нәрсәне күрүче һәм белүче оперуполномоченный Трошкин полк казармасында янә пәйда булды. Кемдер, аны күргәч, күздән югалырга тырышты — казарма түренә узып китап актарган булыпмы, бәдрәфкә барып тәмәке капкан булыпмы, кайберәүләр сабыр гына, мине чакырыр микән бүген, дип бүрек астыннан аны күзәтеп утырды.

«Кызыл почмак»та ярты сәгать эчендә өч солдат белән очрашканнан соң, Фәизне чакырдылар.

Трошкин, гадәттәгечә, ягымлы итеп, дустанә кыяфәт белән, күптән очрашырга хыялланып йөргән кеше сыман чыраена шатлык чыгарып, кул биреп күреште. Шатлануы кайвакыт ихлас күңелдән була торгандыр, чөнки аның эше бит бу, шаяртып әйткәндә, бер күрешү — үзе бер гомер. Ә җитди итеп әйткәндә, чынлап та, элегрәк чекист белән бер очрашып күрешү, кайвакыт, тулаем бер гомерне юк итә торган булган.

— Нихәл, Сибгатуллин,— диде ул, аның кулын кысканда ук кәефен, күңел халәтен үзенең учы белән тоеп.

Каушый Сибгатуллин, кулыннан ук сизелә.

— Ярыйсы,— диде Фәиз, аның каршысына утырып.

Трошкин, гадәтенә хыянәт итмичә, кесәсеннән кабы белән сигарет чыгарды, каршында утыручыга тәкъдим итте, аннары үзе берне кабып өлдерде дә, бүлмәне тиз арада төтенгә күмеп, бермәл елмаеп торды. Фәизнең «Астра» пачкасына карап куюын күреп чекист елмайды һәм

---

Дәвамы. Башы 3—5 саннарда.

«бер генә хәрәкәтең дә, күз карашың да минем игътибардан читтә калмый» диген сыман әйтеп куйды:

— Беркайда фильтрлы сигарет тапмадым бүген, шайтан алгыры. «Астра» тартырга туры килә инде. «Астра» ошаса, тарт, оялма.

Шулай итеп, әңгәмә алдыннан «разминка» һәм киеренкелекне (әңгәмәдәшенең киеренкелеген) киметү өчен вак-төяк, әһәмияткә ия булмаган кыска диалог уздырып ала иде ул.

Сөйләшү тәкәллефсез башлану сәбәпле, Фәиз үзендә киеренкелекнең кимегәнен тойды. Сигарет алу белән Трошкин зажигалкасын кабызды.

— Рәхмәт,— диде Фәиз һәм тончыгып йөткереп алды.

— Күрәм, син хәзер полкта чит-ят кеше түгел,— диде Трошкин, елмаеп.— Син хәзер «фазан». Кыерсытучы юк бугай.

Фәиз читенсенеп куйды:

— Юк, беркем дә кыерсытмый, Павлов аркасында срогымның ахырына кадәр көн күрсәтмәсәләр дип уйлаган идем... Шадринга рәхмәт инде, ул гел яклап килде. Хәзер мин үземнең призывтагылар белән бер рәттә.

Трошкин чын күңелдән сөенеп тагын кабатлады:

— Мин дә бераз синең өчен шүрләгән идем. Хәзер казармада сине күргәч, игътибар итәм: картлар арасында син үз кеше, бүрегең кыңгыр салынган — ничек кирәк шулай.— Ул кеткелдәп көлеп куйды.

— Әйе, әгәр стукачлыкта гаепләп, «фазан» булган килеш тә кыерсытсалар, бик авыр булыр иде. Мөгаен түзәлмас идем.

— Ну-у-у, син андый сүзләр сөйләмә инде,— диде Трошкин җитдиләнеп. Полкта берәрсе түзәлмау турында сүз катса, контрразведчик шундук сагая иде. Бу юлы да шулай булды.

— Үзегез уйлап карагыз, әгәр дә мине фазан дип танымаган булсалар, миннән яшьрәкләр — чижиклар, щеголлар мине кыерсытырлар иде бит, күз алдыма килсә, йөрәкләр жу итә.

Фәиз бу минутларда каршысында кем утырганын да онытып җибәрде булса кирәк. Шул кадәре ачык рәвештә, контрразведка офицеры белән рядовой солдат, ниһаять, фазан булып, картлар рәтенә керүгә сөенеп утыруларын читтән берәү тыңлап торса, гаҗәпләнми калмас иде мөгаен.

Трошкинның күптөрле алымнарының берсе иде бу. Дөрес, башкалардан нык аерылып торучы Сибгатуллинның полкта «үги бала» булмавына күпмедер дәрәҗәдә куанса да, аңа, чекист буларак, әңгәмәдәше белән араны якынайту мәслихәт иде.

— Теге детдомда бергә үскән дустыңның исеме ничек иде әле?

— Зәбир.

— Йә, нәрсә, армиядән соң эзләргә исәбең бармы һаман?

— Анымы?

— Аны.

— Эзләячәкмен... һәм табачакмын.

— Чит илгә китәсеңме аннары?

— Ник алай сорадыгыз?

— Юк, ничектер, шулай тоела. Сез очрашсагыз, чит илгә китү турында хыялланырсыз шикелле. Менә әйт әле дөресен, хыялда берәр чит илгә китәргә талпына идегез бит аның белән.

— Без... ни... юк.

Аның ялганлавы шундук йөзенә чыкты.

— Курыкма, әйт дөресен.

— Хыялланган идек. Ә сез кайдан белдегез?

— Мин белергә тиешмен.

— Ләкин армиядән соң чит илгә китү хакында минем уйлаганым да юк. Анда кем көтеп торган ди мине. Мин Зәбирне табарга тиешмен. Чит илгә качар өчен түгел. Ул үлде! Батып үлде! Сазлыкта!

— Кайчан?

— Белмим.

— Ярар. Бәлки исәндер әле, кайгырма.
Ул сәгатенә карап алды. Фәизнең тизрәк чыгып китәсе килде.
— Китәргә рөхсәт итегез,— диде Фәиз.
— Тагын бер генә сорау. Мирзин Ренат синең дустыңмы?
— Дустым дип... Учебкада бергә булдык. Якташ ул минем. Бер шәһәрдән без.
— Болай якын дуслар түгел идегез, шулай бит?
— Юк. Нигә?
— Очрашкалыйсыз бугай аның белән? Тыштагы курилкада.
— Әйе, буш вакытта йә мин аның янына керәм, йә ул. Аннары чыгып утырып тәмәке тартабыз.
— Эһем... Мирзинны кулга алдылар.
— Ни өчен?
— Яшь солдатны кыйнаган.
— Чынлап әйтәсезме?!
— Чынлап.
— Аны нишләтәләр инде хәзер?
— Хөкем итәчәкләр. Дисбатка җибәрерләр дип уйлыйм. Ә дисбат ул төрмәдән яманрак. Ишеткәнең бардыр андагы хәлләр турында?
— Ба-а-ар.
Трошкинның Фәиз белән кызыксынуының тагын бер сәбәбе бар иде: сержантлар әзерли торган учебкадан рядовой булып килүчеләр — ул һәм сигезенче полктан Мирзин. Характеристикалары әйбәт язылган. Икесе дә отличниклар. Мирзиннар полкының үз оперуполномоченные бар, ә Сибгатуллинны «өйрәнү» һәм аңлау вазифасы — Трошкинда.
— Кызганыч,— диде Фәиз.— Инде утырттылар дамыни?
— Әйе. Тикшерү бара.
— Нык кыйнаганмы?
— Нык.
— Кызганыч. Икесе дә. Бигрәк тә Ренат.
— Кызык кеше син. Ә нигә теге яшь солдат түгел?
— Соң инде... Тән җәрәхәтләре төзәлә ул. Ә менә Ренат хәзер нинди уйлар белән, нинди халәт белән дисбат срогын ерып чыгар? Дисбаттан соң мондагы срогын хезмәт итеп бетерергә тиеш бит әле ул тагын, шулаймы?
— Шулай. Ә яшь солдатның күңелендә җәрәхәтләр калмагандыр дип уйлыйсыңмы?
— Анысы да бар инде. Тик әле эчке хөкем дә бар бит. Ренат хәзер ата-анасына бу турыда ничек язар? Ул бит дисбатта икәнлеген барыбер хәбәр итәргә мәҗбүр булачак. Аннары гаебен үзе таныгач та җиңел булмас бит аңа.
— Менә шул-шул! Вөҗдан газабы кичерсә. Кичерәчәкме соң ул андый газапны?
— Җавап бирү кыйналуга, кимсетелүгә, хәтта үлемгә караганда да авыррактыр, минемчә.
— Кем алдында һәм ни өчен җавап бирәсең бит! Син, Сибгатуллин, әгәр дә үзеңне гражданкада «тапсаң», уңай шартларга эләксәң, зур кеше булачаксың.
— И-и-и, ни өчен шулай юатырга тырышасыздыр мине.
— Юк, юк, син чиста егет. Намуслы. Дөрес, андыйларга бу дөньяда яшәү кыенрак.
Мирзинның армияне сүгеп, командирлар белән тынышмыйча, гел тавыш куптарып йөрүче икәне Аерым бүлеккә мәгълүм иде, шуңа күрә аның белән Сибгатуллин арасында ниндирәк мөнәсәбәтләр икәнлеген ачыкламыйча ярамый иде.
— Мин дә гаепле түгелме соң аның дисбатка эләгүендә? — диде Фәиз.
Опер гаҗәпләнде:
— Ничек инде?

— Белмим. Ничектер... туган яктан еракта. Ул да ата-анасыннан еракта. Әллә ничек минем дә гаебем бар шикелле. Курилкада очрашып сөйләшеп утырганда бераз үгет-нәсихәт бирергә иде. Тыңламас иде инде ул, әлбәттә. Шулай да...

— Син күп гаепләрне үз өстеңә алырга җыенасың түгелме? Павлов сине кыйнаган, үзеңне гаепле саныйсың. Якташыңны төрмәгә утыртырга торалар, монысында да үзеңне гаепле санарга маташасың. Гражданкада дустың югалган, анысында да ничектер үзеңне гаепләгән шикелле син.— Ул игътибар белән Фәизгә карап куйды.— Бу дөньяда һәркем үз гаебе өчен җавап бирергә тиеш. Юк нәрсәләр белән башыңны катырасың бугай син.

Фәиз аның «гражданкада дустың югалган өчен үзеңне гаепле санысың» дигән сүзләрен ишетте, аңлады, ләкин гаҗәпләнмәде, үзенә сорау бирмәде — нәрсә белә Трошкин, кайдан белә? Әйтерсең, Трошкин инде бөтен нәрсәне, хәтта ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ да белергә тиеш иде.

— Менә шул-шул — һәркем үз гаебе өчен җавап бирергә тиеш. Мин Зәбир өчен дә җавап бирергә тиеш. Ренат өчен дә җавап бирергә тиештер мин. Чөнки аның әтисе лесхоз директоры, шул сазлыклар янындагы урман директоры. Аның әтисе УЛ УРЫННАН ерак түгел. Монда бөтен нәрсә бербөтен, аерым-аерым бернәрсә дә юк монда.

Фәиз тиргә батты, аның күзләре акайды, ул кызып-кызып сөйләде.

— Син тынычлан,— дип елмайды Трошкин.— Бер киңәш бирәм. Син дежурга да китаплар алып барасың, казармада да «фазан» булганнан бирле гел китап укып утырасың. Бәлки сиңа, китапларны читкәрәк куеп, яисә аларны сайлабрак, җиңелрәкләрен укып... Кыскасы, син иптәшләрең белән... Ну, ротадагы солдатлар белән күбрәк аралаш, кешеләр белән күбрәк сөйләш, аларның проблемалары белән дә кызыксын, сөйләш, гражданкадагы тормышлары турында, кызыклы вакыйгаларны, кызлар турында. Кешеләр арасына кереп кит син.— Ул тукталып тын алды.— Ярый, вакыт үтте, мине начальство көтәдер. Бир кулыңны! Нык бул! Яхшы егет син. Ә теге якын дустыңны, кем әле исеме?

— Зәбир.

— Ә Зәбирне син армиядән соң тап. Эзлә, тап, син аңа файдалы булачаксың, син аңа ярдәм итә алачаксың дип уйлыйм, тап син аны, тап, теләсә нинди сазлыклардан эзләп тап. Хәзергә сау булып тор!

— Сау булыгыз! — диде Фәиз, таң калып.

Белә Трошкин, белә. Табарга куша. Кемне, нәрсәне? Кемне булсын инде! Билгеле бит! Белә ул, белә. Трошкин әйтмәсә дә, барыр идем сазлыкка!

Армиядән соң барачакмын. Табачакмын. Кайдан белде икән соң ул? Әллә гражданкадан хәбәр бирделәр микән? Милициядән. Һәм минем хезмәт итеп бетергәнемне көтеп яталардыр. Трошкинга хәбәр биргәннәрдер — менә шундый-шундый кеше бар сезнең дивизиядә, зинһар, күз-колак булыгыз. Шундый-шундый җинаять эшләп киткән кеше ул армиягә. Армиядән соң төрмәгә утыртып куйсалар? Рәхәт булмас! Югыйсә үзем төрмәне теләп йөргән идем. Ә-ә-ә, ул бит армиягә кадәр генә. Армиягә эләгеп, үзеңә-үзең буйсынмауның ни икәнен аңлагач, төрмәгә бигүк ашкынып тормый йөрәк. Ничектер башкачарак юарга кирәк гаебемне Зәбир каршында. Мин төрмәдә утырганнан ул терелмәячәк. Әгәр милициягә сөйләп биргәч, аны сазлыктан табып чыгарсалар... Алай яхшырак булмасмы икән? Бәлки инде аны сазлыктан чыгарганнардыр, күмеп куйганнардыр. Туктале, аның сазлыкта икәнен кайдан белергә тиешләр? Ә нишләп соң Трошкин аны эзләп табарга куша? Бәрәч икән, үзем әйттем ләбаса югалды дип. Ә нишләп ул теләсә нинди сазлыклардан йолкып чыгар диде? Туктале, нишләп соң мин! Үзем мыгырдап утырдым түгелме сазлыклар турында? Әйе, әйе, тиле мин, тиле! Үзем серне ачып бирдем түгелме? Ә ул берәр нәрсә аңлады микән соң? Ул минем белән бик әйбәтләп, дусларча сөйләште.

Хәер, һәрвакыт һәркем белән шулай ягымлы сөйләшә бугай. Аны тизрәк очратырга. Киләсе дежурдан соң казармага килсә, янына үзем барачакмын. Алай да булмый. Шикләнәчәкләр, нишләп әле опер янына үзе барып сөйләшә диярләр.

Тагын нәрсәләр турында сөйләштек әле без? Күп гаепләрне үз өстенә аласың, диде ул миңа. Аның бу сүзләрендә шикләнерлек нәрсә юк шикелле. Тагын? Ә, китапны күп укуымны сизгән. Китаплардан ял итеп, иптәшләрем белән аралашырга тәкъдим итте. Монысында да куркырлык нәрсә күрмим.

Полкны кичке ашка барырга тезделәр. Фәиз бармады, казарма почмагында уйга батып утырып калды. Картайган солдатлар үз теләкләре белән генә йөриләр иде ашарга. Аларның тумбочкаларында һәрвакыт ипи-тоз өзелми. Ашханәдәге черек кәбестә белән ашказанын бозганчы ипи-тоз яхшырак. Ләкин һәрвакыт ашханәгә йөргән солдат, «ичмаса бүген яхшы ризык булмасмы», дигән өмет белән бара.

Аңа кат-кат дәшеп тормадылар, аның шулай ялгыз калып үзе генә уйга батып утыруына иптәшләре инде күптән күнеккән иде.

«Трошкин яхшы кеше. Ләкин күренеп тора, бик хәйләкәр, минем турыда әллә нәрсәләр белә. Ренат белән якташлар икәнне дә белешкән. Ренат харап булды. Гел кулын озынайтырга тора иде шул үзе дә, бик холыксыз иде. Учебкада да күпме кешене кыйнаган иде инде ул. Андый вакытларда Фәиз аны каты күралмый иде. Шулай да, аның тикшерү астында утыруын ишеткәч, кызганыч була башлады. Ике ел буена дисбатта ничекләр түзмәк кирәк! Ике ел буена башкайларда нинди уйлар кайнамас, нинди генә газаплар кичерелмәс».

Үзе шундый булгач, башкалар да һәр кылган эшләрен яңадан кичереп, уйлап, үзендә гаеп сизеп, кайгырып йөриләрдер шикелле тоелды.

Трошкин, Трошкин. Әгәр дә ТЕГЕ ВАКЫЙГА турында берәр нәрсә белсә, аның белән бәлки шул хакта ачыктан-ачык сөйләшеп карарагадыр. Болай билгесезлек тә бик авыр бит. Әле алда ярты елдан артык вакыт бар.

Әмма шушы сөйләшүдән соң Трошкин аны бүтән бер тапкыр да чакырмады. Опер казармага еш килеп йөрде, тик Фәиз белән кызыксынмады. Тора-бара Фәизнең дә аның белән ачыктан-ачык сөйләшү теләге юкка чыкты.

## 12

Армия үзенең ыгы-зыгылы, шау-шулы, атулы-шартлаулы тормышы белән яшәвен дәвам итте. Шулкадәр ир-егетләр тупланган җирдә әллә нинди вакыйгалар була — кыйнаулар да, сугышулар да, дезертирлар да, самоволкага чыгып әллә нинди җинаятьләр кылу да. Бу кадәр яшь кеше җыелган җирдә ничек бернинди ЧПсыз барсын икән тормыш? Әле теге дивизиядә, әле монысында, әле теге полкта, әле монысында трибунал хөкемен игълан итеп тордылар, теге подразделениедән берәү качкан диделәр, имештер, хезмәт авырлыгына түзмәгән, күрше полктан берәү самоволкага чыгып бурят кызын көчләгән...

Вакыйгаларга бай хәрби гарнизоннар.

Шул ук вакытта чиратлашып көн саен, сәгать саен, минут саен приборлардан күзләрен алмыйча җир астында дежур торалар — зур сугышка әзерлек кирәк. Бәлки җиңеп тә булыр дошманны, чөнки ракеталар бик көчле, әмма ләкин монда үзебезнең кешеләр арасында дошманлыкны берәр кайчан җиңү мөмкин микән?!

Ничек кенә булмасын, һәрбер вакыйга, вакыт агышында хәтердән юыла, искә төшкән суратта дә, әллә булган, әллә гел булмаган сыман гына, әллә ни зур тәэсир калдырмыйча күңелдә калкып куя. Ясисә инде бүтән бөтенләй искә төшми. Дөнья бара, кая барадыр, ләкин тормыш дәвам итә. Яңа вакыйгаларга урын кирәк — тормышта да, хәтердә дә.

Ә менә бер вакыйга Фәизнең хәтерендә нык уелып калыр. Мәңгегә. Алай гына да түгел, киләчәк тормышына да зур йогынты ясар — дөньяга карашына тәэсир итми калмас.

Беренче ротада Стеклов исемле бер солдат бар иде, рядовой. Уртачадан озынрак буйлы, таза, тыгыз гәүдәле. Ул Фәиздән бер призывка яшьрәк, ягъни әле чижик кына иде. Башка рота солдаты булса да, Стекловның берничә тапкыр Фәизгә сүгенеп, «Стукач!» — дип киткәне булды. Яшь булуына карамастан, ул инде үзенең ротасында сугышып та дан казанырга өлгерде. Картлардан курка, әмма ләкин үз призывдашларын үз көенә биетергә маташа иде, ахрысы.

Бер тапкыр кышкы төндә Фәиз патрульдән кайтты, ә дневальный булып Стеклов басып тора иде. Полк йоклый иде инде, шуңа да карамастан Стеклов кычкырып җибәрде:

— Син сука, кайда йөрдең?!

Ул белә иде Фәизнең патрульдә икәнен, ләкин чандыр гына бу «татарин»га ниндидер яман нәфрәте бар иде аның. Фәиз, «фазан» буларак, аны үз урынына утыртырга ниятләде:

— Син, салага, кемгә кычкырасың?!

— Нәрсә-ә-ә, стукач! Синең аркада Павловны чак кына төрмәгә утыртмадылар. Сине, суканы, көн саен кыйнап торырга кирәк!

Фәиз аның нәфрәтеннән, җүләрләнгән дәрәҗәдә шашып, ярсып кычкыруыннан югалып калды, ләкин бирешергә ярамый иде. Ул Стекловка таба атлады:

— Мин сине хәзер...— диде ул тешләрен кысып, ләкин Стеклов бер тапкыр сукса, Фәизнең сугышыр хәле булмаячагы ап-ачык иде.

Стеклов билендә асылынып торган штык-пычагын чыгарды, чөнки барыбер үзенең «чижик» булуын бөтенләй үк онытмаган иде.

Ул пычагын алга сузып казармага керә торган ишек белән туалет арасында йөгереп йөри башлады:

— Кил, кил, чмо, татарин е... Хәзер эчәгеләреңне чыгарам!

Тиледер бу, дип уйлады Фәиз. Аның пычак чыгаруы бер караганда әйбәт, чөнки Фәизгә аңа таба якын килмәскә сәбәп булды. Әгәр сугыша башласалар, Стеклов аны ботарлап ташлар иде. Каяндыр икенче дневальный килеп чыкты һәм, дәшмичә генә, бермәл аларга карап торды. Шулвакытны, Фәизне коткарып, казарма караңгылыгыннан сүгенеп кычкырган тавышлар ишетелде:

— Кем анда тавыш куптара?!

— Сукалар, йокларга бирмисез?

— Стеклов, синме дневальный?! Тавышланма, торам да бәреп үтерәм, падла!

Фәиз йодрыгын төйнәп янаган булды:

— Мин сине болай калдырмыйм, тинтәк!

Стеклов штык-пычагын кынына тыгып куйды:

— Бар, бар, козел! Куркытма. Рәхмәт әйт тешләреңне коймаганга. Стукач е...!

Фәиз бик озак йокыга китәлмичә ятты. Каты удар иде бу аңа. Ә башкалар каршында шулай бәйләнә башласа, хурлыкка калачакмын бит. Шадрин яклар, ләкин ул һаман янәшә йөрмәс бит. Фәиз беренче рота белән дежурствода булганда Стеклов аңа бер тапкыр бәйләнгән иде инде. Аннары курилкада чәйнәшкәне бар. Казармада шул маңка тотып кыйнаса, Фәизне бит якламаулары да ихтимал.

Курыкты, нык курыкты Фәиз. Элегрәк кыйнауларыннан, җәзаланулардан курыкмый иде. Хәзер исә курка, чөнки үзен мыскыл иткәндә күңелендә протест уяна башлавын тоя.

Мыскыл итүләреннән, мескен хәлдә калудан курка башлады ул. Физик авырту пүчтәк, кыйналу да берни түгел. Ә менә шул мыскыл ителүнең, кыйналуның мораль ягы, мескенлеккә китерүе харап!

Икенче көнне иртәнге тикшерүләрдән соң Фәиз кич белән килеп чыккан матавык турында Шадрингa сөйләргә булды.

— Карале, Саша, кичә кич белән, мин патрульдән кайткач, дежур торган яктан тавышлар ишетмәдеңме?

— Юк. Нинди тавышлар?

— Димәк, ишетмәгәнсең.

— Нинди тавышлар булырга тиеш иде?

Фәиз сөйләп бирде.

Шадрин үзенең расчетындагы кешене һәрвакыт якларга әзер, бигрәк тә Фәизне. Павлов белән булган вакыйганы полкта хәтерлиләр, ә инде Фәизне бер кагарга тотынсалар, туктатып та, яклап та кала алмассың.

Шадрин кечкенә командир булса да, начальникларга хас кайгыртучанлык белән кашларын җыерды.

— Ул хайванны акылга утыртырга кирәк!

— Ничек итеп?

— Җаен китереп маңгаена берне тартырга кирәк аның! Бүтән беркайчан да үзеннән өлкәнрәкләргә сикермәслек итеп. Минем игътибар иткәнем бар: ул бит сиңа берничә тапкыр дорфа итеп эндәште инде.

— Булды шул.

— Син андый вакытта куркып калма. Сук та җибәр! Синең мораль яктан өстенлек бар — син фазан. Син суксаң, башка картлар да килеп өстәрләр дип уйлаячак. Ул синең сукмасыңны белгәнгә шулай әшәкеләнә.

Дөрес әйтә Шадрин: «карт» солдат, физик көче булмаган сурәттә дә, әллә нинди алагаем гәүдәле, әзмәвердәй яшьләргә сугып җибәрә ала. Дедовщинаның иң рәнҗеткән мәле шулдыр инде. Югыйсә, бер суксаң, ул «дед» бүтән тора да алмаячак, ләкин ул — «карт», аңа каршы чыксаң, полкның бөтен «картлары» өерелеп, әллә нинди таза булсаң да егып, кыйнап, барыбер буйсындырачаклар.

Ә бит Фәиз суккач ни белән бетәсе билгесез. Фәизне полкта картларның барысы да якларммы соң? Ә бәлки Шадрин якласа да, җиңеп булмас Стекловны. Бердәнбер чара — ничек тә Стеклов каршында үзеңнең җиңүче икәнеңне күрсәтергә, һич югында аның җиңмәгәнен аңлатырга кирәк. Барыбер Фәизне яклаучылар бар.

Һич югы ул үзе генә, ялгыз түгел икәнне исбатлау кирәк иде.

— Тик торганда башка рота солдатына барып бәйләнә алмыйм инде,— диде Шадрин, бер күзен чекрәйтеп. Улниндидер план кора иде.— Болай итәрбез. Мин, сержант буларак, (карт буларак түгел), үзебезнең биләмәдә бераз тәртип урнаштырырга аны чакырырмын. Мин шунда карап утырырмын. Ә син киләсең дә, аңа сугып җибәрәсең. Син җебемә. Шул бер сугудан күп нәрсә тора. Сиңа каршы суга башласа, мин сикереп торып якларммын. Мин торгач, үзебезнең егетләр безне якламый калмаслар. Болай әйтәм инде, алай-болай икебезнең көчебез җитмәсә дим. Җитәргә тиеш.

Шул ук көнне, обедтан соң, чижиклар һәм щеголлар төрле эш белән мәшгуль булып, картлар телевизор карап утырган сәгатьтә Шадрин үз биләмәсенә Стекловны чакырды:

— Стеклов, мондагы урындыкларны рәтләп тезеп куй әле. Теге анымоны уйламыйча сержант кушканны үти башлады. Чөнки яшьләрне башка рота картлары да эшләтә иде.

Шадрин почмактагы урындыкка барып утырды да, Фәизнең килгәнен көтә башлады. Фәиз телевизор караучылар арасыннан чыгып як-ягына каранды, полк буенча дежур торучы офицер ягына күз ташлады (ул канцеляриедә утыра иде, ахрысы, күренмәде) да тиз-тиз атлап, урындыклар тезеп йөрүче Стекловка таба юнәлде. Стеклов аны-моны уйламыйча урындыклар белән мәшгуль булды, Шадрин әзерләнеп торды, Фәизнең күңелендә көрәш башланды. Кирәк түгел! Кирәк! Шушы капма-каршылыкның уртасында йөрәк ярсып типте. Алагаем гәүдәле кешегә сугу

түгел, гомумән, кешегә соңгы тапкыр кайчан сукканын хәтерләми дә инде ул. Кайчандыр детдомда кем беләндер бәреште бугай. Анысында да янында Зәбир булганга гына суккандыр.

Дөрес, Стекловка нәфрәте зур иде аның, ләкин сугасы да килми бит. Ләкин беренче адым ясалды инде. Ул Стекловка таба якынлашты. Теге аңа борылып карады да эшен дәвам итте, чөнки Фәизнең килеп сугасына ул мәңге ышанмас иде.

Ниндидер көч Фәизне үзе алып барды. Стеклов яны белән торган мәл иде.

Шулай кирәк, шулай кирәк, дип уйлады ул аңа якынлашканда. Һәм ничек алай килеп чыккандыр — бар көченә кизәнеп Стекловның яңагына китереп сукты. Стеклов караватка егылды, дөресрәге утырды һәм яңагын тотып күзләрен акайтты:

— Син нәрсә?!

Бу күренешне тамаша кылып утыручы Шадрин өстәп җибәрде:

— Стеклов, әгәр алга таба да үзеңне шулай дорфа тотсаң, миннән дә эләгәчәк! Тагын бер тапкыр булса да Сибгатуллинга кырын карасаң, үтерәм! Син аның фазан икәнен белмисең мәллә?! Телевизор караучыларның кайберләре борылып карады. Ул яктан берничә тавыш ишетелде:

— Шадрин, син ул Стекловка минем исемнән дә берне кундыр әле. Нахал ул!

— Стеклов, тагын синең аркада тавыш чыгамы анда?!

— Ул салаганы катырак эшләтергә кирәк! Сансыз малай ул! Үзе чижик кына әле югыйсә!

Стеклов кызарып чыккан яңагын кулы белән уып, аптырап басып калды: борылып китәргәме аңа, әллә бирәдә калыргамы?

Шадрин тешләрен шыгырдатып, сытып чыгарды:

— Бар, күземнән югал, чижик е...! Күземә сирәгрәк чалын, сука!

— Үзеңне шулай дорфа тотсаң, полкта якты көн булмаячак сиңа! — дип өстәде Фәиз, әле һаман дулкынланудан еш-еш сулап.

Стеклов аңлады: Фәиз үзе генә түгел икән. Ул фазаннар рәтендә, ул да «карт» икән, аңлашылды. Шаярырга ярамый — карт солдатка кул күтәргән өчен каты кыйныйлар монда. Ул, торып, артына да карамыйча үзенең биләмәсенә йөгерде.

Фәиз әле тынычланып җитмәсә дә, ниһаять Стеклов белән «алыш-биреш» ясый алуына канәгать иде.

Шулай да көне буе, хәтта отбойдан соң төнлә дә уйланды: ничек кулы күтәрелде аның?! Җавабы гап-гади булды: чөнки үзен сакларга-якларга тиеш ул. Әле тагын бер ел хезмәт итәсе бар ләбаса. Әгәр дә бүген сукмаган булса, Стеклов тагын килеп бәйләнми калмас иде. Аңа бирешсәң, сытып, изеп ташлаулары бар, бөтенләй җебек икәнемне аңларлар да. Павловны да искә төшерерләр. Дөрес эшләдем.

Икенче яктан уйлап карасаң, бигрәк вәхши мантыйк. Үзеңне кеше итеп санасыннар өчен син сугарга тиешсең. Гаҗәп — ничек кул күтәрелде икән?! Сукканы өчен никтер бик кайгырмады ул. Чөнки инде болай да күп кичерде җәбер-золымны, күп кыерсытылды түгелме инде?

Берничә көн үткәч, Фәиз быткомнатада Стеклов белән очрашты. Стеклов ниндидер чүпрәк үткли иде, берәр дедныкыдыр инде. Аны күргәч, Стеклов бераз шүрләде, Фәиз үч алуын дәвам итәр дип курыкты, ахрысы. Ни дисәң дә, Фәиз өлкәнрәк призывныкы. Теге көнне сугып җибәргән икән, димәк, мускул көченә генә түгел, үзенең призывы якласына да ышана ул. Шул сәбәпле, Стеклов, аклану рәвешендә, тизрәк үзенең үпкәсен белдерергә ашыкты.

— Син миңа ни өчен суктың? — диде ул иреннәрен бераз турсайтып. — Теге вакытны бәйләнгәнем өченме? Син бит үзең гаепле идең.

Аның шыңшуыннан Фәиз шуны аңлады: Стеклов җиңелде, үз урынына утырды. Һәм коры гына әйтеп куйды:

— Син, маңка, үз урыныңны бел, картларга сикеренмә!

Шуның белән аларның матавыгы төгәлләнде.

Әмма полкны гына түгел, бөтен дивизияне, армияне тетрәндергән бер коточкыч вакыйга әлеге дә баягы ике солдатның бәрелешенә башкачарак карарга мәҗбүр итте. Һәрхәлдә, Стеклов белән килеп чыккан низагка еллар узгач Фәиз бөтенләй башка күзлектән карар һәм вакыйганы һаман хәтерендә саклар. Бәлки ул аны онытмас. Әмма бу хакта әлегә ул белми иде.

Стекловлар ротасында Зосимов фамилияле бер юаш кына кече сержант бар иде; призывы буенча ул Стекловтан яшьрәк һәм әле май аенда гына полкка учебкадан килгән иде.

Көннәрдән беркөнне дежурдан, беренче рота белән бергә, полкка коточкыч хәбәр кайтты: ракета установкасын саклый торган расчет командиры Зосимовны бик каты кыйнаганнар. Имеш, үлем хәлендә госпитальдә ята.

Кем кыйнаган?

Каравылда Зосимов белән Стеклов булган. Зосимов командир, Стеклов аңа буйсына. «Дежур вакытында Стеклов кыйнаган», дияр идең, аларны алыштырырга башка отделение килгәч, Зосимов доттан бер ящик патрон күтәреп чыккан, каравылны тиешенчә тапшырган. Стеклов кыйнаган булса, шундук беленер иде.

Димәк, дежурлыкны тапшырганнан соң җыела торган урында кемдер кыйнаган. Ыгы-зыгыда күрми калганнар.

Госпитальдә тикшергәч, врачлар әйтәләр: эчендәге бөтен органнары каты кыйналудан өзгәләнеп беткән. Эчендә бик күп кан җыелган. Коткару мөмкин түгел, үләчәк.

Зосимов әле аңында була. Аңардан сорыйлар:

— Кем кыйнады?

Зосимов дәшми.

— Кем кыйнады? Әйт. Гаепле кеше җәзасын алырга тиеш. Сине бик каты кыйнаганнар.

Зосимов дәшми. Аптырагач аңа әйтәләр:

— Син барыбер ике-өч сәгатьтән үләчәксең. Әйт, кем кыйнады? Тикшерү өчен кирәк, аңлыйсыңмы? Сине инде беркем дә стукач димәячәк. Сине үтерүчене хөкем итәр өчен кирәк, әйт. Зосимов әйтми һәм үлә.

Дежурлыкны тапшырганда ящик күтәреп чыгуын күрүчеләр булгач һәм каравылда ул үзе отделение командиры булганлыктан, Стекловка башта шик төшми. Стеклов бер призывка картрак булса да, алай-болай дежур вакытында алар арасында сугыш чыга калса, кул астында гына кнопкалар һәм микрофон бар. Бу кадәре кыйналган сурәттә ул дәшми калмас иде, мөгаен. Шулай уйладылар.

Ракета установкаларыннан бөтен расчетлар уртак базага җыелгач кыйнаганнардыр дигән фараз иң дөрес кебек иде. Имеш, ул вакытта ыгы-зыгы була, солдатлар күп, кем — кемне күреп игътибар итеп бетерсен.

Шулай итеп, Зосимов, үзенең каты кыйналуы белән барысын да таң калдырып, көтмәгәндә үлде дә китте. Юаш, тыйнак, күп сөйләшми торган егет булганлыктан, аның үз ротасында бер генә дошманы да юк иде. Ә менә үлеренә берничә сәгать калгач, әле аңында булып та, үзен кыйнап үтерүченең исемен әйтмәве, бәлки, аның үлеменә караганда да ныграк шаккатыргандыр.

Үзен үтерүчене сатмавы — стукач булырга теләмәүдәнме? Бәлки исән калырга өметләнгәндер? Әллә ул кабахәтнең исемен телгә аласы килмәгәнме? Әллә исемен телгә алырга да курыкканмы?

Ә үтерүче шул ук көнне табылды: Стеклов!

Дежурлыкта ул дүрт тәүлек буена үзеннән яшьрәк сержантны мыскыл итеп, кыйнап, көлеп, изеп яткан. Садист Стеклов кешегә авыр сүз дә әйтми торган Зосимовны әллә нинди, болай гына башка килми торган ысуллар белән, кансыз рәвештә, коточкыч вәхшилек белән җәзалаган.

Яңа сменага дежурлыкны тапшырганда әле, күрәсең, Зосимовның аякта басып торырга, хәтта ящик күтәрергә хәле булган. Әгәр дә ул,

дежур торган Стекловның кыйнавы хакында хәбәр биргән булса, бәлки әле исән калыр иде, коткарырлар иде. Юк, түзгән, дүрт тәүлек бу кансыз садистның кыйнауларына, мыскыллауларына түзгән.

Хәрби трибунал Стекловны озак хөкем итте. Офицерләр шәһәрчегенең Культура сараенда барган суд бер атнага сузылды. Прокурор атарга хөкем итүне таләп итте.

Ниһаять, хөкем карарын игълан итү көне җитте. Тугызынчы полкны приговорны тыңларга алып бардылар.

Фәиз дүртенче рәттә утырды, шуңа күрә хөкемдарларны да, җинаятьчене дә, прокурорларны һәм яклаучыларны да — һәммәсен аермачык күрергә насыйп булды аңа.

«Унбиш елга ирегеннән мәхрүм итәргә».

Бу мизгелдә Фәиз Стекловтан күзен алмады. Унбиш ел дигәч, Стеклов, бер урында таптанып, кыймылдап куйды, күгәргән иреннәре белән нәрсәдер пышылдады — әллә белгән догаларын укыды, әллә атарга хөкем итмәгәннәренә куанып мыгырданды. Аның кыяфәтеннән курку китмәсә дә, канәгатьләнү чагылды.

Стекловны конвой белән алып чыкканда залда кабер тынлыгы урнашты. Гүя, һәммәсе аның йөрәк тибешен, бәгырь сулкылдавын ишетергә теләде. Фәиз аның чыраен аермачык күрде. Күзләрендә җанварларча курку, битендә аксыллык, приговорны ишеткәннән соң йөгергән аз гына кызыллык аны мәет төсеннән чак кына арындырып тора иде.

Фәизнең игътибарын бер мизгел аеруча җәлеп итте. Зал буйлап атлаганда Стеклов яман итеп сүгенеп барды. Хәтта богауланган кулларын йодрыклап тарткалап карады шикелле. Аның сүгенүе ишетелер-ишетелмәс булса да, ишетмәгән сурәттә дә, нәрсәнедер әшәке итеп сүгеп барды.

Аның шәмәхә иреннәре бер үк сүгенү сүзләрен кат-кат кабатлады. Дүртенче рәт яныннан үткәндә Фәиз аның ачы итеп сүгенүен үз адресына кабул иткәндәй булды.

Фәизнең йөрәге жу итеп китте. Стеклов аның ягына борылып карамаса да, «мине каргый» дип уйлап куйды Фәиз.

Судтан соң, казармага кайткач та, Стекловның конвой озатуында баруы, яман итеп сүгенүе яңгырап, күз алдыннан китми торды.

Мине сүгеп барды бугай. Ә нишләп әле мине каргарга тиеш ул? Ник үземә кабул итәм соң мин аның сүгенүен? Ник инде кулга алынган, хөкем ителгән, төрмәгә озатылган кеше һаман куркыта әле мине? Сүгенсә ни. Миңа атап сүгенсә дә ни булган?

Барыбер куркыныч. Сорау бар. Җавап юк.

Еллар үткәч бу сорауларга җавап табылачак. Фәиз аларга үзе җавап бирәчәк.

Әлегә ул нindидер курку хисе белән кат-кат Стекловны күз алдына китерде. Хәтта никтер үзен аның урынына куеп карады.

Бәлки Стеклов, үлем җәзасы бирерләр, дип көтеп ятканнан соң, унбиш ел алып, котылуына куанып сүгенгәндер? Аның сүгенүендә нindидер тантана да юк түгел иде бит. Шатлыгы бәлки шул рәвешчә тышка чыккандыр? Күңел күтәренкелеге агрессив формада да чыгарга мөмкин. Ләкин ни сәбәптән сүгенсә дә, куркыныч күренеш иде бу. Кешене җәзалап үтергән җинаятьченең, хөкем ителгәннән соң да, кемнедер әшәке итеп сүгеп баруын күрү куркыныч, бик куркыныч.

Үтерүче әлеге сүгенү-каргышларын сиңа багышласа, бигрәк тә коточкыч икән!

## 13

Әлеге вакыйга бөтен армияне тетрәндерде. Мәскәүдән тикшерүче комиссияләр килеп тугызынчы полкның һәрбер офицеры белән әңгәмә уздырды. Беренче полкта өч офицерның званиесен түбә-

нәйттеләр. Мондый очракларда полкның замполитына да каты эләгә иде, ләкин ни гаҗәп: Степаненко майор килеш калды.

Полкта көн саен политзаниятиеләр, әңгәмәләр уздыру башланды.

Солдатлар арасында да әлеге дә баягы вакыйга хакында гәп куерту бик озак дәвам итте. Әлбәттә, күбесе Стекловны «канэчкеч садист» дип ничек кирәк шулай сүктеләр. Ләкин аны акларга маташучылар да булмады түгел. Имеш, дедовщина элек-электән килгән. Яшь чакта солдатларга эләгә, кыйнамыйча да булмый кайвакыт. Стеклов катырак кыйнаган да, теге үлеп киткән. Тирәнрәк уйлап карасаң, дедовщина гаепле. Ләкин ул системаны казарма оешмасы үзеннән-үзе тудырган ләбаса. Кемнеңдер кемнедер кыйнап үтерүе ихтимал дип, казармада дедовщинадан беркем дә баш тартырга җыенмады.

Фәиз дә шул вакыйга тәэсиреннән озак исәңгерәп йөрде. Каты тәэсир итте аңа бу вәхши вакыйга. Инде расчеттагы башка иптәшләре белән гәпләшеп туйганнан соң, бу хакта Шадрин белән дә сөйләшәсе килде.

Дежур вакытында микрофоннан командирга бөтен докладларны тапшыргач, сөйләшергә вакыт та, теләк тә бар иде.

Сүзне Фәиз үзе башлады:

— Саша, ничектер һаман ышанып җитеп булмый, Стеклов ни өчен шулкадәре каты кыйнаган икән аны? Сәбәбе бардыр бит?

Шадрин, креслода киерелеп, тәмәке тартып утырган җиреннән хәтта кымшанып куйды, чөнки Фәиз инде аны әлеге вакыйга турында сораштырып аптыратып бетергән иде. Әмма андый вакыйга, чыннан да, сирәк була, ул турыда сүз чыкса, барыбер сөйләшмичә булдыралмыйсың, телисеңме-юкмы, әңгәмә үзеннән-үзе алып кереп китә.

— Нинди сәбәп?! Берәр кечкенә генә сәбәп булгандыр да инде. Стеклов бит бер ел буе яшь солдат булып йөргән кеше, бер ел эчендә аны да кыйнаганнар, мыскыл иткәннәрдер. Шул ачу җыелып килгән дә инде. Йә теге мәрхүм Зосимов каршы әйткәндер. Үзең беләсең бит инде, аз гына каршы әйтте исә, фазан чижикны гафу итми. Менә сине Павлов ни өчен кыйнады соң? Сәбәп юк та шикелле.

— Мин дә каршы әйттем бит,— диде Фәиз кинәт уйга калып.

— Менә шулай килеп чыга инде ул.

— Мин башка нәрсәгә игътибар иткән идем. Ул чыкканда сүгенеп, кемнедер ачуланып, каргап чыгып барды.

— Әлбәттә инде, үлгән Зосимовны каргамагандыр. Судьяларны каргагандыр. Йә прокурорны. Прокурор бит баштан ахыргача атарга хөкем итүләрен таләп итеп утырды.

— Мин, ниндер, Стекловны нык кызганам.

— Нәрсә-ә-ә?!

— Хәтта теге вакытта сукканыма үкенәм хәзер.

— Син әллә нинди кеше булып чыктың. Мин үзем дедовщинаны хуплыйм, чөнки тәртип өчен кирәк. Шулай калыплашкан система бит инде ул. Әмма ләкин һәр нәрсәдә һәрвакыт чама дигән нәрсә булырга тиеш. Мин дә сугам кайвакыт яшьләргә. Ну үтергәнче кыйнарга ярамый бит инде. Эчтәге органнары өзелгәнче кыйнамыйлар бит инде кешене. Менә син күз алдыңа китер, Зосимовның әти-әниләренә, туганнарына бу хәбәрне җиткергәч, алар нишләр? Акылдан язарлык бит.

— Кызык кеше син, Саша. Үзең дедовщинаны да яклыйсың, үзең... Ә бит ничек чамаларга кыйнау дәрәҗәсен? Кайда соң аның чиге? Ни хәтле сугарга ярый, ни хәтле ярамый? Кемгәдер бәлки бер сугу да җитәдер?

— Ай, бежек кеше син. Гел шулай казынып интектерәсең. Үзгәртеп кара бу армиядәге тәртипләрне! Без бит синең белән ике елга гына килеп китәбез монда. Шул ике ел дәвамында яраклашып, әлеге тәртипләр белән яшәргә кала.

— Ә менә Стекловның ата-аналарына хәбәр итүләрен күз алдыңа китер. Аларга бу хәбәрне ишетү Зосимовларныкына караганда җиңелрәк булырмы?

— Сүз юк, тегеләргә дә авыр, боларына да.

— Миңа менә бу вакыйгада үземнең да гаебем бар шикелле тоела.

— Син котырттыңмы әллә? — диде Шадрин көлемсерәп. Ул инде Фәизнең үз өстенә күп нәрсәне алырга омтылуына күнеккән иде.

— Мин армиядә башкачарак булыр дигән идем. Павловны да разжаловать итүләре юкка булды. Минем эчеп-косып килгәнемне теге өлкән лейтенант әйткән булса, минем аркада, бәлки, Павловны разжаловать итмәсләр иде.

— Карале, син армиядән соң монастырьга гына кит.

— Мин татар бит.

— Ну-у-у, сезнең дә андый гыйбадәтханәләр бардыр бит?

— Син көлмә әле. Аңларга ярдәм ит. Нишләп мин Стекловның төрмәгә утыруында һәм Зосимовның үлүендә үземне гаепле сизәм?

— Китап күп укыганга шизофреникка әйләнеп барасың. Минем сиңа сүзем шул. — Ул идәндә өелеп торган китапларга ымлады. — Дивизия китапханәсен монда күчереп бетерәсең бит инде.

— Зосимов үлгән инде, ул берни сизми. Бер җире дә авыртмый, кайгырмый да. Уйламый һәм җәзаланмый да. Ә Стекловның яшисе бар бит. Аңа авыррак түгелме? Ул ничек яшәр?!

Соңгы сорауларны ул инде үзенә бирде. Шадрин чигә турысында бармагын төртеп торды да, кул селтәде:

— Тәмам туйдырдың!

— Саша, миңа тышка чыгарга рөхсәт ит.

— Бар, Сибгатуллин, бар, башыңны ял иттер бераз. Ишекләреңне әйбәтләп яп.

Җир астыннан якты дөньяга килеп чыккач та караңгы уйлар аны калдырмады.

Нишләп расчеттагы иптәшләре кебек бөтен дөньясын онытып, вактәяккә төкереп яши алмыйм соң мин? Тагын яз җитте. Шәп-шәрә сопкалар да яшәреп, җанланып китте. Монда да кошлар сайрый. Әнә сарык көтүе җәелгән. Көтүче бурят кемгәдер кычкыра. Нәрсә җитми миңа? Нигә Стеклов, мәрхүм Зосимов өчен кайгырам? Үз кайгым азмы миңа? Минем дә бит әле кичеп чыгасы хәсрәт дәрьям бар, үзем өчен җавап бирәсем бар.

Котылгысыз рәвештә «дембель» килеп җитте. Булырга тиешле нәрсә гел килеп җитә ул. Фәиз кая кайтырга тиеш соң? Кайтып керер җире бармы аның?

Әмма ләкин барыбер кайту ихтыяҗы бар. Чөнки ул ТЕГЕНДӘ кайтырга тиеш. Аны ТЕГЕ ВАКЫЙГА зарыгып көтә. Җавапсыз калган сораулар калды анда. Монда ике ел буена әзерләнде бит ул. Аның үзенә кайтасы бар!

Хәрби хезмәт аның өчен нәрсә булгандыр — ул анык кына әйтәлмас. Кирәк идеме ул аңа, юкмы — әйтүе шулай ук кыен. Бу «мәктәп» нәрсә дә булса бирми калмагандыр, әлбәттә. Бик авыр, кыен хәлләргә калырга туры килсә дә, монда үзе өчен шактый күп ачышлар ясады ул. Ләкин, шул ук вакытта, бик күп сораулар да өстәлде. Күп нәрсәдән өмете өзелде. Армия аңа үзен тикшереп карарга мөмкинлек бирде. Үзеңне аңлар өчен бәлки монда ике ел гомер уздыру ярыйдыр да? Монда ул бик күп төрле, илнең әллә кайсы төбәкләреннән җыйналган кешеләр белән очрашты, аралашты. Күп нәрсә күрде, белде. Ләкин ике ел элек туган сорауга монда җавап эзләп табып булмады. Күп нәрсәгә төшенеп, аңлауга иреште... Әмма иң мөһимен аңламады. Ә бәлки иртәрәктер әле?

## 1

Казанда аның барып керердәй бер генә адресы бар иде. Федосеевская, 14. Төн уртасында килеп ишек шаку уңайсыз, әлбәттә. Нишлисең бит, кая бармак кирәк?

— Кем бар? — диде эчтән карлыккан тавыш. Хатын-кыз тавышымы, ир кешенекеме, аңлашылмады.

— Хәтимә әби өйдәме?

— Хәтимә әбиеңнең өе зыяратта инде...— диде әлеге ямьсез тавыш.

Ишек шыгырдап ачылды да солдат каршында эчке күлмәктән генә юан бер хатын пәйда булды.

— Син кем? — диде хатын.

— Мин — Фәиз.

— Нинди Фәиз?

— Мин Хәтимә әбидә фатирда торган идем ике ел элек. Армиягә кадәр.— Караңгыда хатынның чыраен төсмерләргә тырышты, әмма күрерлек түгел иде.

— Ә-ә-ә, җанкисәгем, Фәиз, синмени бу! Кер әйдә, кер.

Баштан ук зыярат сүзен ишеткәнгәме, әллә хатынның юан тавышыннан һәм аның чит кеше каршында эчке күлмәктән генә оялмыйча басып торгангамы, Фәиз ничектер керәсе килмәгән шикеллерәк таптанып алды.

— Хәтимә әби өйдә түгелмени? — диде ул, аптырагач.

— Хәтимә апа үлде шу-у-ул,— дип сузды хатын, еламсыраган тавыш белән һәм «шул» сүзен бормалап.

— Күптәнме?

— Яз көне, мартта җирләдек. Кер инде, салкын бит,— диде хатын, калтыранып.

Фәизнең барыр җире юк иде. Кергәндә, арттан ишекне бикләргә калган хатыннан аракы һәм тагын әллә нинди исләр бөркелде.

Өйдә эчкечеләрдә генә була торган тәртипсезлек хөкем сөрә иде. Ишекләрне бикләгәч, хатын такылдый-такылдый Фәиз тирәсендә бөтерелде.

— О-о-о, солдатик, син нәрсә, мине хәтерләмисең дәме?

Фәиз алкаш хатынга җирәнеп һәм аптырап карап торды. Хатынның бите сыдырылып, күз төпләре шәмәхәләнеп беткән, пычрак майлы чәчләре тузгыган, шул сәбәпле аның ничә яшьләрдә икәнен дә чамаларлык түгел иде.

— Юк, хәтерләмим. Чардакта куныйм әле бүген. Минем барыр җирем юк.

— Нишләп чардакта! — дип күзләрен елтыратты хатын.— Монда да урын житәрлек. Утыр әйдә. Танымый, эреләнгә-ә-ән. Әллә кыланасың гынамы?

Фәиз кинәт һушсыз калды. Тегендә-монда яткан әйберләрне ашыкпошык җыештырырга маташучы хатынны игътибар белән күзәтте.

— Син... Гөлүсә апамы әллә?

Хатын бер өем чүпрәкне карават астына аягы белән этеп кертте дә, киң елмаеп, солдатка карады:

— Ниһаять, таныды Гөлүсә апасын.— Ул бераз оялган сыман кыланды.— Әй, карама әле алай итеп миңа. Оялам.— Ул, чыннан да, күз төбендәге шәмәхә таплар һәм, гомумән, кыяфәте өчен бераз кыенсына иде шикелле.— Мин сине бит башта милициядән дип уйладым. Караңгыда аңлап булмый, әллә солдат киеме, әллә милицияныеке.

Гөлүсә шаркылдап көлеп җибәрде, хатынның таныш кеше булуы Фәизнең дә кәефен күтәргәндәй итте. Ул да кушылып көлде.

Фәиз чәй кайнатырга маташып мәш килгән хатынга карап утырды. Ике ел элек... чардакта шушы хатын белән... Матур иде ул. Хәзер коточкыч үзгәргән, ямьсезләнгән. Нәрсә булган аңа?

— Ник сөйләшмисең?—диде Гөлүсә катып беткән клеенканы юеш чүпрәк белән ышкып.

— Нәрсә сөйлим соң?

— Бәрәч икән. Армиядән кайтып та сөйләр сүзең юкмыни?

— Үзгәргәнсең син,—диде Фәиз.

Аның болай дип әйтеп куюы икесенә дә авыр тәэсир итте.

— Син дә малай-шалай түгел инде хәзер,—дигән булды Гөлүсә.— Хатынның тамагына төер тыгылды, аның елыйсы килде, әмма үзен кулга алды һәм чүпрәген тоткан килеш Фәиз каршысына килеп утырды.— Арыдым мин. Туйдым. Исерек тормыштан да, аек чагымнан да.

— Туктале, нишләп алай?

Гөлүсә тагын сикереп торды:

— Чәй кайнады бугай.

Хатын бар булган каты-котыны табынга куеп маташкан арада Фәиз чардакка менде.

Салкын. Аның монда утырып уйланасы килде.

Ул тиз генә төшеп шинелен киеп менде. Шулкадәр таныш һәм никтер йөрәккә бик якын урын бит бу. Нишләп алай соң? Шушында кайгыга батып, җан сызлавына дәва табалмый җәфа чигеп утыра иде. Шул җан сызлавын эчтән кемдер, нәрсәдер суырып-суырып чыгарды. Күңел нык тарткан икән монда, тузанга баткан салкын чардакка. Нишләп шушында каласы килә? Чөнки монда нык уйланды ул, моннан ТЕГЕ ВАКЫЙГА аермачык күренә. Бу чардакта ТЕГЕ ВАКЫЙГА турында уйланып утырырга уңай шартлар бар. Ә газапны яңа көч белән кузгатасы килә, күңелдә шундый ихтыяҗ бар. Кирәк ул, кирәк, ул бит каядыр озак качып ятарга тиеш түгел, барыбер, уянып бимазаларга тиеш.

Янында иске бишмәт кигән Гөлүсә пәйда булгач, ул сискәнеп китте.

— Нишләп утырасың?

— Уйланып.

— Без бит синең белән менә шушында рәхәтләнеп яткан идек.

Фәиз хатынга карап торды—әллә шаярып әйтә, әллә, чыннан да, рәхәт булганмы аңа? Моның әһәмияте бар иде Фәизгә. Үзенә үзе ышанмау аны һәркайда, һәрвакыт сагалап йөри.

— Әйе шул,—диде ул танымаслык булып үзгәргән хатыннан карашын читкә күчереп.

— Шул вакытларны сагындыңмы әллә?

— Әйе, шул вакытны сагындым,—дип кырт кисеп җавап бирде Фәиз.—Шул вакытны.

Кайсы вакытны икәнен ул үзе генә белә иде.

— Әйдә, чәй эчәбез.

— Кайнадымыни?

— Күптән инде.

Өйдә чәй эчәргә шикәр дә юк иде. Кайдандыр табылган катып беткән коржикларны җебетеп эчтеләр.

— Син ник бу хәтле эчәсең?—диде Фәиз.

— Ташлыйм мин. Яңа елдан бөтенләй ташлыйм,—диде Гөлүсә, башын иеп.

— Син монда яшисеңмени?

— Монда, ирем белән аерылдык бит без. Эштән утыз өченче статья белән кудылар...

— Эчкәнгә куганнардыр..

— Ташлыйм мин, ташлыйм,—дип үзенә-үзе кабатлады хатын.—Син ачуланма инде мине.

— Нишләп ачуланыйм ди.

— Синең чемоданда эчәргә алай-болай бернәрсә дә юктыр инде? — диде Гөлүсә, гаепле кыяфәт белән мескенгә сабышып.

— Юк. Аракы да, акча да юк. Нишләргә дә белмәссең. Эшкә урнашканчы акча табып торасы бар бит әле.

— Ник, армиядән бераз бирмәделәрмени?

— Ул акча поездда ук ашарга тотылып бетте. Карале, синең кызың бар иде бугай.

Хатынның чырае тагын да ныграк караңгыланды:

— Ба-а-ар, хәзер дә бар. Уналтыда гына, ә инде өметсез сөйрәлчек. Ни укымый, ни эшләми. Базарда өрек сатучы әзербәйҗаннар белән яши кайдадыр. Тфү! Оят!

Ул иелеп идәнгә борынын сеңгерде, кулын озак итеп итәгенә ышкып торды.

— Самат миннән күрә, әйтерсең, мин генә тәрбияләгәнмен кызымны.

— Самат кем ул?

— Ирем. Элекке ирем.

— Хәзер кайда соң ул?

— Кайдан белим. Миңа нигә аның кайдалыгы. Миңа беркем дә кирәк түгел.

— Сиңа эчүне ташларга иде.

Хатын, авызын кыйшайтып, башын читкә борды, күрәсең, мондый киңәшне бихисап күп тапкырлар ишеткәне бардыр һәм дә мондый сүзләрдән аның күңеле, иң каты махмырдагы шикелле, болганадыр.

Ул кинәт җитдиләнеп тагын әйтеп куйды:

— Ташлыйм, ташлыйм. Яңа елдан башлап бер грамм да эчмим.

Ике ел элек чардакка менгән таза, чибәр хатынның шушы Гөлүсә икәнлегенә Фәиз аптырап утырды.

— Син ике ел элек мондый түгел идең.

— Ике ел элек һәркем башка төрле иде.

Гөлүсәнең уйламыйча гына әйтеп ташлаган сүзендә бернишләтеп булмый торган хакыйкать ята иде. Ул авызын ямьсез итеп җәеп елап җибәрде. Фәиз аны юатмады, чөнки юатыр сүзе дә, аның кирәге дә юк иде.

— Ник эчәсең соң син? — диде ул, хатынның шушы хәлгә төшүенең сәбәбен чынлап та беләсе килеп.

Гөлүсә, кулы белән ниндидер бер битлекне сөртеп төшергәндәй, шешенеп беткән битен уч төпләре белән сыпырып алды.

— Белмим. Эчкәч җиңелрәк. Бәлки берәрсенең каргышы төшкәндер.

Каргыш төшү турында Фәиз еш ишетә, каргыш турында күп кеше әйтә — коммунистлар да, алласызлар да, исерекге дә, аегы да.

— Синең нәрсә эшләгәнең бар соң шулай каргыш төшәрлек?

— Белмим. Алай әшәкелек эшләп йөргән кеше түгел инде мин.

— Шулай булгач?

Хатынның хәле начарайганнан-начарая барды. Сулышы ешайды, куллары ныграк калтырады. Ул, түзмәде, инде болай да асты өскә килгән бүлмәне туздырып тагын нидер эзли башлады. Шкаф тартмаларын кат-кат ачып карады, мәрхүмә Хәтимә әбинең сандыгын ачып актарды, тәрәзә төбендәге «Тройной одеколон» шешәсен алып лампочка яктылыгында селкетеп карады, ләкин шешә буш иде. Ул хәлсезләнеп агач караватка утырды, одеколон шешәсен идәнгә шалтыратып төшереп җибәрде.

— Күршеләрдә аракы юк микән соң? — диде Фәиз, хатынның хәлен аңлап.

— Белмим, — дип ыңгырашты хатын.

— Булырга тиеш, бәйрәм бит.

Гөлүсә башын күтәрде:

— Нинди бәйрәм?

— Бүген җиденче ноябрь бит, революция көне. Октябрь бәйрәме.

— Ә-ә-ә, әйе шул. Юк, күршеләр миңа бирми, булса да.

— Минем одеколоным бар чемоданда. Тик тройной түгел... «Русский лес» дигән. Аны эчәргә ярамыйдыр инде.

Хатынның күзләре елтырый башлады, ул кинәт җанланды.

— Ник аны күптән әйтмисең?! — диде ул, канатланып.— Бир тизрәк! «Русский лес» әйбәтрәк тә әле ул, градусы күбрәк аның.

Гөлүсәнең ислемайны су белән болгатып эчеп утырганын Фәизнең карап утырасы килмәде. Ул чардакка менеп китте.

«Каргыш төшкәндер», ди. Каргыш. Ярый ла ул син уйлаганча, син күзаллаганча гына килеп сукса. Мәсәлән, төрмәгә утыртып куйсалар. Нишләп төрмә турында уйлый башладым соң әле мин? Ә-ә-ә, уйлар нәкъ ике ел элек шушы кечкенә тәрәзәдән карап, куркып утыргандагы юнәлешне алып бара түгелме? Китәргә кирәк моннан! Куркыныч монда!

Ләкин нииндидер көч бу чардакка гел тартып торды бит. Армиядә чакта да. Чөнки монда синә генә хас нәрсәләр уяна: эчтә, күңелдә, акылда. Мин бит вокзалда да куна ала идем. Димәк, монда килергә ихтыяҗ булган. Бу чардактан чыгасы да килми бит әле якты дөньяга.

Бәлки минем армиядән кайтуымны көтеп йөриләрдер?

Ул аска төшкәндә Гөлүсә инде исереп караватта ята иде. Башын калкытып, бермәл Фәизне танымыйча торды, аннары сорап куйды:

— Кайда йөрдең син?

Фәиз урындык алып килеп карават янына утырды:

— Гөлүсә!

— Ә?

— Мин киткәч, монда килеп кызыксынучы булмадымы?

— Булды,— диде хатын, күзләре йомык килеш.

Фәизнең йөрәге жу итте:

— Кем?

Гөлүсә, мут елмаеп, алагаем авыр кулын егетнең тезенә ташлады:

— Мин кызыксындым. Ә син, чукынчык, армиягә китеп баргансың.

— Юк, алай-болай милиция кызыксынганы юкмы?

— Ә-ә-ә, ментлар, сволочьлар, алар минем белән генә кызыксына. Айныткычта ничә тапкыр булганымны санап барган идем дә, хәзер чутын югалттым.

— Минем белән кызыксынучы булмады инде алайса?

— Кемгә кирәк соң син! — диде хатын һәм торып утырмакчы булды. Әмма хәле җитмәде, кире лап итеп ауды.

— Торма, торма, ят син,— диде Фәиз.— Йокла.

— Ә син?

— Мин чардакка менәм.

Куркыта. Нәрсә куркыта? Гражданка тормышы. Армиядән соң «ирекле» тормышта үзеңне диңгез уртасында ташлап калдыргандай хис итәсең. Монда төрле яктан килеп эләктерүләре ихтимал.

Тып-тын гына нииндидер таныш халәт якынлашты. Аның килүе куркытса да, ул сагындырган, УЛ хискә сусау бар! Халәт армиядәге шикелле булмас, кайткач нииндидер үзгәреш барлыкка килер, дип үзен күпмедер дәрәҗәдә әзерләгән иде Фәиз. Әмма монда, чардакны сарган пәрәвезгә игътибарсыз карап, хәтер сандыгын актара башлагач, шул нәрсә аңлашылды: үзгәреш, әлбәттә, бар шикелле, тик үзгәреш ТЕГЕ ВАКЫЙГА белән бәйле хатирәләрне уятып хасил булды. Газаплы халәт үзенең инде күптән әзерләнеп куелган пәрәвез-ятмәсен җәеп маташты. Әйе, ике елдан артык вакыт үтте, әмма качып китеп булмады. Менә ул монда, миндә, үземдә.

Бөтенләй үк коелып иңмәде Фәиз бу тойгыдан. Чөнки ТЕГЕ УРЫНга якынрак ул хәзер. Ара кечерәйде. Һәм инде, әлбәттә, ТЕГЕ ВАКЫЙГАГА якынайды.

Бугазыннан нииндидер яман чир эләктерергә җыенган кебек булды. Фәиз аның чирме, башка төрле михнәтме икәнен аңламады, җанның тып-тын гына сыкрап-сулкылдап алуына күңелен салып, коточкыч килә-

чәккә котылгысыз рәвештә буйсынуын һәм алга таба да буйсыначагын аңлады.

Кинәт аның үзәкләре куырылып китте. Ике елдан артык вакыт узган, ә Фәиз исән, яши, хәрәкәт итә, уйлый. Хаклымы соң ул яшәргә?! Каргыш кайдан төшәр дип гомер буе куркып йөрергәме хәзер? Үзеннең шәүләннән өркеп? Туктале, каргыш төшкән түгелме соң инде?! Тагын нинди җәза кирәк соң миңа?! Хәер, кирәкме-юкмы дип сорап торучы юк ләбаса! Үземне кызганам да икән бит әле мин.

Матур каршыламады «гражданка», хәер, Фәиз аны өмет итмәде дә. Армиядән азат булып, туып-үскән төбәгенә күпмедер дәрәҗәдә ашкынуының сәбәбе — нindидер сорауга җавап табып, тыгызланган зур бер төенне чишү, авыр йөктән арынасы, кем алдындадыр акланасы килү галәмәте иде.

Өй җылысы чардакка бик саран гына менсә дә, шинель белән иске юрган астында йокы үзенекен итте.

Уянгач, йорттагы тынлыкка игътибар итеп, шактый вакыт колак салып ятты. Тавыш-тын ишетелмәгәч, торып киенде. Чардак баскычыннан саклык белән генә төшеп, өй эченә күз салды: көн яктысында монда кичәгедән дә ямьсезрәк һәм котсызрак күренде. Караватта иләмсез кыяфәттә Гөлүсә йоклый, идәндә берсеннән-берсе шапшак ике ир тирән йокыда тәгәрәшеп яталар. Берничә буш шешә хасил булган, бүлмә эченә авыр, тыгыз ис тулган — ул йоклаганда монда «бәйрәм» иткәннәр, ахрысы. Идәндә ятучыларның карт кешеләрме, яшьләрме икәнлекләрен аңларлык түгел иде — озын чәч, җиткән сакал-мыек комачаулады. Пәлтәләрен аска җәеп ятканнар, икесенең дә аякларында җәйге ботинка.

Димәк, Фәиз йоклагач, Гөлүсә янына менә бу шешәдәшләре килгәннәр, тагын аракы эчкәннәр. Чардакта солдат барлыгын Гөлүсә боларга әйтмәгән, яисә, әйтеп тә уятмаска кушкан. Арып кайткан, йокласын дигәндер. Бәлки үзләренә аракы күбрәк тисен өчен уятмаганнардыр аны.

Тизрәк моннан чыгып йөгерәсе килде. Бу тынчу фатирның, күгәргән исле чардакның кирәге дә калмады, ахрысы. Чөнки күңел төбендәге теләк кабул булды. Аң астында кемдер, нәрсәдер теләгенә ирешә.

Башланды. Кузгалды. Ике ел дәвамында уяулы-йокылы «йөргән» халәте аягүрә калыкты. Фәиз моны аңы белән аңламады, карусыз буйсынуын гына дәвам итте.

Чыгып йөгерергә, чыгып йөгерергә! Югыйсә үзенең күңеле дә тарта шушы имәнгеч күренешләрне тамаша кылырга, нindидер бер ләззәт хисе дә тоя шикелле. Тик инде эчтәге ГАЗАПны тибеп уятканнан соң, мондый күренешләрнең кирәге калмады. Вакытлыча. Хәзер инде газап белән бергә-бер калуга мохтаҗ ул. Кинәт бу фатир яшәешнең иң лайлалы чокыры булып тоелды. Хәтимә әби җан тәслим кылганда бу йортның да җаны кай тарафларгадыр очкандыр, күрәсең.

Фәиз ишекне ачып бусагадан тышка атлады. Гаҗәеп яктылык белән саф һава берьюлы «һөҗүм» итеп, бермәлгә аның һушын алды, күзләр камашты, сулыш капты. Ап-ак кар яуган — дөнья яп-якты иде. Фәиз әле пычранырга өлгермәгән саф кар җәймәсенә басты. Бу күренешкә аның исләре китте. Әле бер дә тапталмаган аклыкта күнитеге белән кат-кат эз ясап карады.

Кызык. Сәер. Нindидер өмет тә бар сыман. Карап торуга шундый табигый һәм гади бер күренештә нинди сафлык, нинди пакьлек — ап-ак кар төшкән! Дөнья ак тәс алган!

## 2

Ул, армиягә кадәр эшләгән берләшмәнең проходноена барып, житмеш сигезенче цехка шылтыратты.

— Алло! Виктор Степанович! Исәнмесез! Бу мин, Сибгатуллин Фәиз. Сез мине хәтерлисездер. Мин армиядән кайттым. Сезне күрәсе иде. Мин монда, проходнойда.

Трубкада мастерның калын тавышы:

— Обедка кадәр ярты сәгать вакыт калды. Көтеп тор, обед вакытында янына чыгып керермен,— диде.

Виктор Степановичның тавышында канәгатьсезлек яңгыраса да, аның ярты сәгатьтән соң чыгасы Фәизнең кәефен шактый күтәрде.

Мастер, чыккач, ясалма ягымлылык белән аһ-ваһ килгән булды, гәрчә эчтән генә «эшкә алуын үтенмәсе ярар иде», дип уйласа да.

— Солда-а-ат! — диде ул, Фәизнең иңенә шап итеп сугып.— Ике ел узды да китте, ә?!

— Әйе шул, узды, Виктор Степанович.

— Ә син, хәтерлисеңме, куркып йөргән идең, армиягә алмаслар дип.

— Хәтерлим,— диде Фәиз кинәт караңгыланып.

— Кайларда хезмәт иттең соң?

— Белоруссиядә учебкада булдым, аннары Забайкальеда.— Аның тизрәк сүзне мәгънәле юнәлешкә кертәсе килде.— Минем сезгә үтенечем бар, Виктор Степанович.

Мастер сагайды:

— Тыңлыйм.

Фәиз ничек башларга белмәде.

— Сез беләсез инде, минем беркемем дә юк.— Ул башта «минем сездән башка беркемем дә юк» димәкче иде, артык «төче» булыр дип кире уйлады.— Миңа бер айга акча биреп торыгыз, зинһар. Мин шушы көннәрдә эшкә урнашырмын. Хезмәт хакы алу белән түләрмен.

Мастер саргаеп беткән тешләре белән аскы иренен җыеп алды:

— М-м-м. Акча дисең...

Зуррак, катлаулырак, үтенечне көткән мастер акча сорауга да бигүк сөенмәде.

— Күпме кирәк соң сиңа? — диде ул ялгыз солдатны буш җибәрергә кыймыйча.

Фәизнең бу бердәнбер таянычы иде, шуңа күрә, дулкынланып, тезеп китте:

— Миңа... мин... хезмәт хакын алгач та, кичекмәстән... Ышаныгыз миңа. Ышанасыздыр бит?

— Күпме кирәк соң?

— Бер йөз сум,— диде Фәиз ишетелер-ишетелмәс кенә һәм куркып мастерга карады.— Виктор Степанович, эшкә урнашкач миңа әле подъемный акча бирергә тиешләр — закон буенча. Подъемный бирсәләр, бер айга да сузмам, иртәрәк түләрмен. Әлегә бит, эшкә урнашканчы да, акча кирәк.

Виктор Степанович кашларын җыерды:

— Мин йөз сум ук бирәлмим. Җитмешне бирермен.

Фәиз җитмешкә дә шат булды:

— Ярар, Виктор Степанович, рәхмәт! Бер ай вакыт бирегез, алып килеп түләрмен.

— Бер ай вакыт бирәм. Вакытында китер. Чөнки бригаданың уртак казнасыннан бирәм ул акчаны.

— Сезне уңайсыз хәлдә калдырмам, Виктор Степанович.

— Кая урнашасың эшкә?

— Әле белмим.

Фәизнең кинәт сөмсере коелды. Мастер: «Әйдә, безгә эшкә»,— дип әйтмәсме дип көткән иде ул. Юк, әйтмәде, чакырмады. Хәер, аның үзенең дә кире шул цехка урнашу теләге юк иде, әмма ләкин Виктор Степановичның цехка, бригадага чакыруы күңелләрне җылытып җибәрер иде.

Мастерга һәм аның бригадасына Фәиз кирәк түгел иде.

— Эш тә тапмагансың икән әле. Ә акчаны бер айдан ничек түләрсең соң син?

— Сез бер дә борчылмагыз. Чыннан да, кая урнашасым әлегә билгесез. Шулай да, бүген-иртәгә мин инде эш табачакмын, чөнки минем торырга да урыным юк бит әле. Эшкә урнашсам, тулай торактан урын бирми калмаслар.

Сүз тулай торак һәм торыр урын турында кузгалгач, Виктор Степанович, әҗәткә җитмеш сум биреп, проблемалары хәттин ашкан бу солдаттан тизрәк котылырга кирәк дип тапты.

— Бер айдан да озак сузма,— диде ул тагын бер кат.

— Борчылмагыз. Бәлки әле иртәрәк тә түләрмен,— дип инде әллә ничәнче кат ышандырды Фәиз.

Ул бер сигаретын тартып бетергән арада мастер цехтан әйләнеп килде. Акчаны алып шинель кесәсенә тыккач, Фәиз, әдәп өчен генә бригададагы хәлләрне сорашкан булды, барысына да сәлам җиткерүен үтенде.

Виктор Степанович солдатның кыяфәтеннән, күзләреннән үзгәрешләр эзләде. Гәүдәгә калыкмаган Сибгатуллин, шулай да, олыгаю бераз бар. Үзгәргән. Армия үзгәртә ул. Ләкин күзләрендә элеккеге тирән сагыш һаман шул көе сакланган. Мастерның җентекләп карап торуыннан Фәизгә начар булып китте, җавап табылмастай сораулар яудыра башлар дип куркып, ул китәргә ашыкты:

— Ярый, Виктор Степанович, рәхмәт. Киттем мин.

— Ярый, хуш.

— Сез миңа өй адресыгызны бирегез әле шулай да.

Мастер чак кына: «Нигә ул сиңа?» дип сорамый калды. Фәиз аның аптырабрак калуын күреп елмайды:

— Бәлки почта аша җибәрергә туры килер акчаны.

— Ә-ә-ә, әйе, әйе,— диде Виктор Степанович һәм кабаланып кесәсеннән блокнот белән карандаш чыгарды, адрес язылган битне ертып Фәизгә бирде.— Ярый, туган, обед вакыты бетеп килә минем, йөгердем.

Мастерның төпченмәве, тирә-яктагы аклык, саф һава аның күңелен тагын күтәреп җибәрде. Күктән иңгән ап-ак кар һәм бөгәрләнеп беткән унлыклардан торган җитмеш сум кәефне кинәт нык яхшыртты. Киләсе көнгә атлап керергә дәрт һәм дәрман бирде. Адәм баласына күп кирәк түгел! Әмма алдагы көннең нәрсә алып киләсе әле мәгълүм түгел иде.

### 3

Фәизне нindидер көч Т. шәһәренә тартты. Әмма озак уйлаганнан соң, ул шәһәрдә яши алмам дип, анда урнашмаска булды. Барыбер шул тарафларга китте ул — Т. дан унбиш чакрым ераклыктагы К. поселогында тукталырга карар кылды. Килгән көнне үк поселоктагы МТСка слесарь булып эшкә дә кабул иттеләр үзен. Эшчеләр җитмәү сәбәпле, монда килгән һәрбер кешене куанып-шатланып каршы алалар иде. Шул ук көнне поселок үзәгендәге ике катлы тулай торактан кечкенә бер бүлмә дә бирделәр. «Әлегә берүзең яшәрсең, тора-бара янына кеше урнаштырулары да ихтимал», диделәр. Фәизне әлегә булса да ялгызы яшәячәге нык куандырды. Менә бит, килеп төшкән көнне үк эш тә бар, торыр урын да.

Иң мөһиме — ТЕГЕ УРЫН якын. ТЕГЕ ВАКЫЙГА шушы тирәдә булды. Бу тарафтан Т. каласына да унбиш кенә чакрым, сазлыктан исән калып чыкканнан соң больницада яткан С. поселогына да ерак түгел — кырык чакрымлап кынадыр. Монда уйланырга, күңелдә актарынырга уңай шартлар бар, монда ул, тынычланып, күп нәрсәне аңлар, төенне чишәр, сүтәр, сорауларга җавап табыр. Ниһаять, ул ШУЛ ТИРӘГӘ якын килде. Ике ел көткәннән соң!

Беренче төн шыр ялангач бүлмәдә йокысыз үтте. Авыр уй-хисләр нык бимазалады. Туган якка һәм ТЕГЕ УРЫНГА якынайган саен, Казандагы

тынчу чардакта калыплаша башлаган авыру яңа сулыш алды, коточкыч халәт вөҗүдне әкренләп әсир итте.

Шулай да, беренче көннәре эшкә урнашу шаукымында, яңа коллективка кереп эш белән танышу ыгы-зыгысында караңгы уйлардан арынып үтте.

«Подъемный» акчаны алгач, ял көнне, юлда очраган машиналарга утырып, Казанга барып кайтырга булды. Виктор Степановичка акчаны почта аша җибәрәсе килмәде, үз кулым белән тапшырсам, яхшырактыр, дип уйлады. Аннары теге Гөлүсә нихәлдә ята икән анда? Харап була бит ул хатын. Аның янына кереп чыгарга кирәк. Хәлен белеп.

Мастер өендә иде.

— Исәнмесез, Виктор Степанович!

— Сәлам.

Фатир эченнән җыр ишетелде, ниндидер бәйрәм иде бу өйдә.

— Менә җитмеш сумны китердем. Мең рәхмәт сезгә.

Виктор Степанович акчаны алды.

— Ярый. Кайда урнаштың соң?

— К. поселогында.

Фәиз акчаны вакытында кайтару шатлыгыннан тагын нидер әйтмәкче иде дә — җитешәлмәды, мастер кереп китәргә ашыкты:

— Ярар, мин шатмын синең өчен. Гафу ит, миндә кунаклар.

— Сау булыгыз.

— Хуш.

Ишек шап итеп ябылгач, ул баскычларны санагандай, әкрен генә атлап төште. Ничектер, нәрсәгәдер күңелгә ятмады бу очрашу. Виктор Степанович әллә үпкәләгән аңа, әллә санга сукмый. Ничек кенә булмасын, күңелсез, бик күңелсез.

Иске троллейбус аны Казанның үзәгенә, Кремль итәгендәге Федосеевская урамына алып төште.

Озак шакыды ул ишекне. Кат-кат дөбердәтә торгач, ишек ачылды да бусагада затлы халатка төренгән әзмәвердәй бер әү пәйда булды.

Фәиз авызын ачканчы ир:

— Нәрсә кирәк? — диде.

Аның бу соравы ук куып җибәрү кебек яңгырады.

— Миңа Гөлүсә кирәк иде, — диде Фәиз каушап.

Теге ир-ат Фәизнең түшеннән эләктерде, куртка кай җиреннәндер шытырдап куйды.

— Ычкын моннан яхшы чакта, үләксә! — диде ул тешләрен шыгырдатып. — Тагын берәрегез ишегемне килеп шакыса, бәрәм дә үтерәм.

— Туктагыз әле, — дип Фәиз нәрсәдер аңлатмакчы булды, әмма соң иде инде.

Аның яңагына тукмак шикелле йодрык килеп сыланды. Күздән утлар чәчрәп, бер мәлгә аңсыз торганда эченә китереп типтеләр. Ишек ябылгач, эчтән сүгенү ишетелде.

Фәиз, тын да алалмыйча бөгелеп, эчен тотып торды. Хәлсезләнеп җепшек карга тезләнде. Авызыннан карга кып-кызыл кан тамды. Егыласы һәм бераз ятып торасы килде, ләкин ятсам торалмам дип курыкты. Учы белән кар алып иреннәренә тидерде, тагын алып кар ашады. Эч авыртуы тиз арада бетте, баш исә чатнап авыртырга тотынды.

Бу фатирда үзгәрешләр булган, күрәсең. Фәиз бу тирәдән китү мәслихәттер дип тапты. Ул әкрен генә аягүрә басты да, үз-үзенә колак салгандай, бермәлгә тукталып калды һәм, баш авыртудан чыраен сытып, ишегалдыннан урамга атлады.

Поселокка кайтып җиткәндә инде караңгы төшкән иде. Ул үзенең почмакта урнашкан аулак бүлмәсенә кереп ауды. Пружиналы карават бик озак атынып торды. Тулай торакта гаиләле кешеләр дә яши иде. Күрше бүлмәдә хатыны белән яшәүче шофер Фәрит бер ярты аракы кыстырып килеп керде.

— Нихәл, Фәиз?

— Сәлам. Уз әйдә,— диде Фәиз яткан урыныннан гына.

Фәритнең колгадай озын гәүдәсен трико белән тишелеп беткән футболкасы гына каплап бетерерлек түгел — аның балтырлары, беләкләре шәрә калган. Ул өстәлгә шапылдатып яртысын куйды, ботын ботка атландырып урындыкка бөкрәеп утырды.

— Син каядыр барып кайттың, ахрысы?

— Казанга,— дип ыңгырашты Фәиз, гүя, анда барып кайтуына үкенеп.

— Чирлисеңме әллә?

Фәиз торып утырды:

— Юк алай. Ардырды. Баш чатнап авыртып тора.

Фәрит шешәгә ымлады:

— Әйдә, менә моны капкач баш төзәлә ул. Син безнең МТСка эшкә бөтенләйгә урнаштыңмы?

— Әйе.

— Мин сине анда еш күрәм. Кем булып урнаштың?

— Слесарь. Техника төзәтергә ярдәм итүче слесарь.

— Аңлашылды. Кая, стаканнарың бармы?

— Бар, әнә тумбочка эчендә.

— Хәзер хәлең яхшырачак.

Фәизнең күптән аракы эчкәне юк иде. Ул торып утырды:

— Закуска кирәк иде бит.

— Хәзер,— дип Фәрит чыгып китте.

Күп тә үтмәде ярты кирпеч ипи белән килька консервасы алып керде. Ул үзе инде шактый кызмача иде.

— Үзем генә эчә алмыйм, туган,— диде ул стаканнарга аракы салып.— Хатын әниләренә кунакка китте. Отпускы аның. Үзем генә калдым әлегә. Әйдә, тотып куйыйк.

Ярты стакан аракы Фәизне шундук исертте. Аңа күптән болай рәхәт булганы юк иде. Яшиселәр килеп китте. Бигрәк тә сөйләшеп утырыр кеше барда!

— Баш авыртуы беттеме? — диде Фәрит елмаеп.

— Бетте шикелле. Минем баш авыртуы аракыдан түгел иде бит. Кыйнадылар мине.

— Кем кыйнады?! — диде хәйран исерә башлаган күршесе.— МТСта сине кыерсытучы бар мәллә?

— Юк ла. Бүген Казанда. Кыйнадылар дип... Бер тапкыр суктылар, бер тапкыр типтеләр инде. Армиягә кадәр фатирда торганием. Шунда бардым. Анда бер хатын бар иде. Гөлүсә. Ишекне ачтылар да тондырдылар. Аңламый да калдым. Кем ул, ни өчен сукты?

— Һи, нәрсәсен аңламыйсың инде аның?! Көнләшү бу, дустым.

— Гөлүсәнең берәр кеме булды микәнни?

— Бигрәк кызык кеше син. Шул ук фатирдан ир кеше чыккач, синең Гөлүсәң янына килгән була түгелме соң?

— Әйе шул.

— Көнләшү яман чир ул, туган. Әйдә тагын тотып куйыйк әле.

Алар чәкештереп эчеп куйдылар.

— Гөлүсә бик каты эчә башлаган иде.

— Ташла әле син шул Гөлүсәне. Дөньяда беләсеңме күпме Гөлүсә бар? Хәер, мин үзем дә бик нык көнче кеше. И-и-и, туган, белсәң иде минем хәлләремне. Рәмзиям турында ничекләр уйланып, саташып ятканымны. Чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган утарда шашкан җанвардай улап аунаган чакларым бар иде бит минем.

— Төрмәдә утырдыңмы әллә?

— ЛТП да.

— Анда алкашларны гына утырталар түгелме? Нык эчә идеңме әллә?

— Нык дип. Алай башкалардан артыгын чөмергәнем булмады инде. Рәмзия минем өчен, гаиләбез өчен борчылып язгандыр инде ул гаризаны.
— Хатының утырттымыни?
— Әйе. Төрле гайбәтләр ишеттем: имеш, Рәмзиянең сөяркәсе, милиционер оформлять иттергән мине ЛТПга. Күз алдыңа китер. Нинди уйлар белән яшәргә тиеш мин! Ничек көнләшмәссең?
— Рәмзия элекке хатыныңдыр бит?
— Юк, бүгенгесе. Мин шуның янына кайттым. Балага узды әле менә. Яратам мин аны. Тик көнләшәм шул.
— Нык ятратканга күрә көнләшәсеңдер.
Фәрит йодрыкларын төйнәде:
— Хайван, кайтсын әле, үтерәм мин аны!
— Берүк кыйнама хатыныңны,— диде Фәиз, «үтерәм» дигән сүздән куркып.— Яратасың бит син аны. Кыйнама. Ялгыш үтерүең бар.
— Үтерсәм ни! Әллә син аны мин тегендә утырганда сөйрәлмәгән дисеңме?!
— Алайса ник кайттың соң аның янына?
Фәрит бер ноктага карап уйлап торды да:
— Яратам бит мин аны,— диде.— Әйдә, эчеп бетерик инде моны. Син сөер кеше, әлбәттә. МТСта бөтен кеше шулай ди. Бөтен кеше бертөсле булалмый. Син минем күршем. Күренеп тора, син начар егет түгел. Берәрсе җәберләсә, миңа әйт, иманын өшкерәм.
— Ярар,— диде Фәиз елмаерга тырышып.
МТСта барысының да сәерсенүен Фәиз үзе дә сизә иде, әмма күршесе бу хакта әйткәч, ул кинәт пошаманга калды.
— МТСта акча аз инде,— диде Фәрит һәм әшәке итеп сүгенеп куйды.
Фәиз аракы тәэсирендә батыраеп китте:
— Фәрит абый, әйт әле, кайсы төшем сәер соң минем?
Фәрит башын туры тотарга тырышып карап торды да:
— Ә-ә-әй, төкерсәнә. Анда бер юньле кеше юк ла,— диде.
— Сиңа ник сәер тоелам соң мин?
— Ну-у-у, кешеләр белән аралашмыйсың. Кешеләрдән куркасың шикелле. Кемдер сиңа начарлык эшләр сыман тотасың, үзеңне. Гел кайгырып йөрисең шикелле. Миңа шулай тоелды.
— Мин монда яңа кеше бит, ияләнермен әле.
— Шулай анысы, шулай. Юк белән баш катырма. Тагын берәр ярты табарга иде. Синең юкмы?
— Юк шул.
— Ничек уйлыйсың, тагын берәр ярты кирәкме безгә?
— Мин исердем инде.
— Иртәгә машина белән чыгасы юк. Тагын берне табарга иде.
— Син УАЗда йөрисеңме?
— Әйе, баш инженерны йөртәм.
— Карале, Фәрит абый, берәр буш вакыт табып, бер җиргә барып кайтырбыз әле, яме.
— Кая?
— Т.га.
— Бер ярты куйсаң барабыз,— диде Фәрит шаярып. Ул инде исергән һәм аның шаярулары фәкать ярты литр тирәсендә генә чуалды.
— Куярмын. Аннары С. поселогына барырга кирәк әле миңа.
— Анда да барырбыз. Тагын кая барасың бар?
— Лесхозга.
— Анда минем дә йомышым бар. Сәлим Сәлмәневич араталык вәгъдә иткән иде. Барырбыз, туган, барырбыз. Тик менә бер ярты каян табарга икән?
Ул инде тәмам мәлҗерәйде һәм утырган урынында йокымсырый башлады. Фәиз аны сөйрәп үзләренең бүлмәсенә алып керде, алагаем озын гәүдәне көч-хәл белән диванга урнаштырды. Фәритләрнең бүлмәсе

шулай ук кечкенә, ләкин монда хатын-кыз барлыгы һәр җирдә беленеп тора. Ниндидер җылылык бар иде аларның бүлмәсендә.

Вакыт инде соң булса да, коридорда бала-чага шау-гөр килеп йөгереп йөрде. Тышта беренче кышкы буран башланды. Фәизнең күңелендә дә аңлатып булмаслык халәт барлыкка килде. Исергәч рәхәтләнеп китте, ләкин уйлар барыбер аны ташларга теләмәде. Кан йөреше яхшырып, җиңеллек тойса да, тәгаен онытылып булмады. Шулай да, кереп караватына яту белән үк рәхәт йокыга талды һәм таң атканчы бер тапкыр да уянмады.

## 4

Армиядән соң «иреккә» ияләшә алмый интекте ул. Хәрби хезмәттә аны кемдер яклый, саклый кебек иде. Ә гражданкада... Теләсә кайсы яктан теләсә нәрсә яный монда. Үзенә үзең тапшырылгач, әлбәттә, авыррак, бөтен җаваплылык үз өстеңә төшә. Хәзер инде армиядәге шикелле онытылып яшәп булмый. Хәзер инде үзеңдә казынырга вакыт күп. Бигрәк тә ТЕГЕ УРЫНГА якынайгач. Армиядә ТЕГЕ урын белән хәрби часть арасында меңләгән чакрымнар бар иде. Шул сәбәпле ТЕГЕ ВАКЫЙГА да ераграк сыман тоелды. Ә хәзер... Туктале, нишләп үз теләге белән монда килеп урнашты соң ул?! Киресенчә, армиядән соң тагы да ераккарак олагырга мөмкинлекләр бар иде ләбаса. Юк, монда кайтасы килде. Шундый ихтыяҗ, хәтта таләп тә бар иде. Күңелендәге боерыкка буйсынмый булдыра алмады ул.

Бу поселокта яши башлагач, төшләренә Зәбир еш керә башлады. Кызык, армиядә никтер бер тапкыр да күрмәде төшендә. Ә хәзер көнаралаш диярлек керә. Ләкин, ни гаҗәп: дусты төштә һәрвакыт ачык йөз белән, бернинди үпкә-ачусыз, һаман элеккечә дус, туган булып күренә. Дустының шундый якты кыяфәттә төшләренә керүенә сөенергә тырышса да, шундук начарга юрый торган булды. «Төшкә кергәннең өндә киресе була», дип уйлады ул. Мин аны кызганганга, сагынганга күрә генә шулай елмаеп күренәдер. Өндә бик авыр һәм газаплы иде Зәбир турында уйланулары. Күп-күп итеп китаплар уку да ярдәм итмәде. Кайвакыт яртышар китапны укып чыга, ләкин эчтәлеген һич кенә дә аңламый, чөнки баштагы уйлар бөтенләй башка тарафларда сөйрәп йөртә. Җан сызлавы саркыган фаҗигале әсәрләр генә аның игътибарын, күңелен нык җәлеп итте. Үзенең күңел чиренә әһәндәшлек табып, күз яшьләрен агызгалап укыды ул андый китапларны.

Күз яшьләре акканнан җиңеләеп китәсең. Шуңадырмы, Фәиздә сентиментальлеккә омтылу артты. Фаҗигале күренешләрне күреп, йә булмаса күз алдына китереп, газапка гел сусап торган күңеленә ләззәт бирде. Авыр да, шул ук вакытта татлы да бер мохтаҗлык иде ул.

Кинолардагы, китаплардагы һәм тормыштагы фаҗигале күренешләрне тамаша кылып, андагы корбаннарның газапларын, аларның каннарга батып үлем белән көрәшүләрен үзе аша үткәрәсе килү, шундый хәлләргә дучар булган кешеләрнең халәтенә үзенең дә тулысынча керү ихтыяҗы арткannan-арта барды. Әсәрдәге корбанның фаҗигасен, авыртуын, газабын һәрвакыт сазлык йоткан дустының һәлакәте белән чагыштыра башлады. Ул тора-бара аңлады: ТЕГЕ ВАКЫЙГА турындагы иксез-чиксез уйланулары армиядә вакытлыча гына тынып торган булган, ул сүнмәгән, сүрелмәгән, көтеп яткан икән.

Зәбирнең сазлыктан башы гына калкып торган мизгелне күз алдына китереп, дустының шул секундларда ниләр кичерүен, җаны белән тырмашып, ничек тә булса аңларга тырышты. Аңарда хәтта бер коточкыч теләк туды: җәй житкәч сазлыкка барып... батып карарга! Аңлыйсы, татып карыйсы килде. Үзең шул хәлдә булмыйча ничек аңламак кирәк аны?! Хәзер инде башкаларның газабын Зәбир газаплары

белән чагыштыру теләге дә туды. Кинода канга батып тыпырчынып ятучы геройны күрсә, Зәбиргә авыррак, газаплырак булмады микән бу кешегә караганда дип уйлады. Андый вакытта Фәизнең хәле начарланып китә, чөнки шул ике корбанның да тиресенә-хәленә кереп, үзенең көчле фантазиясе белән ике газапны да үзе аша үткәрү сәләтенә ия була башлады. Һәм бу халәт үзенең физик чагылышларын да тапты: пульс ешайды, тир бәреп чыкты, куллар калтырарга тотынды.

ТЕГЕ УРЫНГА бару теләге бәлки батып карарга теләү белән бәйледер. Сазлыктан дустын табып чыгарса, куркынычрак түгелме соң? Аның мәетенә карап торгач йөрәк шартламасмы? Ә нишләп мин йөрәгем шартлаудан куркам әле?! Димәк, минем һаман яшисем килә? Минем газапларым ихлас микән соң алай булгач?! Оят, хурлык! Адәм актыгы бит мин! Йөрәгем ярылып үлсәм, бу миңа бүләк кенә була түгелме? Җайлы гына котылу түгелме бу?!

Аңарда тора-бара җәяү йөрү ихтыяҗы артты. Поселокның шапшак урамнарын әллә ничә кат урап узды инде ул. Ике һәм бер катлы агач өйләр аралашкан шыксыз бу поселокта, район үзәге буларак, урамнарда хәрәкәт хәйран зур иде. Йөргәндә ничектер күңел тынычрак, нервыларниндидер сихәт ала шикелле.

Район китапханәсендәге китаплар арасында ул укырдайлары бик аз иде. Культура сараена да кинога гына йөрде, танцыларга, төрле бәйрәмнәргә бер дә калганы булмады.

Шулай да бердәнбер яратып йөри торган урыны — китапханә булды. Монда тынычрак иде. Җанга тынычрак иде. Аннары монда Нәркизә исемле китапханәче кыз бар. Төскә-биткә әллә кем булмаса да, аңарда хатын-кызлык көчле иде. Ябык гәүдәле, озынча битле, кылыч борынлы булуына карамастан, аның һәр хәрәкәтендә, сөйләшүендә, йөрүендә күңел солтанаты бар иде. Кызгылт-сары чәчләрен матур итеп үреп салган кыз, чәчәкле күлмәк итәген җилфердәтеп, елмаеп яныңнан узганда, аны һич кенә дә матур түгел дип әйтмәссең. Карап торуга әллә кем булмаган әлеге кызда бүгенге заман хатын-кызларына җитеп бетмәгән нәзакәтлек, нәфислек ничектер сакланып калган иде.

Фәизгә ул тора-бара ошый башлады. Нәркизә дә игътибар беләнрәк карагач, бу сәер егеттә башкаларда булмаган затлы сыйфатлар күрде. Китапларны саклык белән генә, кыйммәтле бәллүр тоткан сыман кулына алулары, китапханәгә дә оялып, кыенсынып керүе Нәркизәнең күңеленә бигрәк тә хуш килде.

Алар танышып киттеләр. Фәиз инде хәзер Нәркизә янына махсус керә башлады. Ләкин һәрвакыт кыюлык өчен бераз «кабып» керә торган булды. Нәркизә моңа игътибар итмәде, чөнки Фәиз исерек түгел, тонус өчен генә эчә һәм кәефе яхшы: үзен әйбәт хис иткән чакларда гына Нәркизәнең күзенә чалына иде ул.

Газап өянәкләре вакытында ул Нәркизә янына йөрмәде. Шулай итеп, берничә тапкыр очрашырга вәгъдәләшеп тә баралмый калды. Андый вакытларда акланырлык сәбәпләр табып ничек кирәк шулай ялганлый иде. Нәркизә аның сәерлеген, үзен чит кешеләр янында уңайсыз хис итүен ятим үсүенә, детдомда тәрбияләнүенә «сылтады». Кайвакыт Фәиз кино карап утырган җиреннән сикереп торып чыгып китә иде. Нәркизә шундый вакытларда нык аптыраешта кала, аннары, йә бәдрәфкә чыгасы килгәндер дип, үзен-үзе юата иде.

Кайлардан белсен Нәркизә аның җанында, бәгырендә ниләр кайнаганын. Кайдан белсен бу кыз кино караганда теге яки бу сюжет аның күңелендә нинди хис-кичерешләр уятканын. Кайдан белсен ул аңарда әкренләп ябык биналардан, караңгылыктан курку тойгысы көчәйгәнен?!

Фәиз Нәркизәне югалтудан курыкты. Алар бер-берсен инде ярата да башладылар бугай. Тик куркыта, чөнки якынаерга кирәк. Ә якынайгач эчтәге серләр ачылуы ихтимал. Яратышкач арада ераклык саклап бул-

мый. Иң яшерен серләрне дә күрәчәк бит нык якын килгән кеше. Шулай итеп, Нәркизәне югалтудан да, якынайтудан да курыкты ул.
Аларның очрашулары дәвам итте.

## 5

Фәрит белән утырып эчкәннән соң, ул аракы белән мавыга башлады. Бөтен спазмаларны ачып җибәрә торган «утлы су» ял да иттерә иде, кайвакыт ул җырлаплар җибәрә торган булды. Эштәге механизаторлар гаражда гел җыелып салалар, Фәиз дә тора-бара аларга иярде. Тулай торакка үзе белән «ярты» кыстырып кайту гадәткә кереп китте. Аның даими шешәдәше күршесе Фәрит иде. Шулай да күбрәк ялгызы гына эчәсе килә иде аның. Саранлыктан түгел. Ялгызы гына, аракы белән тонусын күтәреп һаман да үзенең мәңгелек уйлары белән каласы килде аның. Аракы онытгыра диләр, уйларны башка юнәлешкә җибәреп, стрессларны алып ташлый, имеш. Бәлки аяктан егылганчы эчсәң шулайдыр, әмма бит Фәизгә егылу кирәк түгел. Аның уйлыйсы килә. ТЕГЕ ВАКЫЙГАда үзенең ни дәрәҗәдә гаепле икәнен аңлар өчен меңләгән нечкәлекләр белән чуалган коточкыч күренешне хәтердә мең-мең кат уятып, кабатлап ӨЙРӘНӘСЕ бар! Аракы газаплы уйларны уйлаганда фәкать кан йөрешен генә тигез тота, газапны киметми ул.

Әмма ләкин икенче көнне, айныгач бик авыр. Вөҗдүнең аракыдан талчыгуы гына җитмәгән, гаеп хисе, үзеңне битәрләү көче күп тапкырлар арта һәм сөйләп бетергесез авыр, бик авыр. Әйе, махмырдыр бу. Аракы махмыры гына түгел. Үткәннәрнең, кылган гамәлләрең махмырыдыр.

Беркөнне Рәмзия коридорда очрап:

— Син, зинһар, Фәритне эчәргә кыстама инде,— диде.

— Ярар,— диде Фәиз.— Ул бит олы кеше инде. Эчәсе килмәсә эчмәсен.

— Аны синең кебек шешәдәшләре котырта! — дип җикерде Рәмзия һәм авызын җәеп елап җибәрде.— Үләм мин аның белән тиздән.

Фәиз үзенә карата дорфалык сизсә дә, ярсыган хатынның хәлен аңлап:

— Елама, Рәмзия апа. Бу кадәр кайгырырлык берни юк ләбаса,— диде.

Аның тыныч кына әйтелгән сүзләре Рәмзиягә искиткеч тәэсир ясады. Кер элергә җыенган җиреннән тасын күтәреп, ишекләренә таба юнәлде. Туктап борылды, гафу үтенмәкче булдымы, юкмы. Фәизгә хатын үкенгәндер шикелле тоелды.

— Нәрсә беләсең соң син,— диде Рәмзия.— Аны да кызганыч инде.— Ул кер эләсен исенә төшерде һәм коридор аркылы сузылган бауга юеш кер элергә тотынды.

Теге көнне Фәрит алдаган — Рәмзия әниләренә кунакка түгел, качып кайтып киткән булган. Фәрит исерек баштан кыйнаган булган үзен. Күрше бүлмәдән кычкыру-акыру-сүгенүләрне Фәиз еш ишетә. Аның инде берничә мәртәбә, кереп, Фәритне тыясы килгән чаклары да булгалады. Тик ир белән хатын арасына килеп керү дә әллә ничек. Беркөнне шап-шоп хатынын кыйнады. Тегесе акыра. Ничек инде балага узган хатынны шул кадәре кыйнап була, дип җаны әрнеп ятты ул. Икенче көнне очрашкач Фәрит берни булмагандай исәнләшә, сөйләшә.

Хатынын кыйнамаганда, аек чакта шулкадәр әйбәт кеше. Кичә хатынның кыйнадың, ахрысы, дип хәтта сүз башларга кыюлык җитми, тел әйләнми.

Күрше бүлмәдәге гаиләнең фаҗигасе дә Фәизнең җан әрнүенә өстәлде. Шушы ике кеше арасындагы мөнәсәбәтләрнең коточкычлыгында ул үзен гаепле сизде. Нинди гаеп соң ул? Җавап гап-гади: Фәиз аларга берничек тә ярдәм итәлми. Карынында баласы булган хатынны кемдер

якларга тиештер бит?! Фәрит үзенең баласы турында уйламый микәнни? Ә Рәмзия? Ник кайткан монда тагын?! Бала бит дөньяга туачак. Ул тугач, аларның мөнәсәбәтләре үзгәрерме соң? Бала тугач, кешеләр үзгәрәме? Гомумән, балалар тугач, дөнья үзгәрәме соң? Шул ук дөнья, шул ук кешеләр дөньясы.

Ял көне иде. Кич белән коридорны яңгыратып җырлап Фәрит кайтып керде. Аның тавышын ишеткәч, Фәиз ишеген эчтән бикләп мыштым гына утырды. Китап алып саклык белән генә караватына барып ятты. Фәрит аның ишеген бик озак шакыды. Күрше бүлмәләрдән чыгып зарланучылар булгач, ул үз бүлмәсенә кереп китте. Һәм күп тә үтмәде анда җәнҗал купты. Рәмзиянең җан ачысы белән кычкыруы ишетелде. Тулай торакның бер генә кешесе дә аларның арасына кермәде, исерек ирне тыярга омтылмады.

— Үтерәм, б...., с...! — дип үкерде Фәрит.

— Сукма инде,— дип өзгәләнде Рәмзия.

Фәиз бүген дә бераз «салган» иде. Үзендә күпмедер дәрәҗәдә рухи тигезлек тойган сәгатьләр иде. Фәритнең, кайтып, хатынын кыйный башлавы йөрәкне ярсытты. Караңгы уйлар белән үзен-үзе «ашаган» вакытлардагы ярсу түгел, ярдәмсез, көчсез кешенең башка кеше тарафыннан җәберләнүенә каршы уянган ярсу иде бу.

Рәмзиянең улавы тәмам бәгырьгә тия башлады һәм ул түзмәде, сикереп торды.

Ул аларның бүлмәсенә ничек атылып килеп кергәнен сизми дә калды. Диванда бөгәрләнеп яткан Рәмзияне Фәрит кизәнеп-кизәнеп йодрыклары белән төеп маташа иде. Фәиз аңа арттан килеп сукмакчы иде, соңгы мизгелдә сукмаска уйлады, чөнки ул сугып кына бу кадәре алагаем гәүдәне бернишләтеп булмас иде. Фәиз аның җилкәсенә сикерде һәм төенчек сыман күршесенең муенында асылынып калды. Фәрит, нык исерек булганлыктан, чайкалып торды да Фәиз белән бергә ниндидер сыекчалар түгелеп юешләнгән һәм пычранган идәнгә гөрселдәп ауды. Фәиз җәһәт кенә аягына сикереп торды, Фәрит исә, сүгенеп, торырга азапланып идәндә ятып калды. Фәиз янә аның өстенә сикерде, теге тагын идәнгә сыланды.

Фәиз күршесен муеныннан кочып кысты:

— Күрше, тынычлан!

Фәритнең томаланган авызыннан ишетелер-ишетелмәс саркып чыкты:

— Ә-ә-ә, күрше, синмени бу? С..., әллә син дә минем хатын белән булдыңмы?

— Ни сөйлисең син! Акылыңа кил!

Фәрит нык исерек иде, хатынын кыйнап та арыган, җитмәсә, күршесе кереп буа башлады, шул сәбәпле аның каршы торырга хәле юк иде.

— Нишләп әле син Рәмзияне яклыйсың?

Фәиз торып басты, еш-еш сулап җикерде:

— Син! Авырлы хатыныңны кыйныйсың?! Җүләр түгелсеңдер бит?!

Фәрит торырга уйламады да, идәндә яткан килеш авызын кыйшайтты:

— Ә нигә әле син минем хатынымның карынындагы бала өчен кайгырасың? Ә? — Ул кинәт мәлҗерәйде, күзләрен йомды.— Сукала-а-ар!

Рәмзиянең күз төпләре инде кара янарга өлгергән, күлмәгенең җиңе аерылып төшкән, авыз кырыннан кан саркый.

Фәиз идәндә яткан көнче иргә гаҗәпләнеп карап торды:

— Йоклый!

Аның шулай ваемсыз рәвештә йокыга китүе, әле яңа гына булган коточкыч күренештән соң йоклый алуы Фәизне таң калдырды.

Рәмзия исә моңа һич кенә дә гаҗәпләнмәде. Ул стенадагы көзгедән кыяфәтен барып карады. Фәиз рәхмәт сүзләре ишетергә әзерләнгән иде, әмма хатынның әйткән сүзләре шулай ук таң калдырырлык булып чыкты:

— Ник кереп тыгылдың инде?! — диде Рәмзия, киеренкелектән ап-ак булган күршесенә.
— Ул бит сине кыйнады!
— Кыйнасани, анда синең ни эшең бар! Хәзер тагын интектерәчәк инде: ник Фәиз сине яклый дип. Җитмәсә, авырлы икәнне кузгаттың, бала турында сүз каттың. Болай да көнләшеп үтерә бит инде.
Рәмзия елый башлады, ире кыйнаганда еларга мөмкинлеге булмаган, күрәсең.
— Гафу ит, сине кыйнатасым килмәгәние.
Рәмзия килеп иренә карап торды да:
— Әйдә, булыш, диванга күтәреп салыйк әле,— диде.
Фәритне көч-хәл белән икәүләшеп диванга күтәреп салдылар. Фәрит йокы аралаш һаман әле хатынын сүкте.
Фәизнең бу бүлмәдә бер генә минутка да каласы килмәде.
— Ярый, тыныч йокы,— диде ул усал итеп һәм ишекне атып чыгып китте.
Кышкы урамда ярты сәгать чамасы йөргәч кенә тынычлана башлады. Көндез эчкән аракының махмыры төшеп, туңдыра башлады, төне дә бик салкын иде, ул тулай торакка ашыкты.
Фәритләр бүлмәсе турына җиткәч колак салып торды, тавыш-тын ишетелмәде.
Чишенмичә генә йокларга булды. Җил бүлмәнең барлы-юклы җылысын алып бетергән иде. Сәгать унике тула, китап укып ятсам йокыга китәрмен бәлки дип караваты янына килгән иде, ишекне ишетелер-ишетелмәс кенә итеп шакыдылар.
— Кем бар анда?
Җавап бирмәделәр. Шаку кабатланды. Фәиз ишек янына килгәч тагын сорады:
— Кем?
Рәмзиянең ишек ярыгына пышылдаганы ишетелде:
— Фәиз, ач әле.
Фәиз ишекне ачты, чакыруны да көтмичә Рәмзия бүлмәгә узды.
— Синдә салкын икән,— диде хатын һәм калтырап куйды.
Фәиз пәлтәсен чөйдән алып аңа суздьг:
— Мә, иңеңә сал. Тәрәзә ярыклары сыланмаган минем, шуңа салкын.
Рәмзия пәлтәгә төренеп утырды:
— Йокларга ятмаган идеңме әле?
— Юк, китап укымакчы идем.
— Ә-ә-ә.— Рәмзия шешенеп беткән битенә урта бармагын тигезеп карады, чыраен сытты, ыңгырашып куйды.— Ну хайван, тагын битне кара яндырды. Ничек көне буе прилавка артында басып торыйм инде хәзер.
— Иртәгә эшкә чыкма инде син.
— Син нәрсә?!
— Бер-ике көн кибет эшләмәгәннән берни булмас.
— Юу-у-ук, син нәрсә. Поселокның бердәнбер азык-төлек кибете бит ул. Чукынып китсенсәнә чырае! Барыбер ирем кыйнаганны беләләр инде. Беренче тапкыр түгел бит. Син миңа ачуланмыйсыңмы?
— Юк, ник мин сиңа ачуланырга тиеш? Син үзең миңа ачуланасың шикелле.
— Юк, юк, дөрес аңла мине.
— Аңлыйм ла мин. Мин бер нәрсәне генә аңламыйм: ник яшисең син аның белән?
Рәмзия авызын кыйшайтып читкә карады:
— Һе, бөтенесе шулай ди.
Бүлмәдә нык салкын иде, Фәиз торып карават астыннан чемоданын тартып чыгарды. Шинелен алып киде.
— Син авырлы. Ә ул сине...

— Нәрсә син гел шуны кабатлыйсың: «авырлы» да «авырлы». Кайдан беләсең соң син, авырлымы мин, юкмы.

— Фәрит үзе әйтте.

— Ә-ә-ә. Кешегә сөйләп йөрмәсә инде.

— Ул бит сине дә, карыныңдагы балаңны да берәр көнне кыйнап үтерәчәк.

Рәмзия калтырый-калтырый, ихлас күңелдән борчылучы сәер егеткә карап торды:

— Сәер кеше син.

Фәиз сагайды, үзе турында сәер дисәләр, ул һәрвакыт куркып кала иде.

— Син дә шулай дисең инде алайса.

— Син башкаларга охшамагансың. Сөйләшүләрең дә башка төрле. Кибеттән әйбер алганда да әллә ничек син.

— Минем турыда сөйләшмик әле,— диде Фәиз кырыс кына, сүзнең үзе хакында баруына ачуы килеп.— Инде беренче тапкыр түгел дисең. Ничек түзәсең син? Мондый җәберләүгә ничек түзмәк кирәк?!

— Яратам мин аны.

Фәиз телсез калды.

— Ну ярат инде алайса,— диде ул һәм караватына сузылып ятты да түшәмгә текәлде.

Көтмәгәндә Рәмзия елмайды, бите сыдырылып, шешеп беткән булса да, елмаю аның йөзен яктыртты, әле бөтенләй үк югалмаган матурлыгы чагылды:

— Син нишләп шушы хәтле ялгыз?

Фәиз өчен куркыныч сорау иде бу, чөнки кемгә ничек аңлатасың күңеленең ялгызлыкка сусавын, үз уйларың белән бергә-бер калуга мохтаҗ икәнеңне. Кешеләрдән читләшеп йөрүе турында берәрсе сүз катса, аның эчендә сагаю барлыкка килә, гүя, кемдер аның серле, якты дөньяга күрсәтергә ярамый торган почмагына якынлаша. Әйтерсең лә, үзе генә белә торган бер коточкыч һәм бөек серне чишәргә дип чит-ят кеше килә, нәрсәнедер тартып алмакчы яки төшенмәкче була.

— Мин, гомумән, ялгыз бит. Ятим мин. Шуңа күрәдер инде кешеләр белән аралашучан түгелмен.

— Йокың килмиме әле?

— Юк.

— Минем яшереп куйган бер шешә вино бар, алып керимме?

— Алып кер. Ирең уянмасмы соң?

— Юу-у-ук, хәзер аның башына балта түтәсе белән суксаң да, тиз генә уянмаячак.

Рәмзия аяк очларына гына басып үзенең бүлмәсеннән җиде йөз граммлы болганчык кызыл аракы алып керде.

Кызыл аракы эчкәч, Рәмзиянең теле ачылып китте. Ул инде битенең әчетеп авыртуына да игътибар итми башлады. Аның сөйләшәсе килде. Ләкин сөйлисе сүзен башларга ничектер кыймый утырды, шул сәбәпле Фәизгә төрле көтелмәгән сораулар бирде:

— Клубка да йөрмисең бугай син?

— Киногa йөрим.

— Поселокта матур кызлар бар,— диде Рәмзия, елмаеп. Күз төпләре шешеп каралса да, матурлыгы сакланып калган иде аның.— Сезнең МТСта диспетчер Гадилә бик матур.

— Аның егете бар бит.

— Соң инде андый мал хуҗасыз булмас, ха-ха-ха. Син нишләп нәкъ шушы поселокка килдең соң? Бу тишеккә, шушы тынчу базга?! Беткәнмени яктырак поселоклар, шәһәрләр.

— Бу яклар ошый миңа. Ә син үзең дә никтер шушында яшәп ятасың бит әле.

Фәиз тәмәке кабызгач, Рәмзия:

— Миңа да бир әле берне,— диде.

Рәмзия тәмәкене хәйран оста тарта иде, тирән итеп суырса да, тончыкмады, йөткермәде.

— Син кайсы яктан соң үзең? — диде Фәиз.

— Еректан мин,— диде хатын, авызыннан бер бөрек төтен чыгарып.— Ходаем, Фәрит белсә, үтерәчәк мине. Аракы эчеп, тәмәке тартып. Егет кеше белән. Ужас!

— Куркасыңмы Фәриттән?

— Курку да түгел инде шунда. Кызганам мин аны.

— Яратам диден ич.

— Яратырга тырышам. Чөнки минем зур гаебем бар аның каршында. Син аның болай холыксызлануына карама. Ул бик әйбәт кеше. Күңеле бик йомшак, чиста аның.

— Алайса аңа эчәргә ярамый. Авырлы хатынны шулкадәр кыйнап.

— Аптырадың инде — авырлы да, авырлы. Авырлы түгел лә мин! Юри әйткән идем Фәриткә, кыйнаудан туктап тормасмы дип. Балага узарга кая әле, ни торырга юньле фатирың булмасын, ни мөнәсәбәтләр әйбәт түгел.

— Фәрит бит сине авырлы дип уйлый.

— Әйе.

— Соң, шулай булгач, барыбер кансыз кылана бит, авырлы дип белсә дә кыйный.

— Син, күрәм, бик кызганучан бала икәнсең. Бер дә борчылма, миңа бу да аз әле. Үзем гаепле мин. Без аның белән бер авылдан, Ташлыктан. Бер класста укыдык, мәктәпне тәмамлаган елны ук бер-беребезне ярата идек инде. Ул бик чибәр иде, хәзер генә ул... юк, хәзер дә матур ул. Армиядән кайтканын көтеп алдым, каршыладым. Мин инде ул вакытта сәүдә техникумында укый идем. Өйләнештек. Ул ПАТОда шофер булып эшләде. Малосемейка бирделәр, яши башладык. Мин Культтовары кибетенә эшкә кердем. Шунда растрата чыгып, ОБХСС миңа дело ачты. Миңа гына түгел, берничә кешегә. Мин бит товаровед идем. Зур суммага товар юкка чыкты. Кая китте ул — һич аңламый калдым. Яшь идем, баш та эшләп бетермәгәндер инде, тәҗрибә бөтенләй юк бит. Директор эше булгандыр дип уйлыйм инде мин үзем. Әллә нинди кабахәтләр бар бит дөньяда.

Минем артымнан бер милиционер сөйрәлеп йөргән иде. Фәрит армиядә чакта ук танышкан идек. Болай ярыйсы гына, чибәр, акыллы. Ләкин мин Фәриткә хыянәт итмәдем. Камил минем артымнан нык йөрде, Фәрит армиядән кайткач та.

— Камил кем ул?

— Шул инде, минем артымнан йөргән милиционер. Камил Сабитов. Условниклар яши торган спецкомендатурада отряд начальнигы иде ул вакытта. Дуслары бик күп иде аның — ОБХССта, уголовный розыскта да. Мин шуңа ярдәм сорап мөрәҗәгать иттем. Ул үзенең шартларын куйды, теләкләрен белдерде.

— Нинди шартлар?

— Син бигрәк бала-чага сыман. Юри сорыйсыңмы?

— Аңладым, аңладым.

— Мин, әлбәттә, аның теләкләрен үтәдем. Хыянәт иттем Фәриткә дә, үземә дә. Ә бер хыянәт иткәч, нииндидер киртәне сикереп чыккач, күп нәрсәләргә караш үзгәрә ул. Камил коткарды, хәтта сәүдә системасында да калырга мөмкин булды. Гади сатучы булып Каенсар авылының кибетендә эшли башладым.

— Каенсар?! Без Каенсарга детдомнан бәрәңге алырга барган идек!

— Фәритнең берничә тапкыр айныткычка эләккәне бар иде. Шуны Камил ничектер белгән һәм минем белән бер тапкыр йоклаганда: «Әйдә Фәритеңне ЛТПда берәр ел дәвалап кайтартабыз»,— диде. Беренчедән, мин Камилгә бурычлы идем, шуңа күрә аның белән очрашырга, аның

белән йокларга мәҗбүр булдым. Шул сәбәпле кырт кисеп: «Юк!» — дип әйтәлмәдем. Югыйсә әйтергә, каршы торырга кирәк иде. Икенчедән, Фәрит чыннан да, нык эчә башлады, аның дәваланып кайтуы икебезгә дә файдага булыр дип уйладым. Аннары Камилгә дә ияләшә башладым әкренләп. Хата ясаганымны соңыннан гына аңладым — Фәритемне үз кулларым белән төрмәгә тыккач. Гаризаны мин яздым, ә оформлениене әлеге дә баягы Камил дуслары аша ясап, иремне озаттылар. Фәрит аннан бик үзгәреп, әшәкеләнеп кайтты, төзәлмәслек ниндидер яра ясап кайтардылар. Минем күңелемдә дә мәңге төзәлмәслек җәрәхәт әрнеп авырта.

— Ә Камил кайда соң хәзер? Очрашасызмы аның белән?

— Очрашып йөрдек. Каенсарга көн саен диярлек мотоциклына атланып килеп җитә иде. Фу, искә дә төшерәсем килми. Үземнән үзем җирәнәм. Көнче кеше ул бик. Яратты ул мине, чын күңелдән. Ну көнче иде. Миңа гел көнче ирләр туры килә. Фәритемне аңлап була — бер ел төрмәдә утырган ирнең кайсысы көнләшеп шашмас икән. Менә шулай. Камил минем янга гел килеп йөрде. Ә мин Фәрит алдындагы гаебемне көннән-көн ныграк сиздем һәм Камилне читләштерергә тырыштым. Камил мине: «Төрмәгә утыртам, теге эш әле ябылмаган»,— дип куркытырга тотынды.

Ә беркөнне килгәч, әйттем: «Теләсәң нишләт, тик бүтән яныма эзеңне дә атлама!» — дидем. Ул шаккатты. Ялынырга тотынды. Имеш, ярата ул мине, миннән башка яши алмый. Көнче тәре! «Фәритеңне барыбер ЛТПдан тиз генә чыгарттырмыйм!» — ди башлады. Уф, бир әле тагын бер папиросыңны.

— Кайда соң ул хәзер?

— Камилме?

— Әйе.

— Ул хәзер зур начальник. Спецкомендатура башлыгы ул хәзер. Майор.

— Ә бу поселокка, син әйтмешли, тынчу базга ник килеп урнаштыгыз?

— Фәрит ЛТПдан кайткач икебезгә дә эш булган төбәкне карадык инде. Ул әнә МТСта баш инженерны йөртә, мин кибеттә инде.

— Фәрит беләме соң Камил турында?

— Гайбәтләр ишетелә бит инде ул. Шуңа тузына да. Дөресен әйткәндә, мин инде аны яратмыйм.

— Фәритнеме?

— Әйе.

— Яратмагач ник үзеңне җәфалыйсың?

— Мин гаепле аның каршында. Мин аны яратырга тырышам, үземне көчләп аның яхшы сыйфатларын, яшь вакыттагы мөнәсәбәтләрне эзлим һәм кайвакыт табам да шикелле. Ул бит болай әшәке түгел иде. Хәер, ул хәзер дә әшәке түгел. Ни сөйлим мин, тиле хатын!

— ЛТПдан кайткач та эчә башладымы?

— Әй, ЛТП дип атала гына бит соң ул! Анда бит эшче куллар гына кирәк, шуңа тутыралар ул төрмәләрне ирләр белән. Менә шундый хәлләр, мин үземнең дә, аның тормышын да бозып ташладым.

— Туктале, нишләп син бөтен гаепне үз өстеңә аласың?

— Аны аңлатып булмый бит, Фәиз.

— Аңлыйм, аңлыйм, нишләп аңламаска. Миңа җан сызлавы нык таныш, мин беләм җан газабын. Тик менә Сабитов Камилнең күңелендә нинди халәт икән? Газап-мазар аңарда бар микән?!

Рәмзия көлеп җибәрде:

— Камилдә бөтен нәрсә бар, шул вөҗданнан башка.— Ул кинәт җитдиләнде.— Мин төрмәдә утырып чыгарга тиеш идем. Мондый пычрак юл белән котылып калганчы. Котылумыни бу?! Минем хәзер бөтен гомерем төрмәдә үткән шикелле булачак. Минем Камилгә әйткәнем бар:

«Без синең белән зина кылып ятабыз, Фәритне төрмәгә яптык та. Ә бит аның каргышы төшәчәк». Каргыш бит ул эзләп таба гаепләне.

— Кая, Камилгә нинди каргыш төште соң — майорга әйләнгән, начальник итеп куйганнар үзен. Синең дә тормышыңның үзгәрүе үзеңнән генә тора, ирең белән аерыласың да.

— Ә мин, шул каргышны аласым килмәгәнгә, ничек тә булса яхшылык эшләргә телим аңа. Янында булып, ярдәм итеп, элеккечә яратырга тырышам. Минем аркада күп михнәт күрде ул, күңеле җәрәхәтләнеп кайтты аның. Ә Камил... Аның гөнаһлары түгел, гомумән үзе дә мине һич кенә дә кызыксындырмый.

— Әллә син җәзаңны алыр өчен торасыңмы аның белән? Син бит үзеңне гаепле сизеп, аның белән интегергә карар кылгансың.

— Бәлки шулайдыр,— диде Рәмзия һәм, әле яңа күргәндәй, кинәт кызып киткән егеткә карап торды.— Яшь кенә булсаң да, акылың бар синең.

— Мин бит үзем дә җәзамны эзләп килдем... дөресрәге кайттым монда.

— Ә сиңа нинди җәза кирәк соң?

— Юк, мин болай гына әйттем. Рәмзия, син, дөресен сөйләп, гафу үтен иреңнән. Икегезгә дә җиңел булып китмәсме. Гаебеңне тану шул булыр. Фәрит сине гафу итәчәк. Ул тере, исән кеше. Ә менә мин кем алдында гафу үтеним икән?! Мине ярлыкасы кеше исән түгел бит.

— Кем ул? Кем алдында гафу үтенергә тиешсең?

— Армиядә булды ул хәл. Учениеләр вакытында безнең рота — сазлыклар аша маневр ясарга тиеш иде. Минем дустым... безнең отделениедән... батып үлде. Ә мин янәшә идем, аның батып үлгәнен күрдем. Ярдәм итәргә тырыштым, кулымны суздым, әмма коткара алмадым. Кулымны ныграк сузсам, коткара идем мин аны.

— Сиңа хәзер генә шулай тоеладыр, мөмкин булса коткарыр идең.

— Юк, юк, мин ниндидер сиземләү белән кулымның ныграк сузылырга мөмкин икәнен хәтерлим шул! Ник сузмадым ныграк, ник тырышыбрак үрелмәдем — һич аңламыйм. Югыйсә бик якын дуслар идек.

Фәиз үзенең оста алдашуына үзе дә гаҗәпләнде — шик-шөбһә төшәрлек түгел иде.

— Үзеңне алай кыйнама, сазлык бит ул. Синең гаебең юк, минемчә.

— Син барысын да белмисең бит! Алай гына түгел ул! Бөтенләй алай түгел бит ул!

Киеренкелек артканнан-артты. Фәиз, салкын булса да, барып форточканы ачты.

— Болай да салкын бит,— диде Рәмзия.

Фәиз көтелмәгән дорфалык белән хатынны гаҗәпкә калдырды:

— Бар үз бүлмәңә, ардым мин! Бар, бар нәрсә карап торасың?

Рәмзия ишек тоткасына тотынгач:

— Үпкәләдең мәллә миңа? — дип сорады.

Фәиз бүлмә буйлап атлады:

— Нишләп үпкәлим ди.

— Берәр авыр сүз әйттем мәллә?

Фәиз, туктап, хатынга карап торды да:

— Юк, эчем поша. Үзем генә каласым килә,— диде.

Рәмзия чыгып китте.

## 6

Фәрит икенче көнне МТСта Фәиз янына килде.

Фәиз ремонттагы машина астында үз эше белән мәшгуль иде, күршесенең авыр атлап килүен күреп алды да яман әңгәмәгә үзен әзер тотты.

Фәрит машина янына килеп чүгәләде:
— Күрше!
Килүен күрсә дә, Фәиз сискәнеп китте.
— Нәрсә? — дип машина астыннан чыкты да майлы кулларын чүпрәккә ышкыды.
Фәритнең таушалган кыяфәтендә бернинди усаллык юк иде.
— Син гафу ит мине,— диде ул һәм башын читкә борды.
Фәиз аптырашта калды:
— Ник гафу үтенәсең?
— Кичәге өчен. Мин сиңа да пычрак сүзләр әйтеп бетергәнмен бугай.
— Юу-у-ук, хәтерләмим. Кем әйтте?
— Рәмзия әйтте.
Алар кырыйда яткан машина тәгәрмәченә утырып тәмәке кабыздылар.
— Син үзең гафу ит мине, гаилә арасына кереп тыгылуым өчен.
Фәрит тәмәкене бер-ике суырды да ташлады, чыраен сытып башын чайкады:
— У-уф, хәлем авы-ы-ыр. Ярый әле главный инженер Казанга китте. Берәр җиргә машина белән чыгасы булса, үләр идем.
Фәиз аңа карап үз уйларын уйлады.
— Син нишләп мине тыгылуым өчен ачуланмыйсың?
— Ничек тыгылуың өчен?
— Син бит көнче кеше, кереп Рәмзияне яклавым белән көнләштергәнмендер сине.
Фәрит елмайган булды:
— Син нәрсә инде? Нишләп мин синнән көнләшим?!
Фәизнең моңа ачуы килде:
— Ә нәрсә?! Әллә мин кешедән кимме?! Мин булдыра алмыйммы әллә?!
Фәрит як-ягына карап куйды:
— Кычкырма, кеше ишетә бит!
— Ишетсеннәр!
Фәиз тәмәкесен ташлап таптады.
— Фәрит, тыңла мине! — Үзеннән ун яшькә олы Фәриткә беренче тапкыр абый дип дәшмәде ул.— Кыйнама Рәмзияне! Ул бик әйбәт хатын. Әйбәт кеше дип әйтмәкче булган идем мин. Ул сиңа хыянәт итми. Кичә син йоклагач, без аның белән төн буе сөйләшеп утырдык. Кыйнама син аны.
— Анда синең ни эшең бар? — диде Фәрит ачусыз гына. Аның хәтта ачуланырлык хәле дә юк иде.
— Минем эшем бар анда! Чөнки мин аңладым Рәмзияне. Тагын берәр тапкыр суксаң...
— Нәрсә була?
Фәиз башын аска иде:
— Бернәрсә дә булмый.
Фәиз кинәт Рәмзия сөйләгәннәрне исенә төшерде, уч төбе белән иске бушлат эчендәге йөрәген угалады. Янында күршесенең язмышы да фаҗигале икәнне оныткан лабаса. Ул Фәриткә карады. Фәрит ярдәмсез, хәлсез һәм беркемгә нәфрәтсез кыяфәттә башын аска иеп утыра иде. Аңа бу озын гәүдәле, эре сөякле һәм ярдәмгә мохтаҗ адәм баласы шундый кызганыч булып тоелды, әле яңа гына җикеренүе өчен шундук үзен битәрләде. Күңел кинәт җебеп китте, бугазда төен җыелып нәрсәнедер буып алган кебек итте, ләкин күңелдәген тыеп торырлык түгел иде, ул елап җибәрде. Аның сулкылдый-сулкылдый елавын Фәрит башта көлү дип кабул итте, ә инде пычрак куллары белән битен буяп чын күңелдән елавын күргәч, таң калды, нишләргә белмәде.
— Син нәрсә, Фәиз... брат... күрше... туган... нәрсә булды?

Фәиз дәшмәде. Берничә механизатор, аптырап карап, үтеп киттеләр. Тимерчеләр цехының тәрәзәсеннән ике баш чыгып карап торды.

— Фәиз, Фәиз, миңа үпкәләдеңме? — диде Фәрит өзгәләнеп.

— Юк,— диде Фәиз, мөлдерәп аккан күз яшьләрен тыймыйча.— Мин шулай еш елыйм. Җиңел булып китә. Күрәсең, әйтелеп бетмәгән сүзләр, гамәлгә ашмаган ниятләр, аһ-зарлар шулай күз яшьләре булып чыгадыр.

— Тынычлан, Фәиз. Кыерсытучы юктыр бит?

Фәиз инде елаудан туктады, елмаеп Фәриткә карады:

— Син һаман бала-чага шикелле. Кыерсытучы юкмы, имеш.

Фәрит күршесенең сәер, нечкә күңелле икәнен сизенсә дә, менә болай тик торганда елап җибәрүен күреп шаккатты.

— Мин бала-чага шикелле шул кайвакыт,— диде ул.— Ә менә син зур гомер кичергән кешегә охшап куясың. Ашыйсың килмиме? Обед вакыты җитә бит.

— Ашап килсәк, әйбәт булыр иде,— диде Фәиз, елаганнан соң җиңеллек тоеп.

— Әйдә поселок кафесына. Үзем түлим. Мин берәр стакан акны эчми булдыралмыйм инде, махмыр бит. Әйдә, киттек. Әйдә, туган. Син үзеңне-үзең кимерә торган кеше. Алай йөрәккә якын кабул итмәскә кирәк. Хәер, мин үзем дә шундый. Тик менә синең ник елавыңны аңламый калдым.

— Сиңа анысын аңлау кирәк түгел. Син башыңны төзәт, махмырдан килеш кешенең күңелендә казынма.

— Ярар, ярар, гафу ит.

Соңыннан Фәиз шулай да читенсенеп куйды — егет башы белән чит кеше янында елап утыру бер дә матур түгел. Матурлыгы кадалып китсен, миннән шикләнә башларлар, шунысы начар.

Аның елавы өянәк булып кайвакыт котмәгәндә башлана, көтмәгәндә дип әйтеп тә булмый аны, нинди дә булса бер сәбәбе чыга — кызганыч вакыйга, сентиментал әсәр, авыр хатирәләр тәэсирендә үзеннән-үзе күз яшьләре тәгәри иде. Айга бер-ике була иде андый халәт.

Бу юлы Фәритнең боек кыяфәтенә карагач, Рәмзиянең сөйләгәннәрен исенә төшергәч, үзенең дә яшәү дәрте кимеп киткән мәл дә булгач, күз яшьләре сорап тормады, бәреп чыкты. Күңел бушану сорады, нәрсәдәндер арынасы, чистарынасы килде.

— Ашау качмас,— диде Фәиз, күшеккән кулларына өреп.— Минем сиңа бер үтенечем бар, Фәрит.

— Тыңлыйм.

— Баш инженер кайчан кайта?

— Тагын берәр атнадан.

— Ул кайтканчы С. поселогына барып кайтыйк әле. Ерак түгел бит.

— Ни калган анда?

— Дөресен әйткәндә, минем андагы лесхозга барасым бар, шунда минем йомышым. Лесхозны беләсеңме?

— Белмәскә! «Кызыл йолдыз» урман хуҗалыгы бит ул.

— Минем лесхоз директорын күрәсем бар. Аның улы Ренат белән бергә хезмәт иттек. Барып әйтәсе сүзләрем бар. Улын дисбатка утырттылар аның. Әтисен барып юатырга кирәк.

— Аңлашылды. Әйдә алайса, иртәгә барып кайтыйк. С. кибетеннән аласы әйберләр дә бар минем. Кибет шәп анда. Сине эштән җибәрерләрме соң?

— Җибәрерләр,— диде Фәиз битараф кына.— Анда Тәлгать абый янына да кереп чыгарбыз.

— Анысы кем?

— Врач. Элекке врач. Минем әнигә операцияне шул ясаган. Бик әйбәт кеше ул. Миңа акча биреп торган иде.

— Нишләп төсең агарды синең? Чирләмисеңдер бит?

— Чирлим,— диде Фәиз һәм авыр сулап куйды.— Лесхозга барырга куркам. Тик барыбер барырга кирәк анда.

— Әтисе беләдер бит улының дисбатта икәнен?

Фәиз төссезләнгән күзләрен Фәриткә күтәрде:

— Эш белүдә-белмәүдә түгел. Минем тагын бер ЭШЕМ бар әле анда. Җәй көне барырга кирәк ул ЭШ буенча. Син андагы сазлыкларны беләсеңме?

— О-о-о, танылган, дан казанган сазлыклар бит ул.

Фәиз кипшергән иреннәрен ялап юешләтмәкче булды, Фәритнең куркып карап торуын күргәч, елмаерга тырышты.

— Авыру кеше бит мин, Фәрит. Менә шул сазлыкта бер үлән үсә ди. Шул үләнне кайнатып көнаралаш эчәргә кирәк икән. Ярты елдан чирнең эзе дә калмый ди.

— Синең нинди чир соң?

— Исемен онытгым.

— Ә ул үләннең исеме ничек?

— Белмим. Миңа Забайкальеда бер бурят хатыны аңлатты: шул даруны эчсәң, терелəсең, диде.

— Ә ул хатын кайдан белә безнең сазлыкта нәрсәләр үскәнен?

— Ул хатын әллә ниләр белә,— диде Фәиз үзенең шактый оста алдашуыннан канәгать булып.— Төпченмә, Фәрит.

— Нинди чир соң ул синең? Кай төшең авырта?

— Хәл бетә. Йөрәк нык кага. Куркыта.

— Кара син аны, ә, белмәгән идем. Күптәнме соң ул синең?

Фәрит аның елаганына хәзер инде гаҗәпләнмәде, күршесенең сәерлеген чамалап йөрсә дә, аның чирле икәнен белмәгән иде бит ул.

— Тумыштан! Әйдә ашарга,— диде Фәиз әңгәмәдәшен ышандыруыннан канәгатьләнеп.

Алдашу мондый очракларда кәефне күтәрә һәм ләззәт бирә иде, шуңадырмы, аның хәле яхшырып китте. Өстәвенә, иртәгә ул лесхозга бара — ТЕГЕ УРЫНГА аннан бик якын калачак. Анда барып әле бернишли алмаса да, ике елдан артык ярсып типкән теләк барыбер тормышка ашарга тиеш. Яз җиткәч, сазлыкны барып капшар алдыннан чирканчык алу булыр бу.

Ренат турында сөйләшү сәбәп кенә бит ул. Аның дисбатта утыруы әти-әнисенә инде мәгълүм. ТЕГЕ УРЫН тарта аны, ТЕГЕ УРЫН. Ул инде үзенә мең тапкыр сорау биргәндер: «Анда барып нишли алам, нәрсәне үзгәртәм?!» Җавап юк. Чөнки бернәрсәне үзгәртә алмыйсың. Ә бару ихтыяҗы һаман яшәп килә. Акланырга, офтанырга, үкенергә, ярлыкау сорарга бары тик шунда гына мөмкин дип котыртты аны какшаган психикасы.

## 7

Яп-якты кышкы көнне урталай ерып, УАЗ машинасы С.га таба барды. Ак юрганга төренгән кырлар, урманнар кайчандыр яшелләнеп утыргандыр, мең төрле авазлар сирпеп, яшәү сулышы белән сулагандыр һәм ул киләчәктә тагын терелер дип ышанырлык та түгел иде. Гәрчә бу аклык күз явын алырлык һәм кышкы табигатьнең хозурлыгын сүзләр белән генә әйтеп җиткереп булмаса да, әлеге бөек гүзәллек яшәешкә тынычлап хәл җыярга, шытып чыгып, чәчәк атып, үсеп, күкрәп-яшьнәп алыр өчен һәр тереклеккә, һәр үсемлеккә ял бирәдер дип ышанасы һәм әйтәсе килә. Юкка гына ак төс белән капланмыйдыр язын гөрләп чәчәк атасы табигать. Моның үз сере бардыр. Чисталыкка юкка гына төренмидер киләчәк яшәеш.

С.га җитәрәк Фәрит:

— Монда озак тормыйбыздыр бит? — дип сорады.

— Мин Тәлгать абыйларга кереп чыгам. Ә син кибеттә озак буласыңмы соң?

— Юк. Кирәк әйберне алам да...

— Шулай булгач, озак тормабыз. Лесхозга юл ничек икән?
— Әйбәт булырга тиеш. Аны гел чистартып торалар.
Фәиз нык дулкынланды. Аның хәтта, машинадан төшеп калып, ап-ак кыр буйлап кире якка юл тотасы да килде. Кызганыч, бөтен халәтне Фәриткә сөйләргә ярамый. Берничә тапкыр тыны кысылып, башы әйләнеп куйды. Юл буена бер генә тәмәке дә капмады — тәмәке тартса, күңеле болганачак иде.
Фәрит аңа карап-карап сорады:
— Хәл авыр мәллә?
— Бераз күңел болгана.
— Кан басымың түбәндер синең.
— Күтәрелә дә, төшә дә бугай ул шунда.
— Бу яшьтә иртәрәк әле, туган. Япь-яшь килеш кан басымы белән интегү ай-һай. Дәваланырга кирәк.
Кибет янына туктагач, Фәиз җәяүләп кенә Тәлгатьләр йортына китте. Аларның капка төбендә берәү кар көри иде. Якынлашкач, аның хатын-кыз икәне ачыкланды.
— Исәнмесез!
Хатын тирләп-кызарып чыккан битен калкытты. Бу — Тәлгатьнең хатыны Нәҗибә иде.
— Исәнмесез.
— Сез мине танымыйсыздыр инде. Мин — Фәиз.
— Юк, танымыйм,— диде Нәҗибә, хәтерендә казынып.— Кем соң син?
— Тәлгать абый өйдәме?
Нәҗибәнең бит алмалары кинәт агарып китте, ияге дерелдәп алды, газап белән чырае мыймылдады:
— Өйдә түгел шул Тәлгать абыең. Юк инде Тәлгать абыең.
— Ничек юк?
— Үлде Тәлгать абыең.
— Гафу итегез. Кайчан?
Бу сорауны ник биргәненә шундук үкенеп тә куйды.
— Мартта.
— Белмәдем. Гафу итегез.
Ул китәргә дип борылгач, Нәҗибә:
— Кем соң син? — диде.
— Сез оныткансыздыр инде. Ике ел ярым элек мин сездән бурычка егерме биш сум алган идем.
— Ә-ә-ә, әйе, әйе, хәтерлим,— диде Нәҗибә ыңгырашкан сыман итеп.
— Нишләп үлде соң ул? Яшь иде бит әле.
— Үлем ул яшен-картын араламый. Инфаркт булды аңа.
— Ярар, гафу итегез. Мин киттем. Сез белмисезме, лесхозга юл яхшы микән?
— Белмим.
— Ярый, сау булыгыз.
— Лесхозда берәр кемең бармы әллә? — диде Нәҗибә.
— Лесхоз директорын күрәсе бар. Исемен генә оныттым менә...
— Сәлим Сәлмәневич.
— Әйе, әйе, Сәлим Сәлмәневич.
— Кемең соң ул синең?
— Беркемем дә түгел. Аның улы белән бергә хезмәт иттек.
— Төрмәдә түгелме соң аның малае?
— Төрмәдә түгел, дисбатта. Әтисен күреп сөйләшәсем килгән иде.
Фәиз тизрәк китәргә омтылды.
— Ярый, сау булыгыз.
Нәҗибә аңа бик шикләнеп карап торды да:
— Бар тизрәк почтага,— диде.— Лесхозга барып йөрмәсәң дә була. Мин әле яңа гына ипи кибетеннән кайттым. Поселокка килде ул, почтага кереп киткәнен күрдем.

— Шулаймыни! — диде Фәиз шатланып.— Алайса чаптым мин. Рәхмәт. Сау булыгыз.

Ләкин йөгермәде, адымнарын гына кызурак атларга тырышты. Сәлимне бер тапкыр да күргәне юк, әмма никтер каушата. Монда, поселокта, булуы әйбәт. Лесхозда бөтенләй коелып инәр иде. Монда урман түгел, иркенрәк. Сазлык та ераграк. Нәрсә турында сөйләшергә аның белән? Ренат турында инде. Ә минем бит күбрәк башка нәрсә турында сөйләшәсем килә иде. Сазлык турында! ТЕГЕ УРЫН турында! ТЕГЕ ВАКЫЙГА турында ярамый. Фәкать ТЕГЕ УРЫН тирәсендә әңгәмә корырга кирәк. Почтадан чыгып китмәгән булса ярар иде. Ул аның төскыяфәтен белмәсә дә, таныйсына ышанып барды.

Чыннан да, ул аны бер күрүдә таныды. Почтадагы биш-алты кеше арасында уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, нык гәүдәле кешенең гади поселок кешесе түгеллеген әллә кайдан чамалап була, затлы тун, башындагы алтын төсле төлке бүрек, теләсә кем кими торган унты — болар барысы да аны башкалардан аерып тора иде.

Ул инде эшен тәмамлаган икән, куян тиресеннән тегелгән олы бияләйләрен кулларына кияргә әзерләп, ишеккә таба юнәлде. Шунда Фәиз аның каршысында пәйда булды, каушаудан ул аның юлына аркылы төште диярлек. Сәлим начар гына киемле егеткә кырыс караш ташлады да аны әйләнеп узарга теләде.

— Сәлим абый, исәнмесез!

Фәиз бу кеше белән күрешкәнче үк каушый башлаган иде, моның сәбәбенә һич төшенә алмады. Хәзер инде үзен күргәч, бөтенләй югалып калды.

Сәлим, болай да бәләкәй күзләрен чекрәйтеп, егетне танырга тырышты.

— Исәнме,— диде ул, исәнләшүгә җавап бирергә кирәк дип табып.

Сәлимнең зур игътибар белән карап торуы Фәизне тәмам хәлсезләндерде.

— Сез Ренатның әтисе бит,— диде ул, кипкән иреннәрен чак кына кыймылдатып.

Сәлим никтер як-ягына карады.

— Әйе. Әйдә, чыгыйк,— диде ул сөйләшкәннәрен ишетерләр дип шикләнеп.

Алар урамга чыктылар.

— Без Ренат белән бергә хезмәт иттек. Белоруссиядә. Аннары Забайкальеда. Тик төрле полкларда.

Сәлимнең йөзе кинәт караңгыланды, авыр сулап куйды.

— Шуннан? Куандырырлык сүзең юктыр бит? Әллә аның дисбатта икәнлеген әйтергә килдеңме? Аны син әйтмәсәң дә, беләбез.

— Юк, Сәлим абый, алай түгел. Мин шуны әйтмәкче булам. Мин Ренатны яхшы беләм. Ул тырышып хезмәт итте. Чын солдат ул. Сугышу була инде ул. Сез бик кайгырмагыз. Вакыт тиз үтә. Мин фәкать аның яхшы хезмәт иткәнен сезгә җиткерәсем килгән иде. Ул бит горур, үзе өчен нык торучы егет, сәбәбе шул. Хәрби хезмәте буенча хилафлык китермәде ул.

— Шул әйбәт булганы өчен төрмәгә тыгып куйдылар инде аны! — диде Сәлим, тешләрен шыгырдатып. Аның бу нәфрәте улы дисбатка эләгүдән генә түгел, гомумән, шундый күңелсезлек килеп чыгып, башка бәла төшүдән иде.

— Төрмә түгел бит ул, дисбат,— дие Фәиз.

— Син нәрсә, дисбатның ни икәнен белми дип уйлыйсыңмы әллә мине?!

Сәлим аңа текәлеп карап торды, аның бу карашыннан Фәиз нык уңайсызланды.

— Минем бит сине кайдадыр күргәнем бар,— диде Сәлим күзләрен чекрәйтеп.

— Сезнең дә йөзегез миңа таныш,— диде Фәиз куркып.
Сәлим елмайды, ләкин бу елмаю ямьсез килеп чыкты.
— Син нишләп йөрисең соң монда?— диде лесхоз директоры һәм сәгатенә карап алды.
— Мин... сезнең янга лесхозга бара идем. Сезне монда, диделәр.
— Лесхозга?
— Әйе.
Фәизгә начар булып китте. Саф һавада басып торсалар да, аңа һава житмәде.
— Кем әйтте минем монда икәнемне?
— Нәжибә апа. Мәрхүм Тәлгать абыйның хатыны.
Хәзер инде Сәлимнең елмаюы тагын да киңрәк һәм шул ук вакытта тагын да ямьсезрәк килеп чыкты.
— Синең миңа соравың бар шикелле.
Фәиз үзен кая куярга белмәде, бермәлне йөгерәсе, качасы килде, ләкин йөгерерлек хәле юк иде. Юк, булмады, сазлык турында ничек сорашырга соң хәзер. Булмый. Болай да шикләнә ул миннән. Әйтерсең лә, нәрсәдер белә. Гүя, хәбәрдар. Ник алай серле итеп карый, ямьсез итеп елмая.
— Мин Ренат турында жылы сүз әйтү нияте белән генә сезнең янга барырга чыктым.
— Рәхмәт, рәхмәт. Ренат турында яхшы сүзләр сөйлисең, димәк, сез дуслар булгансыз?
Дуслар булмасалар да, Фәиз:
— Әйе,— диярга мәжбүр булды.
— Тыярга, сугышмаска өндәргә иде аны. Дус кешене сакларга кирәк бит ничек тә.
— Без... анда... Забайкальеда төрле полкларда идек шул. Сез, Сәлим абый, миңа бик сәер карыйсыз. Миннән шикләнәсезме, әллә берәр нәрсә өмет итеп килгән дип уйлыйсызмы?
— Юк, төрле фәлсәфи уйлар килә башка. Мәсәлән, минем улым төрмәдә утыра, ә син иректә саф һава сулап йөрисең!
Сәлимнең кыяфәте яман усалланды, һава салкын булуга карамастан, куе каш өсләре тирләп чыкты.
Фәиз өчен каты удар булды бу. Шул гомере буе болай да иректә йөрүенә үзен-үзе битәрләп жәфаланучы кешегә башка берәү шул ук фикерне әйткәч, әлбәттә, үзеннең гаебеңне бермә-бер арттырып таный башлыйсың. Шулай да, абзыйның әйткән әлеге сүзләре кинәт аңарда протест та уятты.
— Ник алай дисез? Мин дә төрмәдә утырырга тиешмени?
— Анысын белмим. Мин болай гына әйттем. Син армиядән кайткансың, ул юк, шуңа күрә генә әйтүем.— Ул тагын сәгатенә карап алды.— Ярар, минем әле сельпога кереп чыгасы бар, машинам да шунда киләчәк. Рәхмәт Ренат турында жылы сүзләр алып килүең өчен. Ә шулай да сине монда алып килүче сәбәп ул гына түгел.
— Туктале, Сәлим абый, ник алай дисең?
— Кыяфәтеңнән күренеп тора.
Фәиз калтырана башлады:
— Нәрсә күренә минем кыяфәтемнән?
— Дустыңны бәладә ташлап кача торган кеше икәнлегең күренә кыяфәтеңнән.
— Мин Ренатны берничек тә коткара алмас идем!
— Мин гомумән әйтәм!
Сәлим китеп барды. Аның олы итекләре астында шыгырдаган кар тавышы Фәизнең баш миенең үзәгендә яңгырап торды.
Бетерде, үтерде! Берәр нәрсә беләме бу кеше, әллә чынлап та кыяфәтемнән бөтен эчке халәтем күренәме? Аннары... Кайда күргәнем бар минем аны?..» Ул аның артыннан йөгерде:

— Сәлим абый, тукта әле!
Теге туктады:
— Нәрсә?
Фәиз ни әйтергә белмәгәч:
— Мин монда Тәлгать абыйны да күрермен дип килгән идем,— диде ул, акланып карамакчы булып.
— Үлеп китте шул,— диде Сәлим ясалма үкенү белән.— Нишләп кыяфәтең аламаланды? Чирлисеңме әллә?
— Сәлим абый, син миннән шикләнәсең! — диде Фәиз һәм төссезләнгән күзләре белән табак биттән нәрсә дә булса «укымакчы» булды.
— Син үзеңнән-үзең шикләнеп йөрисең,— диде Сәлим коры гына.— Син кайгырма. Киләчәк күрсәтер — тәкъдиреңә ни язылгандыр...
— Нишләп әллә ничек аңлашылмый торган итеп сөйләшәсең минем белән?
— Син нәрсә эзлисең тагын бу тирәдә?
— Эзләмим. Сезнең янга баруым иде. Шуны да әйтәсем килә. Сезнең урман артындагы сазлыкларда дару үләннәре бар. Миңа дару үләннәре кирәк.
— Кыш көне үлән үсми бит,— диде Сәлим һәм сынап карап торды.
— Алдан сөйләшеп, сезнең белән киңәшләшеп, миңа кирәк үләннәр үсәме икәнне белмәкче идем.
— Алай гынамы икән? Шулай да, нишләп тагын бу тирәдә йөрисең син?
— Нишләп ТАГЫН?!
— Ничек курыкмыйсың безнең урманнар тирәсендә йөрергә, ә? — Ул тагын күзләрен чекрәйтеп карап торды.— Әле, җитмәсә, минем янга урманга ук бармакчы булгансың, хи-хи-хи. Син җәй көне кил, сазлыклар ачылгач. Мин сиңа экскурсия оештырырмын шул тарафларда.
Фәиз телсез калды. Башы кинәт әйләнеп китте. Сәлим тагын нәрсәдер әйтте, әмма Фәиз инде аның сүзләрен ишетмәде. Нәрсәгә дә булса таянырга, тотынырга кирәк иде.
Ул почта стенасына барып сөялде, үзенең халәтен аңларга тырышты. Һәм аңлады: бу — курку иде. Курку әсир итте, бөтен тәне куырылып килде, башы гүләде. Ул үзенеке түгел, курку колы иде бу минутта. Аның эчтәге иң кадерле бер хисен — газаплы кайгысын ят кеше күрде. Бәлки элегрәк белгәндер. Барыбер түгелмени?! Аның халәтенә, чирләвенең сәбәбенә чит кеше төшенгән түгелме?! Сер түгел икән яшереп йөргән уйлары, башкаларга да мәгълүм икән ләбаса! Алайса нишләп һаман төрмәгә утыртмыйлар? Әллә үземне-үзем бимазалап йөрүемне күреп, җәза бирми торалармы?
Каты җилтерәтүдән генә һушына килде ул. Фәрит, шаккатып аңа карап тора иде.
— Нишләдең? Ни булды?
— Булмады.
— Төсең качкан. Кайчаннан бирле эндәшәм үзенә. Чирлисеңме?
Фәиз иелеп бер уч кар алды һәм авызына капты.
— Юк, Фәрит, чирләмим. Лесхоз директорын очраттым мин.
— Кайда?
— Почтадан чыгып килә иде.
— Шуннан? Әйдә машинага кереп утыр, аннары сөйләрсең. Алар юл читендә калдырган машиналарына кереп утырдылар.
Фәиз авыр сулап үтенде:
— Тәрәзәне ачам мин, яме.
— Ач, ач. Нәрсә булды?
— Миннән шикләнә. Мыскыл иткән сыман да шунда. Кайдадыр күргәнем бар ди мине.
— Бернәрсә аңламыйм. Әллә улы дисбатта утыруда синең гаебең бармы?

— Бар,— диде Фәиз, сорауның мәгънәсен аңламыйча.
— Синең аркада утырмагандыр бит?
Фәиз мондый халәттә ничектер җиңел алдаша, сораштырып төпченүләрдән саклана ала иде. Бу юлы да фантазиясе искиткеч яхшы эшләде:
— Армиядә учение вакытында сазлыкта бер иптәшебез батып үлде. Без өчәү идек. Ренат, мин һәм теге батып үлгән егет. Шуны коткара алмауда гаепләделәр безне. Дөресрәге, коткармауда.
— Нишләп соң Ренатны гына утырттылар дисбатка?
— Чөнки Ренат аның белән янәшә атлап барган иде, мин арттарак бардым.
— Алай булгач, синең гаебең юк ла монда.
Фәрит машинасын кабызды.
— Кая барабыз?— диде Фәиз сискәнеп.
— Лесхозга бармыйбыздыр бит?
Фәиз кычкырып җибәрде:
— Юк!
Фәрит сискәнеп китте,:
— Нишлисең син, Фәиз! Тынычлан инде!
— Син дә шикләнәсеңме миннән?— диде Фәиз аптырашта калган Фәритнең туң җиңен умырып тотып.
Фәрит, дусларча елмаеп, аның иңенә төртеп куйды:
— Син нәрсә инде, күрше. Борчылма син. Аның малае төрмәдә утыра дип, син дә үз теләгең белән төрмәгә барып утырмассың бит инде. Син шул вакыйга аркасында кайгырып йөрисеңме әллә гел?
— Әйе,— диде Фәиз, Фәритнең күзләренә карап. Ул аның җиңен һаман җибәрмәгән иде әле.
— Әйтәм бик сәерләнеп, кешеләр белән аралашмыйча йөрисең. Сәбәбе аңлашылды хәзер. Синдә гаеп юктыр бит? Гаебең булса, сине дә утырткан булырлар иде. Кайтабызмы?
— К. гәме?
Фәрит көлеп җибәрде:
— Шунда булмый, кая кайтасың инде тагын! Лесхоз директорыннан нык курыккансың син.— Ул машинаны кабызды.— Ничего, аның улы да исән-сау әйләнеп кайтыр. Тынычлан. Төсең бөтенләй качкан. Нәрсә диде соң ул сиңа?
— Кайдадыр күргәнем бар, диде.
Фәрит сөйләшүдә мәгънә юклыкны аңлады. Машина ап-ак басу буйлап сузылган бормалы юлдан К. гә таба китте.
Фәизнең киеренкелеге бераз басылды шикелле. Курку кимеде, әмма Сәлим әйткән сүзләр колакта яңгырап торды. Ул әйткәннәрнең иң куркынычлары гына яңгырады колакта. Хәзер инде уйланырга, газапланырга мөмкинлек, җирлек киңәйде. Яңа сәбәп бар хәзер казынырга.
Машина сикерткән саен як-якка әвеш-тәвеш килеп, ул үзалдына мыгырдап утырды:
— Кайдадыр күргәне бар. Ничек ди... соравың бар шикелле миңа диме? Улым төрмәдә, син иректә, диде ул миңа.
— Төкер син ул әйткәннәргә,— диде Фәрит, аның мыгырдаганына колак салып.
Фәиз аңа игътибар итмәде:
— Сине монда алып килүче сәбәп бу гына түгел, диде. Нәрсә белә соң ул ямьсез кеше? Имеш, мин үземнән-үзем шикләнеп йөрим. Нишләп ТАГЫН бу тирәдә йөрисең ди бит әле ул, кабахәт! Тагын! Димәк, минем инде бер тапкыр ул урманнарда адашып йөргәнемне белә. Ә бәлки С. больницасында ятуымны гына беләдер? Шунда күргәне бардыр аның мине. Юк, юк, ул күбрәк белә. Ничек курыкмыйсың бу тирәдә йөрергә, диде бит ул миңа.
Машина туктады. Фәрит күршесенең иңенә төртте:

— Син, туган, саташа башладың бугай.

Ул чын-чынлап курыккан иде.

Фәиз аңа берни аңышмыйча карап торды:

— Ни дисең син?

— Саташасың мәллә дим!

— Юу-у-ук,— диде Фәиз гаҗәпләнеп. Ул үзенең машинада баруына, рульдә Фәрит утыруга гаҗәпләнде, күрәсең.

— Син әллә ниләр сөйләнеп барасың, курка башладым. Хәлең ярыйсымы соң синең?

— Мин дә куркам бит,— диде Фәиз, кинәт тынычланып. Бу битарафлык тынычлану түгел, бәлки киеренкелекне тотып торырга вөҗүднең хәле бетеп китү галәмәте иде.

Фәрит скоростька салып машинаны кузгатты һәм боерулы тавыш белән:

— Курыкма син! — диде.— Әллә кайда, әллә кем батып үлгән өчен кайгырып йөрмә. Булган, беткән.

Фәиз рульгә ябышып утыручы күршесенә озак карап торды.

— Юк, алай түгел шул ул. Алай тиз генә бетми икән бит ул!

— Коммунистлар «юк» дисәләр дә, Алла барыбер бар ул. Шуңа күрә, кем гаепле, кем гаепсез — күктә беләчәкләр.

Фәиз күзләрен акайтып күршесенә якынайды:

— Менә шуңа күрә куркамдыр мин бәлки.

— Гаепле түгел икәнсең, аны Алла да беләчәк, димәк, куркасы юк. Әгәр инде гаебең бар икән — кайгырудан шулай ук мәгънә юк. Рас төзәтеп булмый.

— Ничектер төзәтеп буладыр шикелле тоела бит! Ничек инде... Алай гадел булмый бит ул. Ялгышлар, хаталар китүе ихтимал бит. Төзәтергә, үзгәртергә мөмкинлек калырга тиештер бит кешегә.

Фәрит бу әңгәмәдән тәмам туйды.

— Әйдә, сөйләшмичә утырыйк әле бераз,— диде ул аптырагач.

Фәиз исә аның белән сөйләшми, аңа әңгәмәдәш бөтенләй кирәк түгел иде. Ул тагын үзалдына мыгырдана башлады:

— Ничек инде кайгырудан мәгънә юк?! Ничек инде кайгырмыйсың?! Ул бит миңа коточкыч сүзләр әйтте: «Җәй җиткәч, сазлыклар ачылгач кил...»

Фәрит түзмәде, тагын сүз катты:

— Син ул Байкал артындагы сазлыклар турында уйлама инде, зинһар!

Фәиз кырт кисте:

— Забайкальеда сазлыклар юк!

Фәрит башын чайкады һәм үзалдына сүгенеп куйды.

Фәиз мыгырдавын дәвам итте:

— Сазлык турында уйламыйча нәрсә турында уйлыйсың! Лесхоз директоры сазлыкка чакырды бит. Мин сиңа экскурсия оештырам дип көлде ул, аңлыйсыңмы! — Ул машина ишегенә сөялеп утырды, күзләрен йомды.— Бәлки аның минем турында белүе яхшырактыр. Бәлки тиздән ачыкланыр барысы да. Бәлки чик куелыр. Болай дәвам итәлмый бит инде гомер буе.— Ул күзләрен ачты.— Ничек кенә булмасын, Фәрит, син мине ничек кенә тынычландырма, ә шулай да кулымны җитәрлек итеп сузмадым мин.

Фәрит дәшмәде.

## 8

Тулай торакка кайткач, Фәиз рәхмәт йөзеннән күршесен аракы белән сыйламакчы иде:

— Әйдә, бер ярты ак аракы бар, салабыз.

Фәрит баш тартты — әллә аракыдан вакытлыча җаны бизгән, әллә Фәиздән туйган.

Фәиз өчен исә бу тагын күңелдәге утка коры утын өстәгән сыман булды: «Нишләп әле ул миннән кача, минем белән утырып бер ярты салырга да теләми?!»

Шул ук вакытта аның тизрәк ялгызы каласы да килде, чөнки Сәлим белән булган әңгәмәне башыннан ахырына кадәр «сүтеп җыясы» бар иде. Фәрит качмас, аны аңларга тырышырмын, әле вакыт бар. Ә менә лесхоз директоры Сәлим...

Нәрсәдер мәгълүм аңа! Хәзер ничек аның янына бармак кирәк?! Аның янына гына түгел, гомумән, ул урманга барырлык хәл юк. Сазлыкка бару турында уйларга да кирәк түгел! Хәл җитмәячәк УЛ УРЫНГА барырга.

Ул, шешәне ачып, ярты стакан аракы салды. Эчеп, артыннан ипи ашагач, бүлмә җылынып киткәндәй булды. Аракы эчкәч, уйлануы җиңеләйде.

Сәлим шикләнсә ни булган! Нишләп әле мин кешедән куркам?! Кешенең миңа мөнәсәбәте ник уйландыра мине! Кеше минем турыда фәләнне уйлар дип, нишләп кайчаннан бирле куркып йөрим соң мин?!

Бу сорауны үзенә еш бирсә дә, кешеләрдән, аларның фикерләреннән курку аны һаман ташламады. Кешеләрнең мөгамәләсенә бәйле булу аны нык чирләтте. Иң авыр халәте — берәр кешенең үзенә карата шикләнеп караудан барлыкка килә иде. Бигрәк тә җан сызлаган вакытта, күзләр төссезләнеп, баш томаланып, кыяфәте тиле кешенекенә охшаган чакларда тирә-яктагылар сәерсенеп, аның тышкы кыяфәтеннән нәрсә дә булса «укырга» тырышып караганда читен! Андый минутларда әллә нинди каты үлем җәзаларына да ризалашыр сыман тоела иде аңа. Моны аңларга тырышты ул, әмма һич кенә дә төшенә алмады. Югыйсә ТЕГЕ ВАКЫЙГА өчен хөкем ителеп төрмәгә утырудан да курыкмый бит ул. Курыкмый, курыкмый, бу хакта озак һәм күп уйланды инде. Дустын БАТЫРЫП үтергәне өчен ул җәзаны һичшиксез алырга тиеш. Шулай булгач, нигә куркырга кешеләрдән?! Бигрәк тә, тубал башлы лесхоз директорларыннан. Аның ни хакы бар шикләнеп, төрттереп, мыскыл итеп сөйләшергә?! Аның улы кеше кыйнап... Аның улы кансыз, рәхимсез җан. Шундый баланың атасы булгач, аның ни хакы бар мине хөкем итәргә?! Йа ходам, хөкем итми ләбаса ул мине. Шулай да, аның минем белән төрттереп сөйләшүе хөкем итүгә тиң түгелме соң? Минем турыда нәрсә дә булса белә икән, аның ни хакы бар мине интектереп турыдантуры сөйләшмәскә?! Юк, юк, Сәлимне тагын бер очратырга кирәк! Бераз хәл кергәч, яз җиткәч.

Ул тагын салып эчте. Тартылып-кысылып калган гасаб җепселләре киңәеп, спазмалардан арынган кан тамырларына яшәү биреп, кан йөгерде.

Барасы калмаган бүген С.га! Ничектер, уңышсыз булды анда бару, курку гына артты. Алай дисәң, барыбер барырга кирәк иде. Кайчан булса да.

Берәрсе белән уртаклашырга иде кайгым белән. Мәсәлән, кем белән уртаклашырга мөмкин икән?.. Юк, беркем белән дә булмый бу турыда сөйләшеп. Ышанычлы, таянычлы кешеләр беткән микәнни дөньяда? Юк, алар бар, ләкин Зәбирне сазлыктан чыгарып терелтү мөмкин түгел барыбер!

Фәиз әле иң мөһимен аңламый иде. Кешегә үзеңнең хәлеңне сөйләр өчен бит иң элек үзеңне аңларга кирәк. Ул әле аңламый иде: үзенең халәтен дә, шул халәтнең төп сәбәбен дә.

Газабы турында дәшмәве, кешеләргә үзенең күңелендәге хәлләрне ачмавы — кеше хөкеменнән куркудан иде шикелле. Әмма ләкин бу — чын КУРКУ түгел, гомумән, хөкемнән, җәзадан курку түгел иде. Күңелендәген ачып салса, ул бит кешеләр хакимлеге астында калачак. Аны бит кешеләр хөкем итәчәк, Алла түгел. Аңа исә Алла хөкеме кирәк! Кешеләр хөкеме түгел!

Үтеп киткән, дөресрәге, яшәлгән егерме елдан артык гомер аның өчен «үткән заман» түгел. Бигрәк тә ТЕГЕ ВАКЫЙГА. Ул «үткән заман»

аныкы, бары тик үзенеке генә. Ул аның үткәннәре түгел, бәлки бүгенгесе! Чөнки үзенә алган әхлакый җаваплылык аның эчке асылын һәм чынбарлыкта үзен тотышын шәхес дип аталган бер төшенчәгә бәйләп төйнәп куйган инде.

С. дагы бүгенге очрашу зур киртә сыман калыкты. Аның МӘҢГЕЛЕК СОРАВЫНА җавап эзләгәндә юлда бер комачау булып чыкты. Төпченергә, сорашырга иде. Каян белә ул һәм нәрсә белә?

Шешә яртылаш бушады. Ул, тәмәке кабызып, коридорга чыкты. Анда Фәрит тәмәке тартып тора иде.

— Ничек хәлләр? — диде Фәрит, елмаеп.

Фәиз игътибар белән күрешесенә карады, Фәритнең һәрвакыт мөлаем йөзендә ул үзенә карата бернинди шик-шөбһә, ачу яисә үпкә-мазар күрмәде.

— Ярыйсы. Салдым бераз. Әйдә, иптәш өчен булса да, бераз сал инде минем белән.

Фәрит тәмәкесен ишек төбендәге чүп чиләгенә төкереп ташлады да, уң кулын йөрәк турысына куеп, гафу үтенгәндәй:

— Рәхмәт, туган. Аракыдан беркавым ял итәргә кирәк. Бу арада болай да күп эчелде,— диде.

— Син тәмәкегә баймы?

— Тәмәкең беттеме әллә?

— Әйе, төнгә кирәк булачак. Булса, бер-икене бир әле.

Фәрит:

— Хәзер,— дип кереп китте.

Ул озак тормады, бер кап «Астра» тотып чыгып җитте һәм күршесенә сузды.

Фәиз, аптырап, алмыйча торды:

— Бөтенләе белән миңамы?

— Сиңа, сиңа, тартынма, ал. Рәмзия Каенсар кибетендә эшләгәндә күп итеп алып куйган булган. Миңа ЛТПга посылка белән җибәрер өчен. Унлап пачкасы һаман исән әле.

— Рәхмәт.

Фәиз, кинәт тәмәкеле булып куюына карамастан, күңелсезләнеп китте. Каенсар, кибет, Рәмзия, ЛТП...

— Син тагын коелып индең әле,— диде Фәрит, аның чырае караңгылануга чын күңелдән борчылып.

— Ничәнче елларда эшләде әле Рәмзия Каенсарда? — диде Фәиз, үзендә киеренкелек тоеп. Аның соравы таләпчән һәм кичектерергә һич ярамаган сыман яңгырады. Җавап хәзер, кичекмәстән, шушы мизгелдә үк кирәк иде аңа. Гүя, бу җавап мөһимрәк, бөегрәк сорауга җавап бирүгә турыдан-туры бәйле иде.

— Ике елга якын. Җитмеш сигездән сиксәненчегә кадәр. Мин ЛТПдан кайткач та эшләде әле ул анда. Ник алай сорап куйдың?

Фәрит тә аның бу соравыннан пошаманга калды.

— Мин ни... болай гына. Син, Фәрит, гафу ит алай сораганым өчен. Без детдомнан Каенсарга бәрәңгегә барган вакытта эшләмәде микән дип соравым иде минем.

Фәрит гаҗәпләнеп карап торды:

— Ник, ә ул вакытта эшләгән булса, мәсәлән?

Фәиз ни әйтергә белмәде — чыннан да, аерма юк лабаса, ул вакытта эшләгәнме, юкмы. Шулай да үзен-үзе саклар өчен оста алдашуга соңгы вакытта маһирланды ул. Әллә нинди уңайсыз чакларда да әңгәмәдәшен алдап, адаштырып калдыру сәләтенә ия була башлады. Гомумән, хәле, сәламәтлеге отыры начарлана барган саен алдап, ялган сәбәпләр табып, теләсә кемне ышандыра, үзенең авыр хәлетен акларлык дәлилләр таба һәм үзенең серен ачмас өчен дөньяның иң зирәк инсанын да саташтырырлык сәләтне үзендә тоя башлады.

Хәзер дә җиңел генә ялганларга тотынды:

— Минем кылт итеп исемә төште: җитмеш бишенче елны Каенсарга бәрәңге алырга баргач, шул авылның кибетендә мине алдадылар. Сатучы хатын бозык консервылар бирде. Ә мин бөтен төркемебез өчен алган идем — унсигезе дә срогы чыккан, бозылып сасыган балык консервылары иде. Шул искә төште...

Фәрит шатланып елмайды:

— Ю-ук, Рәмзия әле ул вакытта укый гына иде.

Ул нык сөенде. Рәмзия турында тагын әллә ниләр ишетермен дип курыккан иде көнче ир. Каенсардагы берәр мәхәббәт маҗарасын әйтеп бирерләр дип котсыз калган иде ул.

— Башка сатучы булган ул, Рәмзия әле укый иде ул вакытта,— дип өстәде Фәрит.

Фәиз исә инде үзенең уйларына чумган иде. Фәрит моны сизеп алды һәм кулын сузды:

— Тыныч йокы. Ятып йоклыйк. Иртәгә бәйрәм түгел, эшкә. Синең дә кыяфәтең арыган. Ял ит.

Фәиз җавап бирмәде һәм саубуллашырга да онытып, үзенең бүлмәсенә кереп китте.

Тагын ярты стакан аракы эчте, хәтта артыннан ипи дә капмады. Аракы исертмәде, киресенчә, көндез кичергән киеренкелектән, башындагы уйлар көченнән арындырды, айнытты. Бүлмә буйлап ары-бире атлады ул. Рәмзия булган, димәк, теге кибетче хатын! Әйтерсең лә, зур ачыш ясады — кинәт илһамланып, дәртләнеп китте. Ул бит хәтерли, аермачык хәтерли Зәбирнең сөйләгәннәрен. Каенсарга барып, алтын балдакны кибетчегә сатып, ашарга алып килгәндә Зәбирне бер милиционер куып тотты юлда. Агачлар арасыннан үзе күреп торды. Нык курыкты ул анда. Эләктек дип. Сатучы хатынның көнче сөяркәсе булып чыкты ул. Рәмзия дә сөйләде бит ул милиционер турында. Бөтенесе туры килә. Кызык. Сәер, бигрәк тар бу дөнья. Әллә Рәмзияне уятып сорашырга микән? Юк, ярамый, Фәрит дөрес аңламас, көнләшер, аның белән сөйләшүдән ни мәгънә? Иртәгә Рәмзия белән сөйләшергә кирәк. Зәбир шул хатынга саткан бит алтын йөзекне. Димәк, Рәмзия, күрше бүлмәдә генә ятучы Рәмзия дә фаҗигадә. Гаепле кеше буларак түгел, болай, гомумән, аның да катнашы бар ТЕГЕ ВАКЫТТА һәм ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА.

Аның сөяркәсе — милиционер. Камил бугай. Рәмзиянең ирен ЛТПга утыртып, Рәмзияне куркытып... Ә минем ни эшем бар ул Камил кылган эшләрдә? Ник борчылам әле мин Рәмзияләр, Фәритләр, Камилләр өчен?

Ул туктап караватына утырып карады, ләкин тыныч кына утырып булмый икән — тагын торып йөри башлады.

Туктале! Шул Камил гаепле түгелме соң ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА? Ул ихлас күңелдән хезмәт итүче милиционер булса, Зәбирдән шикләнер һәм аны кулга алыр иде. Әгәр шул вакытта Зәбирне мотоциклына утыртып отделга алып китсә, уголовный розыскка җинаятьчеләрне эзләү бүлекчәсенә тапшырса, ТЕГЕ ВАКЫЙГА булмас иде ләбаса! Зәбир исән калыр иде. Тиешле срокны утырып чыгарлар иде дә калган гомердә җан тыныч булыр иде.

Рәмзия эшләде микән соң ул кибеттә? Шулдыр, чөнки җитмеш сигезенче елны булды бит ул хәл. Шул инде, шул! Зәбирнең теге милиционердан котылгач килеп сөйләгәннәре белән Рәмзия сөйләгән туры килә бит.

Фәиз кулларын угалап алды. Ник сөенгәнен үзе дә белмәде. ТЕГЕ ВАКЫЙГАГА бәйле кешеләр килеп чыгуы куандырды, ахрысы, аны. ШУЛ ВАКЫЙГАГА аз гына булса да кагылышлы кешеләрнең табылуы аның ШУЛ ВАКЫТ белән яшәвенә ярдәм итә иде. ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ хәтердә яңартыр өчен шәп ул, ә онытмау ихтыяҗы көчле, һай көчле!

Сәлим очрап котны алуы гына әлегә зур табышмак булып кала бирде. Башка кешенең ТЕГЕ ВАКЫЙГА хакында хәбәрдар булуы шулкадәре коточкыч тоелды, хәтта моны күз алдына китерүе дә кыен иде. Аның күз алдына тагын ТЕГЕ УРЫН килде.

Сазлык. Мүк, торф, су исе. Тынчу. Әнә теге куак. Менә түмгәк. Түмгәктән тегендәрәк... Әнә ул — Зәбирнең башы гына калкып тора, инде куллары да күренми. Куе бөдрә чәчләре юешләнгән, күзләре акайган, авызын ачып кычкырмакчы була, инде авызына су да тулды бугай. Зәбиргә дә охшамаган бит инде ул. Юк, Зәбир ул! Әнә инде юкка да чыккан. ШУЛ УРЫНДА су гына бераз бөтерелгән сыман, күбекләр генә йөзеп йөри.

Нишләп ныграк сузмадым кулымны, буем җитә иде ләбаса? Инде ничәнче кат үзенә шушы вәхши сорауны бирде ул. Ләкин җавап юк. Әллә соң булдыра алганчы сузмадыммы кулны? Бар көчемнән килгәнчә коткарырга тырыштыммы әллә? Бу сорауга да җавап юк. Нишләп үзеннән шикләнә соң ул? Димәк, ышанмый үзенә. Ышанмый икән, димәк, тикмәгә түгел!

Инде меңенче каттыр ШУЛ ВАКЫЙГАНЫҢ һәр мизгелен хәтерендә барлап, күз алдына китереп анализларга маташты. Сузды ул дустына кулын, сузды, ләкин тагын да ныграк сузу мөмкин иде түгелме? Ярар, бу сорауга җавап юк ди. Алайса минем исән калырга хакым бар идеме соң? Ул үзенә сорауны шулайрак куеп карады. Мин, үлемнән куркып, бар көчемне куймадыммы аны коткарырга? Үлемнән курыкканга үземне гаепли алмыйм бит инде. Туктале, алай микән? Рас инде, Зәбир белән бер сукмакка басканбыз икән, беребез исән калып, икенчебез батып үлү гаделме соң? Юк, сорауның боларына да шартлатып җавап бирү мөмкин түгел шул.

Мин бит йөгердем. Аның башы әле калкып тора иде, мин йөгердем. Әллә инде башы күренми башлагачмы? Юк, юк, аның башы сазлык өстендә үкерә иде әле. Ләкин аны йолкып чыгарырлык түгел иде бугай инде. Бугай. Аның куллары су өстеннән калкып торганда йолкырга тырышырга иде аны.

Эчкән аракыдан бары тик калтырану, авыз тәмсезлеге һәм нервылар киеренкелеге генә калды. Коточкыч хатирәләр нәтиҗәсе бу. Ул торып утырды, калган аракыны эчеп бетерде. Тагын тәнгә бераз җылы йөгергәндәй булып китте.

Хәзер менә бу сорауларга ничек җавап бирергә соң? Бу — сорауларга җавап эзләү түгел, үзенә ШУЛ ВАКЫЙГА өчен җәза эзләү иде. Гөнаһын юу ихтыяҗы иде бу. Сорауларга җавап эзләр өчен ул Т.га да барачак. Теге кибеткә дә керәчәк, хәле җитсә, сазлыкка да, тагын әллә кайларга да барачак һәм әллә кемнәр белән сөйләшәчәк.

Әгәр аның урынында мин батып үлгән булсам? Зәбир үзен гаепле санап бимазаланыр идеме? Көлке! Зәбир мине әллә нинди упкыннардан йолкып, сөйрәп чыгарыр иде. Ул бит мин түгел.

Әгәр аны коткарган булсам? Бөтен нәрсә башкача барыр иде, мөгаен, тормыш та, халәт тә, дөньялар да матуррак төскә буялыр иде.

Икебез дә үлгән булсак? Яхшырак булыр иде түгелме? Нишләп Зәбирне сайлаган соң үлем? Бәлки мине дә сайлагандыр, тик мин куркам бит үлемнән. Ә Зәбир курыкмадымыни?!

Мин үземне аклар өчен төрле-төрле сораулар уйлап чыгарам микән әллә? Мин бит гаепле, мин!

ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ күз алдына китереп, дустының яшәү өчен көрәшеп тыпырчынган мизгелләрен уйлаганда аның хәле авыраеп китә, җан газабы бөтен вөҗүден бер тораташ сын итеп буып ала. Дустының үлем белән көрәшкән мизгелләрен үзе кичермәкче булып, хыялларында әллә нинди газаплар уйлап чыгарса да, уйлануларының бер коточкыч мәле була. Газабының үре — бу фаҗигадә үзеннең гаебеңне тою! Үзенең гаепле, гөнаһлы икәнен тану аңа тынгылык бирмәде һәм бирергә җыенмады да.

Иртәгә тагын эшкә. Салкын, шыксыз, ямьсез МТСка. Җансыз тракторлар, машиналар, комбайннар, тимер-томыр, кап-кара киемле механизаторлар, мәңге исерек слесарьлар — бу күренешләрнең барысында нин-

дидер ямьсезлек бар иде. Яшәүчәнлек юк иде бу оешмада. Фәизгә монда үзенең газаплы уйлары белән яшәргә шартлар шактый уңай, чөнки ремонттагы агрегат тирәсендә көннәр буе үз көенә маташып була.

Ләкин монда сорауларга җавап юк, сөйләшер, аралашыр кеше дә күренми. Аның үзен сәер, кешеләр белән аралашмаучан дигән булалар. Монда ул аралашыр кеше бармы соң? Бәлки бардыр, тик аның кайгысын аңларлык кешеләр бармы соң монда? Гомумән, андый кеше бар микән бу дөньяда?!

## 9

Какшаган психиканы аракы хәйран тотрыклы итеп торды. Күңел тигезлегенә ирештерә иде ул. Эчкәч кыюлык арта, үзеңнең күп кимчелекләрең гаип була һәм, ниһаять, үзеңә ышаныч тоясың. Фәизнең кирәгеннән артык калыккан кимчелекләр комплексын аракы уңышлы гына җиңә башлады.

Салган баштан клубка танцыларга да чыккалады ул. Хәтта кызлар белән аралашты.

Айныгач авыр иде хәлләр — гүя, газаплы уйлар аның айныганын гына көтеп торалар. Ул төндәге спазмаларны, тын бетүләрне, шул вакытта башка килгән коточкыч уйларны һәм аңлатып булмаслык куркуны сөйләсәң, кеше ышанмаслык бит!

Гаеп хисе, гаеп хисе! Үткәннәр өчен, кичәге өчен, һәр кылган эше өчен үзендә гаеп сизде.

Шул сәбәпле, аның тәгаен аек көннәре бик сирәк була башлады. Аз-азлап аракы эчеп, ул һәрвакыт тонусын күтәреп, күпмедер дәрәҗәдә рухи тигезлеккә ирешеп йөрде. Газаплы уйлар аны ташламасалар да, халәте тотрыклы һәм җиңелрәк булды. Ә аңа бит газапның юкка чыгуы кирәк түгел, киресенчә, ул ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ һәм, гомумән, шуның белән бәйле кайгылы уйларны уйларга үзендә һәрчак ихтыяҗ тоя иде. Шул үзенең кайгысын «иркәләргә», җан сыкравын тәрбияләп «асрарга» физик көч кирәк — шуңа күрә аракы ярдәменә мөрәҗәгать итте ул.

Шулай кыш үтеп китте. Поселокта аның аралашкан кешеләре МТСтагы берничә эшче һәм тулай торакта Фәрит белән Рәмзия генә иде. Фәрит һәм Рәмзия белән ныграк һәм күбрәк аралашырга туры килде, чөнки аларның мөнәсәбәтләре гел эт кояшы сыманрак булып торды. Фәрит хатынын еш кыйнады, көнләшүдән һич туктамады. Тулай торакта аларны бердәнбер аралаучы Фәиз иде, башка күршеләр тыгылмадылар. Фәрит Фәизне дә бер тапкыр сугып аударды, ләкин аңа карап аралары бозылмады, бер-берсен аңлаштылар, гафу иттеләр. Фәиз шуны аңлый алмады: ник аерылышмый алар? Балалары юк, бүләсе малларын ике чемоданга тутырып була. Юк! Имеш, яраталар бер-берсен. Рәмзиясе дә, күз төпләре кара янып, чәчләре йолкынган суәттә дә: «Яратам!» — ди. Тегесе дә айныгач, елап, гафу үтенеп хатынына: «Яратам, синнән башка яши алмыйм!» — ди. Фәизнең инде үзенә ант та биргәне бар, үзенә генә түгел, бер тапкыр Рәмзиягә дә, Фәриткә дә әйтте: «Моннан соң бер-берегезне суешсагыз да, араларга кермим!» — диде. Гаҗәеп хәл: барыбер бергә торалар. Инде бер-берсенә әйтмәгән әшәке сүзләр калмады, бер-берсенең башына сукмаган әйбер калмады. Барыбер бергә йоклыйлар!

Шулай да, Фәрит аның бүлмәсенә сирәк керергә тырышты. Рәмзиясе дә, бергә булсагыз, гел эчәсез, ди. Сәбәп ул гына түгел. Фәиз белә, аңлый: Фәрит аңардан шикләнә, Фәиз үзенең холкын аңлый — аның белән сөйләшеп утыруы авыр, кайвакыт бөтенләй сөйләшеп булмый. Фәизнең бит аның сөйләшүе әллә нинди сәер, артык акыллы, шул ук вакытта тузга язылмаган фикерләр белән чуалана. Шуңа күрә Фәиз һич кенә дә Фәритнең читтәрәк йөрүенә үпкәләми. Фәрит аны барыбер дус итә. Кирәк вакытта гел ярдәм күрсәтергә тора, эштә дә аны кирәк чакта яклый.

Ярый Фәрит белән Рәмзия бар әле — алар белән бөтенләй үк ялгыз түгел бит ул. Аларның тормышлары шулай талаш-сугыш белән баруга Фәизнең ихлас күңелдән эче поша, ничек булса да, аларны мәңгегә татулаштырып, Фәритне көнләшми торган, Рәмзиянең битендә беркайчан да кара таплар булмаслык бәхетле итәсе килде.

Әмма тормыш үзенчә барды — һәркемнеке үзенчә. Беркем беркемне, хәтта үзеңне дә «бәхетле итәм» дип максат куеп, бәхеткә ирештергәне юк әле.

Һәм инде ничәнче мәртәбә яңа өметләр биреп, бәхет вәгъдә итеп, тагын яз җитте. Язгы ташуларның да көче бервакыт бетә икән шул. Ярсулар вакытлыча гына була! Яз үзе дә озын гомерле түгел ләбаса. Ә нәрсәнең яки кемнең гомере озын соң бу дөньяда? Шулай булгач, язгы яшәүләргә сөенүләр, язлар үтеп киткәнгә көенүләр — вакытлыча, нидер мизгелләр эше генә бит. Шатлыгы да, кайгысы да кайчандыр бетә. Кош кебек талпынган йөрәк тә бер мәлне тына. Җан газабының да чиге, азагы бар микән? Җиһанның кайсы ноктасында башланып, кайсы төшендә сүнә икән бу газап? Әгәренки бу коточкыч яман авыру бер инсанның гына милке икән, әгәр әлеге дә баягы чир бер вөҗүдкә генә хас булып, дөньяга мәгълүм түгел икән? Бу очракта язын чәчәк аткан гөлләреңнең гүзәллегендә, яшел хәтфәләргә төренгән болыннарның хозурлыгында ни мәгънә бар?! Җан газабы шартлап чәчрәп чыкса, бу табигатьтә нәрсә булса да үзгәрер иде микән әллә? Бәлки шуңа күрә бер кешене генә шиңдерергә, киптерергә тиештер ул газап. Гаеп — гөнаһ газабы!

Беркөнне төшке аштан соң МТСта бер генә начальник та калмады — каядыр таралышып беттеләр. Шуннан файдаланып механизаторлар, слесарьлар эшләрен түгәрәкләп, кулларын бензин белән ышкып юып, кайсы кайтып китте, кайсы домино уйнарга дигән сәбәп белән аракы эчәргә калды.

Фәиз китапханәгә барып китаплар сайларга кирәк дигән ният белән гаражда өс киемен алыштырып маташканда Фәрит килеп җитте:

— Нәрсә, күрше, эш тәмаммы?

— Тәмам бугай, таралышып беттеләр бит барысы да.

— Синең әйткәнең бар иде Т.га барып кайтырга исәбең бар дип.

Фәиз дулкынлануын яшерә алмады:

— Әйе!

— Мин хәзер шунда барам. «Баш» рөхсәт бирде. Теләсәң, әйдә минем белән.

Фәиз, аның кире уйлавыннан курыккандай, тотлыга-тотлыга такылдады:

— Хәзер, хәзер. Әлбәттә. Минем күптән барасым килә анда. Минем кыш көне җаем чыкмады. — Ул чак кына, «барырга куркып йөрдем», дип ычкындырмады. — Хәзер, менә киемнәремне алмаштырам да.

— Ашыкмасаң да була. Арттан куучы юк бит, — диде Фәрит һәм машинасын кабызырга китте.

Т.га барырга элегрәк Фәизнең кодрәте җитмәде. Хәзер дә ник барасын, нинди йомышы барлыгын үзенә-үзе дә әйтә алмады ул. Тик барыбер анда барырга кирәк. Шунда башланды барысы да. Шул калада. Шул кибеттә.

— Син анда кем янына барасың соң? — дип кызыксынды Фәрит, машина инде дамбага чыккач.

— Анда минем беркемем дә юк. Интернатка кереп чыгармын. Аннары ни дисәң дә, минем туган шәһәрем бит ул.

— Әйе шул. Синең туган калаң бит ул. Мин абыйларга барам. Йомышым бар минем аңа.

Фәиз алдан ук кисәтергә ашыкты:

— Фәрит, син мине интернат каршында төшереп калдырырсың, яме.

— Ярар.

— Мин үзем попутка белән кайтырмын.

— Нишләп инде! Кире кайтканда мин сине кереп алырмын.

— Юк, юк,— диде Фәиз өзгәләнеп. Аның болай үтенүенә Фәрит бераз гаҗәпләнсә дә, күршесенең сәерлегенә күнеккән иде инде, шуңа күрә артык аптырамады.— Мин интернаттан соң шәһәр буйлап йөрим әле. Урамнарыннан атлыйм.

— Аңлашылды,— диде Фәрит һәм борын астыннан ниндидер җыр көйли башлады.

Шәһәргә якынлашкан саен Фәизнең йөрәге катырак типте, Фәритнең әллә нинди таныш булмаган җыры саруны кайнатты. Машинадан төшеп җәяү китәсе килде. Юк, әнә инде Т. күренде.

Кинәт Фәиз сорап куйды:

— Т.да нинди яңалыклар булды соң?

— Кайчан?

— Мәсәлән, мин армиядә чакта?

— Син җитмеш сигездә киткәнсең бит?

— Әйе.

— Алай шаккатырлык яңалыклар булмады бугай. Мин ЛТПдан кайттым, иң зур яңалык шул булгандыр.

Фәрит рәхәтләнеп көлеп җибәрде, аның шатлыгы үзенең шаяруыннан гына түгел, инде ЛТПдан исән-имин кайтып йөрүеннән иде күбрәк.

Фәиз беркавым хәл җыйганнан соң сорарга булды:

— Ә теге ювелирныйны басучыларны соң... ничек?

— Нәрсә ничек?

— Тотмадылармы?

— Нишләп тотмасыннар. Бер караганда, жалко аларны.

— Кемнәрне?

— Каракларны.

— Кемнәр соң алар?

— Әрмәннәр булды бугай алар. Бик караңгы эш булып чыкты бит ул. Рәмзия бит шул кибеттә эшләде. Аларның директорлары... Рәмзия миңа күп нәрсә сөйләде — директор турында да, гомумән, сәүдәдәге хәлләр хакында да. Рәмзия бит бер гаепсезгә чак кына төрмәгә эләкми калды. Гәрчә кибеттән төк тә алмаса да. Теге алтын әйберләрне урлаучыларны тоткач, тиз-тиз генә ябык суд ясадылар да беркем берни белми калды. Тотканнар, утыртканнар, дигән хәбәр генә чыкты. Кавказдан килгән кешеләр булган, имеш. Минем бер таныш шоферым шул кибеттә эшләгән иде. Ул әйтә, директор үзе оештырмады микән ди.

— Ул директор исәнме соң әле?

— Исән булмый, нишләсен ул! Матур гына пенсиядә яшәп ята.

— Аның кызы бик чибәр диләр,— диде Фәиз, Казанда Марат янына килгәч, Әлфия белән очрашуын исенә төшереп.

— Ул аның үги кызы. Үзенеке түгел.

Фәиз, никтер, моңа зур әһәмият бирде:

— Каян беләсең?

— Рәмзиянең әйткәне бар.

— Ә син яңалыклар булмады дисең. Шунысы куркыныч, бер гаепсез кешеләрне төрмәгә утыртып соң инде. Ай-яй!

— Син кемнәр турында әйтәсең?

— Теге әрмәннәр турында әйтәм. Ничә кеше булганнар соң алар?

— Әллә тагын. Әйтәм бит, бик яшертен алып бардылар ул эшне.

— Кавказ кешеләре алтынны тапканнармыни?

— Ничек инде тапканнармыни? Мин бит сиңа татарча әйтеп торам: кибетне басканнар, алтын товарларны урлап чыкканнар.— Ул башын чайкап куйды.— Ай-һай авыр синең белән сөйләшүе, күрше.

— Нинди товар булган соң анда?

— Әллә нәрсә түгел инде. Балдаклар бик күп булмаган, ахрысы, алтын-көмеш кашыклар, алкалар, диләр.

— Аларны кайда тотканнар соң?

— Син бик нык кызыксына башладың әле бу эш белән.

Фәиз, үзе дә сизмәстән, кызып-кызып сораулар биреп утырды:
— Урмандамы?
— Белмим, белмим, аптыратма. Кайда тотсалар да барыбер түгелмени?!
— Барыбер түгел! — дип кычкырды Фәиз, үзен тыя алмыйча.
Фәрит аңа аптырап карады, шул вакытта машина чокырга эләгеп сикереп куйды.
— Син нәрсә, Фәиз, ычкына башладыңмы әллә? Псих!
— Нахакка кешеләрне рәнҗеткәннәр! Алар гаепле түгел.
— Кайдан беләсең син, кем гаепле, кем гаепсез?
Фәиз Фәриткә карап торды.
— Әйе шул, белмим. Кем гаепле, кем гаепсез. Кеше хәтта үзе турында да анык белми: гаеплеме, юкмы. Син гафу ит мине.
— Ярар ла, гафу үтенеп утырган булма! — диде Фәрит, ачуланып.— Просто сине аласы калмаган Т.га.
— Фәрит туктат әле,— диде Фәиз, күкрәген угалап.
— Нәрсә, тагын хәл начарландымы?
— Әйе, тыным кыса. Чыгып һава сулыйм әле мин.
Фәрит көрсенеп машинасын туктатты. Аның офтануы мәшәкать барлыктан түгел, Фәизнең сәламәтлеге өчен кайгырудан иде.
Алда шәһәр күренә иде инде. Алар туктаган урында төзелеш башларга җыеналар, ахрысы — бетон, ком өеме, кирпеч белән тирә-як тулган иде. Буш кырлар, зәңгәр төтен эчендәге шәһәр, тәртипсез рәвештә башланган төзелеш — һәммәсе җансыз күренеш иде. Язга тәңгәл түгел иде тирә-юньдәге яшәеш.
— Ничек? — диде Фәрит, Фәизнең чыраена җентекләп карап.
— Синең бардачогыңда гел аракы була торгание. Юкмы?
— Бар, кызыл аракы.
— Салыйм әле мин.
— Хәлең яхшырыр дип уйласаң, пажалысты. «Кызыл»дан хәл бигүк яхшырмый да инде ул.
— Барыбер җиңелрәк булырга тиеш.

## 10

Интернат тирәсендә озак йөрергә ярамый, күрүләре ихтимал. Үзенең кереп чыгарга да нияте юк түгел иде, ләкин Зәбир турында сорасалар, ни җавап бирерсең?! Аның шунда башына чынлап сукты: Зәбир турында беләләр микән соң болар, юкмы? Аның юкка чыгуы интернатта мәгълүм микән? Юк, юк, интернатка керергә ярамый. Бу тирәдә ул үзенең үсмер чагын эзләде, әмма юк, күңел теләгән бер генә мизгел дә табылмады, очрамады. Менә ул интернат, ләкин Фәиз армиядә чакта сагынган интернатмы соң бу?
Ул, тиз-тиз атлап, автобус тукталышына таба китте. Интернаттан ераккарак таерга кирәк! Әнисе исән вакытта яшәгән йортны да никтер барып күрәсе килмәде.
Ул үзенә кат-кат сорау бирде: нишләп балачак, үсмер чак гөрләп узган урыннардан качасы килә?
Һәрбер таныш урам, таныш йорт аннан «нишләдең, нишләргә җыенасың?» дип сорыйдыр кебек тоелды. Ул үзе йөз төрле сорауларына җавап эзләп килде бирегә, әмма ләкин кая гына барып төртелмәсен, аның үзенә меңләгән сорау бирәләр шикелле тоелды. Ул, нәрсәгәдер, кемнәргәдер зур бурычлы итеп тойды үзен.
Кыршылып беткән иске автобус аны Культтовары кибете урнашкан урамга алып китте.
Менә ул кибет. Менә шушында башланды...

Кибет эченә ул ТЕГЕ вакыттагы кебек атылып диярлек керде. Эзләнеп як-ягына каранды. Шуннан соң, бернинди таныш әйбер тапмагач, сул якка — алтын урлар алдыннан качып яткан якка атлады. Ләкин ул якта хәзер балалар бүлеге икән, анда уенчыклар саталар иде. Хәзер инде кайсы төштә качып ятканын да табу мөмкин түгел! Бу уй аның рәнҗүен кузгатты. Аның «изге» бер урынын юк иткәннәр, җимергәннәр. Югыйсә бу дөньяда ул качып яткан тар гына, кабердән дә таррак урын бик аз мәйдан алып тора лабаса! Әйтерсең лә, аны газиз бер нәрсәдән мәхрүм иттеләр. Чишеләсе төеннең очын ремонтка әзерләнеп куелган такталар арасыннан чишә башларга кирәк иде бит!

Сатучы кызның чәрелдек тавышы аны сискәндереп җибәрде:

— Нәрсә эзлисез?

Фәиз төссез күзләре белән түгәрәк йөзле, кап-кара күзле кызны «капшады» һәм сорауга җавапны шундук тапты:

— Каравылчыны.

— Нинди каравылчыны?! — диде сатучы, аптырап.

Фәизнең тез буыннары калтырап куйды. Тыны бетә башлады. Салкын бармаклары белән күлмәгенең өске сәдәпләрен ычкындырды. Аяклары аны алтын-көмеш товарлар сатыла торган бүлеккә алып киттеләр. Менә ул якыная. Ләкин нишләп яп-якты соң? Кая китте яклый, саклый, коткара торган мәрхәмәтле караңгылык?! Кулда таш бар да, юк та сыман.

Ә монда инде хуҗалык товарлары сатыла иде. ТЕГЕ витринадан да җилләр искән.

Булмады. Вакыт узган. Күп нәрсә югалган. Кайдан тотынырга соң?! Кайлардан эзли башларга җавапны?!

Фәиз шабыр тиргә батты. Килеп витринага таянды. Олы яшьтәге сатучы апа аның аксыл чыраена карап каушап калды:

— Чирлисез мәллә?

— Әйе, — дип пышылдады Фәиз, кибеттәге кешеләрдән куркып. Ул хәтта сатучы апага да йөзен күтәреп карарга батырчылык итмәде.

— Нәрсә булды? — дип сорады апа, аналарча кайгыртучанлык белән.

Фәиз күкрәген уып алды:

— Белмим, тын бетә.

— Урамга, саф һавага чыгыгыз.

Әйе, апа дөрес әйтә — урамга чыгарга кирәк. Тик бер сорауны бирәсе бар бит.

Фәиз башын аска игән килеш пышылдады:

— Апа, ә алтын-көмеш кайда? Элек монда саталар иде бит.

— Хәзер инде сатмыйлар.

Сатучы апа, аның хәле тагын да начарланганын күреп, витринаны әйләнеп чыкты һәм сузылып үзе утыра торган урындыкны алды.

— Менә утырып торыгыз.

Фәиз урындыкка утырды. Ул инде текәлеп караучы сатучыларга да, кибет эчендә кешеләргә дә игътибар итми башлады.

— Мә, валидол кап, — диде кемдер.

— Скорый чакыртыйкмы? — дигән тавыш ишетелде.

Кемдер стакан белән су алып килде. Фәиз бер стакан суны түшенә түгә-түгә эчеп бетерде. Як-ягында кешеләр җыелганны күргәч, торып басты, чайкалып куйды, ләкин егылмады.

— Кирәк түгел бернәрсә дә, беркемне дә чакырмагыз, — диде ул һаман пышылдарга тырышып. — Аракы күп эчкән идем мин.

— Әй, шул аракыны эчеп чукынасыз инде! — диде бер хатын-кыз тавышы.

— Япь-яшь килеш. Шушы хәлгә җиткәнче эчеп соң инде.

— Аңа эчәргә ярамый — күренеп тора.

Аның артыннан аракының начар нәрсә икәнлеге турында хатын-кыз тавышлары яңгырады, ә ул исә ишеккә таба юнәлде. Атлавы бик авыр булса да, Фәиз авызын кыйшайтып елмайды — бер төркем кешене

алдады бит ул, «аракы эчкәннән», имеш. Беркем белмәде, сизмәде аның шушы кибетне басканын, каравылчының башына таш белән сукканын. Ишек катына җиткәч бу сәер шатлык кинәт юкка чыкты. Монда килүдән мәгънә булдымы соң? Монда бит инде УЛ ВАКЫЙГАНЫ яңадан кузгатып, уйный алмыйсың! Кабат ЯШӘП булмый бит инде УЛ ВАКЫЙГАНЫ! Ә кайда мөмкин соң?

Урамга чыгып, ул язгы һаваны күкрәген тутырып сулады. Тагын баш әйләнеп китте, әмма бу әйләнү саф һава тәэсире иде. Кизәнеп-кизәнеп кибет каршындагы тротуарны себерүче агай туктап аңа карап торды. Фәиз кибет эчендәге киеренкелектән соң тәнендә спазмаларның бетүен тойды һәм үзендә күпмедер дәрәҗәдә көч һәм батырлык тойды. Аның халәте штурмга барыр алдыннан сыман иде. Ул үзендә һөҗүмчел халәт сизде. Кемгә, нәрсәгә юнәлергә тиеш бу көч — билгесез, әмма ләкин сәерсенеп карап торучы дворниктан да җайлырак объект юк иде. Фәиз тешләрен кысып бер-ике адым агайга таба атлады.

— Нәрсә катып калдың? Себер!

Бу начар гына гәүдәле, ак чырайлы бәндәдән агай һич кенә дә курыкмады, башын кыңгыррак салып, җүләргә караган кебек бакты да калды.

— Бераз хәл алырмын да тагын себерермен,— диде агай тыныч кына.

Аның үзен тыныч тотуы Фәизнең ачуын кабартты, ул үзендә тагын киеренкелек сизде. Һәм инде, әлбәттә, тагын спазмалар башланды һәм янә хәле бетеп китте. Себерергә тотынган агайның килеп беләгеннән тотты һәм әле яңа гына дорфа сөйләшүе турында онытып, спазмалардан нечкәребрәк киткән тавышы белән эндәште:

— Абзый, син каравылчы түгелме?

— Юк, мин грузчик. Ярты ставкага, менә, җыештыручы да.

— Каравылчы кирәк түгелме соң? — диде Фәиз, абзыйның җиңен йомарлап тоткан килеш.

— Юк, кирәк түгел. Каравылчыбыз бар безнең.

— Теге, ике ел ярым элек эшләгән каравылчымы?

— Ә нәрсәгә сиңа ике ел элек эшләгән каравылчы?

Фәизнең кычкырып таләп итәсе килде, ләкин үзендә боерырлык көч табалмады.

— Абзый, миңа ул кешене кичекмәстән күрергә кирәк,— диде ул ялварулы тавыш белән.— Минем аны күрәсем килә. Әйтәсе сүзем бар. Сорыйсы сорауларым бар. Кайда яши ул?

— Кайдан белим мин ике ел элек кем эшләгәнен! Мин үзем быел гына эшли башладым.

Фәиз аның чыраена текәлеп карап торды. Ул тагын салкын тиргә батты. Калтыранган бармагын дворникның маңгаена терәп диярлек пышылдады:

— Ә менә бу... маңгаеңдагы җөй кайчангы соң синең?

Агайның түземлеге бетте, ул себеркесен җиргә ташлады да бер-ике адым читкә тайпылды, чөнки тиле кыяфәтле бу егетнең күз карашы яман иде.

— Синең ни эшең бар минем маңгаемда?! — диде ул һәм як-ягына карап куйды. Аннары үрелеп кибет ягына да карап алды. Бу начар гына гәүдәле егеткә каршы торырлык көче булса да, ярдәм кирәк булмагае дип уйлады, ахырысы. Әнә бит кыяфәте ничек яман.

— Кайда суктылар синең маңгаеңа?

— Нәрсә кирәк сиңа?!

Хәзер инде агай да аны җентекләп күзәтте, шул ук вакытта сугышырга да әзер булып торды. Аның табак битле чыраенда курку юк, бары тик ачу гына күренде. Фәиз аның маңгаендагы сузылып киткән җөйдән күзләрен ала алмады, гүя, ул җөйне танырга тырышты.

— Танымыйсыңмы мине? — диде Фәиз, сәер елмаеп.

Аның күңелендә, чынлап та, шатлык туды, әйтерсең лә, күптәнге танышын, якын кешесен тапты.

— Юк, танымыйм.

— Мин сине бик еш искә алам, абзый.

— Кем соң син?

— Син кибеттә эшләмәгән идеңме ике ел элек?

— Юк.

— Ә мангаеңа кибет эчендә сукмадылармы?

Абзый йодрыкларын төйнәде:

— Син, давай, ычкын моннан яхшы чагында! Кайда суксалар да барыбер түгелмени сиңа?!

Фәиз, никтер, абзыйны күралмый башлады.

— Кызма, кызма,— диде ул нәфрәтләнеп.— Курыкмыйм мин синнән.

Абзый кинәт аның түшеннән эләктереп алды.

— Нәрсә кирәк сиңа?!

Фәизнең инде каршы торыр хәле юк иде. Шулчакны хатын-кыз тавышлары ишетелде — кибеттән сатучы хатыннар чыгып аларны аралый башлады:

— Габделхәй абый, тимә, хәле начар аның.

— Суга күрмә!

— Хәле начар булса, бәйләнмәсен миңа! — дип акырды дворник бөтен урамга.

Шуннан соң ул кизәнде, ләкин сукмады. Фәиз куркудан һәм килеп чыккан хурлыктан, үзенең көчсезлегеннән качарга тырышып, бар көченә йөгерде.

Ләкин озак йөгерергә хәле житмәде. Йөз адым чамасы киткәч, борылып карады. Сатучылар кибеткә кереп киткәннәр, абзый бу якка карыйкарый себерүен белә иде. Фәиз әкрен генә китеп барды, кай тарафка — хәзер аңа барыбер иде.

Шул микән каравылчы? Ничек белергә? Баш эшләмәде. Нервылар беткән. Кеше белән сөйләшә дә алмыйм икән мин! Дөрес сөйләшмәдек. Туп-туры андый сораулар бирергә ярыймы соң? Ничек белергә икән — шулмы каравылчы, юкмы. Габделхәй дип эндәштеләр аңа. Исеме Габделхәй. Туктале! Рәмзия Каенсар кибетенә күчкәнче шушы сәүдә йортында эшләгән бит. Ул белми микән бу кибеттә кем каравылчы булып эшләгәнне?

Тулай торакның гөж килгән вакыты иде. Коридордагы шау-шу арасында Рәмзиянең дә тавышы ишетелде. Фәиз әкрен генә ишекне ачты да сулга каерылып карады. Рәмзия үзләренең ишек төбен юып маташа иде. Өч тәгәрмәчле велосипедка утырган биш яшьлек малайның үтеп китүен ул түземсезлек белән көтте.

— Рәмзия! — диде ул тыныч кына.

Хатын сискәнеп китте.

— Ә? Уф, котымны алдың. Син нәрсә, тагын чирлисеңме әллә?

— Әйе, йөрәк авыртып тора.

— Аракы эчмәскә кирәк! — диде Рәмзия гадәттәгечә.

— Рәмзия, син хәтерләмисеңме, ювелирный кибеттә... Т. шәһәрендәге... житмеш сигезенче елны кем каравылчы булып эшләгәнне?

Рәмзиянең башын аска иеп идән юудан бите кызарып тирләп пешкән иде. Ул аскы иренен алгарак чыгарып битенә өреп куйды.

— Болай төскә-биткә хәтерлим инде мин аларны. Исемнәрен генә белмим. Нигә соң алар сиңа?

— Ә нишләп син алар дип сөйләшәсең? Каравылчылар берничә идемени анда?

— Юк, ювелирныйда бер каравылчы. Ну, алар бит, беренчедән, еш алышып торалар, ә икенчедән, грузчиклар да кайвакыт каравылда торалар. Каравылчылар гел алкашлар туры килә — йә эчеп эшкә чыкмый

калалар, йә шунда тагын берәр нәрсә килеп чыга иде. Шул сәбәпле грузчикларны да кайвакыт каравылда тоталар иде. Кайвакыт каравылчы үзе, берәр грузчик белән сөйләшеп, аның урынына дежур торуын үтенә иде.

— Грузчиклар да тора идемени каравылда?

— Әйе. Нәрсәгә соң ул сиңа?

— Анда Габделхәй исемле каравылчы юк идеме?

— Габделхәй? Габделхәй абый. Ул бит грузчик булып эшләде анда. Хәзер эшлидерме, юкмы — белмим.

— Ә аның каравылда торганы бар идеме?

— Мәсәлән, мин эшләгәндә булды бугай.

— Димәк, аның да каравылда торганы бар.

Рәмзия аптырап калды:

— Нигә сине кызыксындыра ул каравылчылар, грузчиклар?

— Мин туганымны эзлим. Минем ерак туганым бар.

Рәмзия артык сораулар биреп йөдәтмәсен өчен тиз генә үзенең бүлмәсенә кереп китте дә эчтән ишеген бикләде. Аннары бүлмә буйлап ишекле-түрле йөри башлады.

Исән, каравылчы исән. Габделхәй шулдыр инде, маңгаенда шрамы бар бит. Шулдыр, шулдыр. Шул булса ярар иде. Исән, каравылчы исән. Үтермәдем микән дип икеләнеп йөрдем. Ә ул исән! Зәбир генә исән түгел. Нишләп минем каравылчыга алай нык ачуым килде соң әле? Аның ни гаебе бар? Әллә җүләрләнәм инде.

Шунысы кызык: Фәиз беркайчан да югалган алтынны кызганмады, шулкадәрле байлыктан колак кагудан бер генә тапкыр да үзалдына лаф ормады. Һәм менә инде каравылчы да исән. Нишләп соң УЛ ВАКЫЙГА Зәбир өчен генә чарасыз рәвештә фаҗигале булды соң? Туктале, ә минем өчен? Минем хет нәрсәне дә булса үзгәртә алуым ихтимал. Мөмкинлегем, ышанычым бар шикелле. Нәрсә сөйлим мин, нинди мөмкинлек, нинди ышаныч? Зәбирне терелтә алмагач, нинди мөмкинлек турында сүз алып барып була? Кайсыбызга ныграк җәза эләкте соң әле безнең? Зәбиргәме, миңамы? Гел ШУЛ ВАКЫЙГАНЫ уйлап, газап чигеп яшәүләре авыррак түгелмени?! Шунда бергә батып үлгән булсак? Әйтүе җиңел. Ә бата башласаң... Аллам сакласын.

Теге Габделхәйниләр уйлады икән? Танымады бугай. Ничек танысын инде! Юкка шулай якын килдем аның янына. Юк, юк, зерәгә түгел, чөнки аның исән икәнлегенә инандым. Ул, әлбәттә, шикләнгәндер. Әй, шикләнсә шикләнер! Исән. Ярый әле ичмаса ул исән.

Әмма ләкин каравылчының исән булуы гаеп-гөнаһ хисен сүрелдермәде. Ул абзый исан калса да, калмаса да, сазлыкта ТЕГЕ ВАКЫЙГА булды. Фәизнең ул гөнаһын каравылчы исән булса да, дөньяга тагын әллә ничә каравылчы туган суретта дә беркем һәм бернәрсә юа алмас, ахрысы.

Аның башланган аракысы бар иде. Эчәргә кирәк. Бүгенге очрашудан соң, бүгенге вакыйгадан соң эчсәң дә ярыйдыр.

Ул стаканны тутырып аракы салды.

## 11

Аның, прокуратурага барып, нишләп гаепсез кешеләрне төрмәгә утыртулары белән кызыксынасы килде. Ләкин үзендә анда барырлык көч тапмады. Хәзер инде төрмәгә утыртуларыннан да курка башлады, чөнки нindidер коточкыч өянәк кинәт-кинәт бөтен барлыгын әсир итеп тотты. Эчәргә ярамый миңа, дип уйлады ул, аракыдан бу, дип үзен тынычландырырга маташты. Ләкин аракысыз да бик авыр иде шул. Аракы халәтне тиз арада тотрыклы итә, газаплы уйлардан тәгаен арындырмаса да, аларны уйларга хәл бирә.

Беркөнне эштән кайткач, гадәттәгечә, ярты стакан аракыны эчеп куйды. Инде күптән Рәмзия белән аулакта калып әңгәмә корасы бар иде аның. Рәмзия Каенсарда эшләгән ул вакытта. Аның сөяркәсе Сабитов Камил булган, милиционер. Бөтенесе туры килә бит. Фәрит ике атнага командировкага китте Белоруссиягә, ниндидер запчастьлар алып кайтырга, имеш. Ул өйдә булганда Рәмзия белән иркенләп сөйләшергә яхшы түгел — Фәритнең көнләшүе ихтимал. Хәтта үзе өйдә булмаганда да әле җайлы гына: «Рәмзия, әйдә сөйләшеп утырыйк»,— дип тәкъдим ясау әллә ничек. Бөтен нәрсәне күреп, ишетеп торучы күршеләр кечкенә генә тулай торактагы һәр хәрәкәтне, һәр әйтелгән сүзне ригаясез калдырмый.

Тагын ярты стакан эчкәч, шулай да, Фәиз, күрше-күләнгә эчтән генә төкереп, Рәмзияләрнең ишеген шакыды.

Рәмзия ашап утырган вакыты булган, күрәсең, нәрсәдер чәйни-чәйни ишекне ачты.

— Фәрит кайчан кайта? — дип сорады Фәиз аңардан көтмәгәндә.

Күршеләрнең фикерләреннән гел куркып яшәүче хатын каушап калды:

— Тагын бер ун көннән. Ник?

— Барып кайтасы җир бар иде. Вәгъдә иткән иде УАЗигы белән алып барырмын дип. Көтәргә туры килә инде алайса,— дип ялганлады Фәиз һәм борылып китмәкче булды.

Бәхетенә күрә, Рәмзия сорап куйды:

— Кая бармакчы идегез?

Фәиз кинәт борылды:

— Каенсарга.— Сүзнең үзе теләгән якка борылып керүенә шатланып өстәп куйды.— Теге, син эшләгән авылга.— Рәмзия ишеген ябып куймасын дип куркып ул тиз генә сорап куйды.— Каенсар турында бер соравым бар иде минем сиңа.

— Сора,— диде хатын аны-моны уйламыйча.

Фәиз як-ягына карап куйды да пышылдады:

— Ишетүләре бар. Керимме?

Рәмзия бермәлгә уйга калды.

— Бар үзеңнең бүлмәңә. Хәзер керермен,— диде ул, ниһаять.

Рәмзия кызыл чәчәкле халатын киеп кергәч, Фәизнең шыксыз бүлмәсенә бәйрәм төсе иңгәндәй булды. Фәиз хәтта бермәлгә булачак әңгәмә турында да онытып торды.

— Көзге һава бик шәп, әллә урамга чыгабызмы,— диде ул соңгы берничә көндә тагын да чибәрләнеп киткән хатыннан күзләрен алмыйча.

Хатын аңлады аның хәләтен, ир кешеләрнең күз карашын аңлый торган яшьтә инде Рәмзия. Ул бераз артистланып күзләрен акайткан булды:

— Син нәрсә, тилердеңме әллә! Хәзер бөтен тулай торак, бөтен поселок сөйли башлаячак синең белән прогулкага чыкканыбызны.

— Әйе шул,— дип аскы иренен тешләде Фәиз.— Бигрәк инде. Очрашып сөйләшергә дә ярамый микәнни?!

— Ул бит әле, ирең көнче булгач, гайбәтләр бигрәк тә саллырак була. Димәк, ире тикмәгә көнләшми, әнә ничек егетләр белән йөри дип уйлыйлар.

— Ә син бүген бик матур,— диде Фәиз көтмәгәндә.

Рәмзия елмайды:

— Рәхмәт.

Һәм бераз оялып куйгандай булды. Рәмзия үзе дә бик яхшы белә: Фәрит командировкага киткәнгә берничә генә көн, ә инде талашучы, сугышучы булмавы нервыларны тынычландырган күрәсең, һәм инде, әлбәттә, кыяфәткә дә чыккан. Бу турыда әйтмәкче иде, ләкин тыелып калды. Ә Фәиз ул әйтмәсә дә белә: Фәрит аркасында таушалып, йончып йөри Рәмзия, чөнки якты көн күрсәтми Фәрит.

Паузаның озакка сузылуын сизеп, Рәмзия сорады:

— Нинди соравың бар иде?

— Рәмзия, син Каенсарда эшләдең бит?
— Эшләдем.
— Кибетеңә кергән һәр сатып алучыны хәтерләмисеңдер инде.
— Барысын да хәтерләп булмый инде ул. Нигә?
— Рәмзия, син гафу ит, мин дулкынланам.
— Тыңлыйм, тыңлыйм,— диде Рәмзия аның бите аксылланып киткәнне күреп.
— Анда, синең кибетеңә кереп, бер егет алтын йөзек сатмадымы сиңа?
Рәмзия сагайды һәм шундук зур кызыксыну белән гәүдәсен калкытып торайтты:
— Ә син кайдан беләсең?
— Димәк, сиңа йөзек саттылар?
Растраталар, товар югалулар аркасында чак кына төрмәгә эләкми калган хатын, ачы тәҗрибәсе булганлыктан, дөресен җавап бирергә курыкты:
— Ә мин әйтмәдем бит әле миңа йөзек саттылар дип!
— Рәмзия, әйт әле дөресен, сатып алдыңмы син берәр кешедән алтын йөзек?
— Минем нәрсә сатып алуым сине нигә кызыксындыра?
Рәмзия мизгелләр эчендә әллә ниләр уйлап бетерде. Фәрит белән Фәиз Каенсарга барырга йөриләр. Әллә Фәрит шул көнчелеге аркасында һаман минем язмышымда, элекке тормышымда төпченеп казына микән, дип уйлады ул.
— Карале, Фәиз, әллә Фәрит минем турыда мәгълүматлар җыярга куштымы сиңа?
— Юк ла инде! Син дә бик шикчел булып чыктың!
— Ә нигә Каенсарга барасыз соң сез?
— Ул барырга җыенмый анда, мин барам! Минем анда күрәсе кешем бар!
— Кем ул?
— Рәмзия, мин сиңа барысын да сөйләрмен. Мин барыбер үзем турында кемгәдер чын күңелдән сөйләргә тиештер. Шунсыз булмый. Мин сине бик хөрмәт итәм. Хатын-кыз булганың өчен. Түземлегең өчен. Үз теләгең белән, гафу ит, интегеп яшәвең өчен. Син миңа, ничектер, якын кеше. Әйт әле зинһар, булдымы шундый хәл җитмеш сигезенче елны?
Рәмзия аның бернинди начар ният белән сорамаганын аңлады.
— Булды андый хәл. Хәтерлим. Ничек инде хәтерләмисең ди. Бер кап-кара, чибәр, таза гына яшь егет керде дә мине, маңка кызны алдаган шикелле, күзгә карап көпә-көндез алдады да чыгып китте.
— Ничек инде алдап чыгып китте?
— Алтын йөзек дип миңа фальшивка саткан бит ул, зараза!
— Ничек инде фальшивка?!
— Ничек, ничек! Самодельный булган. Үзем гаепле, ныграк карап алырга иде. Пробалары да булгач, ышандым шул.
Күрәсең, Рәмзиянең хәтерендә ул вакыйга нык уелып калган. Аның әле хәзер дә борын тишекләре киңәйде, куллары торымнан-торымга йодрык булып төйнәлде.
— Исемен хәтерләмисеңме син аның?
— Юк, исемен сорамадым. Үзем дә инде бер таныш түгел кешедән...
— Нииндирәк кыяфәтле иде ул?
— Кап-кара, бөдрә чәчле, егерме яшьләр чамасы булгандыр аңа. Туктале, син кайдан белдең соң ул йөзек турында?
— Мин тагын бик күп нәрсә беләм әле, Рәмзия. Ә син кайдан белдең ул йөзекнең чын алтыннан түгел икәнен?
— Тутыга башлады да тикшерттем таныш ювелирга. Ул карады да туфта диде. Мин башта уйлап куйган идем: кибеттән урланган түгел микән дип. Алдагы көнне генә Т.да ювелирныйны басканнар иде бит.

— Башта уйлап куйгансың? Ник, ул йөзек ювелирныйдан булмаганмыни?
— Ничек инде ювелирныйдан булсын? Фальшивый булгач! Камил как раз килгән иде. Ну, теге, сөйләгән идем бит инде.
— Сабитов. Синең сөяркәң.
— Элекке сөяркәм!
— Әйе, әйе.
— Ул бит аны куып җиткән.
— Беләм куып җиткәнен. Ул егетне синең сөяркәң дип көнләшкән.
— Кайдан беләсең?!
— Беләм, Рәмзия, беләм. Ул егетнең исеме Зәбир. Ул минем дустым иде. Ул миңа үзе сөйләде: алтын йөзек сатканын да, синең сөяркәң, гафу ит, Камил куып җиткәнне дә. Аннары ул миңа бик озак итеп бер әби турында сөйләде. Каенсарда, кибет урнашкан урамда, иң кырый йортта бер әби яши, диде ул миңа. Исән микән әле ул?
— Закирә әби. Мин Каенсардан киткәндә исән иде әле ул.
— Зәбир шул әби турында бик озак сөйләде миңа, нык тәэсир иткән ул әби аңа. Тиздән ул әбигә йорт салып бирәм, дип вәгъдә бирде ул миңа. Ник ул әби аңа шулкадәр ошагандыр?
— Сез икәүләшеп ясалма йөзекләр сатып йөрдегезме әллә?
— Юк. Бер йөзек кенә иде ул. Ашарга кирәк иде безгә.
— Аны бит әйбәтләп сөйләшеп, аңлатып, әҗәткә сорап торып та була иде. Алайса бигрәк ачуым килде: мине алдап...
— Син гафу ит аны. Кичер. Мине дә, аны да. Мин түләрмен сиңа. Ул акчаны мин сиңа кайтарачакмын. Минем хәзер генә юк әле. Акча алгач бирермен.
— Ә ул Зәбир кайда соң хәзер?
— Үлде ул. Коточкыч үлем белән үлде. Батып үлде. Син аны гафу ит. Теге әби... Кем дисең әле?
— Закирә.
— Закирә әби дога кылып калган да бит. Тик менә аның догалары әллә кабул булмаган, әллә...
— Каенсарга шул әби янына бармакчы буласыңмы әллә?
— Әйе.
— Ник?
— Шул әби белән сөйләшәсем килә никтер. Башкалар белми торган нәрсәләрне беләдер шикелле. Инде күпме вакыт сорауларыма җавап эзлим. Бәлки ул җавап бирә алыр. Зәбир кабат-кабат сөйләде миңа ул әби турында. Нык уелып калган ул аның күңелендә.
— Ай, сәер кеше син. Нәрсә эзлисең син?
— Ник алай дисең?
— Син һәрвакыт нәрсәдер эзләп йөрисең шикелле.
— Мин үземне эзлим, Рәмзия.
— Ә урманда нишләп йөри идегез соң сез?
— Эзләп. Хәзер Зәбир юк, үзем генә эзлим.
— Аңлап булмый сине.
— Мин бит үзем дә үземне аңламыйм!
— Кызык килеп чыкты. Йөзекнең тарихына син дә бәйле икән.
— Ул йөзек исәнме?
— Чыгарып ташладым мин аны. Нәрсә, истәлеккә сакларга идеме әллә?!
— Ташлыйсың калмаган. Миңа шунысы гаҗәп: нишләп чын алтыннан булмаган соң ул йөзек? Син ялгышмыйсың микән?
— Ялгышмыйм. Теге таныш ювелирым әле тагын бер ювелирга күрсәтте. Алтын түгел диделәр. Кайда, кем тапкан иде соң ул йөзекне?
— Урлаган идек.
— Кем, синме, дустыңмы?
— Икәү бергә.

— Кайсы сазлыкта батып үлде соң дустың?

— Кайсы сазлыкта булса да барыбер түгелмени? Мин батырып үтердем аны. Мин төкерәм йөзеккә, сине алдавына! Мин коточкыч җинаять эшләгән кеше — бергә үскән дустымны батырып үтердем.

— Ышанмыйм.

— Үзем дә ышанмыйм. Ышанмыйча булмый. Ышанасыңмы, юкмы, бу — факт.

— Ни өчен батырдың соң син аны?

— Сәбәпсез. Ул бата башлады, мин ярдәм итмәдем.

— Ә-ә-ә, алай икән. Ярдәм итә алмагансыңдыр.

— Син дә шулай дисеңме? Ярдәм итә ала идем мин аңа. Тырышлыгым җитмәде. Син беркемгә дә әйтмә бу турыда. Фәриткә дә. Минем әле ачыклыйсы нәрсәләрем күп. Минем әле иректә яшәп аңлыйсы нәрсәләрем байтак. Миңа вакыт кирәк, мөмкинлек кирәк, миңа шанс кирәк.

— Ярар, ярар, тынычлан, Фәиз. Син нәрсә, кемгә әйтим ди мин. Нишләп мин синең сереңне кемгәдер әйтергә тиеш?!

— Рәхмәт сиңа. Аракы эчәсеңме?

— Юк.

— Минем бераз калган аракым бар. Мин эчимме?

— Эч, әгәр дә җиңеләйтсә. Тагын да начарракк булмасмы? Төсең качкан синең.

— Качар да.

— Сазлыкта нишләп йөрдегез соң сез?

— Анда синең ни эшең бар?

— Болай гына.

— Юлны кыскартыр өчен турыга чыкмакчы идек. Казанга барышыбыз иде безнең.

— Ә-ә-ә, алай икән. Әллә эчмисеңме? Аннары чирләтер бит.

— Киресенчә, бераз салырга кирәк миңа.

Калган аракы ярты стаканнан артыграк булып чыкты. Фәиз аны закускасыз-нисез эчеп бетерде.

— Син, Фәиз, ул йөзекнең акчасын миңа бирергә җыенма. Кирәк түгел. Инде күптән булган вакыйга ул. Аннары синең үзеңә дә акча кирәк. Әллә кайчан булган вакыйга өчен инде...

— Юу-у-ук, әллә кайчан булган вакыйга түгел ул минем өчен. Ул менә монда, йөрәгемдәме яшәп ята. Ул күптән булган вакыйга түгел. Мине хәзер бер сорау борчый — нишләп ювелирный кибеттәге йөзек фальшивка булып чыккан?

— Сез аны кибеттән урлаган идегезме әллә?

Башка вакытта Фәиз, мөгаен, кинәт бирелгән бу сорауга: «Әйе, кибеттән урладык», — дип ычкындырыр иде. Әмма хәзер аракы эчкәннән соң күпмедер дәрәҗәдә тотрыклылык бар һәм курку да алай нык түгел иде. Мондый сорауга бу халәттә саклык белән генә дә җавап биреп була.

— Юк, кибеттән сатып алган кешенекен урладык, — дип ялганлады ул. Син мине ачуланасыңдыр инде?

— Ни өчен?

— Кеше йөзеген урлаганым өчен?

— Яшь вакытта үсмер егетләр ниләр генә кыланмыйлар! Барысын да хөкем итә башласаң.

— Син эшләгән кибетне басканнар иде бит, хәтерлисеңме икән?

— Нишләп хәтерләмәскә! Бөтен тирә-як шау-гөр килде бит.

— Минемчә, ул кибетне баскан өчен бөтенләй гаепсез кешеләрне төрмәгә утыртканнар бугай. Сәер, бик сәер. Шул кибеттән сатып алынган йөзек фальшивка булып чыкты. Каравылчы урынына грузчик дежур торган. Ул көнне алтын-көмеш әйберләр витринада калган. Югыйсә бит аларны сейфка бикләргә тиешләрдер. Сәер, бик сәер.

— Кызык, син бу вакыйганың кайбер нечкәлекләрен беләсең икән. Минем һич кенә дә шигем юк — директор оештырган моны.

— Нәрсәне?
— Кибет басуны. Үзенең кара эшләрен майтарыр өчен, урлаган әйберләрен списать итәр өчен, башка төрле җинаятьләрен каплар өчен үзе оештырган ул аны.
— Ничек син алай дип әйтә аласың?! Белмәгән килеш!
— Беләм, бик яхшы беләм. Ул мине һәм тагын ике товароведны чак кына төрмәгә утыртмый калды. Үзе урлый, кешене пычрата. Кабахәт ул! Мин дә шикләнәм. Суд ябык булды. Ләм-мим, кемнәр басканын да белмиләр, нәрсә, күпме урланган — билгесез. Монда бергә-бергә эшләнгән эш түгел микән әле бу. Аның әшнәләре, туганнары, кодалары прокуратурада, милициядә, сәүдә министрлыгында да бар иде.
— Мин аңлыйм, аңа нәфрәтең зур синең. Исеме ничек әле аның?
— Габдрахманов Ильяс Хәмитович. Нәфрәтем зур булмый. Безне, яшь товароведларны батырып, үзенең җинаятьләрен безгә сылтамакчы булды ич ул. Көчкә котылдык.
— Ильяс Хәмитович... Юньле кеше түгелдер инде ул, сиңа ышанам мин. Ләкин кибетне басуны ул оештырды микән?
— Шул! Шул! Бик караңгы эш ул! Анда бит минем дус-ишләрем һаман эшли, алар да бит аның үзеннән шикләнәләр.
— Пенсиядәме ул хәзер.
— Пенсиядә.
— Кайда яши соң ул?
— Т.да.
— Кибетне басучыларны тотмадылар шул, шунысы сәер. Директор үзе оештырган диюең дә сәер.
— Ә син кайдан беләсең кибет басучыларны тотмаганнарын?
Рәмзия инде сизенә башлады бугай. Фәиз тизрәк алдашуга күчте:
— Минем Т.да бер танышым бар. Ул кайбер нәрсәләрне белә. Ул да нәкъ синең шикелле директорны гаепләргә маташа. Урлаучыларны тотмадылар, имеш, бер гаепсез кешеләрне төрмәгә утырттылар, ди.
— Менә бит, Т.да беләләр аның кем икәнен.
— Кавказ кешеләрен утыртканнар ди бугай, әйеме?
— Кем белгән! Анысы да имеш-мимеш бит әле аның. Әйтәм бит, бик караңгы эш булып чыкты ул.
— Син аның адресын белмисеңме?
— Кемнең?
— Директорның. Ильяс Хәмитовичның.
— Беләм, яттан беләм адресын да, телефонын да. Кояшлы урам, 14-32. Телефоны: 2-31-44.
— Язып алыйм әле.
Фәиз өстәлдә яткан карандаш белән гәҗит почмагына адресны һәм телефонны сызгалады.
— Ярый, тыныч йокы,— диде Рәмзия һәм ишек янына җиткәч борылып карады.
Фәиз аңа ачу белән, авызын кыйшайтып елмайды:
— Аңладыңмы берәр нәрсә?
Рәмзия ни әйтергә белми аптырап торды:
— Нәрсә «аңладыңмы»? Сөйләгәннәреңне аңладым. Ә үзеңне һич кенә дә аңлап бетереп булмый.
— Шикләнәсең бит миннән?
Рәмзия, өзгәләнеп, аңа таба атлады:
— Син нәрсә инде, Фәиз! Нишләп шикләнеим мин синнән?! Син үзеңне-үзең ашап, эчтән кимереп яшисең, ахры. Нишләп шикләнергә тиеш мин синнән! Күп уйлыйсың син.— Фәизнең, күзләрен төссезләндереп, аның сөйләгәннәренә игътибар итмәвен күреп ул ишеккә таба чигенде.— Ярый, киттем мин. Тыныч йокы.

*Ахыры киләсе санда*

## ФАРСИЛ ЗЫЯТДИНГА 60 ЯШЬ



# ТУГАН ҖИРДӘН КӨЧ АЛЫП...

Алтмышынчы еллар шигърияте. Татар әдәбиятының үсеш юллары турында сөйләгәндә бу гыйбарә бик еш кулланыла. Бу бер дә тикмәгә түгел. Моңа кадәр әсәрләрен уку түгел, исемнәрен дә телгә алырга ярамаган «буржуаз» яки «халык дошманнары» дигән кара мөһер сугылган классик әдипләрнең яңадан әдәбиятыбызга кайта башлаган еллар бу. Татар шигъриятендә һәм башка жанрларда да чын, тормышчан конфликтның, фикри юнәлешнең әлегәчә булмаганча үсеш алган еллары. Илдә корыч куллы тирания салкыннарын куып, демократиянең күптән көтелгән-тансыкланган йомшак җилләре исә башлаган вакыт. Вәләкин шуның белән бергә, «ата-аналар теләге белән» дигән булып, милли мәктәпләрнең моңа кадәр булмаганча тизлектә урыслаштырыла башлаган, ягъни, татар теленең дә кадере киткән еллар иде бу.

Без, бер төркем яшьләр, Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә әнә шундый каршылыклы чорда килеп кердек. Мәгълүм ки, тора-бара милли телләр бетәчәк, яңача тәрбияләнгән совет халкы гомум-уртак бер телдә генә сөйләшәчәк-аралашачак дигән шомлы-ялган теорияләр хөкем сөргән заманда татар теле бүлегенә ана телебезне ихлас яраткан яшьләр генә килә ала иде. Шөкер, андыйлар аз түгел икән әле. Конкурс шактый булып чыкты. Хәтерем ялгышмаса, бер урынга өчдүрт абитуриент идек шикелле. Ул вакытта әле үзе дә яшь, чибәр укытучы Диләрә апа Тумашева җитәкчелегендәге кабул итү комиссиясе әнә шундый яшьләрдән иң өметле вә талантлы дигәннәрен аралап, татар бүлеге группасын тупладылар. Әнә шушы группага эләгүче бәхетлеләр арасында түшендә «Совет Армиясе отличнигы», шәп спортчы булуын күрсәтүче значоклар балкыган яшел гимнастерка кигән, төп кебек таза егет — Фарсил Сәхәп улы Зыятдинов та бар иде.

Фарсилнең шуннан соңгы тормыш юлы гел минем күз алдымда узылды дисәм, ялгышмамдыр. Бер группада биш ел бергә уку, хәтта Кызыл позиция урамындагы тулай торакның бер бүлмәсендә бергә тору, соңыннан журналистика өлкәсендә эшләп, бергә-бергә иҗатта янып яшәү...

Чыгышы белән Актаныш районының Качкын авылыннан булган бу егет тиз арада үзен гаять тынгысыз, искиткеч тырыш һәм максатка омтылучан буларак танытты. Ул университетның гыйльми һәм җәмәгать тормышына чумып, иң булдыклы, иң актив студентларның берсенә әверелде. Университетта уку программалары гаять тыгыз һәм катлаулы булуга карамастан, Фарсил Казан авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укырга ниятләде һәм берьюлы ике югары уку йортын тәмамлап, ике дипломлы белгеч булып чыкты. Һәм бу ике белгечлек тә аңа тормыш юлында бик тә ярап куйды, үзе сайлаган журналистлык хезмәтендә ныклы ике канат булды.

Фарсилнең авыл хуҗалыгы экономикасын яхшы белүенең файдасы без, группадашлары өчен дә тигәләде. Көз көннәрендә студентларны республикабыз колхоз, совхозларына урып-җыюда булышырга җибәрәләр иде. Бервакыт без Питрәч районының Надеждино авы-

лына бәрәңге алышырга бардык. Кото-чкыч тузган, фәкыйрьләнгән авыл. Ир-атлары кибет янында пирәшләнеп көн уздыра. Безнең кичен арып-талып кыр-дан кайтуыбызны елмаеп-көләп карап калалар. Ашау-эчүебезнең рәте-чираты юк. Чучка исе аңкып торган киез җәй-гән идәндә тәгәрәшеп йоклыйбыз. Дө-ресрәге, төне буе кандалалар белән су-гышып чыгабыз. Авылга — бер җимерек мунча, ишегә купкан бер бәдрәф... Шун-дый шартларда бер ай эшләдек. Җитәк-челәребез: ул вакытта аспирантураны яңа тәмамлаган Сәгадәт абый Ибраһи-мов, аның ярдәмчесе — Фарсил дусты-быз, үзләре тырышып эшләп, безгә шә-хси үрнәк күрсәтәләр. Бәрәңгене көрәк белән казып алабыз, кызлар чүпли. Ма-шина килде исә, әрҗәсен мөлдерәмә бә-рәңге белән тутырып җибәреп торабыз...

Бер ай чиләндек шулай. Инде кай-тып китәбез, дип шатланырга өлгермә-дек, колхоз рәисе янә атна-ун көнгә ка-луыбызны үтенә. Алдыбызда тезләнми генә. Деканат рөхсәт итә икән. Тагын калдык. Бәрәңгене көрәкләр белән алып бетердек тәки. Инде хезмәт хакы-бызны алыйк дисәк, менә хикмәт: бөтен эшләгәнебез ашау-эчүгә кереп беткән, имеш. Шул вакыт Фарсил колхоз рә-исенең каршына килеп басты да, ачуын эчкә йотып, тыныч, әмма нык тавыш белән:

— Әйдәгез әле, бергәләп санап ка-рыйк. Мин — экономист, сезгә ярдәм итәрмен! — диде.

Һәм сәгать-сәгать ярым вакыт үт-теме икән, Фарсилебез идарәдән кояш кебек балкып килеп чыкты.

— Эшләгәнебез өчен акча алабыз-мы, әллә бәрәңгеме? — ди.

— Ничек алып кайтырбыз соң ул бәрәңгене? — дибез.

— Машина белән үзләре илтеп ку-ячаклар. Һәркемгә — берәр капчык! Калганын акчалата алырбыз.

Шулай итеп, без авылдан тәмам ба-еп кайтып киттек. Бәрәңге дә, аз булса да акча да студент халкына бик ярап куйды...

Фарсилнең чын ир-егетләргә хас сыйфатлары турында иркенләп вә күпләп яза алыр идем. Мәгәр аның шигырьләренә кереш мәкалә боларның барысын да сыйдыра алмаганлыктан, сүземне кыскарак тотарга мәҗбүр-мен. Фарсил Зыятдинов шактый еллар Татарстан радиокомитетының яшьләр өчен тапшырулар редакциясендә, ан-нары Казан авыл хуҗалыгы институ-тында, хәзерге вакытта исә Финанс-икътисад институтында доцент һәм Та-тарстан Фәннәр академиясендә бүлек мөдире булып эшләвенә карамастан, балачактан күңелен алгысыткан хыя-лына тугрылыклы булып калды. Са-лкын гакыл сорый торган хезмәтләрен-нән аз гына буш ара таптымы, каләмен кулына алды, хисләнеп-дулкынланып, шигъри һәм чәчмә әсәрләр язуын дәвам итте. Монда да аның тормышны ти-рәнтен белүе, филология фәннәре белән берләттән, агрономия, экономика кебек конкрет гыйлемнәрне үзләштерүе ярдә-мгә килде. Ул үзенең даими геройла-ры — Гыйльми белән Белми аша бала-ларга үсемлекләр һәм хайваннар дөнья-сыннан бик күп кызыклы вә гыйбрәтле хәл-әхвәлләрне шигъри телдә бәян ит-те. Аның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кызык дөнья», «Бе-лми белән Гыйльми», «Онытылмас ава-злар», «Минем әни», «Тагын килер яз-лар» һ. б. шигъри һәм чәчмә әсәрлә-рдән торган китапларын, «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Көн вә төн» (Изге йорт) повестен ба-лалар да, зурлар да яратып кабул ит-теләр.

Ә икътисад фәннәре кандидаты Фарсил Зыятдинов радио һәм телеви-дениедән яңгырап торган экономик те-мага кагылышлы тирән эчтәлекле, дә-лилл чыгышлары белән бүгенге катла-улы чорда хезмәт кешесенә акны кара-дан аерырга булыша, дәүләт кесәсен үзенеке белән бутаучыларны рәхимсез фаш итә.

Өстәп шунысын да әйтми булмас: Фарсил Сәхап улы башкаларга үрнәк итәрлек гаилә башлыгы да булып чык-ты бит, әй! Алар шагыйрә Фирая ханым белән тупырдап торган өч малайны мил-ли рухта тәрбияләп үстерделәр.

Безнең заманда монысы да бик мө-һим, монысы да һәркемнең кулыннан килә торган эш түгел ләбаса.

Мәкаләмне төгәлләр алдыннан та-гын шуны уйлап куйдым әле: универси-тетка безнең татар группасын туплаган-да хөрмәтле укытучыларыбыз, нигездә, талантлы, булдыклы, киләчәктә мил-ләтебезгә игелек китерерлек егетләрне вә кызларны сайлый белгәннәр икән бит. Күрегез әле: безнең группадан гына да Равил Фәйзуллин, Салисә Гәрәева, Фарсил Зыятдинов һәм мин фәкыйрегез кебек әдипләр, Рүзәл Йосыпов, Фир-дәүс Гарипова, Ленар Җамалетдинов, Әнвәр Шәрипов, Шәрип Асылгәрәев, Флера Баязитова кебек галимнәр чыгу үзе генә дә күп нәрсә сөйли түгелме?! Башка сабакташларыбыз да тормышта үз юлларын табып, университетта алган белемнәре белән туган халкыбызга хез-мәт итәләр. Бу турыда факультетыбыз-ның 50 еллык юбилей тантанасында да горурланып сөйләделәр.

**Без — элеккеге сабакташлар әледән-әле очрашкалап, бер-беребезнең хәл-әхвәлләрен белешкәләп торабыз. Кайвакыт елларның бик тиз узуыннан, өлкәнәю белән бергә, төрле авыру-сырхаулар эзәрлекләвеннән зарлангалап та алабыз. Ә Фарсилнең зар кылганын күрмәссең-ишетмәссең. Ул солдат киеменнән университетның текә баскычларыннан йөгереп менгән вакытларындагыча һаман шат күңелле, җор сүзле, ашкынулы ир-егет. Аның белән очрашып, гәпләшеп алганнан соң, син үзеңдә яңадан яшьлек энергиясе, тормышны, кешеләрне ярату хисе, милләтебез наменә армый-талмый хезмәт итү теләге артуын тоясың. Янәшәңдә Антей кебек туган җирдән көч алып, җирдә нык басып торучы, авыр чакта хәлеңә керергә, рриясыз ярдәм кулы сузарга әзер, шигъри күңелле шундый замандашың булу — үзе зур бәхет.**

**Шамил МАННАПОВ**

# Фарсил Зыятдин

## Кайту

Идел-йортым кат-кат чайкалганда,
Сибелгәнбез бөтен дөньяга:
Аерылырбыз, бүленербез, диеп,
Ул чагында кем соң уйлаган!

«Бүленгәнне бүре ашаган»ын
Төшенсәк тә, соңлап төшендек.
Идел-йорттан һаман ераккарак —
Аю урманына күчендек...

«Аерылганны аю алган»ны да
Аңласак та, бик соң аңлаштык:
Җаның саклап калыр өчен күпләр
Маңкорт булып җирдә җайлашты —
Аю табаннарын ялаптыр...

Бүленгәнне бүре эләктерде,
Аерылганны аю таптады.
Изге сукмакларда туфрак булдык,
Ә туфракны үлән каплады.

Тапталсак та, бер горурлык хисе
Сүнми калган күңел түрендә:
Сынауларда сынмас Ватаным бар —
Туып килә ал таң күгендә.

Кыр казлары кебек каңгылдашып,
Кайта татар изге иленә:
Тамыр төпкелләре тарта — «изге
Сөт», кан тарта Болгар җиренә!

* * *

Халкыбызга ирек даулыйм, диде...
Ә үзенә алды ул аны:
Уңга-сулга чәчеп долларларны,
Күр: әйләнә бөтен дөньяны.

Өметен җуйган халык аста һаман,
Өстә яшь байлар, кикереп...
(Чиновниклар үтә төкереп.)
Кимсетелгән җаннар таба җәннәт,
Тик балконнан аска сикереп...

## Ак вә кара

Күккә баксаң, ак болытлар агып бара,
Җиргә баксаң, күз җиткәнме — бар җир кара:
ак вә кара, ак вә кара.

Тәрәзәмдә тулган айның ак шәүләсе,
Ә шәүләдә — Каракошның күләгәсе:
ак вә кара, ак вә кара.

Кайда соң сез, яклаучылар — изге җаннар,
Дүрт ягымда баш калкыта хамелеоннар:
ак вә кара, ак вә кара.

Төн үтәр дә атар таң, дип, көтә хаклык,
Серле Галәм йолдызлары сибә аклык:
ак вә кара, ак вә кара.

Йолдызлардан очкын ал да яктырт җирне,
Яндыр утта коллык дигән яман чирне:
ак вә кара, ак вә кара.
ак вә кара...

## Соңгы мизгел

Ник әле син шау чәчәктә бүген,
Сизмисеңме кышлар җиткәнен?
Иртәгесен шул бакчада сине
Белмисеңме ниләр көткәнен?

Бал кортларың инде күптән поскан,
Кояшың да сүрән, бик сүрән.
Ә шулай да, алмагачым, җаның
Бик канәгать шушы бер көннән.

...Гомереңең соңгы мизгеленме
Аклык белән шулай каплады?
Язлар килде... Алмагачым гына
Кабат инде чәчәк атмады.

Ул ел кышлар гаҗәп суык килде...

## Безнең гомер

— Нинди озын безнең бу гомер:
Күпме җирләр күреп өлгердем.
Елга тиңдер туган һәр көне —
Кайчан җитәр икән унҗидем?!

— Кыска да соң безнең бу гомер:
Эшләнмәгән әле күп эшем.
Аңламыйча менә шуны да,
Кулын изи инде җитмешем...

## Назларыңнан аерма

Гөлем, диеп, дәшә күбәләгең...
Шактый әле кояш баерга.
Язларыбыз инде үтте, диеп,
Назларыңнан мине аерма.

Игътибарым җитеп бетмәсә дә,
Канатымны минем каерма.
Дорфалыгым кайчак әрнетсә дә,
Назларыңнан берүк аерма!

Син бәхетем минем, таянычым,
Язлар үтте, диеп кайгырма:
Шактый әле кояш баерга,—
Назларыңнан мине аерма...

* * *

*Рәшит Әхмәтҗан истәлегенә*

Ирек даулап тынган йөрәгеңне
Сәрхуш таңнар хөкем итә калса,
Басар яшьләр, синең эшне яклап,
Йөрәгендә татар каны акса...

Дастаннарга тиң бу исемеңне
Байрак итеп, утка кергән чакта,
Берлек кирәк безгә, ныклык кирәк,—
Бүленүдән, Ходай, безне сакла!



# «ҺӘРКЕМ ҖИРДӘ БЕР БИЗӘК...»

Дөресен әйтим, кыска гына бу кереш мәкаләне авыр яздым. Бер башлыйм, бер ташлыйм, бер ташлыйм, бер башлыйм дигәндәй... Төп сәбәп шул: Кави Латыйп кем ул? дигән бик гади сорауга тәгаен инанып, чатнатып әйтү кыен. Шагыйрьме? Әйе, берәүләр шуны раслый. Унга якын шигырь китабы бар. Прозаикмы ул? Моны да танучылар бар. Чәчмә әсәрләре тупланган берничә җыентыгы чыкты. Кайбер әсәрләре безнең «Казан утлары»нда басылды. Тәрҗемәчеме? Әйе, бу да факт. Аеруча чуаш әдипләре белән тыгыз бәйләнештә. Берничә ел элек Чуашстанның олуг премиясенә лаек булды. Публицистмы? Монсын да инкярь итеп булмый. Җәмәгать эшлеклесе, сәясәтчеме?.. Бәлки, ул, беренче чиратта совет офицерыдыр, ә калган әдәби гамәлләре бер хоббидыр? бусы белән дә килешүчеләр табылырга мөмкин.

Мин үзем шәхсән Кави Латыйпны халкыбызның самими күңелле, үзенчә талантлы, иманлы бер улы дип саныйм. Күпне күргән, күпне кичергән Кави абый. «Балачактан туры без көрәшкә кердек» дигән шикелле, язмыш аны яшьли гарасат упкыннарына еш ыргыткан. Җитмеш ел гомер кичергән һәркем житмеш жиде бәла-каза, кайгы-хәсрәт кичеп мең сынаулар үтәдер.

Бу дөньялыкта һәркемнең үз сират күпере. Кави аганың ярты вөҗүден, ярты дөньясын сугыш кичерешләре билидер дип уйлыйм. Аны, шәхес буларак, сугыш еллары калыплаган. Гомумән, Ватан сугышы (мин аны Бөек Ватан сугышы дип түгел, Бөек Афәт дип атар идем) совет иле биографиясенең төп вакыйгасы, төп фаҗигасы һәм берничә буын илдәшләрнең аңын формалаштыручы фактор. Гуман фактор түгел, әлбәттә. Язмыштыр инде... Үсмер егет Кавига сугыш янгыныннан көйрәп яткан утлы күмерләр өстеннән күп йөрергә туры килә. Ялан тәпиләрен үк булмаса да, яшь егет бәгырен байтак көйдергәндер алар...

Кави абый белән утыз еллар буе дустанә мөнәсәбәттә яшәсәк тә, кызганыч, гомере сәхифәләрен җитәрлек белмәгәнмен икән. Соңгы биш-алты елда матбугатта дөнья күргән истәлек язмалары К. Латыйп турында байтак яңа мәгълүмат бирә. Тәэсирәттән сискәнеп куйган мизгелләр дә булмады түгел. Бу яктан «Югалган кыйбла» дип исемләнгән новеллалар циклы («Идел», № 7, 1993) аеруча гыйбрәтле. Кереш сүзендә автор болай яза: «НКВД гаскәрләренең бер рядовое буларак, мин унҗиде яшемдә... сугыш операцияләрендә катнаштым. Абверчылар, эсэсовчылар, террорчылар, диверсантлар... Көнбатыш Украинаны

аркылыга-буйга кат-кат үттем. Сугыштан соң, КГБ (НКВД) гаскәрләренең хәрби училищесында укыганда, без курсантларны Балтыйк буена алып киттеләр, анда безгә Литва, Латвия, Эстония җирләрендә хөкүмәтнең «махсус заданиеләрен» үтәү йөкләнелде... Милләтчеләр биргән сабаклар мәңге онытылмас... Мәгънәсез, канлы ул көрәштә, сугышта ике яктан да корбаннар гаять күп булды. Әле дә мин аларның соңгы авазларын ишетәм. Без үзебезне тикмәгә генә «Сталин корбаннары!», «Әҗәл кешеләре!» дип атамадык шул... Хәрби училищены тәмамлагач, мин чит илдә, Кара диңгез буенда хезмәт иттем... Соңыннан Татарстан Язучылар берлегенең һәм үземнең тырышлыгым аркасында Совет Армиясеннән китә алдым. Әле һаман да солдат чактагы тәэсирләр белән яшим...»

Әйе, гомер юлын яңадан үтеп булмый. Нәрсә булган — шул булган. Үзәгендә ниндидер фаҗига ятмаган язучы бездә сирәктер. Кави Латыйп шагыйрь булып туып, офицер булып яшәп, соңрак аңга килеп, янәдән юл башы — шагыйрьлегенә кайткан кеше. Бу кайту каршылыклар һәм күңел җәрәхәтләре аша озакка — берничә дистә елларга сузылды. Ул аны үзе дә таный: «Ә төптән уйланганда гаеп минем үземдә. Аяз Гыйлаҗев әйткәнчә, ориентирым дөрес булмады. Гаскәри вә офицер буларак яшьлегем армия сафларында узды, төп тәрбияне мин шунда алдым... Шигырьләрем ничектер, ә бит чыннан да гражданскида олыгайгач кына яшәргә өйрәндем. Соң булса да уң булсын! Үземә шундый теләк теләп калам» («Шигърият мине яшәргә өйрәтте», 1995 ел). Кем әйтмешли, Кави Латыйп — башлаган юлы белән китсә, бәлки, күптән генерал булыр иде. Әмма ул, үз сүзе белән әйтсәк, гражданскида да рядовой булмады... Хәер, гаҗәп тә түгел, хәрби дөньядан киткәненә дә 40 елдан артык бит. Беләсез, 50 елларда, соңрак та, офицер халкы бик дәрәҗәле санала иде. 25 яшен яңа тутырган капитан Кави Латыйпның җәмгыятьтәге урынын чамалап була.

Юллар ачык! Һәм тәвәккәл Кави Латыйп капка-читәннәр ашамы, сукмак-магистральләр үтепме әдәбият-сәнгать дөньясына ыргыла. Шул чорның күренекле шәхесләре, мәшһүр талант ияләре белән аралаша, иҗади хезмәттәшлеккә омтыла. Салих Сәйдәшев, Хәсән Туфан, Рәшит Ваһапов, Әнвәр Давыдов, Габдрахман Әпсәләмов, Сара Садыйкова, Фатих Хөсни... Әдәби кичәләр, театр премьералары, сахраларга чыгып күңел ачулар... Үзе бер дөнья, үзе бер мәктәп! Күргәнне генә күзаллап, белгәнне генә искә төшереп, кичергәнне генә хәтерләп була. Ә Кави аганың хәтер сандыгы бай! Соңгы елларда дөнья күргән «Кояшны күмү» (1990), «Югалган кыйбла» (1993), «Әдрән диңгез» (Салих Сәйдәш ядкәре) — (1994), «Мин дә мишәр, син дә мишәр» (1996), «Җәйге шәфәкъле, шәфкатьле көннәрендә» (1996), «Боеручылар һәм башкаручылар» (1996) һ. б. истәлек язмалары укучыларда зур кызыксыну уятты һәм бу бәрәкәтле башлангыч артабан дәвам ителер дип ышанасы килә. Хәтерне яңарту, үзебездән бигрәк, киләчәк буын өчен кирәк.

Быелның май аенда Кави Таһир улы Латыйпка 70 яшь тулды. Матбугатта шактый тәфсилле мәкаләләр чыкты. Юбилей мөнәсәбәте белән, гадәттә, укучылар өчен беркадәр биобиблиографик мәгълүмат та бирелә. Без дә шул вазифаны үтәп китик.

Ул 1927 елның маенда Чуашстанның Батыр районы Кызыл Чишмә авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Татар Тимәше авылында укытучы булып эшләп ала. Алда әйтелгәнчә, 1944—1955 елларда хәрби хезмәттә. Демобилизацияләнгәч, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында, Мәгариф министрлыгында, Казан телестудиясендә, күп тиражлы газетада, СССР педагогия фәннәре Академиясенең фәнни-тикшеренү институтында эшли. Читтән торып М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый. Пенсиягә чыккач та җәмәгать эшләрендә актив катнаша: Татарстан республика партиясендә җаваплы эшләр башкара.

Әдәбиятта кылган гамәленә килсәк, ул инде ярты гасыр дәвамында актив иҗат итә. Татар, рус, чуаш телләрендә унбишләп китап чыгарды. Күбесе — шигырь китаплары. Минемчә, арада аеруча игътибарга лаеклылары — «Вакыт канатында», «Хәтер йомгагы», «Иркен сулыш»... Кайбер шигырьләренә композиторларыбыз матур-матур гына көйләр яздылар. Кави Латыйп шигырьләре турында төрле фикерләр бар. Шагыйрьлеген танымаучылар да юк түгел. Болары — нигездә, кулуар сөйләшүләрдә. Рәсми тәнкыйтьтә иҗатын хуплаучылар

күп. Мәрхүмнәрдән Ә. Давыдов, С. Хәким, М. Мәһдиев, исәннәребездән — И. Юзеев, Р. Мостафин, Н. Фәттах, Р. Гаташ, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Зөлфәт... «К. Латыйп үзенең сөйләм ысулын, поэтик интонациясен тапты. Аның шигырьләрендә нинди дер эчке драмага, бик тирән яшерелгән трагедиягә ишарә бар. Аның һәр шигыренең нигезендә фикер ята, ләкин коры риторика түгел — хисле фикер»... ди Р. Мостафин. «Алда — ачылмаган дөнья» исемле кереш мәкаләдә И. Юзеев болай дип өсти: «Һәм менә... һич тә уйламаганда, К. Латыйп үзенчәлекле шагыйрь булып ачылды... Минем алга жаны белән хыялый-сабый, акылы белән абый, дөньяның михнәтен дә, рәхәтен дә татыган, йомшак табигатьле, әмма каты характерлы Кави килеп басты». Бәлки, бу урында бәхәсләшергә дә мөмкиндер. Картаеп барган бер бирмеш көндә кинәттән генә яңа Уитменнар, Нерудалар туа алмастыр... Поэзия — Бөек Сер. Үтә күренмәле примитивизмны, ирекле йәки ирексез формада, нинди генә рифмалар белән үрмә, Поэзия кабул итмәячәк. Миңа калса, К. Латыйп инде шул Бөек Сергә ачкыч тапты шикелле. Әмма алда әле ачасылар да ачасылар!.. Аның «Үземә» дигән кыска шигырендә мондый юллар бар:

> Шагыйрьмен тумыштан,
> каләм тотарга миңа Тәңре үзе кушкан.
> Шигърият дигән сандал сукканмын,
> шигырь яза-яза чыныкканмын
> вә җинеп чыкканмын.

Җиңеп чыгу тойгысы — бөек хис. Бу очракта Козьма Прутков сүзләре искә төшә: «Если хочешь быть счастливым, будь им!»

Шагыйрьне аңлыйсың, беләсең килсә, аның туган җирен барып күр, диләр. Үткән ел «Казан утлары» егетләре белән без Чуашстанга кергән Батыр районы авылларында булып кайттык. Кави аганың туган авылы — Кызыл Чишмәдә булган очрашулар бик нык хәтердә калды. Затлы, иманлы кешеләр күрдек, мәктәптә сөйкемле балалар белән очраштык. Мәктәп директоры Сәет Гаязов сүзләре һаман колакта: «Безнең авыл Казанга Кави Латыйпны бирде. Сез саклый күрегез инде аны! Ул безнең өчен бик кадерле кеше!» Бераз төчерәк тоелырга мөмкин бу сүзләрне мәнә ни өчен дә язам: Татарстаннан читтә татарлар яши торган бүтән төбәкләрдә хәл бүтәнчәрәк, аянычрак дип беләбез. Әйтик, Һ. Такташның Сыркыдысында, Ш. Камалның Пешләсендә, Г. Кутуйның Кынадысында... Барып кайткан кешеләр бу якларда элеккеге милли рух нык какшаган, диләр. Татар мохите, татар рухы, татар мәктәпләре ипле генә эшләп килгән Батыр якларыннан, шөкер, әдәбиятыбызга яңа көчләр әле һаман килеп тора. Р. Зәйдулла, Р. Султи, Җ. Сөләйман, Р. Якушев... Кави абый бу яшьрәк әдипләрнең үзенчә бер өлкәннәре-старосталары сыман тоела.

Кави аганың бер китабы «Тормыш бизәкләре» (ул урыс телендә «Краски жизни» исеме белән чыкты) дип атала. Төптәнрәк уйлап, шагыйрь яшәешенең бөтен рухын, омтылышын, холкын күңелең аша кичерсәң, ирексездән мондый тәгъбир телгә килә: фронтовик әдип Кави ага Латыйп үзе дә тормышыбызның бер бизәге бит!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*Май, 1997 ел. Балык Бистәсе.*

# Кави Латыйп

# СЕРЛЕ КУЛТАМГАЛАР


*Автограф — култамга —*
*гел күңелдә, гел анда.*
*Шәхсән үзең генә белгән*
*серле хикмәт бар анда...*

Әйе, култамгалар — серле бер дөнья. Аларның телләрен, серләрен бары тик үзең генә беләсең. Шул серле култамгалар, ерак еллар аша, сине кызыклы шәхесләр белән кабаттан очраштыра, күзгә-күз караштыра, сөйләштерә, серләштерә...

Әйтсәң, язсаң, кеше ышанмаслык, мин — яшь бер татар әдибе, егерменче гасырның бөек фикер иясе, фәйләсуфе, француз язучысы Жан Поль Сартр каршына утырып, аның «Экзистенциализм — ул кешелеклелек» дип аталган трактатының, гыйльми хезмәтенең төп концепциясен, кайбер тезисларын тыңлыйм. Авторның сөйләгәннәреннән шуны аңлыйм, галимнең тел төбендә ике мәсьәлә: «Кеше табигате» вә «Кеше иреге». Жан Поль Сартрның әйтүенчә, экзистенциализм (латинча — яшәеш, тормыш-көнкүреш дигән сүз) тәгълиматына нигезләнеп җавап биргәндә, кешенең яшәеше, язмышы үз кулында. Кеше — үзенең тумышы, табигате белән эчке азатлык иясе. Кеше — якты дөньяга килүе, эчке табигате белән ирекле. Кеше үзе ирекле икән, димәк, аның уй-фикерләре дә ирекле.

Әнә шундый кызыклы фикерләр авторы белән без 1966 елның көзендә Мәскәүдә, Әдәбият институтында очраштык. Жан Поль Сартр сул радикализм, экстремизм, чиктән тыш карашлар тарафдары иде һәм соңгы сулышына кадәр шундый булып калды. Чигенмәс, килешмәүчән фәйләсуф, «Иблис вә Хак-Тәңре», «Чебеннәр», «Азатлык юллары», «Яшәеш вә бушлык» дигән әсәрләр авторы иде.


Сартр үзенең тышкы кыяфәте белән Виктор Гюгоның Квазимодосын хәтерләтә иде. Бәләкәй генә гәүдәле, шар күзле, бөкресе дә бар. Күз карашы куркыныч, кешене үтәли күрә. Тешләре ыржаеп тора: менә хәзер сиңа ташланыр да, өзгәләр шикелле. Үзенең бер көнен уздырды ул без — яшь әдипләр белән гәпләшеп. Мин аңа каршы өстәлдә, беренче рәттә утыра идем. Тәнәфес вакытында үзеннән автограф бирүен үтендем. Фамилиямне әйтүгә, ул отып алды. 1966 елдан бирле саклана аның култамгасы. Сартр безнең белән бик җылы саубуллашты. Һәркайсыбызның кулын кысты, һәркайсыбызга матур теләкләр әйтте. Ишектән чыкканда ул: «Бөтендөнья гражданнары булыгыз! Шаблон буенча яшәмәгез, Сталинны фаш итегез, властька ярашмагыз, Франция гел сезнең белән!» — диде. Бу очрашуда мин аның бернинди абруйга баш имәвен, хәтта әсәрләре өчен бирелгән Нобель премиясеннән дә баш тартканлыгын белдем.



Бөтен дөньяда билгеле булган шәхесләрдән миндә тагын бер бөек кешенең култамгасы саклана — ул Бразилия язучысы Жоржи Амадуныкы. Амадуның култамгасын мин 1954 елны, язучы Казанга килгәч алган идем. Ул чакта атаклы романчы татар әдипләре белән дә очрашты. Ул «Иксезчиксез җирләр», «Ильеус каласы», «Кызыл шытымнар», «Идән асты азатлыгы» исемле романнарын вә повестьларын ничек язуы турында сөйләде, тугрылыклылык, намуслылык турында сүз алып барды. Ул Халыкара Ленин премиясе лауреаты иде, бик абруйлы чагы. Ерак океан артыннан Идел буена кунакка килүченең һәр сүзе тансык тоелды. Әмма еллар узган саен язучы үзе дә, аның укучылары да үзгәрде. әйтергә кирәк, безнең татар укучыларының зәвыкъларына карап, Жоржи Амадуның «Габриэланың гыйшкы» дигән күләмле популяр әсәрен

күренекле тәрҗемәчебез Кыям Миңлебаев татарчалаштырды. Әлеге әсәрнең өзекләре «Казан утлары»нда басылып, журнал укучыларында зур кызыксыну тудырган иде.

Жоржи Амадудан автограф алуга кырык ике елдан артык вакыт узды. Аннан соң күпме сулар акты, ә очрашу нәкъ кичә генә булган шикелле. Озын буйлы, ыспай киемле, кара бөдрә чәчле, көләч йөзле, кыяфәте белән мулатны хәтерләткән, аксөяк-зыялы Жоржи Амаду һаман да күз алдында. Әйе, бер очрашу, бер күрешү — үзе бер гомер, дөресе, гомерлек хатирә.



Анна Ахматова әйтүенчә, Александр Твардовский шигъриятендә сер, драматиклык җитенкерәми. Дөрес сүзгә җавап юк. Ә бит Александр Твардовский туып-үскән гаиләнең язмышы бик тә фаҗигале вә серле. Аның әтисен-әнисен, бертуганнарын сөргенгә сөрәләр. Әйе, утызынчы елларда шагыйрьнең утар тоткан урта хәлле әтисе Трифон Гордеевич Твардовский үзенең тормыш иткән хатыны вә дүрт улы белән Себергә сөрелә. Трифон агайның тагын бер улы Саша — Александр Твардовский үз гаиләсеннән ничек итеп аерылып калалгандыр, аныСын шәхсән өзеп әйтә алмыйм. бәлки аның Загорьедан китеп институтта укуы, аннары Смоленск өлкә газетасында хәбәрче булып эшләве, инде егерме ике-егерме биш яшьләрендә социализм вә колхозлаштыру турында күләмле ике поэма иҗат итүе ярдәм иткәндер, кем белә? Әмма шунысы билгеле: ерак сөргеннән ярты гасырдан соң, исән калган бердәнбер ир туганы, җитмеш яшьлек Иван Трифонович кына Загорье утарына әйләнеп кайта. Калганнары эзсез югала. Иван Трифонович сугыш вакытында финнарга әсирлеккә эләгә, шунда швед телен өйрәнә вә «эстон» булып Швециягә каЧа, менә дигән балта остасы булып китә. Паспорт ала. Җае чыккач, совет консуллыгында була. Туры килә бит, шунда «Огонек» журналында бертуган абыйсының шигырьләре белән таныша... Загорьега кайткач, Иван Трифонович үз куллары белән туган утарын — йортны-кураны, корылмаларны, җил тегермәнен торгызa, дөресен әйткәндә, яңадан сала. Утар тирәсендә яшәүче кешеләр белән бергәләп, әр-яңа бинада шагыйрь Александр Твардовскийның музеен оештыра.

Александр Твардовский талантлы вә колачлы шагыйрь иде. «Новый мир» журналын рәттән уналты ел җитәкләгән Александр Трифонович Твардовский беренчеләрдән булып хәбәрдарлыкка юл ярды. Баш мөхәррирлектән алынса да, тууының алтмыш еллыгы (1970) уңае белән аңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелачәк дигән хәбәр таралган иде. Бирелмәде, бары тик Хезмәт Кызыл Байрагы орденына гына лаек булды...

Шәхес культы фаш ителгәннән соң, башкаладагы журналлар арасында ачы хакыйкатьне, дөреслекне беренче булып «Новый мир» журналы, аның баш мөхәррире әйтте. Мин үзем ул елларда Мәскәүдәге Әдәбият институтында читтән торып укый идем. Без «Агымдагы әдәбият» дип аталган семинарларда Твардовскийның натуралистик мәктәбен уздык, «Новый мир» журналындагы проза әсәрләренә анализлар ясадык, редколлегия әгъзалары белән очраштык. Безнең өчен Твардовскийдан да абруйлы, кыю, туры сүзле әдип, мөхәррир юк иде. Йомшак кәнәфиләрдә утыручы номенклатурачыларга баш имәс «АТЭ» — Александр Твардовский белән без горурлана идек.

1968 ел. Менә өч атна инде мин дөнья хәбәрләрен мәскәүлеләрдән ишетеп яшим: «Сахаровның «Уйланулары», Сталинның кызы Светлананың әтисе хакында китабы басылып чыккан, Паустовский авырып ята, Дубчек, «черегән» интеллигенция ярдәмендә, тулы мөстәкыйльлек даулап, Чехословакиядән совет гаскәрләрен чыгаруны таләп итә. Әлеге зыялылар дигәннәре, бергәләп, хартия — сәяси документ язганнар. Конбатыш радиостанцияләре көн-төн шуны укыйлар, колакка тукыйлар икән.


21 май көнне, әйләдән соң, мине институтның партбюросына дәшеп, кулыма чакыру билеты тоттырдылар. Коми прозаигы, сабакташым Иван Торопов (соңыннан РСФСРның Дәүләт премиясен алуга ирешә) белән Әдипләрнең Үзәк йортына (ЦДЛ) партия

активы җыелышына килдек. Зал тулы язучылар: атаклыларыннан билгесезләре күбрәк. Актив җыелышының көн тәртибендә — Чехословакия мәсьәләсе. Рәис җыелышны ачык дип белдергәч, нотыкчыга сүз бирде. Нотыкчы сөйли, ләкин аны беркем дә тыңламый, кайсы үз уйлары белән мәшгуль, кайсы күршесе белән гәпләшә. Мин президиумда утыручыларны барлыйм: Михалков, Кочетов, Алексеев, Грибачев, Полевой, Кожевников, Сартаков, Соболев, Софронов, Чаковский (Кочетовтан тыш һәммәсе дә — булачак «Алтын Йолдыз» кавалерлары)... Шулчак күземә иң арткы рәттә, кырыйда утыручы Александр Твардовский чалынып китте: таза гәүдәле, карашлары бик тә җитди, елмаюның әсәре дә юк. Кулында — «Труд» газете. Нотыкчы сөйләп бетергәч, аерым чыгышлар башланды: берәүләре антикоммунистларны, антикультурачыларны фаш итә, икенчеләре чехларны, словакларны ничек яшәргә, нинди юл белән барырга өйрәтә. Күршем Торопов нилер уйлыйдыр, ә минем бер колагымнан керә, икенчесеннән чыга...

Твардовский исә «Труд» газетен тезенә куеп укый бирде: нотыкчыга да, чыгыш ясаучыларга да игътибар итмәде.

Җыелыш тәмам. Мин ишек төбендә түземсезләнеп Твардовскийның чыгуын көтәм. Менә ул минем яныма килеп җитте. Һәм мин, бар кыюлыгымны җыеп, аңа каршы киттем. Исәнләштек. Ул ашыкмый гына җавап-сәлам кайтарды. Шулчак кулымда «Книга лирики» дигән үзенең шигырьләр китабын күреп алды. Исәбем — мәшһүр шагыйрьдән автограф алу иде. Әмма Александр Трифонович култамга салырга ашыкмады: «Үзең кайдан?» — дип сорады. Мин әйтеп бирдем. «Нәрсә, бөтен ил язучыларын җыйганнармы әллә? Булыр, булыр. Чехлар һәм словаклар теләсә нишләсеннәр, ләкин безнең алар тормышына тыкшынырга хакыбыз юк! Син үзең кем, шагыйрьме?» «Әйе, ләкин Әдәбият институтында проза бүлегендә укыйм». «Исеңдә тот: проза — роза түгел. Безнең журналга тәкъдим итәрлек әсәрең юкмы?» «Бар!» «Әсәр нәрсә турында?» «Бандеровчылар хакында». «Кызыклы тема. Ләкин четерекле. Баш каһарман үзеңме?» «Юк, минем элеккеге рота командирым. «Дезертир» дигән хикәям дә бар». «Кулъязмаңны кемнәр укыды?» «Доцент Прямков». «Кем ул?» «Әдәби осталык семинары җитәкчесе». «Мин андый кешене белмим». «Тагын кемнәр?» «Тәнкыйтьче Борис Леонов». «Знамя» штыгы! Җитди белгеч. Әсәрең белән бергә Леоновның бәяләмәсен дә алып кил. Кыскасы, бандеровчылар турындагы әсәреңне көтәм».

Александр Трифонович, кесәсеннән авторучка алып, китабына автограф язарга кереште. Мин аның кулларына игътибар иттем. Көрәктәй иде алар. Урман кисә торган, колач җитмәс агачларны күтәрер өчен яралган куллар! Твардовскийның «Василий Теркин» поэмасындагы «Бу нәни сабантуй», «Бу олуг сабантуй» дигән шигъри юллар хәтергә килде. «Александр Трифонович, сабантуйны кайдан беләсез? Ишетепме, әллә бил тотышыпмы?.. Кулларыгыз сөбханалла!» — дип әйтергә уйлаган идем, тыелып калдым. «Димәк, син татар... Смоленск җирендә сугышкан Кутузов армиясендә татар полклары булган, алар Наполеон гаскәрләрен тар-мар итүне, ягъни җиңүләрен сабантуй дип атаганнар. 1812 елгы сугышта Смоленск җирендә күпме татар ятып калган». «Әйе, бабаларымның сөякләре бөтен дөнья буйлап сибелгән»...



Александр Трифонович тынып калды, аннары киң маңгаендагы тирне уң кулы белән сөртте дә: «Нинди лихорадка! Әлеге җыелыш та шуны хәтерләтте. Йә хуш, изге теләкләр үзеңә! — диде. Александр Трифонович өстәл аша кулын сузды: Игътибарың өчен рәхмәт! Мин бераз хәл җыям да өйгә тәпилим...»

Александр Трифонович, богылны хәтерләтеп, өстәл янында калды. Әллә нигә кәеф начарланып, күңелсез булып китте... Әмма үземне тынычландырырга тырыштым: «1962 елның сентябрендә Күктүбәдә мин Александр

Трифоновичны чак кына күрми калган идем. Ә бүген — 1968 елның 21 маенда аны күрү генә түгел, үзе белән өстәл артында сөйләшеп тә утырдым. Алай гынамы, хәтта «Әсәреңне көтәм!» — диде ул. Бу сүзләр миңа тылсымлы булып тоелды, кыскасы, шагыйрь белән очрашу миңа гипноздай тәэсир итте. Повестьны мин көн-төн эшләдем, йокы качты, әсәрем белән Твардовскийны «шаккаттырасым» килде. Әлеге повестьны филология фәннәре докторы, әдәбият белгече, тәнкыйтьче, уку дәверендә минем сердәшемә әверелгән Борис Леоновка бирергә булдым, әсәрне «Новый мир» журналының баш мөхәррире үзе көткәнен әйттем. Борис Леонов гаять таләпчән, чын мәгънәсендә ир холыклы, кыю, колачлы тәнкыйтьче иде. Кыскасы, Борис хупламады: әсәрең йөгерек тел белән язылган, кызыклы, ләкин журналга тәкъдим итәр өчен яңалык җитми, үз позицияң билгеле түгел, диде. Әсәр диплом эшеннән дә төшеп калды. Борис тәкъдиме буенча мин диплом өчен хикәяләрне генә тупладым, чөнки ул повестька карата килешмәүчән булып калды, фикере бер мыскал да үзгәрмәде. Яңадан эшләр өчен синең барлык мөмкинлекләрең бар, диде.

«Новый мир» журналы редакциясенә мин кергәләп йөри идем, әмма анда хәл-әхвәл киеренке иде. Баш мөхәррир бүлмәсенең ишеге һаман ачык килеш тора, сәркәтип-машинистка язу машинкасының хәрефләренә бармаклары белән бәргәләп утыра. Коридорда, бүлмәләрдә туктаусыз ике исемне тәкърарлыйлар: «Твардовский!» «Солженицын!» Сораша торгач, ачыкланды: башкаланың бер төркем язучылары, төрле төбәкләрдән чакырылган әдипләр белән бергәләп, төгәле, Рязаньга барып, Александр Солженицынны Язучылар Союзыннан чыгарганнар икән! Аңарчы Солженицын «Новый мир» журналына усал хат язган булган. Ә Михаил Шолохов, Солженицынның кулына каләм тоттырмаска кирәк, дип әйткән. Александр Твардовский үзе Кунцево шифаханәсендә авырып ята икән... Институтта көзге сессия вакыты, 1970 елның сентябрь азагы иде бу.

...1971 елның май азагында, дәүләт имтиханнарын тапшырып, Мәскәүдә булып кайттым. Александр Трифонович исән иде әле. Шул ук елның азагында, декабрь аенда, Борис Леонов миңа һич тә көтмәгәндә шалтыратты: «АТЭ дөнья куйган... Ә син повестеңны эшләвеңне дәвам иттер һәм аны «АТЭ» истәлегенә багышла. Ул чын солдат иде. Беләсеңме, ул Бөек Ватан сугышы башланасы көн алдыннан туган. Ә 21 июнь — җәйге фасылның иң озын көне. «АТЭ»нең гомере кыска булды. Алып гәүдәле ир-егет өчен алтмыш яшь нәрсә ул!? Нишләп телеңне йоттың?..»

Борис белән сөйләшә алмадым, тамак төбенә ачы төер утыргандай булды... Соңыннан Мәскәүгә баргач белдем: Александр Трифонович 1971 елның декабрендә үпкәсендәге яман шеш авыруыннан вафат булган икән. Исән чакта бертуктаусыз гаять тә көчле «Прима» сигаретларын суырган. Минем белән очрашканда да шул сигаретларны тарткандыр әле. Кем әйтмешли, гел тәмәке пыскытты. Хәер, мин үзем тартмыйм, шуңар папирос вә сигаретларның сортларын һич кенә дә белми идем.

Александр Твардовский Новодевичье зиратында күмелгән. Бәхиллләшкәндә, Солженицын аны чукындырган, урысча әйткәндә, перекрестил. Ә мин, үзе исән чакта ук, Твардовскийга шигырь багышлап язган идем.


Татар шагыйрьләре белән якыннан аралашкан, күпләре белән дуслашкан Михаил Львов — милләте белән татар. Аның мулла кушкан исеме Рәфкать, ә чын фамилиясе Маликов. Әйе, аны татар хатыны тапкан, ә бишеген татар карчыгы — әбисе тирбәткән. Үзе әйтүенчә, ул гүзәл Башкортстандагы Нәсибаш авылында, мөгаллим гаиләсендә туган, балачагы сандугачлы Ләклә авылында узган. Әтисе-әнисе үлеп киткәч, Рәфкать балалар йортында тәрбия алган. Балачагында ук шигырьләр яза башлаган. Ә үзен шагыйрь дип хис итә башлагач, ул Михаил Львовка әверелгән. «Татар улы була торып кайдан таптың ул псевдонимны?» — дидем мин аңар бер сөйләшүдә. «Әйткәнемчә, мин балалар йортында тәрбияләндем. Гел урыс мәктәпләрендә укыдым. Ятим бер үсмер булarак, ятим бер исемне, кушаматны (Лев Толстой да ятим үскән) алдым. Бик тә олы әдип буласым килгән иде. Шул сәбәпле Львовка әверелдем. Ә Михаил дигән исемем бар иде инде. Балалар йортында миңа Миша дип эндәшәләр иде. Мәскәүдә яшәгәндә яшьлектәге каләмдәшләрем Николай Майоров, Павел Коган, Алексей Недогонов, Семен Гудзенко, Михаил Луконин, Сергей Наровчатов, Марк Максимов, Александр Межировлар арасында «Михаил Львов» булып киттем. Шул исем белән шигырьләрем Ватан сугышына кадәр үк басылды. Сугышта да фронтовиклар мине Михаил Львов

буларак беләләр иде. Минем барлык дус каләмдәшләрем диярлек фронтовиклар: Мостай Кәрим, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Хөсәен, Сергей Наровчатов, Марк Максимов, Сергей Орлов, Михаил Дудин, Юлия Друнина, Александр Межиров...»

Рәфкать Маликов белән мин 1956 елны көзен ул Казанга килгәч таныштым вә шуннан безнең озакка сузылган дуслык башланган иде. Аның белән Казанда, Мәскәүдә күп тапкырлар очрашырга туры килде: кешеләр белән бергәләп тә, икәүдән-икәү генә дә. Фронтовиклар, офицерлар, каләмдәшләр буларак безнең тел уртак иде. Казанда чакта ул миңа кадерле кунак булса, Мәскәүдә мин аңар нөкъ шундый идем. Башкалада, ягъни Мәскәүдә мәҗлесләр җыеп, ул мине кырык-маса-кырык тапкыр кунак иткәндер. Ихлас, юмарт, киң, хөр күңелле, җор сүзле иде ул. Каләмдәш Рәфкать Мәскәүдәге вә төрле төбәкләрдән килгән әдипләрне магнит сымак үзенә тарта иде. Әдипләрнең үзәк йортындагы кунак бүлмәсендә, бергәләп, самавыр «җыры»н тыңлый-тыңлый чәй эчүләр, мәзәк сөйләүләр, шаярулар, көлүләр ничекләр итеп онытылсын! Әнә, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Давид Кугелтинов, Мостай Кәрим кебек олуг әдипләр дә аның авызына карап тора. Әдәбият институты шәкертләре арасында да ул үз кеше. Ул үзе җитәкләгән иҗат семинарындагы һәр студентка сәләтле шагыйрь, яхшы иптәш. Җитәкче, остаз, киңәшче. Сүз белән дә, эш белән дә һәркемгә ярдәм итәргә әзер, тик әйт, сора гына. Матди ярдәм кирәк икән, рәхим ит, соңгысын бирер. Аның семинарындагы яшь шагыйрьләрнең туксан тугыз проценты татарлар, башкортлар, үзбәкләр, казакълар, әзәрбайҗаннар, чеченнар — кыскасы, үзебезнең диндәшләр иде.

Хозурлыктан ямь, тәм табучы, Хозыр-Ильяслык кылучы, исеме җисеменә туры килгән Рәфкатьнең озата баручы, юлдаш булучы Переделкинода чакта йөрәгә ярылып, тибүеннән туктады. Миндә аның култамга салган биш китабы бар. Аларның мин һәммәсен онытылмас олуг дустымның истәлеге итеп, күз алмасыдай кадерләп саклыйм.

Белгәнемчә, Белла Әхәт кызы Әхмәдуллина үзенең 1962 елны дөнья күргән «Кыллар» («Струны») исемле шигырьләр җыентыгы белән танылып китте. Ул китапта күңел кыллары турында сүз барды. Яшь шагыйрә үзенең ихлас, самими, бик тә табигый, үзенчәлекле шигърияте-аһәңе белән




шигырь сөючеләрнең күңелләренә үтеп керде дә инде. Әлегә кадәр әйтелмәгән, яңалык алып килгән лирик-фәлсәфи шигырьләр иде алар. Кыскасы, Белла Әхмәдуллина урыс поэзиясендә яңа катлам шигырь сөючеләрне тудырды. Алтмышынчы елларда Әдәбият институтында укучы яшь шагыйрьләр белән бергәләп, берничә тапкыр аның белән очраштык, үз укуында аның шигырьләрен тыңладык. Аның шигырьләре беркемнекенә дә охшамаган, алар бары тик аныкылар иде. «Белла Әхмәдуллина — кабатланмас бер шигъри шәхес», — дигән уй-фикергә килдем мин. Әйе, аның шигъриятенең төмен татыр, назын белер, гамен тояр өчен шигырьләрен шагыйрәнең үз укуында тыңларга, ишетергә кирәк иде. Шигырь укыганда, ул нинди бер күренмәс, билгесез, яшерен музыка коралы белән эш итә дә, күңел кылларына чиертә төсле. Белла шигырьләрендә мин, ир-ат буларак, шигъриятә әлегә кадәр үзем белмәгән, кичермәгән тылсымлы вә сихри көчләр — иркәләнү хисләре таптым. Минемчә, хатын-кызлардан җиһанда андый шагыйрә юктыр.

Белла шигърияте — юксыну-сагыш, моң-зар белән тулы, ул бәлале, фаҗигале. Белла — тумышы, язмышы белән бәлале, фаҗигале шагыйрә. Ул язмыш, ул фаҗига Әдрән диңгезе ярларыннан Русиягә бер шарманкачыга ияреп килгән әнисенең әнисенә — әбисенә бәйле. Ул әбинең фамилиясе

Стопани булган. Стопанилар нәсел-нәсәбе белән дөм кара чәчлеләр, кара күзлеләр, кара кашлылар, итальяннарча музыкага сәләтлеләр. Шәхсән мин үзем Белла башкаруында итальянча «Санта Лючия» җырын тыңлаганым бар: «Са-а-нта-а-Лю-у-чия, Сан-та-Люч-ия...»

Белла безнең дә милләттәш. Ул Әхәт абзый кызы. Белланың бабасы Вәли ятим үскән, аны «Казан ятиме» дип йөрткәннәр. Белла сөйләвенчә, шул татар егете итальян канлы кәләшкә өйләнгән. «Казан ятиме» Вәлинең әтисе Әхмәдулла исемле булган. Шулай итеп, шагыйрә бабасының әтисе исемен үзенең фамилиясе итеп йөртә. Әмма минем Белланың әбисе, әнисе йөрткән фамилиягә түгел, ә аның бабасының улы, Белланың әтисе исеменә басым ясыйсым килә. Әхәт исеме — ялгыз, берәү генә диган мәгънәне аңлата. Әйе, җиһанда Белла Әхәт кызы Әхмәдуллина берәү генә, ул шигърият-диңгезнең икенче табылмас хәзинәсе, энҗесе.

Миндә култамгалы китаплар аз түгел. Әмма кеше күңелен бакчага тиңләүче, аңар дан җырлаучы, мәдхия укучы шагыйрәнең автографы минем өчен аеруча кадерле. Әлеге автографлар арасында «Рәхмәт... бәхетле бул, Кави!» — дип култамга салучы тик бер Белла гына. Ул култамга, әйтерсең лә, минем тылсымлы талисманым. Тормыш юлымдагы бәхетсезлекләрдән шул талисман, шул сихри сүзләр мине коткармадымы икән? Әллә ирекле шигырь юлына да мине шул талисман алып чыктымы икән? Рәхмәт, Белла — Изабелла!

*Белла Ахмадулина*

# МОЯ РОДОСЛОВНАЯ

Спасибо, Кави, за внимание, будьте счастливы — Белла Ахмадулина 17 апреля 1964



Сергей Баруздинны мин, балалар вә яшүсмерләр язучысы буларак, илленче еллардан ук белә идем. Алтмышынчы елларда Сергей Алексеевич Баруздин «Дружба народов» журналының баш мөхәррире булып эшли башлады. Бер очрашуда семинар җитәкчебез үзенең шәкертләрен, без — яшь әдипләрне Сергей Баруздин белән таныштырды. Ул, беренче очрашуда ук, үзе турында киң карашлы, кешелекле, ярдәмчел икән диган фикер калдырды. Әлеге гәпләшүдә баш мөхәррир милләтләр әдәбиятының үсешенә басым ясады, яшь прозаикларны әсәрләре белән журналда катнашырга чакырды. Бу безнең күңелләргә бик тә хуш килде. Күп тә үтмәде сабакташым, коми язучысы Иван Тороповның «Карабодай боткасы» («Гречневая каша») исемле күләмле хикәясе «Дружба народов» журналында басылып та чыкты. Шуннан соң Иван Тороповның да, минем дә һәм бүтән милли яшь прозаикларның да журнал редакциясенә, баш мөхәррирнең үзенә сукмагы өзелмәде. Әллә ничә еллар рәттән ул безне канатландыра, илһамландыра килде. Баш мөхәррир Сергей Баруздин бер үк вакытта СССР Язучылар идарәсе каршындагы тәрҗемәчеләр шурасының рәисе дә иде. Ул җитәкләгән советның утырышларында, пленумнарында, Кыям Миңлебаев белән бергәләп, миңа күп тапкырлар катнашырга туры килде.

Милләтләр әдәбиятын, мәдәниятын үстерүдә Сергей Баруздинның роле гаять тә зур. Белгәнемчә, аның тәкъдиме буенча журнал битләрендә төрле темаларга дискуссияләр, бәхәсләр, фикер алышулар оештырылды. Ул елларда журналда Айдар Хәлимнең «Минем телем — минем дустым»

(«Язык мой — друг мой») («Дружба народов», № 6, 1988) исемле мәкаләсе журнал укучыларында ифрат зур кызыксыну тудырды. Кыскасы, «Дружба народов» белән «Новый мир» журналлары хәбәрдарлыкның беренче карлыгачлары булдылар. А. Рыбаковның дөньяны шаулаткан «Арбат балалары» («Дети Арбата») исемле романы белән бергә, «Дружба народов» журналында (№ 5, 1987), танылган төнкыйтьче Р. Мостафинның кереш сүзе белән, минем шигырьләрем дә төкъдим ителде. Ул хакта миңа беренчеләрдән булып, баш мөхәррир Сергей Баруздин үзе хәбәр итте, миңа аңардан берничә данә журнал да килде. Әйтергә кирәк, журнал битләре аша Сергей Баруздин үзенә яңадан-яңа дуслар тапты. Шундыйларның берсе мин идем. Шул дуслары ярдәмендә ул Таҗикстандагы Нурек ГЭСында олы бер китапханә оештырып, аның киштәләрен каләмдәшләренең китаплары белән тулыландырды. Әлеге китапханәгә, Сергей Баруздинның үтенече буенча, үземнең китапларымны мин дә юлладым вә шул уңайдан китапханә хезмәткәрләреннән рәхмәт хаты да алдым. СССР таркалгач, Таҗикстан бер «кайнар нокта»га әверелде. Инде ул китапханәнең язмышы ниндидер? Татар әдипләренең уртак вә якын дусты Сергей Алексеевич Баруздин да дөньяда юк. Гүр — үр түгел. Татар халкын, аның әдипләрен үз иткән олы йөрәкле әдәбият әһеленең авыр туфрагы җиңел булсын!

25 мая 1987 г.
Переделкино

Дорогой Кави Тагирович!

Поздравляю Вас со стихами в № 5 нашей "ДН"!

Не забывайте нас!

Заодно большая просьба.


Пришлите мне, пожалуйста, в редакцию две-три своих книги – можно на татарском – с автографами для нашего подшефного Нурека: "Интернациональной дружбинской библиотеке в славном Нуреке от одного из авторов "ДН"..." и т.д.

Хорошо?

Жду!

Всего Вам самого доброго!

Искренне Ваш



Ватан сугышында Ленинградны яклап, саклап калучы каһарманнарга салынган мөһабәт Монументта: «И ташлар! Кешеләрдәй нык булыгыз, нык торыгыз!» — дип чокып язылган шигъри юллар бар. Әлеге юллар башка ленинградлылар белән бергә 900 көн-төн бөҗра эчендә — блокадада яшәп, немец-фашист илбасарларга каршы аяусыз көрәш алып баручан Юрий Вороновның «Ташлар» («Камни») исемле шигыреннән алынган. Туган шәһәре өстендә бомбалар вә снарядлар ярылганда үсмер Юра шигырьләр яза. Еллар узгач, 1968 елны, яшь шагыйрьнең «Блокада» дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Ленинградлыларның тиңдәшсез батырлыгына багышланган әлеге җыентыкка егерме җиде шигырь тупланган. Аларга олуг шагыйрьләр Н. Тихонов, М. Дудин, С. Орлов зур бәя бирә.

Урыс укучыларына Юрий Воронов исеме башка шигырь китаплары белән дә яхшы таныш. Ә мин Юрий Воронов белән алтмышынчы елларда, Әдәбият институтында укыганда, Максим Горький иҗаты буенча махсус семинар

алып баручы профессор, татар миллəтен остазы Горький кебек ихтирам итүче Панков аша таныштым. Ул чакта Юрий Воронов «Знамя» журналында баш мөхəррир иде. Юрий Воронов беренче очрашуда ук миндə бик тə җылы тəэсир калдырды. Чөнки без — ул да, мин дə бер рухлылар идек. Соңгарак мин аның шигырьлəрен туган телебезгə тəрҗемə кылып, аларны миллəттəш шигырь сөючелəргə тəкъдим иттем. Аның шигъриятe минем шигырь рухына, стиленə, алымына охшаш иде. Югарыда телгə алынган тəрҗемəчелəр советының бер пленумында мин Юрий Вороновның үзем тəрҗемə иткəн шигырьлəрен укыдым. Алар төрки халыкларның əдиплəре-вəкиллəре тарафыннан алкышлап каршы алынды. Тəрҗемəлəрем белəн автор шəхсəн үзе танышканнан соң, аңардан автографлары куелган ике шигырь китабы вə хат килде. Кыскасы, без аның белəн куллар кысышып яшəүче дуслар булып киттек. Ə бит ул «Литературная газета»ның баш мөхəррире иде. Еллар узган саен безнең ике арадагы дуслык хислəре яңара торды. Тормышның ачысын-төчесен үсмер чагыннан ук татыган шагыйрь беркайчан да номенклатура, хакимият шагыйре булмады. Төүге шигырьлəреннəн алып, бүгенге көндə иҗат ителгəн шигырьлəренə кадəр, Юрий Воронов батырлыкка, каһарманлыкка дан җырлаучы булып калды. Бер үк вакытта ул менə дигəн лирик шагыйрь дə. Юрий Вороновның мəхəббəт турында җан тетрəткеч шигырьлəре бар. Менə аларның берсе:

Бер-берен усаллыктан тыймадылар,
Мəхəббəтне, икеүлəшеп, дүрт кул белəн кыйнадылар...
Үзара ярыша-ярыша,
Төрле яктан.
Мəхəббəт пышылдады ятып чалкан:
— Ахмаклар сез, шыр тилелəр!..—
Ə тегелəр, котырынып,
Мəхəббəтне тукмый бирделəр.

Киң дөньяга сыймадылар...
Мəхəббəтне көн-төн кыйнадылар.
Мəхəббəт корбан булды.
Ə бит аңа исəн калсын өчен,
Сулыш алсын өчен,
Кыланырга гына кирəк иде, сүндем дип, үлдем дип.
Мəхəббəт кылана да, ялганлый да белмəде.
Тегелəр дə, йодрык сорап,
Күршегə бурычка кермəде.


Мəхəббəтне, икеүлəп, дүрт кул белəн бетерделəр.
Мəхəббəтне, икеүлəп, дүрт кул белəн үтерделəр...
Бергəлəп бетергəч кенə,
Бергəлəп үтергəч кенə,
Ислəренə төшерделəр.
Икесе дə, лəкин түгел бергə —
Бер-береннəн кача-кача —
Мəхəббəтлəре күмелгəн каберге су сибəргə йөрделəр.

Мəхəббəт кабере өстендə саргаеп үсə иде гөллəр.

Юрий ВОРОНОВ

БЕЛЫЕ НОЧИ

стихи



Москва. Издательство «ПРАВДА»
1987

1964 ел, 25 июнь. Менə без мəшһүр татар композиторы Рөстəм Яхин квартирында казакъ халкының танылган җырчысы, СССРның халык артисты Ермəк Бекмөхəммəт улы Серкебаев белəн гəплəшеп утырабыз.

— Сезне нинди сихри көчлəр музыкага тартты? — дип сорыйм мин Ермəктəн.

— Дөресен əйткəндə,— ди җырчы елмаеп,— минем тормышымда могҗизалар булмады. Ике ир туганым думбра, скрипка вə мандолинада йөрəк кылларын чиертерлек итеп уйныйлар иде. Нəселебезгə хастыр җыр-музыка, күрəсең.

Кинəт җырчының күзлəре чаткыланып китте. Ул тирəн ихтирам белəн əнисе Зөлəйха Хəбибулла кызы Сабирова турында сөйли башлады:

— Белəсезме, минем əбием дə, əнием дə татар миллəтеннəн,— диде ул.— Җыр, моң, көй миңа алардан килə. Əнием мандолинада татар, казакъ көйлəрен əле дə гаҗəеп матур уйный. Мин Казанда, дустым Рөстəмдə икенче тапкыр кунакта. Үземне биредə үз туганнарым арасындагы шикелле хис итəм.


Үзе əйткəнчə, аның җырчы булып китүе очраклы түгел. Ермəк балачагында ук скрипкада оста уйный. 1941 елны уйнау осталыгын үстерү телəге белəн Алма-Ата музыка училищесына

укырга керә. Ләкин дәһшәтле сугыш скрипка кылларын «өзә». Ермәк, икенче курсны тәмамлагач, радиода диктор булып эшли башлый. Артистлар белән очраша, үзе яраткан җырларны бирелеп тыңлый. Шул чакта радио хормейстеры Ермәкны бер җыр коллективына кушылып җырларга чакыра. Яшь егетне тыңлагач, хормейстер таңга кала: «Менә бу тавыш ичмасам!» — ди ул, сокланып.

1946 елны Ермәк Алма-Ата консерваториясенең җыр классына укырга керә. 1951 елны, консерваторияне уңышлы тәмамлагач, яшь җырчы буларак, мөстәкыйль юлга баса. Ермәк Серкебаев — ике тапкыр җырчыларның Бөтенсоюз һәм халыкара конкурсы лауреаты. Ул опера җырчысы гына түгел, талантлы кино артисты да. «Минем докторым» дигән кинофильмда ул төп рольне башкара.

Ермәк Серкебаев Рөстәм Яхинның җыр-романсларын башкаручы буларак та татар җыр сөючеләренә билгеле. Рөстәм Яхинның минем шигыремә язган «Бишек җыры»н җырларга да нияте бар иде. Шул җыр очраштырды да инде безне. Шуның истәлеге итеп мәшһүр җырчы үзенең фотосурәте артына автограф язып бирде.

Соңыннан Ермәк Бекмөхәммәт улы Серкебаев 1966—1970 елларда СССР Югары Советы депутаты булды, Алма-Ата консерваториясендә укытып, профессорлыкка иреште. Шулай ук аңар СССР Дәүләт бүләге, Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Утыз өч яшеннән үк ул СССРның халык артисты иде инде.



Чапаевның тормыш юлы вә аның эше — инкыйлабта туган риваять ул, ләкин тылсымлы риваять. Хәтта байтак вакыт бергә яшәгән, бергә һөҗүмгә барган, китап язар өчен командирының һәрбер адымын, хәрәкәтен, сүзләрен күңеленә теркәгән комиссар Дмитрий Фурманов та Василий Иванович Чапаевның чын чыгышын, туган урынын белә алмаган. Д. Фурмановның «Чапаев» романы — тулаем дөреслекне, чынбарлыкны чагылдырган әсәр, әмма ул документ түгел, ә иҗат җимеше. Чапаев һәлак булгач, Балаково шәһәренә Чапаевск исеме бирү турындагы хөкүмәт карары кабул ителә. Әйе, хәтта рәсми органнарда эшләүчеләр дә, командирлар, шулай ук Фурманов та Чапаевның туган җире Балаково дип исәпләгәннәр. Әйтергә кирәк, бу ялгышлык шактый вакыт, 1934 елда «Чапаев» исемле нәфис фильм дөнья күргәнче, яшәп килгән. Чапаевның төп якташлары, Будайка авылы кешеләре, аны кино караганда таныган.

Будайка — урыс авылы, ул, башка милләтләрне изүдә урыс патша самодержавиесенең бер терәк пункты буларак, Чабаксар янында, Себер трakты узган урында салынган. Василий Иванович Чапаев менә шул Будайка авылында туган. Чабаксар чиркәвендә саклаган метрика кенәгәсенә болай дип язылган: «Туучының исеме — Василий. Туган көне — 28, ае — гыйнвар (яңа стиль белән 9 февраль). Туган елы — 1887. Милләте — урыс. Чабаксар өязе Будайка авылы. Әтисе — крестьян — Иван Степанович, әнисе — Екатерина Семеновна...» Ул чакта Василий исә Чапаев фамилиясе белән язылмаган. «Чапай» — Василийның бабасы Степан Гавриловичның кушаматы була. Степан бабай сал агызганда: «Чепай! Чепай! Мәле белән!» — дип әйтә торган булган икән. Ул «цепай» дип әйтәсе урынга, «чепай» дигән. Шулай итеп, «чепай» кушаматы фамилия булып киткән. Баштарак Чапаев фамилиясен Степан Гаврилович йөртә, тора-бара бөтен нәсел Чапаевка әверелә.

Василий Иванович Чапаевның шәҗәрәсен, нәсел җебен мин җентекләп өйрәндем. Миңа хәтта Василий Ивановичның бабасының бабасы Александр, ә әбисенең әбисе Степанида исемнәләр икәнлеге дә билгеле. Василий Ивановичның үги әбисе Прасковья Алексеевна Краснова — милләте белән чуваш.


Берничә тапкыр мин В. И. Чапаевның кызы Клавдия Васильевнада булдым, әтисе турында ул миңа күп нәрсә сөйләде, үзендәге архив материаллары белән таныштырды, фоторәсем-

нәр, документлар күрсәтте, яралы әтисенең Урал елгасында батып үлмәвен, ә аны йөзеп чыгуын раслау ниятеннән-ме, Чапаев дивизиясендәге интернационалист сугышчыларның — мадьярларның озын бер хатын да укыды. Абыйсы генерал Александр Васильевич вә Мария — Анка белән таныштырды, әтисенең ир туганы, Себердә яшәүче Николай Алексеевич Чапаевның адресын бирде. Николай Алексеевич белән мин хатлар алыштым. Ул миңа унар битле хатлар язды, аның һәрберсе Чапаев турында була иде. Шулай да минем В. И. Чапаевның замандашын, туганын үз күзләрем белән күрәсем, Чапаев белән малай вакытлары бергә узган кешедән язылачак героем турында үз колагым белән ишетәсем килде. Ерак Себергә барып, Н. А. Чапаев белән очраштым, истәлекләрен язып алып кайттым.

Эзләнүләр дәвам итте: Будайкага барып, гражданнар сугышы батырын бишектә тирбәтеп үстергән сиксән җиде яшьлек Надежда Гавриловна һәм Василий Чапаевның балачак дусты Тимофей Алексеевич Кузнецов белән очраштым, алар да миңа истәлекләр сөйләделәр, фотолар бирделәр. Аннары Балаковага барып, йорттан йортка йөреп, шәһәр тирәсендәге авылларда булып, Василий Иванович Чапаевны бүгенгедәй хәтерләүче әбиләр-бабайлар белән очраштым. Аларның әйтүенчә, Чапай көченең сере шунда: аның сугышчылары да, командирлары да — күбесе якташлары. Бригада командирлары Иван Плясунков, Иван Кутяков, полк командирлары Илья Топорков, Гаврил Шустов, порученецлары Петр Исаев белән Семен Садчиков, рота командиры Петр Чеков, взвод командиры Иван Панфилов (Мәскәүне саклаучы Ватан сугышы генералы), шәфкать туташы Мария Попова һәм башка бик күпләр Балаково тирәсендәге авыллардан булганнар икән.

«Бөлекәй Чапай» — документаль повесть. Ул моннан ундүрт ел элек дөнья күргән иде. Фаҗигале каһарманның образын сурәтләгән повесть икенче тапкыр нәшер ителсә, олылар да, бөлекәйләр дә нәширләргә рәхмәтләр генә әйтер иде.

Василий Иванович Чапаев турында халык арасында таралган мәзәкләр бихисап. Аның шамакайлыгы, сәвәләйлеге, мәзәкчелеге, җырчы-музыкант булуы, Балаковада театр уйнап, тамаша ясап йөрүләре мәгълүм. Боларны белер өчен «Бөлекәй Чапай»ны укырга кирәк. Клавдия Васильевна Чапаеваның култамгалары миндә тикмәгә генә кадерле истәлек буларак сакланмый, әлбәттә.


Дорогому Кави
Тагировичу Латыпову!
На память о нашей
встрече в Москве.
От дочери В.И. Чапаева
Клавдии Васильевны
Чапаевой
12.10.1965 года
г. Москва
ул. Георгиу Дежа
дом 3, кв. 31.
Евгений Петрович
Д7-18-50

«Йолдыз тапкан егет» повесте — галәм каһарманы, чуаш егете Андриян Григорьевич Николаев турында. Сембер губернасының Буа өязенә кергән туган авылым Убыйга күмәкләшү елларында Кызыл Чишмә исеме бирелеп, ул Чуашстанга тапшырыла. Әнә шулай Чуашстан минем туган җиргә әверелә. Туган җир — изге вә кадерле. Мин — бер татар баласы, күрше авылдагы чуаш малайлары белән аралашып үстем. Миңа чуашның гадәтләре, көйләре кече яшьтән таныш. Космонавтның туган авылы Шоршелы дигәчтен нигәдер безнең күрше чуаш авылы Алманчы искә төште, Андриян шуннандыр кебек тоелды. Шул сәбәпле, мин Андриян Николаевның галәмгә күтәрелүенең икенче көнендә үк Шоршелыда булып, аның туганнары, авылдашлары белән очраштым, ул яктагы матур табигатьне үз күзләрем белән күрдем вә әсәр язарга булдым. Ә инде Андриян галәмне гизеп кайткач, аның белән Чабаксарда, Мәскәү янындагы космонавтлар шәһәрчегендә очрашып, күзгә-күз сөйләштем. Повесть чагыштырмача тиз язылды. Миңа минем чуаш халкының тарихын, мәдәниятен белүем белән бергә, элеккеге ел-

ларда үземнең дә хәрби офицер булуым ярдәм итте булса кирәк. Ә инде космонавтикадан консультант миңа Андриян үзе булды. Повесть татарчадан чуашчага тәрҗемә ителгәч, тәрҗемәче аны Андриянга үз кулы белән илтеп укыткан. Тәрҗемәче әйтүенчә, космонавт әсәргә югары бәя биргән.

Дорогой друг КАВИ ЛАТЫПОВ !


Ваши чудесные подарки: книжки, посвященные мне, получил. Мы от всего сердца передаем Вам большой привет и благодарность за Ваши теплые слова, за приглашение в гости и такое внимание к нам. Книги Ваши очень понравились.

Мы желаем Вам блестящих творческих успехов, большого личного счастья и крепкого здоровья на долгие годы.

В знак глубокого уважения высылаем Вам свои фотокарточки.

С горячим приветом

ЛЕТЧИКИ-КОСМОНАВТЫ СССР:



(А.НИКОЛАЕВ)

(В.НИКОЛАЕВА-ТЕРЕШКОВА)

Космонавтлар шәһәрчегендә, Андриян янында мин әллә ничә мәртәбә булдым. Бер тапкыр менә мондый бер мәзәк тә булып алды. Дежур торучы полковниктан Андриян Николаев белән очраштыруны сорыйм. Ә ул: «Кызганычка каршы, бу юлы үтенечеңне канәгатьләндерә алмыйм. Ул утыра». «Кайда утыра?» «Кайда булсын, камерада». «Нинди камерада?» «Гади камерада димәс идем. Уникенче тәүлеккә китте инде, әле тагын утырачак». «Сәлам тапшырасы иде, телефон аша булса да». «Рөхсәт кирәк». «Кемнән?» «Космонавтларны әзерләү үзәге башлыгы, авиация генерал-полковнигы Каманинның үзеннән». «Гауптвахтага да ул башлыкмы?» «Ул! Шаяртам, полковник Николаев гауптвахтада түгел, ә барокамерада. Икенче тапкыр галәмгә очарга әзерләнә, үзе генә түгел...» «Кем икәнлеген фамилиясен әйтмәсәгез дә беләм». «Белсәң икән, үзең генә бел!» Әйе «Союз-9» корабында Андриян Виталий Иванович Севастьянов белән бергә галәмгә икенче тапкыр күтәрелде. Аннан алдарак бер очрашуда Андриян мине В. И. Севастьянов белән таныштырган иде. «Таныш бул, минем иң яраткан, иң ышанычлы дустым Виталий Иванович Севастьянов. Перле космоса кайталла сугыш пур (бергәләп космоска барып кайтырга исәп бар)». Ә менә татар космонавты турында сорашкач, Андриян болай диде: «Әйе, безнең отрядта бер татар егете бар иде. Әмма без аны бер истребительләр полкына озатырга мәҗбүр булдык. Сәбәбен мин сиңа әзеп әйтә алмыйм. Аның белән котелмәгән бер күңелсез хәл булды бугай». «Татарстаннан идеме?» «Урта Азиядән иде бугай ул. Идел буеннан булса, дуслашкан булыр идек, мин дә Идел егете бит. Минем уемча, син шуңа күрә якташың Андриян Николаев турында повесть яздың да инде».

Соңрак белдем: язмыш шаярулары-на тап булган теге татар егете, безнең милләттәш Марс Рәфыйков булган икән. Галәмгә күтәрелсә, бик тә исеме җисемене туры килгән булыр иде, ләкин...

**Автографлар-култамгалар — серле, телле шаһитлар алар...**

# ШИГЪРИЯТ



**Рифә Рахман**

**КАЕНЛЫ ҖЫР**

### Теләктәшлек

Кәеф — юлчыныкы. Тәмам туйдырды йорт.
Яшәү торадыр ник ыгы-зыгылардан?
Чемоданнар инде ишек төбендә үк.
Күңел җыелмаган, күңел җыелмаган...

Сагындырды аны керләнмәгән хисләр,
Иске-москыларны бар шул ыргытасым.
Алган әйберләрем инде тузып беткән,
Шуңа ике куллап миңа тотынгансың.

Кирәк икән ал син, төйнәп төенчеккә,
Ертык-портык кием кигән минем тәнне.
Чемоданнар инде ишек төбендә үк,
Көтеп тора минем ялгыз китәр мәлне.

Йә ал кулларыңны — тәнне күгәртмәсен.
Яшә миннән башка, тузан кебек пырлап.
Кәеф — юлчыныкы, өйдән күңел күчкән.
Китәм шуңа күрә өмет җыры җырлап.

Иске хисләрдән соң битем юылмаган.
Күзгә тотынма син, минем, ике куллап.
Чемоданнар инде ишек төбендә үк...
Тора минем җырның кушымтасын җырлап.

* * *

Ялгыз аем бата төпсез күккә.
Бат син минем кара күзләремә.

Бас син минем сиңа сусынымны,
Тулып таш син минем үзәгемнән.

Йөрәгемне имгән сагышларны
Оныттырып тор син беразга.
Көннәр инде бик санаулы калды —
Исән чыгармынмы бу язга?

Һәрбер төндә аем бата күккә.
Сизгән йолдыз китә бит өркенеп.
Айның иләс-миләс көннәрендә —
Күгем — кара диңгез өсте кебек.

Каплый болыт күкне, ул хәлләрне
Яшерә ул кеше күзләреннән.
Баса аем шулай сусыннарын,
Күкне эчә, төшеп үзәгенә.

Дулкынлана — диңгез өстемени,
Иренәнә чыга ак күбекләр.
Юкса көндез, ай килмәгән чакта,
Ул да тыштан тыныч кебек лә...

Бас син минем сиңа сусынымны,
Тулып таш син минем үзәгемнән.
Оныттырып тор син, башкаларны
Чайпалдырып чыгар күзләремнән.

## Синле әкият

Синле әкият — синең әкият булган.
Ахыры да менә — синеке.
Сине генә...— дип башлаган идең,
— Башканы да сөям,— дип бетте.

Зур күзләрем учак каршысында.
Көл тузгытам, яшьне биетеп.
Җирдә әле синле әкият яши,
Минем онытуга үч итеп.

Бер әкиятне ике тапкыр тыңлап
Яшәмим шул — күңел кыбырсына.
Чит җиләк тә өзеп салганым юк
Шул әкияттән калган тырысыма.

## Такыялы кыз шигыре

Берчак үзем ачылырмын,
Түзми синең карашыңа.
Постым каен артларына,
Качтым яфрак арасына.

Тамырыннан урлагән су
Хәл бирә күк яшәвемдә.

Яфраклары такыя үрде,
Ятып чигә чәчләремә.

Яфраклары такыя булды,
Төшкәч чигә чәчләремә...
Рәхәт сабый сыман уйнау...
Аптырама дәшмәвемә.

*1996*

* * *

Каенлы кар
Агып китеп бара
Урамнарны иңләр ташуда.
Кырдагысы хәлсезләнеп ята,
Урын киң дә юкса ярсуга...
Агып бара
Минем моңсу күзләр
Каен ботагына тотынып.
Калмаган күк урын сагышларга...
Аклыкка да урын юк кебек...
Каенлы кар агып китеп бара.
Ага өйләр,
Ага ташуларда.

— Әйдәгез-з-з! — дип
Салган авазлары
Ишетелә булыр басуларда.
Уяныр лар
Хәлсезләнгән карлар,
Җилпенгәләп алыр, кагыныр...
Бәлки елар
Шушы кара җиргә
Ничек кунганнарын сагынып...
Һәм кар суы күмәр басуны да,
Урын киң бит анда ярсуга!
Каенлы җыр
Агып китеп барыр
Күңелләрдән аккан ташуда.

## Мәхәббәт

Мәхәббәт, син — минем Мәккәм.
Мәхәббәт, син — минем кояш.
Күзләремне яктыртканда
Еламсырап карамый яшь.

Карамыйм мин еламсырап,
Карамый яшь, ярдәм сорап.
Тора тик сәҗдәгә китеп,
Ярлыкауны өмет итеп.

Берлегеңне, барлыгыңны
Танган хәлдә буй сонам мин:
Мәхәббәткә бәйле генә
Язмышыма буйсынам мин.

Буйсынам мин Мәхәббәтнең
Иң-иң ачы карарына:
Әле үбә иренемнән,
Әле суга яңагыма.

Карамыйм мин, еламсырап.
Карамый яшь, ярдәм сорап.
Торам тик сәҗдәгә китеп,
Беркөн җәннәт өмет итеп.

Мәхәббәт, мин берлегеңне,
Барлыгыңны синең тандым.
Шуның белән Аллаһының
Каршысында гөнаһландым.

Шуның белән яшәвемдә
Бары синнән әмер көттем.
Җаным сәҗдә кылган чакта,
Тәнне җиңәр хәмер иттем.

Шуның белән Аллаһының
Каршысында гөнаһландым.
Аннан мең-мең җәза алдым...
Инде — Мәхәббәтсез калдым!

ПУБЛИЦИСТИКА

# ФАҖИГАЛЕ МИЗГЕЛ

## ТАТАР МИЛЛӘТЕНЕҢ ПСИХОЛОГИК ХАЛӘТЕ ХАКЫНДА УЙЛАНУЛАР

XX гасыр азагында бөтен дөньядагы халыклар язмышына кискен үзгәрешләр китергән вәзгыять татар халкын да читләтеп үтмәде, әлбәттә. Аның асылы, безнең карашка, түбәндәгечә. Илләр, халыклар бүлгәләнде, бинһаяә олы дәүләтләр — империяләр таркалып бетте, җимерелеп төште. Дөнья сәясәтендә бер үк вакытта оешу һәм таркалудан гыйбарәт булган процесс башланды кебек. Мондый шартларда төрле милләтләр үз җирләренә ныграк берегергә, рухи халәтләренә тәңгәл килерлек экологик куыш булдырырга омтылалар. Бу бик тә табигый күренеш. Бары тик шул омтылыш-максатына ирешкәндә генә һәр халык үзенең милли яшәешен тәэмин итә ала.

Шул уңайдан соңгы чорларда татар милләтендә барган психологик күренешләрне барлап, булдыра алган хәтле күзәтү ясап китү урынлы булырдыр. Никадәр генә кызганыч булмасын, бүгенге татар милләтенең рухи халәте ике өлешкә бүленгән, милләт ике яссылыкта яшәп ята. Аларның беренчесе — телен, гореф-гадәтләрен, динен саклаган, татар халкында булган бөтен асыл сыйфатларны үзендә туплаган һәм моң белән сугарылган психологик халәт булса, икенчесе — телен һәм гореф-гадәтләрен оныткан, диненнән ваз кичкән, башка милләтләргә яраклашырга тырышып көн күрүчеләрнең милли рухтагы фәкыйрьлеге, яки манкортлык чире.

Ләкин милләтне халык буларак бүлгәләп карау һәм аларның берсен икенчесенә каршы куярга тырышу һич тә дөрес гамәл булмас иде. Без бу проблемага. бербөтен милләт күзлегеннән чыгып карарга, аның сәламәт һәм сырхау өлешләре арасындагы мөнәсәбәт чараларына ачыклык кертергә дә тиешбез.

Милләтебезнең бүгенге көндә шулай йотыла, югала баруының төп сәбәпләре нәрсәдә?

Манкортлык чире ничек барлыкка килгән?

Бу сырхаулыктан котылу юлы бармы һәм булса ул нинди чараларны эченә ала?

Сорауларга җавап бирү өчен ерак тарихка күз ташларга кирәк булыр. Кайчандыр шан-шәүкәтле, мәгърур бер халыкның үткәнен онытуы мөмкинме? Әллә бу кемнәрдер тарафыннан оныттырырга тырышуның «гүзәл» җимешләреме? Әйе, ничек кенә булмасын, Русия империясенең барлык аз санлы милләтләрне ничәмә гасырлар дәвамында басып килүе, урыслаштыру, йоту-юк итү сәясәтенең нәтиҗәсе икәнен дә без яхшы беләбез. Язмышыбызмы, ялгышыбызмы?! Без кайчандыр дәүләтле бер халык икенче бер дәүләт эчендә аз санлы милләт булып яшәргә дучар ителгән идек.

Бер үк дәүләт эчендә яшәгән милләттәшләрнең дә, кайсыбер сәбәпләр, әйтик, сыйнфый, төркемчелек һ. б. сәбәпләр аркасында үзара тыныша алмау очраклары бар. Моны психология фәне дә таный. Һәм әнә шул килешә алмау һәрбер төркемне үз янына яңа тарафдарлар җыярга мәҗбүр иткән. Ә инде үз милләтендәге тарафдарлары җитмәсә, алар чит милләткә мөрәҗәгать итүне дә кимхурлык санамаган. Монысын да тарихтан яхшы беләбез. Шулай итеп, башка милләт вәкилләреннән килгән тарафдарлык аша, татарларның да бер өлешендә үз милли традицияләрен югалту күзәтелә башлый. Югалганнары урынына, әлбәттә, башка милләтнең гореф-гадәте, теле, дине үтеп керә. Нәтиҗәдә, әле генә бер кавем, бер дәүләт булып яшәгән милләт эчендә психологик каршылык хасил була, ул үз чиратында милләтне саклаучы, яклаучы, үстерүче булып килгән принципларны да җимерә башлый. Дәүләтчелеген югалткан халык, әлбәттә, теге

яки бу дәрәҗәдәге ассимиляциядән котыла алмый. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң татарлар кичергән югалтулар моның ачык мисалы.

Сер түгел, бүген төрки телле татарлар да, урыс телле татарлар да һәм хәтта инглиз телле татарлар да бар. Шулай ук мөселман, христиан һәм башка диннәрне тотучылары булуы мәгълүм. Яшәү урыны һәм мәдәни традицияләре буенча Идел буе, Кырым, Себер, Әстерхан һәм башка урынчылык татарлары бар. Кыскасы, элеккеге Алтын Урда дәүләтенең барлык төбәкләрендә дә бүгенге көнгәчә милләттәшләребез яши, үзенчә көн күрә, тырышып-тырмашып дөнья көтеп ята.

Татар халкының бу төркемнәрен рухи берләштерү өчен бүгенге көндәниләр эшләп була? Миңа калса, беренче чиратта этник бердәмлекнең психологик нигезен булдырырга кирәк, ягъни аларның чыгышлары буенча зур бер милләт вәкилләре икәнлеген аңлау һәм аңлату зарур. Тел һәм мәдәният берлеге, милли психология һәм тарихи аңның бердәйлеге бу төркемнәрнең үзара якынаюын тәшкил итүче нигез ташлары була алыр иде. Төркемнәрнең шушы нигездә берләшүе, үзара теләктәшлеге киләчәктә мәсьәләне этнополитик категория дәрәҗәсенә үстереп җиткерергә мөмкинлек бирәчәк тә. Шулай итеп, милләтнең үзбилгеләнүе кысаларында, без дәүләтчелекне торгызу проблемасын төп шарт итеп куя алачакбыз.

Ни кадәр кызганыч булмасын, бүгенге татар сәяси эшлеклеләренең күбесе бәйсез дәүләт категориясе дәрәҗәсендә фикер сөрергә һәм эш йөртергә читенсенәләр. Аларның күпчелеге бер көнлек мәшәкать белән генә чикләнә, халыкның иртәгәсе, киләчәге хакында артык кайгыртмый. Аңыбызга коллык психологиясе шул кадәр тирән сеңгән ки, кылган эшләребездә дә, әйткән сүзләребездә дә үзебез аңышып та бетермәгән ярашу, яраклашу омтылышы бүселеп килә дә чыга. Әйтерсең лә ни кадәр яхшырак, остарак итеп яраклашсак, теләгәнебезгә дә шул кадәр тизрәк, җиңелрәк ирешербез.

Фаҗигабезнең тирәнлеген аңлау өчен татар милләтеннән булган кайбер шәхесләрнең фикер йөртү дәрәҗәсенә күз салып карыйк. Аның югары ноктасы ил башы дәрәҗәсендә фикерләү булса, түбән ноктасы әле тормышка аяк басып кына килүче мәктәп баласы дәрәҗәсендә булыр.

Татарстанның суверенитеты хакында Декларация кабул иткән көннәрдә җитәкчеләребездән берсе «суверенитетның милли төсе юк» дип белдерде. Әйе, бәлки ул көннәр өчен бу акыллы сәясәт булгандыр да. Әмма яшь буынга ул инде «син, татар баласы, бервакытта да бәйсез була алмассың» дигәнне дә аңлатмый идеме соң? Икенче бер вакытта шундый ук югары даирәдәге җитәкчеләребездән «милли университетның бүгенге көндә кирәге юк» дигән сүзләрне дә ишетергә туры килде. Бу шулай ук яшь буын аңында «татар теленең кирәге бар микән?» дигән шик-шөбһә уятуы бәхәссез. Шик дигән нәрсә бала күңеленә бер керсә, ул инде алмага төшкән корт кебек аны эчтән ашый, җимерә башлый.

Тагын бер мисал.

Мин Казан мәктәпләренең берсендә директор булып эшләүче бер кешене беләм. Милләте белән татар. Алдынгы фикерле, милләтпәрвәр бер кеше дип йөри идем. Заманына күрә мәктәбендә татар класслары да ачтырды. Әмма ләкин мәктәпнең тулысынча татар мәктәбенә әйләнәчәге хәбәре аның өчен чып-чын фаҗигага әйләнде. «Мин инде татар класслары ачтым, шунысы җитмимени?» дип өзгәләнде ул. Хәтта ата-аналар, танышлары арасыннан теләктәшләр табып, мәктәпне урыс телендә укытучы итеп калдыру юлында йөри башлады. Мин бу кешене дә аңлыйм, һәрхәлдә, аңларга тырышам. Ул күңелендәге психологик киртәне җимерә алмады. Урыс телендә укып урысча тәрбия алган татар кешесе бөтен мәктәпнең татарча эшләячәген күз алдына китерә алмый. Хәер, ул гына да түгел. Мәктәп татарча эшли башласа моның үзенә урын калмаячак. Чөнки телне белеп бетерми һәм өйрәнергә дә атлыгып тормый. Шулай иттереп, беренче планга шәхси мәнфәгать килә дә чыга.

Инде хәзер тагын бу бәхәсне белеп, күреп торган яшьләрнең — укучыларның психологик халәтен күз алдына китерик. Аларга «Татарга мәктәп кирәкме икән?» дигән фикер кереп утырса — гаҗәпме? Шуның өстенә, татар теле укытучыларының «Татар мәктәбен бетергән балаларга югары уку йортында уку авыррак булачак» диюләре дә бала күңеленә шик өстәмиме? Җитмәсә, ата-аналар да «Төп фәннәрне урысча укытсак, дәрес хәзерләшергә җиңелрәк булыр иде», дип алар тегермәненә су коялар.

Тирә-якта татар мохиты булмау, үз милләтендәге кешеләрнең шундый дәрәҗәдә фикер йөртүе балаларның, яшьләрнең формалашуына гаять зур тискәре йогынты ясый. Һәм ул бер дә икеләнмичә, татарча эндәшкәнгә дә урысча гына

җавап бирергә керешә. Мондый мисаллар шәһәр җирендә адым саен бит! Ул гына да түгел, хәтта татар авылларында урысча эшләүче мәктәпләрдә белем алучы балалар урамга чыккач үзара урысча сөйләшүгә күчә баралар. Сорап караганым бар. Җаваплар бер чама.

— Ни өчен татар телендә сөйләшмисең, акыллым?

— Не знаю, так хочется...

Психология фәне аңлатканча, дөньяга тугач, аңсыз рәвештә кыз бала атасына, малай кеше анасына бала мәхәббәте тота. Ләкин 12—13 яшь тулганда тирә-якның тәэсире нәтиҗәсендә баланың мәхәббәте башка субъектка күчә. Телләрдә дә шулай. Әйтик, баланың ата-ана теленә мәхәббәте, тирә-якта татар мохиты булмау сәбәпле, урыс теленә күчә. Инде үсеп җиткәч, бу егет яки кыз тормыш иптәше итеп урыс кешесен сайламас дип кем әйтә ала? Эчке психологик каршылык инде моңа нигез дә салып куйган ич. Дөрес, генетика фәне табигатьтә катнаш никахларның 10 процентка кадәр булуын табигый күренеш дип саный. Әмма ләкин алар инде бездәгечә 40—45 процентка җитсә, монысы дәүләткүләм чаң кагарга кирәклекне, милләтнең юкка чыгуга йөз тотуын аңлата торган фаҗигале фал.

Миңа ничектер шушы проблемалар буенча бер галим — медицина фәннәре кандидаты белән сөйләшергә туры килгән иде. Ул үзе дә катнаш никахта тора һәм моны үзенчә бик югары бәяли дә әле. Ярый, монысы да табигый күренеш. Бер-берсенә мәхәббәтләре көчле икән, яши бирсеннәр. Чын мәхәббәт тә хәзер сирәгрәк очрый торган күренеш ләбаса. Борчыганы ул түгел. Иң аянычы, катнаш никах җимешенә ике телнең дә кирәклеген, ике культураның да матурлыгын аңлатып тәрбияләмәү мондый гаиләләрдә табигый күренеш. Шуның нәтиҗәсе буларак, бала үсеп җиткәч, үз теләге белән кайсы милләт культурасын сайлап алу мөмкинлегеннән мәхрүм ителә. Һәм, гадәттә, татар теле кирәк түгел дип табыла. Бу күренеш башка милләтләргә дә хас.

Совет империясе чорында совет халкыннан бер бөтен «суперэтнос» ясау өчен интернационализм җыры аша катнаш никахларга югары бәя бирелде, аларга дан җырланды, һәм... байтак кына милләтләр шул юл белән эреп юкка да чыктылар.

Алдарак искә алынган әңгәмәдәшем дә үзенең шул «суперэтнос» вәкиле булуына ишарә ясаган иде. Минем: «Совет империясе җимерелде, кая китте ул суперэтнос һәм ул хәзер ничек атала?» — дигән соравыма ул бер дә исе китмичә генә: «Элек совет халкы дип атала иде, хәзер россияннардыр инде», — дип куйды.

Совет дәүләтендә яхшырак яшәү, карьера баскычы буйлап өскәрәк үрмәләү өчен ике шартның үтәлүе зарур иде. Беренчесе — коммунистлар партиясе әгъзасы булу, икенчесе — үзеңне урыс милләте вәкиле дип тану һәм һичъюгы катнаш никах аша үзеңнең шул принципларда торуыңны раслау иде. Казан университетында белем алган ике танышым — татар кызы белән чуваш егетен искә төшереп үтәсем килә. Диплом алган көннәрендә гаилә корып җибәрделәр болар. Озакламый балалары туды. Балага, гадәттә, ата-аналардан берсенең милләтен бирәләр. Әмма ләкин югары белемле бу ике милләт вәкиле балаларын урыс милләтеннән дип яздырдылар. Бу инде Совет системасында югары белем алуның «сыйфаты» суперэтнос ясарлык дәрәҗәдә икәнен бик ачык күрсәтә.

Совет чорында динен югалткан халыклар коточкыч рухи агрессиягә дучар ителде. Бер татарны гына түгел, бөтен милләтләрне эчүчелек сөреме каплап китте. Элек үзендә начар сыйфатларны (тәмәке тарту, эчүчелек, зина кылу һ. б.) булдырмау татар ир-атының үзенчәлеге булып саналса, хәзерге татар ире урыс ир-атыннан бер ягы белән дә аерылып тормый диярлек. Хатын-кызлар арасында белешү-сорашу нәтиҗәсе шуны күрсәтә: ирләреннән аерылуга китергән төп сәбәпләр арасында беренче урында эчүчелек, аннан соң хыянәт һәм аннан соң гына аз акча алып эшләү күрсәтелә. Бүгенге көндә саф татар авылларында эчүчелекнең чәчәк атуыннан да зуррак фаҗига булырга мөмкинме? Эштән арып кайткан хатын-кыз һәр көн өйдә исерек ирен күреп ничек рухлансын, бала тәрбияләсен, киләчәккә өметләр багласын?!

Фикерне дәвам иттереп, татар тормышындагы тагын бер күренешкә ачыклык кертеп китү урынлы булыр. Авыл җирендә, татар мохитында тәрбия алган милләттәшебез шәһәргә укырга яисә эшкә килгәч зур психологик каршылыкка дучар була. Чөнки ул үз ана телендә аралаша алмый. Авылдан килгәннәргә кимсетебрәк карау, хәтта татарлар тарафыннан аңа ярдәм кулы сузмау гадәти хәлгә әйләнде. Менә шундый шартларда «авыл кешесе» яңа мохитка яраклашырга теләп, психологик киртәне атлап чыгарга омтыла башлый. Һәм күпмедер вакыттан соң ул теләгәненә ирешә дә, ягъни анда милләттәге ассимиляциягә битарафлык уяна, рухи коллык психологиясе формалаша.

Бүген без ачы фаҗигабезнең авырлыгын, тирәнлеген чын мәгънәсендә аңлаганда гына, милләт буларак, олы максатыбызны бәйсез дәүләтчелек таләп итү дәрәҗәсенә күтәрә алачакбыз. Әмма, кызганычка каршы, бүгенге көндә максатларыбыз бердәм түгел, таркалган, вакланган. Кемдер мәдәни автономия, кемдер мәктәпләр, кемдер тел мәсьәләсен өстен куя. Әлбәттә, тел дә, мәктәпләр дә, Татарстаннан читтә яшәүчеләргә мәдәни автономия дә кирәк. Анысы бәхәссез. Әмма төп максатыбызны дәүләтчелек таләп итү югарылыгына күтәрә алмасак, инде яулап алынган әйберләребезне дә тартып алырга мөмкиннәр. Татар тарихында мондый фаҗигале хәлләр күп булган. Бары тик бәйсез милли дәүләт кенә үзен яклау, саклау институтларын булдыра ала, бары тик ул гына киләчәгебезне тәэмин итүдә бердәнбер гарант була ала. Кешелек дөньясының дәүләтчелектән дә югарырак, камилрәк оештыру механизмы уйлап чыгара алганы юк әле.

Дәүләтчелек идеясе татарның барлык төркемнәрен дә канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә булырга тиештер. Шул чакта гына халкыбызны бербөтен милләт буларак үстерү мөмкинлеген ачылачак та.

Дөньяда барган глобаль процесслар, үз чиратында, милләт эчендә зур үзгәрешләргә алып килде. Аларны файдаланып һәм үз мәнфәгатебезне истә тотып, татар кешесендәге эчке процессларны да дөрес оештыру кирәк. Бүгенге көндә, мәсәлән, бездә татар кешесенә тискәре йогынты ясаучы күренешләргә каршы көрәш, ягъни саклану тактикасы гына өстенлек итә. Бөтен көч-куәтебезне, егәрлегебезне шуңа сарыф итү яңа сыйфатларыбызны үстерергә урын калдырмый диярлек. Бу күренештән котылу өчен татар милләте дәүләти дәрәҗәдә тел сәясәте оештырырга бурычлы. Шуның нәтиҗәсе буларак, киләчәктә милләттә этник укмашу, туплану өчен нигез барлыкка килер иде. Әмма, хәтта этник укмашудан соң да татар милләте дәүләтчелеген торгызудагы барлык мәсьәләләрне хәл итеп бетерә алмаячак әле.

Мәсьәләгә ачыклык кертү өчен гасыр башындагы вәзгыятькә игътибар итик. Ул чакта милли бердәмлек сыйфаты (тел, дин берлеге, милли традицияләрнең яшәве) югары булса да, инкыйлабтан соң милекнең дәүләтләштерелүе татар кешесенә үз мәнфәгатьләрен тиешенчә якларга урын калдырмады. Хәзер исә киресенчә, шәхси милеккә күпмедер чамада юл ачылса да, милли бердәмлек булмау тагын шул ук мәнфәгатьләрне яклау юлында тупланырга мөмкинлек бирми. Менә шунлыктан, бүгенге көндә милләтнең укмашуы милли традицияләргә нигезләнгән милли экономика белән дә үрелеп барырга тиештер. Шул чакта гына яшь буынны милли рухта дөрес итеп формалаштыруга юл ачылачак.

Татар буларак башкалардан үзгәлегеңне танып белү, шуның аша рухлану һәм милли сыйфатларыңны үзеңнеке буларак яклый һәм саклый белү дә кирәк. Әгәр шулай булмаса, милли егәрлегебез кимер, башка милләтләр тарафыннан йотылуыбыз дәвам итәр. Котылу юлы бер генә: һәрбер татар кешесе үз эш урынында дәүләти дәрәҗәдә татар теленә, милли традицияләргә таянып эш йөртергә бурычлы.

**Фәрит УРАЗАЕВ,**
**Татар иҗтимагый үзәге рәисләше.**



Сәлман Гобәйдуллин

# ОНЫТЫЛМАС ӘТИЕМ

ИСТӘЛЕКЛӘРДӘН[1]

**1997 елда без күренекле галим, татар тарихчысы, фикер иясе һәм язучы Газиз Гобәйдуллинга (Г. Газизгә) баглы ике тарихи вакыйганы билгеләп үтәбез: 1887 елда Г. Гобәйдуллин дөньяга килгән, ә 1937 елның 13 октябрендә НКВДның Баку подвалларында дөньядан кичкән — атып үтерелгән. Димәк, галимнең тууына — быел 110 ел, атып үтерелүенә — 60 ел. Аваз салып дөньяга килү тантанасы һәм, ату тавышын да ишетмәстән, нибары 50 яшендә китеп бару фаҗигасы...**

**Бу күренекле шәхеснең үзенә дә, төрки кешелек дөньясы тарихына, беренче чиратта, әлбәттә, үз туган халкы татарлар тарихына керткән әйтеп бетергесез зур хезмәтләренә дә тиешле бәяне бирер өчен вакыт бик җиткәндер.**

**Безнең уебызча, Г. Гобәйдуллин сирәк очрый торган зыялы затларның берсе булган, андый илаһи талантлар хакында халыкта «фәрештә канаты тигән» дигән гыйбарә дә бар. Нинди генә эшкә — иҗади хезмәткә тотынмасын,— тарихмы ул, тел гыйлемеме, әдәбиятмы һ. б.,— һәр барча төрки халыклар телендә иркен сөйләшкән һәм язган, Шәрекъның гарәп вә фарсы телләрен, Гарепнең урыс, немец, француз телләрен яхшы белгән, инглизчә дә сукалый башлаган Г. Гобәйдуллин һәрвакыт фәнни нигезле, тирән фикерле һәм, шул ук вакытта, үз заманы өчен гаять аңлаешлы фәнни хезмәтләр язган. Г. Гобәйдуллинның иң зур хезмәтләре — татар, әзербайҗан, үзбәк һ. б. караган фундаменталь хезмәтләр. Алар бүген дә үз әһәмиятләрен югалтмаганнар.**

**Тарихчы галимнең тоталитар режим тарафыннан рәсми кабул ителгән идеология кысаларына сыймаслык һәр сүзе-фикере аңа турыдан-туры фәннән куылу һәм хәтта үлем куркынычы янаган шул авыр шартларда да Г. Гобәйдуллин искиткеч күп эшләп өлгергән: китап арты китап чыгарган, Әзербайҗанда берьюлы ике югары уку йортында кафедра җитәкләгән, лекцияләр укыган, әледән-әле Урта Азия шәһәрләренә сәяхәт кылып, аларга да хезмәтләр язган... Кыскасы, аның тормышы хакында безгә эзләнергә дә эзләнергә, хезмәтләрен өйрәнергә дә өйрәнергә, алар турында язарга да язарга кирәк әле. Без соңгы елларда татарның З. Вәлиди, С. Максуди, Б. Баттал кебек фикер ияләренең хезмәтләренә игътибар итә килдек, алар хакында күп сөйләдек. Бәлки, бу хәл аларның чит илләрдә мөһаҗирлектә яшәп иҗат итүләре, шунда вафат булулары белән дә бәйледер. Монысы табигый һәм дөрес гамәл. Әмма аларның иҗади эшчәнлекләре өчен булган рухи ирекле шартлар Г. Гобәйдуллин яшәгән һәм эшләгән шартлардан җир белән күк арасыдай аерылып тора.**

[1] Истәлекләр татарчага Марс Шабаевның ирекле тәрҗемәсендә һәм аның эшкәртүендә бирелә. *Ред.*

Бүген без укучыларыбызга Г. Гобәйдуллинның улы Сәлман ага Гобәйдуллинның (аңа да инде 82 яшь!) «Онытылмас әтием» исемле истәлек язмаларыннан өзекләр тәкъдим итәбез. Сәлман ага үзе дә кызыклы шәхес: «халык дошманы улы» буларак, аңа ачы хәсрәт җамын тулысынча эчәргә туры килә, аның фронт юллары да башкаларныкыннан икеләтә авыр була. Хәзер Сәлман ага Гобәйдуллин Мәскәүдә яши, биология фәннәре кандидаты. Соңгы елларда ул әтисенең бәһасез рухи мирасын туплау белән шөгыльләнә, Гобәйдуллиннар нәселенең тамырларын һәм фаҗигасын ачыклый.

«Онытылмас әтием» («Незабываемый отец мой») истәлеге урысча язылган. Авторның тормыш шартлары аңа Казанга кайтып яшәргә ирек бирми (әтисе язмышы!), шунлыктан ул татар теленнән дә ераклаша, аны «оныта» төшә.

Булат СОЛТАНБӘК

* * *

Фән биеклекләренең иң югары түкләрендә йөзгәндә, очар кош шикелле, атып төшерелгән әтием минем кем иде соң? Гомере өзелгәндә аңа нибары 50 яшь булган... Ә эшләгән эшләре, язган хезмәтләре! Ә эшләнмичә, язылмыйча калганнары...

1916 елны Казан император университетын уңышлы тәмамлап, танылган урыс галимнәре Н. Н. Фирсов, Н. Ф. Катанов, М. М. Хвостовлар кул астында аспирантурада саллы гына фәнни әзерлек туплаганнан соң, Газиз Салих улы Гобәйдуллинның нәтиҗәле фәнни һәм педагогик хезмәт юлы башлана. Ул үз гомерендә йөздән артык фәнни хезмәт һәм китаплар язып калдырырга өлгерә.

Октябрь инкыйлабыннан соң Г. Гобәйдуллин Казанда яши һәм эшли. Ә 1925 елдан соңгы көннәренә кадәр — Бакуда. Аны Казаннан китәргә мәҗбүр иткән сәбәпләр турында алга таба әйтелер, әлегә кагылмый торыйк анысына.

Төрки халыкларның һәм Якын Көнчыгыш халыкларының тарихын яхшы белгән галим буларак, Г. Гобәйдуллин Казан, Баку, Мәскәү, Ташкент, Сәмәрканд, Пятигорск ВУЗларында укыта; танылган галимнәр-академиклар белән аралаша, актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара. Аның ташып торган көч-дәртенә сокланып та, көнләшеп тә караучылар була. Әйе, көнләшеп тә...

Фәнни-педагогик эшчәнлеге белән берррәттән Г. Гобәйдуллин татар телендә кыска-кыска гына сатирик хикәяләр дә яза, аларны Г. Газиз псевдонимы (тәхәллүсе) белән бастырып чыгара да тора (беренче китабы — «Г. Газиз хикәяләре» — 1918 елда, соңгысы — «Хикәяләр» — 1958 елда Казанда басылып чыгалар). Аның «Марс, уян!» исемле тәүге хикәясе Ф. Әмирхан хәер-фатихасы белән 1907 елда ук «Казан мөхбире» газетасында дөнья күрә.

Тарихчы галим һәм әдип Газиз Гобәйдуллинның исеме «Зур Совет энциклопедиясендә» (19 т., 1930) үзе исән чакта, аннары «Совет Тарих энциклопедиясендә» (4 т., 1963), «Кыска Әдәби энциклопедиядә» (2 т., 1964), «Совет Татарстаны язучылары» библиографик белешмәсендә (1986) һ. б. чыганакларда урын алган.

* * *

*Без кабызган утлар сүнмәс алар,*
*Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...*

Г. Гобәйдуллинның яраткан җыры — К. Тинчурин һәм С. Сәйдәшнең «Казандыр буе» спектакленә язган җырыннан.

Балачагымнан ишетеп белүемчә, әтием ягыннан бабамның бабасы Сабит тумышы-чыгышы телән Пошалым Башы дигән татар авылыннан булган. Кайсы еллардадыр Казанга күчеп килеп, ул өсте ябулы-сиртмәле арбалар — кареталар ясау остасы булып танылган, аннары сәүдә белән шөгыльләнгән, улы Салихка шактый мая калдырып, дөнья куйган.

Салих бабам исә бик гайрәтле-тырыш, булдыклы-эшлекле кеше булып чыккан: әтисеннән калган маяны ул мануфактура, ягъни кызыл мал белән сәүдә итүгә салган, урысча укырга-язарга өйрәнгән, бухгалтерлык һөнәрен үзләштергән (аның бик картайгач та матур-пөхтә каллиграфик почерк белән һәм татарча, һәм урысча язып утырган чакларын хәтерлим әле). XIX йөз ахырына Салих бабам шактый баеп киткән, атаклы Казан бае Айтугановның кызларының берсенә табышлы гына итеп өйләнеп тә куйган, Казанда кибетләр ачкан, җигеп чыгып йөрергә ат-фаэтон тоткан, кибетчеләре вә хезмәтчеләре дә байтак булган.

Аның хатыны, минем әбием Өммегөлсем күп бала китергән, әмма балаларының барысы өчесе исән-сау үскәннәр: әтием Габделгазиз (Газиз), аның энесе — Габделкадыйр (Кадыйр) һәм сеңлесе Мәрьям.

Үзе аралаша торган сәүдәгәр вә муллалардан аермалы буларак, Салих бабам европача киенә, яшьтән ук татар милли киемнәреннән баш тарта. Монысы — кеше алдында. Әмма гаиләсендә ул татар гореф-гадәтләренең иң кадими-катгый таләпләрен тота. Әбием Өммегөлсем гомеренең соңгы көннәренә кадәр чапан ябынып йөрде, иренең рөхсәтеннән башка урамга да чыга алмады. Балаларын да кырыс мөселманлык рухында, шәригать кануннары нигезендә тәрбияләргә тырыша бабам. Әмма... заман җилләре башкача исә башлый шул!

Балаларның өчесе дә яшьтән үк кызыксынучан, һәвәс-сәләтле булып үсәләр. Араларында бигрәк тә Газиз аерылып тора. Ул бик зиһенле, яхшы хәтерле була: эне-сеңелләренә кызыклы хикәятләр сөйли, өлкәннәр кушкан эшне дә теләп, җитез бер үткенлек белән башкара. Шуның өчен аңа «Тыр-тыр Вафа» дигән кушамат тагалар. Күрәсең, ул заманнарда Казанда тиз йөрүе белән танылган Вафа исемле кеше булгандыр инде. Газиз бик иртә гармун уйнарга өйрәнгән, аннары соңрак фортепьяноны да әйбәт дыңгырдата башлаган. Татар көйләрен ул вакытларда бай йортларда гына була торган фисгармониядә да уйный икән. Махсус музыкаль белем алмаса да, хәтерлим — әтием эштән ял иткән араларда фортепьяно янына яратып-рәхәтләнеп килеп утырыр иде дә, күңелдән генә төрле көй-моңнар уйнар иде; еш кына кулына скрипка яки мандолина алыр, алардан да сызып-чиртеп көйләр чыгарыр иде. Бу музыкаль сәләт аңа әнисеннән күчкән, әнисе исә гармунда бик оста уйнаган. Мәрьям исә махсус музыкаль белем алган һәм фортепьянода уйнаган. Кадыйр абзыйның музыкага бик исе китмәгән, әмма мәгәр кечкенәдән рәсем ясарга һәвәслеге ачылган, ул карандаш-пумалалар белән җиңел эш иткән, рәсемнәрен майлы буяу һәм акварель белән дә, төсле карандашлар һәм күмер белән дә бердәй оста ясар-язар иде.

Салих бабам, кырыс холыклы, буйсындыручан табигатьле булып, балаларыннан да тулысынча карышусыз буйсынуны, сүз тыңлауны таләп итә. Ә Өммегөлсем әбием исә, киресенчә, йомшак күңелле, көләч-ягымлы табигатьле була, әмма, шул заманнардагы татар хатыннарына хас булганча, иренә берсүзсез буйсынып яши.

Салих бабам, үзе Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган кеше, олы улы Газизне дә укымышлы мулла итеп күрергә хыяллана. Сигез яшьлек Газизен 1985 елда «Халидия» мәдрәсәсенә укырга бирә. Бу мәдрәсә исә Казанда иң кадими, иң артка калган уку йортларыннан була.

Соңыннан, 1915 елны Газиз, үзенең шул мәдрәсәдә укыган елларын исенә төшереп, сөрсегән карашлы мулла-мөгаллимнәрдән көлеп, «Чалбар» дигән бер хикәя дә яза.

Алай да заман җилләре үтеп керә тора. 1903—1904 елларда алдынгы татар яшьләре — шәкертләр, реаль училище укучылары, гимназистлар, студентлар арасында күтәрелеш-яңарыш башлана: яшьләр үзләренә алдынгы Европа илләре һәм урыс мәдәнияте үрнәгендә белем-тәрбия бирүне алга сөрәләр. «Шимбә» исемле яшьләр түгәрәге оеша. Бу түгәрәккә Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов кебек, соңыннан күренекле шәхесләр булырдай байтак яшьләр йөри. Алар әдәби кичәләр үткәрәләр, яшь татар язучыларының яңа әсәрләрен кычкырып укып, фикер алышалар, үзешчән спектакльләр куялар.

Бервакыт «Шимбә» түгәрәге утырышыннан соң гына төнге урамга чыккан Газиз тиз-тиз атлап өенә ашыга. Түгәрәктә ишеткән-күргән тәэсирләреннән айнып өлгермәгән егет аны-моны абайламый башта. Төн тын һәм караңгы, бераз шомлы да. Шәһәр тирән йокыда. Бер адәм заты күренми. Шунда кинәт егет

уйларыннан айнып китә: чү, аның артыннан кемдер килә түгелме соң? «Эзгә төшкәннәрдер, бәлки...» Газиз, адымын тагын да кызулый төшеп, урам-тыкрыкларны гизә башлый — янәсе, шул рәвешле теге «койрык»ны юлдан яздырмакчы. Ә «койрык» калмый гына бит! «Әй, беткән баш беткән, ни булса — шул, өйгә кайтырга кирәк...» Газиз ашыга-кабалана капкадан керүгә, янә капка шылтырап ачыла һәм... ишек алдында мышнап-янып чыккан Гани абзый — Салих картның кучеры күренә. «Ну, тыр-тыр! Яндырып чыгара яздың бит!» — ди ул Газизгә пышылдап кына. Гани абзый Газизне бик ярата, үз итә, шуңа күрә, Салих картның «күз-колак булырга» кушкан боерыгыннан бигрәк, үз теләге белән, Газизгә сиздерми генә, аны саклап-озатып йөри икән. Менә сина — «койрык»! Икәүләп көлешәләр.

Әтием Газизнең «Шимбә» түгәрәге белән бәйле тагын бер романтик мажарасын мин әле күптән түгел генә белдем. Шәриф Байчураның «Фатих Әмирхан һәм татар яшьләре хәрәкәте» дигән мәкаләсендә («Казан утлары», № 1, 1966) бер төркем яшьләрнең фоторәсеме дә бирелгән. Рәсемдә — жиде кеше: әтием Газиз, аның сеңлесе Мәрьям, Гайшә Богданова, апалы-сеңелле Рабига һәм Зәйнәп Габитовлар, тагын ике яшь егет. Миндә бу фоторәсемнең шул ук жиде кеше башкачарак позада сурәтләнгән төп нөсхәсе бар. Россиядә ислам кабул ителүнең 1100 еллыгына мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин чакыруы белән 1989 елны ерак Австралиядән кайтып төшкән Ләйлә ханым Садрига (Габитовага) шул фоторәсемне күрсәткән идем. Белдем: 1905—1906 елларда әтием шул рәсемдәге чибәр туташның берсенә — Рабига Габитовага гыйшык тотып йөргән икән. Ул аңа тәкъдим дә ясаган, әмма Рабига туташ, сугышта һәлак булган (күрәсең, 1905 елгы урыс-япон сугышыдыр) бер яшь офицерны яратканлыгын, аны яд итеп, берәүгә дә кияүгә чыкмаска сүз биргәнлеген әйтә. Чынлап та, бу туташ гомере буе ялгызы яши, күпләп эт-мәчеләр асрый. Хәтта ач-ялангач калган картлык көннәрендә дә, соңгы сыныгын авызыннан өзеп, аларга ашата торган булган.

Әтием Газизнең беренче гыйшкы булган бу гүзәл затның фажигале язмышы әнә шулай тәмамлана.

Әлеге фоторәсем артына әтием кулы белән бер моңсу шигырь язылган:

Зак фәзага багыб өмет илә,
Киләчәкнең әмәлен төшенү белән,
Яшь чәчәкләр арасында көтү белән,
Басыб торамын кызыл шәфәкъ көтеб.
Атармы гөлләр, житәрме язлар? — белмим,
Килерме бәхет-сәгадәт илгә диб уйлыймын,
Киләчәкнең эзләрен әле дә мин күрмимен,
Бары аны күрсәтәчәк тарих факт белән...
Үтәр заман, үтәр яз да,
Житәр жәй дә, килер черкен көз дә,
Бәлки, уйнар кыш жиле — буран да,
Бәлки, шул буран күмәр үтереб мине дә...

Яшь егетнең беренче мәхәббәтен югалтуы аны әнә шундый моңсу юллар белән өйрәнчек шигырь язарга этәргән булса кирәк.

Кадыйр абзый сөйли иде: Газиз кечкенәдән төрле кешеләр булып кыланырга ярата, кемнәрнедер үчекләп-үртәп күрсәтә, көлкеле кәмитләр уйный икән. Аның бу күңелле гадәте еллар үткән саен чарлана-баеый бара, телдән сөйләнгән хикәяләрен язып та бара башлый ул. Аларны яшьләр алдында укый, уңыш казана. Дуслары аңа хикәяләрен жыеп бер китап итеп чыгарырга киңәш итәләр. Әмма Газиз үзе бу шөгыленә әле бер күңел ачу, кәмит уйнау дип кенә карый. Бары тик 1913 елны гына, Фатих Әмирханның акыллы-төпле киңәшен тотып, ул «Аң» журналында басыла башлый. Беренче әдәби уңышлары аны илһамландырып җибәрә, күбрәк яза башлый. Әти үзе бу хакта: «Мин әдәбиятка Фатих Әмирханның хәер-фатихасы белән аяк бастым.» — дип сөйли торган иде. Беренче әсәрләрен ул «Г. Г.», «Габделгазиз», «Сәлман» (менә кайдан килә минем исемем!) һ. б. имзалар белән бастырып килә. Соңрак инде даими псевдонимы «Г. Газиз» була.

Мәдрәсәдә тугыз ел чалбар төбе туздырып («Чалбар» хикәясен хәтерләгез!) чыкканнан соң (1904), Газиз әтисе Салих картның ихтыярын үтәүдән — муллалыкка китүдән каты рәвештә баш тарта. Әмма әтине мин һич кенә дә алласыз, атеист булган дип әйтмәс идем. Минем белән тәрбияви әңгәмәләрендә ул еш кына бу мәсьәләгә дә кагыла иде. Алласызлык кешене рухи ярлылыкка илтә. Аллаһыга иман китерү, аңа инану кешене күтәрә, аны хайваннардан өстен

зат — аң иясе итә, Аллаһы Тәгалә һәр акыллы-аңлы кешенең күңелендә-кальбендә булырга тиеш. Менә болар — әтием миңа сеңдереп калдырган хакыйкатьләр.

Мәдрәсәне тәмамлаган елны ук, әтисеннән яшереп кенә, Газиз урыс теле фәнен өйрәнә башлый, экстрен имтихан тотып, гимназиягә керергә әзерләнә. Әмма Салих бабам, улының «гөнаһлы мавыгуын» сизеп алгач, аны үз кибетләренең берсенә «акылга утыртырга» һәм сәүдә эшләренә өйрәнә торырга жибәрә. Кибетчеләр байбәтчәне ягымлы каршылыйлар, алар аны эшчән-тырыш егет вә кызыклы хикәяләр сөйләүче итеп беләләр. Аның укырга теләге барлыгын аңлап алгач, хужага сиздерми генә, егеткә прилавка астында яшерен урын кормаштыралар. Газиз шунда дөньясын онытып Лев Толстой, Герцен, Чернышевский, Достоевский кебек классикларның әсәрләрен йотлыгып укый, гимназия программасы буенча тырышып әзерләнә.

1905 елгы урыс инкыйлабы башлангач, Газиз әтисенә кистереп әйтә: «Сәүдә эшләре белән шөгыльләнмәячәкмен, миңа өмет тотма!» — ди. Әлбәттә, Салих бабам башта бик каты тузына, өйдә буран куба. Әмма аек акыллы, үзе дә эшләрендә-киемнәрендә «европалы» булырга тырышкан сәүдәгәр инкыйлаб җилләренең кай якка таба искәнен аңлый, татар яшьләрендә уянып килгән яңалыкны тоеп тора һәм улының теләгенә каршы килми, тиздән ризалаша. Абыйлары йогынтысында кечеләре дә шул якка карый бит әле: европача белем алырга омтыла!

Салих Гобәйдуллин йорты икегә бүленә: аскы кат тулысы белән балалар иркенә бирелә — теләсә нишләсеннәр; өске катта ата-ана торып кала — алар үзләренчә, искечә яшиләр. Хөррият! Бу йортка инкыйлаб шулай килеп керә. Сүз уңаеннан, ул йорт һаман исән әле: Зәйни Солтан урамы, 12 йорт ул. Анда әүвәлрәк милиция бүлеге урнашкан иде, соңрак — «Вторцветмет» конторасы, хәзер нәрсәдер — әйтә алмыйм.

Шул ук елларда Газиз Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчуриннар белән якыннан таныша-аралаша башлый. Бигрәк тә Гафур Колахметов белән дуслашып китә ул. Аларны Фатих Әмирхан таныштырган була. Гафур атна саен Газизләргә килә, еш кына куна да кала. Газиз үзе дә аларга барып йөри. Ул килсә, Гафурның әнисе тәмле пәрәмәчләр пешерә.



*Сулдан уңга: Г. Гобәйдуллин, Г. Тукай, Г. Колахметов. 1910 ел (?)*

Гафурның бик бай шәхси китапханәсе була. Газиз китапларга «чума». Бередә, урыс классикасыннан тыш, Европа классикасы да күп, философлар Спенсер, Кант, Гегель... Гафур белән төн уртасына кадәр сузыла торган әңгәмәләр... Бу әңгәмәләр бик озын-озакка китсә, Гафур сүзен кырт бүлә дә Газизгә:

— Укы, укы, шайтан малае! Сиңа күп укырга кирәк! — ди.

Газиз Гобәйдуллин үз истәлекләрендә: «Гафур начар агитатор иде. Ул мине бер вакытта да үз сәяси карашларына күндерергә тырышмады, үгетләмәде,» — дип яза. Әмма китапханәсендәге марксистик тәгълиматка караган хезмәтләрне дә «йота» бара Газиз.

Колахметовлар гаиләсенә килеп-китеп, тәмам «үз уллары» кебек булып беткәч, яшьлек үзенекен итә: Газиз Гафурның сеңлесе Суфияга гашыйк була да куя. Яшьләр бит, нишләмәк кирәк! Фатих Әмирханның «Яшьләр» әсәрендәге алдынгы карашлы, милли рухлы егет-кызлар — нәкъ әнә шулар ич...

Газиз өйләнергә уйлый. Әмма... гаилә башы — әтисенә әйтмичә, аның хәер-фатихасын алмыйча, бу — мөмкин эш түгел. Нишләргә? Җитмәсә, әнисе дә күптән түгел дөнья куйган чак... Киңәшергә-яклашырга канат юк...

Әтисе белән сөйләшүне Газиз барысы да кичке чәйгә җыелгач тәвәккәлләргә була. Гадәттәгечә, самовар янында әтиләре утыра, чәй ясап тора. Тезелешеп Газиз, Кадыйр, Мәрьям чәй көтәләр. Шунда Газиз сүз башлый:

— Әти,— ди ул,— мин инде балигъ булдым...— тирән итеп бер сулый да ярып сала:— Мин укымышлы, бик сөйкемле бер кызны яратам. Син аны беләсең: ул — дустым Гафурның сеңлесе Суфия... Өйләнергә ният... Хәер-фатиханны бир, әти...

Салих байның төсе китә: башта агарынып кала, аннары кызарынып-бүртенеп чыга. Ул бер сүз дә әйтми, торып баса, алдында гөҗләп утырган самовар капкачын йолкып алып, бар көченә Газизгә тондыра:

— Моның гомергә булачагы юк! — дип, бүлмәдән җенләнеп чыгып китә.

Самовар капкачы Газизнең маңгаен яра. Шаулап кан китә. Куркынган Кадыйр белән Мәрьям ярдәмгә ташланалар. Мәрьям елый ук башлый:

— И ходаем! Күзең... күзең...— дип такмаклый. Абыйсының маңгаена Кадыйр сөлге куя, Мәрьям йөгереп кенә йод алып килә, яраны йод белән яндыралар. Әмма яра тирән, кан агуы туктамый. Газизнең күзе-бите шешеп чыга, күзләре бөтенләй томалана. Тиз генә табиб чакырталар, ул яраны әйбәтләп юып-эшкәртеп, тегеп куя...

Бу тарихны әти безгә: «Әти, маңгаеңда нинди җөй ул?» — дип сорагач, үзе сөйләгән иде. Җөе, Салих бабам истәлеге булып, гомеренә сакланып калды шулай.

Шул рәвешле, Газизнең икенче мәхәббәте дә челпәрәмә килә...

1909 елны, биш ел буе үзлегеннән өлгергәнлек аттестатына әзерләнгәннән соң, Газиз Гобәйдуллин Казан император университетына керү имтиханнары биреп карарга уйлый. Беренче имтихан урыс теле һәм әдәбиятыннан иркле инша язу була. Бу — татар һәм башка «инородец» балалар өчен махсус корылган тозак: шуны үтә алсаң, алга таба имтихан тотасың, үтмәсәң — коелып каласың... Газиз өчен иң авыры шул: ул бит гимназияләрдә укып йөрмәде, мәдрәсә белеме алган татар байбәтчәсе өчен урыс теле шул ук чит телгә бәрабәр инде ул. Шунлыктан, Газиз «мөгез чыгарып» азапланмаска була, иншасын кыска-кыска гади җөмләләр белән яза, янәсе, тыныш билгеләре азрак булсын. Тема сайлау, иншаның эчтәлеген ачу аның өчен әллә ни кыен эш түгел анысы — ни әйтсәң дә, хикәяче бит. Әнә шул тыныш билгеләре белән хәреф хаталары гына...

Газиз, язган эшен тапшырып, аудиториядән чыга. Чыкса... диварларга сөялгән, тәрәзә төпләренә кунаклаган абитуриентлар гөҗләшә: кем нинди тема сайлаган да, кем кайсы классиклардан нинди цитаталар китергән... Күренеп тора: боларның белем згы Газизнеке кише генә түгел шул инде! Егетебез тыңлап-тыңлап тора да, борынын төшереп өенә кайтып китә: әлбәттә, булдыра алмады!

Икенче көнне Газиз, авыр уйларыннан арынырга теләп, аугa чыгып, җилләнеп кайтмакчы була. Иртән, ау кирәк-яракларын җыештырып, биек резин итекләрен киеп, ау эте Дамканы да ияртеп, Гани абзыйның тарантасында өйдән кузгала ул. Шулай да күңелен корт ашый, түзми — атны университет ягына борырга куша. Кереп, алдагы имтиханнарга үткәннәрнең исемлегенә күз саласы килә аның. Керә, карый — юк «Гобәйдуллин» фамилиясе исемлектә... Әлбәттә, үтмәгән! Сөмсере коелган «татарчонок»ның чыгып барганын ишек төбендә торучы швейцар карт күреп ала. Сәерсенеп, өстендәге ау киемнәренә, резин итекләренә карап-карап тора да, туктатып, фамилиясен сорый. Аннары, кичә имтихан алган доцентның бер профессорга инша язучылар арасыннан аеруча бер татар егетен мактап торганын әйтә: «Бәлки, ул синдер?» — ди. «Юк,— ди Газиз,— исемлектә мин юк...» «Алай да син әнә теге бүлмәгә кереп белеш әле»,— ди швейцар. Газиз кереп белешә. Фамилиясен әйтә. Егеткә иншасының иң яхшы дип табылганын, шунлыктан аерым исемлектә булачагын әйтәләр. Газиз «ура!» кычкырып чыгып йөгерә. Гани абзыйга кабалана-кабалана сөйли: «Минем иншам иң яхшы дип табылган! Мин икенче имтиханга үткәнмен! Чаптык, абзыкаем, өйгә!»

Газиз Гобәйдуллин, барлык имтиханнарын да бик яхшы билгеләренә генә тапшырып, Казан император университетының юридик факультетына укырга керә.

1913 елны Газизнең шәхси тормышында янә бер бик әһәмиятле вакыйга була. Ул үзенең булачак хәләл җефете Рабига Шакир кызы Казакова белән таныша. Бу эштән Газизнең дусты Гафур Колахметов та читтә калмый.

Әниебезнең сөйләвенчә, эш болай була. Әти белән алар укытучы Мөхетдин абзыйлар өендә яшьләр кичәсендә очрашалар. Яшьләр арасында Гафур Колахметов та була, әни инде аның белән таныш икән. Табигате белән тыйнак кызый дуслары арасында тын гына утыра. Аларны Гафур «учитель» әллә нинди кызыклар сөйләп көлдереп тора. Дустын күреп, алар янына Газиз дә килә. Гафур аны төркемгә шаян сүзләр белән тәкъдим итә:

— Һа-а-а! Таныш булыгыз, кызлар, Казан император галиҗәнапләре университеты студенты Газиз Гобәйдуллин булыр бу! Тегенди-мондый гына егет түгел — булачак «личный дворянин»!

Төркем гөрләшеп көлеп куя. Кайбер кызлар Газиздән сораштыра башлыйлар: кайсы факультетта укый, кемнәр укыта, лекцияләр кызыклымы?..

Булачак «личный дворянин» (инкыйлабка кадәр Казан университетын тәмамлаучыларга, чынлап та, «личный дворянин» дәрәҗәсе бирелә торган була. Бу дворяннар дәрәҗәләрен мирас буенча калдыру хокукыннан мәхрүм саналалар.), менә шул булачак «личный дворянин» Газиз тиздән үзләшеп китә, кызларга төрле кызыклар сөйләп күңел ачу бурычын үз кулына ала. Шулай күңелле-матур утырган яшьләр арасыннан сөйкемле-тыйнак гимназистка Рабиганы шәйләп ала ул. Газиз кич буе аның янында бөтерелә. Егетне кыз да ошата. Шуннан соң Газиз гел аның белән очрашу җаен гына эзләп йөри башлый. Әмма ул заманнарда татар кызлары белән тиктомалдан гына күзгә-күз очрашу — килешә торган эш түгел. Монда да яшьләргә ярдәмгә Гафур Колахметов килә. Ул аларны, икесенә аерым ложа алып, театрда очраштыра. Шунда әти әнигә тәкъдим ясый. Кыз риза була, әмма ике шарт куя: беренчесе — Газиз рәсми рәвештә Шакир Казаковтан кызының кулын сорарга тиеш, икенчесе — Газиз Рабиганың гимназияне тәмамлавын (йә, хода, тагын бер ел!) көтәргә тиеш, шуннан соң гына — туй... Нишләсен, кызның шартларына күнми хәле юк егетнең. Күнә. Шакир Казаков белән сөйләшеп, аның ризалыгын ала. Хәзер инде эшнең иң четереклесе кала: киребеткән үз әтисен — Салих байның хәер-фатихасын аласы бар. Газиз җөйле маңгаен сыпырып куя. Нишләргә? Нишләргә? Тагын дусты Гафур ярдәм кулы суза. Ике дус бик хәйләкәр уй-ният коралар. Эш шунда ки, Салих бабам ел саен җәен Кырымга ялга бара икән. Гадәттә ул үзе белән берәр яшь егетне дә ала икән. Менә шунда Газиз әтисенә үзе белән Гафурны алып барырга киңәш итә һәм күндерә. 1914 елның җәе була бу.

Салих бай белән Гафур Кырымга китеп озак та үтми, Газиз мондый телеграмма суга: «Өйләнергә җыенам Рабига Казаковага Әтисе риза Хәер-фатиханы бир әти Улың Газиз».

Хәйләкәр Гафур «учитель» Салих байны ничекләр итеп ризалаткандыр, әмма ризалаткан: әтисе Газизгә хәер-фатихасын биргән.

Әмма, Тукай әйтмешли, «өйләнү — түгел сөйләнү». Мәшәкатьләр моның белән генә бетми бит әле. Газиз Гобәйдуллин, университет студенты буларак, өйләнергә рөхсәтне ректордан яки губерна попечителеннән дә алырга тиеш икән. Газиз үзенең үтенечендә: «Россиянең потомственный почетный гражданины, Казан сәүдәгәре Шакир Казаковның 1914 елны гимназия тәмамлаган Рабига исемле кызына өйләнергә рөхсәт бирүегезне үтенәм»,— дип яза.

Бу үтенеч кәгазе безнең гаиләдә озак еллар сакланып, каһәрле 1937 елны юкка чыкты. Үтенеч өстенә: «Разрешено жениться на Чабиче» дип резолюция салынган, имза куелган. Урыс ректорына Рабига ни дә, Чабича ни син — барыбер. Әти-әни ул «дүкәминтне» кызык итеп искә төшерер өчен саклый иде. Әти исә, шаяртып-үртәп, әнине «Чабыч» дип тә йөрткәли иде.

1914 елның җәендә, Салих бай да Кырымнан кайтып төшкәч, хәстәрләнеп туй үткәрәләр. Туй гадәттәгечә генә булмый. Ул Идел-Кама акционерлык җәмгыятенең бер пароходында үтә. Әниемнең әтисе, минем бабам Шакир Казаков шул җәмгыятьнең акцияләрен тотучы бай икән. Байларныкы — байларча: музыка уйный, салонда бал-биюләр кыза, шампаннар елга булып ташый...

Туйдан соң яшь килен Рабига, туган-үскән йортын ташлап, Гобәйдуллиннар йортына (Зәйни Солтан урамына) күчеп килә, яшь гаилә аскы катта Газиз

бүлмәсенә урнаша. 1915 елның май аенда шул бүлмәдә мин дөньяга килгәнмен. Без анда 1916 елга кадәр торганбыз.

1916 елны Газиз Гобәйдуллин Казан император университетының тарих-филология факультеты тарих бүлеген (юридик факультетта ул бер генә ел укый, галимнәре-остазлары киңәше белән бирегә күчә) беренче дәрәҗәле диплом белән тәмамлый.

Укытучылары — профессорлар Катанов, Фирсов, Хвостов кебекләр сәләтле егеткә университетта калырга, фән белән шөгыльләнергә киңәш итәләр. Газиз үзе дә моны бик тели. Әмма... «Әмма,— дип яза Газиз Гобәйдуллин үзенең автобиографиясендә,— минем сәяси яктан ышанычсызлыгым (большевик Гафур Колахметов белән дуслыгы!) һәм татар булуым казна эшенә кереп, университетта калуыма киртә салды.»

Казан губернаторының күрсәтмәсе нигезендә, Газиз Гобәйдуллин, хатынын һәм бер яшьлек улын алып, 1916 елның көзендә Казаннан китәргә мәҗбүр була. Үзенә күрә сөргенлеккә охшаш бу тибәрелү аркасында, ул гаиләсе белән Оренбург губернасының Троицк шәһәренә барып урнаша. Ләкин анда да рәсми уку йортларында укытырга рөхсәт ала алмый. Хосусый татар мәдрәсәләрендә генә эшләргә мөмкинлек таба: биш сыйныфлы мөселман ирләр мәктәбе «Вазифа»га мөдир булып урнаша, бер үк вакытта Яушеваның кызлар мәктәбендә тарих та укыта. Яшьләр арасында сәяси-җәмәгатьчелек эшләрендә катнаша башлый.

Яшь гаиләнең бәхетенә, 1917 елгы февраль инкыйлабы Казанга кайтырга мөмкинлек ача. Газиз Гобәйдуллин башы-аягы белән фәнни һәм әдәби иҗат эшенә чума.

Аннары — Октябрь инкыйлабы...

1919 елны яшь галим Газиз Гобәйдуллин университетның Россия тарихы кафедрасында профессорлар Н. Ф. Катанов (ориенталист) һәм Н. Н. Фирсов (тарихчы) карамагында эшкә калдырыла.

Шаулатып-гөрләтеп кызының туен үткәргән һәм зур чыгымнар тоткан Шакир бай Казаков та, улының туена бер тиен дә бирмичә, бар булган акчасына Казанда берничә йорт сатып алып, шуларның килеренә картлыгын тыныч үткәрергә хыялланган Салих бай Гобәйдуллин да Октябрь инкыйлабы корбаны булалар: инкыйлаб аларны кычкыртып талый — бар булган мал-мөлкәтләрен конфискацияли, тартып ала. Таланып калган картлар балаларына барып егылалар.

Шулай итеп, инкыйлаб яшьләр өчен зур бер бәхет — киләчәккә якты юллар ача, картлар өчен каһәрле язмыш булып чыга...

Октябрьдән соң Казан хакимияте яшь галим Газиз Гобәйдуллин гаиләсенә Тукай урамы, 73 нче йортның ишек алдындагы флигельдән (флигель — төп йортка янкорма итеп салынган кечерәк өстәмә йорт) ике бүлмәле фатир бирә. Гаиләнс икенче каттагы Исхак абый Казаковлар белән бер гомуми фатирга урнаштыралар. Исхак абый — әнинең туганнан туган абыйсы — Татарстан Җөмһүриятенең Совнарком Рәисе урынбасары була.

Шул рәвешле, тормышның совет чоры башлана.

Илдә гражданнар сугышы әле тынып өлгермәгән, һәркайда — кытлык, Идел буйларында — ачлык. Безнең төп азыгыбыз — бәрәңге дә бәрәңге кабыклары белән көрпә кушып пешергән ипи. Шикәр урынына сахарин дигән нәрсә, ит-май бөтенләй юк. «Нансен күчтәнәчләре» бик ярап куя иде (Фритьоф Нансен (1861—1930) — атаклы норвег галиме, Котыпны яулаган кеше, Нобель бүләге лауреаты. Егерменче еллардагы ачлыкта Идел буе халыкларына һәм яшь Совет дәүләтенең галимнәренә ярдәм оештырган.). Ул посылкаларда бераз бодай оны, шикәр комы, ярма, берәр банка куертылган татлы сөт, хәтта какао да була иде. Күчтәнәч, әлбәттә, озакка бармый, без тагын бәрәңгегә күчәбез. Аннары әтигә эшеннән паек талоннары да биргәлиләр иде әле.

Бервакыт кышын әти мине чанага утыртты да, без паек алырга киттек. Безнең талонга галәмәт зур дуңгыз башы бирделәр, аны минем алдыма куйдылар, мин, бу «кыйммәтле мал»ны төшереп җибәрмәгәем дип, куркып, аны кысып кочаклап та алдым. Әти кәлә. Җитмәсә, Бутлеров урамы тавыннан төшкәндә чананы үз иркенә җибәрде. Менә мин, әлеге галәмәт зур дуңгыз башын кысып кочаклаган килеш, таудан очам, йөрәгем чыгардай булып тибә, куркуымнан сулышым кысыла. Әгәр дә шул каһәр төшкән чучка белән бергә Кабан күленә үк барып төшсәм?.. Ул арада әтием килеп җитә. Аны күрүгә мин шунда ук тынычланам, авыз ерып елмаерга итәм.

Дуңгыз башын башка азык-төлеккә алыштырдылар, без бит мөселманнар, әлбәттә, аны ашамый идек. Әй рәхәтләнгәндер берәр урыс малае, дуңгыз колагын кетердәтә-кетердәтә!

Октябрь инкыйлабыннан соң әти зур кайгы кичерә: яраткан дусты, киңәшчесе Гафур Колахметов туберкулездан үлеп китә. Әти бик озак ятимсенеп йөри...

Казанда әтинең төп эше — укыту. Алган хезмәт хакына ул гаиләсен ашата. Ә аннан да төп эше — иҗат: фәнни хезмәтләр, татарча дәреслекләр, үз хикәяләрен язу. Боларына басылып чыкса гына каләмхак түлиләр.

Ул искиткеч күп эшләгән. Менә аның шул елларда татар телендә дөнья күргән кайбер хезмәтләре: «Борынгы тарих» (1918), «Тарих гомумидән корун әүлия» (1918), «Тарих әдьян. 1 җилд. (1918), «Диннәр тарихы»1919) һ. б. Аннары 1925 елга кадәр янә дистәләрчә китаплар, өзлексез казна эше... Үзе эшли, үзе аспирантурада укый. Аны уңышлы тәмамлый. Казандагы хәрби татар-башкорт мәктәпләрендә, үзе оештырган Көнчыгыш Академиясендә, Татар коммунистик университетында, тагын төрле курсларда тарих фәне буенча дәресләр алып бара. Татарстан җир эшләре халык комиссариатында укыту идарәсе начальнигы урынбасары була. 1921 елны ук Казан дәүләт университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза булып сайлана. Зур фәнни тикшеренүләрен әйткән дә юк: гомуми тарих, татар тарихы, татар әдәбияты, мәдәнияте, иҗтимагый фикер үсешенә караган хезмәтләр... Ул аларны бер-бер артлы китап итеп бастырып чыгара да бара.

Бу гаҗәп күпкырлы талантлы шәхескә көнләшеп караучылар да булган, әлбәттә. Кемнәрдер аны чит илгә, әйтик, Төркиягә китәргә димли. Уфадагы бер пароходта Газиз Гобәйдуллин өчен дә урын калдырылган була. Маршрут: Агыйдел — Кама — Идел — Каспий. Аннары — чил илгә, мөһаҗирлеккә... Әти каттый баш тарта. Ни генә булса да, туган илен беркайчан да ташлап китмәячәген әйтә.

1922 елны әтигә Кабан күленең сул як ярындагы урамнан әйбәт кенә икенче фатир бирәләр. Дүрт катлы бу таш йортта элек семинария укытучылары яшәгән. Ә хәзер аны тулысы белән Казан ВУЗларында укыткан профессорларга тапшырганнар. Нинди генә асыл затлар юк иде алар арасында! Мироновлар, Воробьевлар, Корбангалиевләр, Фирсовлар... Тагын әллә кемнәр. Безнең подъездда — Җамал Вәлидиләр. Мин аларның балалары белән бик тиз дуслашып киттем: Искәндәр, Ибраһим, Әминә, мин көне буе уйнап әвәрә килә идек. Кунакка да йөрешәбез.

1923 елны гаиләбездә шатлыклы вакыйга булды: игезәк энекәшләрем Микаил белән Исрафил дөньяга килде. Аларга ни өчен шундый сәер исем кушканнардыр — хәзергәчә белмим. Әтием мине әнием янына энеләремне күрергә алып барды. Әни ике бәбие белән аерым палатада ята иде. Әни безне елмаеп каршылады. Ә менә энеләремә бер дә исем китмәде — миңа әле сигез генә яшь иде. Шуңадырмы, әллә эчтән генә бераз көнләштем дә микән — әтинең куанычын һич аңлый алмадым. Ике елак өчен шул кадәр шатланмаса!

Әти һаман да күп эшли. Аның фәнни хезмәтләрен Татарстаннан читтә дә таныйлар. Үзен Мәскәүгә, Ленинградка һәм башка шәһәрләргә лекцияләр укырга чакыралар. Ул үзенең туганнан туган энесе Гали Рәхим белән берлектә «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәт — зур хезмәт! — яза башлый (Гали абзый Рәхим турында алдарак иркенләбрәк язармын әле). Аларның ул хезмәте ел саен (1922, 1923, 1924, 1925) тулыландырылып, яңартылып басылып чыга тора. 1925 елны Мәскәүдә СССР халыклары Үзәк нәшриятында Газиз Гобәйдуллинның «Татар тарихы» дигән монографиясе дөнья күрә. Ул әле дә, татар халкының килеп чыгышы һәм үсешенә күләмле күзәтү буларак, үзенең әһәмиятен югалтмаган.

Үзе баштанаяк фән һәм педагогик эшчәнлеккә чумган әтием табигате белән хәйлә-мәкерсез, астан ут уйнату кебек интригаларны белми-аңламый торган бер зат иде. Ә менә аның тирәсендә болытлар куерганнан-куера бара икән... «Кара әле, бу «байбәтчә» артык азынып бара түгелме соң? Китап арты китап...» — дип көнләшеп караучылар әтине, бурзайлар өере кебек, талый башлыйлар. Ул еш кына эшеннән кәефсез, борчулы кайта башлады. Элекке көләчлеге-шаянлыгы югалды. Әни белән сөйләшүләреннән мин аның үзенә гаделсез карауларын, «байбәтчә» итеп ышанычсызлык күрсәтүләреннән зарланганын абайлап калдым.

Ул елларда кешеләрнең тумыш-чыгышларына нык игътибар иткәннәр шул. Әйе, татарга хас хөсетлек-көнчелек кара елан булып һәр почмактан әтигә ысылдый башлый...

Ул елларда Татарстандагы фән һәм педагогик эшчәнлекнең идея һәм партия җитәкчесе сыйфатында Галимҗан Ибраһимов тора. Ул һәм аның тирәсендәгеләр күбрәк чыгышы белән пролетар-ярлы балаларын өскә үрләтергә теләгәннәр, күрәсең. Ә «элеккеләргә», «байбәтчәләргә»,— нинди генә талантлы, нинди генә намуслы булмасыннар,— шикләнеп караганнар, ышаныч күрсәтмәгәннәр. Ул заманнардагы «юлбашчыларыбыз», иң беренче чиратта — Сталин эшләтеп җибәргән бу мәкерле «машина», кызганыч ки, соңыннан зыялыларның агын да, карасын да — барысының да башын ашаган. Шул исәптән, Галимҗан Ибраһимовның үзен дә...

Кыскасы, әтигә киләчәктә Казанда эшләргә бирмәячәкләре көннән-көн ачыграк була бара.

1925 елның язында: «Газиз Гобәйдуллинны кулга алганнар!» — дигән яман хәбәр шәһәр буйлап яшен тизлегендә таралып өлгерә. Имеш, ул кайдадыр Урта Азиядә нәрсәдер урлаган... Әтинең ул якларга барып чыкканы да булмый әле юкса! Бу мәгънәсез кулга алуның кемнәр тарафыннандыр оештырылуы, әтине каралтып күрсәтү, исеменә тап төшерү өчен — «утсыз төтен чыкмый», янәсе — эшләнгән әшәкелек икәне ачык билгеле була.

Казан университетының Н. Н. Фирсов туплаган абруйлы профессорлары әтине порукага, ягъни үз җаваплылыкларына алып, төрмәдән чыгарталар. Тиздән «Красная Татария» газетында «Досадная ошибка» (янәсе, «Күңелсез ялгышу») дигән хәбәр дөнья күрә. Имеш, Урта Азиядә әтинең ниндидер бер фамилиядәше урлашкан икән... Әтидән гафу үтенәләр.

Гаделлек җиңгән кебек тоелса да, әти бик нык рәнҗетелгән һәм бик нык хурланган иде. Ул бу хыянәтчел пычраклыкны бик авыр кичерде. Шуннан соң Казаннан китәргә кирәк дигән карарга килде.

Шулай итеп, хөсет-көнчел кара елан үз эшен эшләгән, әтине чагып өлгергән иде инде...

Нәкъ шул вакытларда тарихчы галим Газиз Гобәйдуллинны Бакуга эшкә чакыралар: Баку университетында төрки телләрне белгән галимнәр житешми икән. Әни белән, хәтта мин — ун яшьлек улы белән дә киңәш-табыш иткәннән соң, әти Бакуга күчәргә ризалыгын белдереп телеграмма суга. Тиздән Әзербайҗан Мәгариф халык комиссариатыннан яшәү һәм эш шартларын тасвирлаган җавап килеп төшә, шунда ук Газиз Салих улы Гобәйдуллинның Баку университеты шәрекъ факультетына — төрки-татар халыклары кафедрасына приват-доцент итеп сайлануы да хәбәр ителә.

Шул рәвешле, Татарстан Мәгариф халык комиссариаты рөхсәте белән, 1925 елны Газиз Гобәйдуллин, Казандагы эшләрен ташлап, әлегә гаиләсез генә килеш Бакуга китеп бара. Ул әле үзенең алга таба гомере буе туган җирен, якын кешеләрен сагынып-җирсеп яшәячәген белми...

Әйе, кара елан әнә шулай да чага...

Без исә Баку якларына җәй ахырында гына кузгалабыз. Башта Идел буйлап пароходта Әстерханга кадәр барабыз, анда безне әти каршы ала. Ары таба Каспий аша — Бакуга!

Бакуда әти безне «Кызыл шәрекъ» кунакханәсенә алып китте. Без фатир тапканчы шунда яшәдек. Фатирыбыз хосусый йортта, татар мәктәбенә якын гына иде. Ерак та түгел Бакуның сәүдә үзәге, иртә таңнан төрле товарлар төягән дөяләр кыңгырауларын шылтыратып үтәләр. Миңа кызык!

Без ул фатирда ике ел чамасы тордык. Шунда игезәк энемнең берсе — Исрафил менингиттан үлеп китте. Аның үлеме гаиләбезгә авыр кайгы булды. Моны бигрәк тә әти кыен кичерде. Ул гомумән бик тә нечкә хисле кеше иде.

Әти, Казандагы кебек үк, биредә дә бик күп эшли, ару-талуны белми иде. Берьюлы ике югары уку йортында — Әзербайҗан дәүләт университетында һәм Югары педагогия институтында укыта. Лекцияләрен төрки телдә укый, бу үз чиратында зур әзерлек сорый. Шул ук вакытта ул әле фәнни-тикшеренү эшләрен дә туктатмый, 1926 елдан башлап фәнни хезмәтләр язуын тагын да киңрәк колач белән алып бара, аның тематикасы да киңәя.

Бер ел дигәндә, әти «Татар буржуазиясе тарихыннан», «Казан татарларында феодаль сыйныфлар җимерелү тарихына карата», «Татар тарихы»ның тулыландырылган варианты кебек хезмәтләрен язып бетерде. Шуннан аны Әзербайҗан дәүләт университетына Шәрекъ тарихы буенча доцент итеп сайладылар. Шул ук

елны ул Югары педагогия институтының иҗтимагый-тарих бүлегенә декан итеп тә билгеләнә.

Җәйге айларны без гадәттә Төньяк Кавказга — Минеральные Воды, Кисловодск, Ессентуки, Пятигорск санаторийларына бара идек. Әти санаторийда торып дәвалана, ә без берәр фатирда яшибез. Безнең белән әтинең дуслары — университет ректоры Таһир Шахбази, язучы Абдрахимбек Ахвердиев, профессор Бәкер Чобанзаде һ. б. булыр иде. Әй күңелле дә була иде соң!

1927 елны әти тагын берничә фәнни хезмәт язып тәмамлады. Аңа профессор исеме бирделәр. Беренче татар профессоры! Кырык яшендә! Казаннан якын дусларыннан котлаулар да килде. Остазларыннан берсе — профессор Н. Н. Фирсов «Красная Татария» газетында куанычлы мәкалә белән дә чыга.

1928—1929 елларда әти барып-кайтып Ташкент һәм Сәмәрканд югары уку йортларында да лекцияләр укып йөрде. Анда да ул шәркый мөселман кафедрасында профессор иде.

Әтинең ул елларда язган хезмәтләрен санап бетерерлек түгел. Шуның өстенә, дистәдән артык тел белүенә карамастан, ул инглиз телен дә өйрәнә башлаган иде.

1927—1929 елларда ул Казанга, туганы Гали Рәхимгә хатлар язып тора. Барысы 37 хат яки открытка. Ул хатларны аерым шәрехләп, бастырып чыгарырга кирәк дип саныйм. Алар минем тарафтан шулай эшләнгәннәр дә, алар — үзләре бер тарих...

Шушы урында Гали Рәхим турында бераз язып китү хаҗәттер.

Әтиемнең туганнан-туган энесе Гали Рәхим әтидән биш яшькә кечерәк була; димәк, 1997 елда аның тууына да 105 ел тула. Язучы һәм әдәбият белгече Гали Рәхим әтиемнең әнисе Өммегөлсем әбинең бертуган сеңлесе Бибигайшә улы була. Әтисе исә — Казан сәүдәгәре Мөхәммәтшакир Габдерәхимов. Әтисенең теләге буенча Галине «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Аннары ул Казан сәүдә училищесында укый, әтисе аны да үзе кебек сәүдәгәр итмәкче була. Кыскасы, Салих бай йортындагы хәл боларда да кабатлана. Гали Газиз абыйсы белән бик нык дуслаша, бала чагыннан ук Гобәйдуллиннарда еш була. Газизгә аның белемгә омтылышы, әдәбият белән мавыгуы, табигый зыялылыгы ошый. Ул Галине күз уңыннан ычкындырмый, үз дуслары, таныш-белешләре арасына да кертә. Алар икәүләп Казанда ул заманнарда танылып өлгергән Шәрекъ клубына йөриләр. Шунда алдынгы карашлы татар зыялылары белән очрашааралашалар.

Әтисе Мәскәү сәүдә институтына югары белем алырга укырга җибәрсә дә, Гали дә, абыйсы Газиз шикелле үк, сәүдәгәр булу ниятеннән баш тарта. Ул бик иртә әдәбиятка кереп китә: хикәяләр, пьесалар, повестьлар яза, аларны беренче итеп Газизгә укый. Соңрак, күрәсең, Газизнең йогынтысы беләндер, ул тарихи фәннәр белән мавыгып китә, фәнни һәм педагогик эшчәнлеккә тартыла.

Мин Гали абыйны йомшак күңелле, тыныч-сабыр, бик әдәпле, пөхтә-төгәл кеше итеп хәтерлим. Бала чагында имгәнүдән аның бер аягы икенчесеннән алты-сигез сантиметрларга кыскарак булып калган. Шул сәбәпле, ул махсус аяк киеме киеп йөри, бераз аксавы да сизелә, таяк та тота иде. Күрәсең, бу гариплеге аны тагын да тыйнак-оялчан иткәндер дә әле.

Сөйләп узганыбызча, Газиз Гобәйдуллин белән Гали Рәхим бик әтрафлы фәнни хезмәт — «Татар әдәбияты тарихы»н язалар һәм аны күп мәртәбәләр дәреслек сыйфатында бастырып чыгаралар.

Татар зыялыларының күбесенеке шикелле үк, Гали Рәхимнең дә язмышы фаҗигале тәгәлләнә. Сталин терроры елларында аны кулга алалар, гарип булуына карамастан, Ак диңгез — Балтыйк каналы төзелешенә сөрәләр. 1943 елны, инде бөтенләй бетерешкән галимне, ниһаять, кайтарып җибәрәләр. Ул Казанга кайта, әмма бер җирдә дә эшкә урнаша алмый, эшләрлек хәле дә булмый. Шулай итеп, ачлык-ялангачлыкта татарның бу күренекле галиме Казанда вафат була. Ике кыз туганы, аның мәетен чанага салып, көч-хәл белән генә зиратка илтеп җиткерәләр. Кабере югалган... Сугыш еллары бит!

Бервакыт әтием миңа уң һәм сул куллары белән берьюлы ике хат язганын күрсәтте. Хатлар икесе ике кешегә адресланган иде. Минем исем китте. Әти исә миңа карап хәйләкәр елмая, күзләре шаян уйнаклый иде.

Ләкин фәнни хезмәтләрен язганда ул бик төгәл иде, архив документларын, аерым фикерләрне бик ачык-матур итеп йә блокнотларга, йә аерым карточкаларга язып бара, ә фәнни текстларын яки китапларын америкалы портатив язу машинкасы «Корона»да баса һәм гаҗәеп тиз баса иде.

Бакуда эшләгән чорында әти үзенә тагын бер чит тел — инглиз теле житенкерәмәгәнлеген аңлап, — ул аңа фәнни журналлар һ. б. уку өчен кирәк иде, — инглиз телен үзләштерә башлады. 1929 елны аерым бер тырышлык белән көн саен сәгать ярым вакытын шуны өйрәнүгә сарыф итә иде.

Шул кадәр күп эшләп, әти әле безнең белән мәш килергә дә вакыт таба иде. Уйнап та ала, иркәләп тә сөя. Ул табигате белән бик ягымлы, бала жанлы иде. Безнең белән немец яки әзербайҗан телендә әңгәмә кора, ирләрчә бик житди үгет-нәсихәт бирергә дә онытмый. Безне әдәп-тәртип кагыйдәләренә өйрәтә, өлкәннәр белән, хатын-кызлар белән мөгамәләдә үзеңне ничек тотарга икәнлеген дә аңлата. Уку-өйрәнүне, аң-белем арттыруны бик житди эш дип карый. Ул һәрвакыт халыкка, Ил-Ватанга намуслы хезмәт итү фикере белән яшәде, үзенең мәнфәгатьләрен барыннан да элек шуңа буйсындырды. Безне дә шулай тәрбияләде.

Ул безнең барыбызны да жыеп симфоник концертларга алып бара иде. «Музыканы аңламаган, аны яратмаган кеше — ярты кеше», — ди торган иде ул. Үзе Бетховен әсәрләрен бик ярата, житди музыканы тирәнтен аңлап кичерә белә иде. Мине ул әзербайҗан мугамнарын (мәкамнәрен) тыңларга өйрәтте, шәрекъ музыкасының борынгы серләрен, аларның күңелләргә үтеп керә торган тирән фәлсәфәсен ачып бирде. Мин ул көй-моңнарны тәүге мәртәбә ашуглар — халык жырчылары авызыннан ишетеп, күңелемә сеңдергән идем. Хәзер дә мугамнар тыңласам, искиткеч бер ләззәт алам.

Әти безне опералар тыңларга да йөртте. Бигрәк тә истә калганы Бизеның «Кармен»ы булды, аеруча баш рольдәге жырчы Фатима Мохтаровага әти мөкиббән китә иде. Ул Әзербайҗанның барлык композиторлары һәм жырчылары белән таныш. Гозәер Гажибековның музыкасын бик ярата, ә жырчылардан — халыкның сөеклесе Бюль-Бюльне.

Драма театрларына да күп йөрдек. Бигрәк тә Хөсәен Җавид спектакльләренә бара идек, әти аны Әзербайҗан Шекспиры дип атый иде.

Бакуга кайчак Казан театрлары да килгәли иде. Аларның спектакльләренконцертларын калдырмыйбыз да калдырмыйбыз инде. Бервакыт шулай гаилә белән театрда утырабыз. Ут сүнгәч, спектакльне алып баручы сәхнә алдына чыгып басты да, залда атаклы татар профессоры, хөрмәтле Газиз Гобәйдуллин дә бар, дип белдерде. Зал гөрләтеп кул чапты. Утны кабыздылар. Әти торып басты, туган Казанына Бакуга артистларны җибәргәне өчен рәхмәтен әйтте, бу безнең кебек туган жирдән читтә яшәүчеләр өчен зур бәйрәм, күпмилләтле совет мәдәнияте бәйрәме, диде. Тагын гөрләтеп алкышладылар. Мин дә әтием һәм туган татар халкым өчен горурлык хисләре кичереп утырдым. Димәк, безне онытмаган Казан, безне беләләр!

Бакуга гастрольгә килгән ул татар артистлары еш кына спектакль-концертлардан соң безгә жыелышып килә, аннары шаулашып-гөрләшеп, жырлашыпбиешеп утыралар иде. Берсендә шундый килүчеләр арасында атаклы татар композиторы Салих Сәйдәшев тә булды. Әти аны бик хөрмәт итә, үз итә иде: «Сәйдәш музыкасы — халкыбызның жаны», — ди торган иде. Салих абый Сәйдәшев 1945 елны минем туганнан-туган сеңелем Асия Казаковага өйләнгән дә иде.

1928 елны әти Микаил белән мине ныклап торып немец телен өйрәнергә утыртты. Шул максат белән безгә Эмилия Георгиевна Вернер дигән немец укытучысы чакырдылар. Ул безне ике-өч ел буена немец телендә иркенләп сөйләшергә, укырга-язарга өйрәтте, өйдә гел немецча гына сөйләшә идек. Немец телен белүем миңа соңыннан сугыш елларында бик ярдәм итте, еш кына мине тәржемәче итеп файдалана иделәр. Ә Микаил, сугыштан исән-сау әйләнеп кайткач, Казан педагогия институтының география факультетын тәмамлап, мәктәптә география белән бер рәттән немец теле дә укыта башлады.

Әти мине әзербайҗан телен дә яхшылап өйрәнергә мәжбүр итте. Бервакыт ул өйгә Жюль Верннның гарәп шрифтлары белән төрек телендә басылып чыккан тулы әсәрләре басмасын алып кайтты. «Сиңа, бәлки, рабфакның әзербайҗан бүлегендә укырга туры килер, син ул телне яхшы белергә тиеш», — диде. Аның таләбе белән мин әлеге китапларны көн саен ике сәгать кычкырып укый башладым. Баштарак уку авыррак барса да, соңга таба, эчтәлекләре белән кызыксынып, күпме теләсәм, шул кадәр укый торган булып киттем. Әти хаклы булып чыкты, аның шулай алдан күрүчәнлеге бар иде: 1930 елны мин әзербайҗан бүлегенә рабфакка укырга кердем.

Әтиебез безне эш сөяргә өйрәтеп үстерде. Урын өстендә иркәләнеп-киерелгәләп, иртән аунап ятарга ирек бирмәде. Йокыдан тору һәрвакыт иртәнге жидедә булыр иде. Әти өстебездән одеалны тартып алыр да, катгый итеп: «Ир кеше иркәләнеп ятарга тиеш түгел!» — дияр иде. Өй эшләре дә һәркемгә бүлеп бирелгән. Мин идәнне балавыз белән ышкып ялтыратам, кибеткә азык-төлеккә йөрим, чүп түгәм. Әниебез бик күп татар халык әйтем-мәкальләрен күңелдән белә, сөйләшкәндә аларны бик оста һәм урынлы гына кыстырып та жибәрә, шуның белән әтине чиксез шатландыра иде. Әти ул мәкаль-әйтемнәрне аерым бер блокнотка язып та бара, берәр вакыт китап итеп чыгарырга җыена иде. Кызганыч, өлгерә алмый калды...

Әнинең фамилиясе — Казакованың кайдан килеп чыкканын да тикшерергә өйрәнергә өлгерә алмый калды ул. Әнинең туганнары, ул үзе дә — барысы да зәңгәр күзле, сары чәчле иделәр. Татарча булмаган фамилия мине дә кызыксындыра иде. Казаковларның шәҗәрәсен төзегәндә, мин XVIII йөз урталарында яшәгән Метри бабама барып чыктым. Бу исем татарча булмаганлыктан, мин аптыраушта калдым. Сүз уңаенда әйтеп үтим, Казаковларның шәҗәрәсен мин Шиһап Мәрҗани әсәрләреннән эзләп тапкан идем. Күптән түгел Михаил Юхманың «Күнгеш — үлемсез кош» исемле повестеннан Мулланур Вахитовның әнисе Өммегөлсем Мостафа кызының да Казакова булганлыгын, аның әниемә туганнан-туган икәнлеген укып белдем. Алар бертуган Шакир һәм Мостафа Казаковларның кызлары икән ләбаса! Бу бертуганнар чыгышлары белән Шырдан дигән татар авылыннан булганнар. Әлеге китапта Казаковлар фамилиясе турында да кызыклы риваять бар.

Емельян Пугачевның бер көрәштәше Дмитрий Казаков, авыр яралы хәлендә, бер татар авылына килеп юлыга, татар гаиләсе аны яшереп саклый һәм дәвалый. Рәхмәт йөзеннән Дмитрий мөселман динен кабул итә, татар кызына өйләнә һәм татарлар арасында төпләнеп кала. Аның яшәгән еллары нәкъ менә Пугачев хәрәкәте вакытына туры килә, бәлки ул Ишбүләк дигән татарның уллыкка алган малае Метри булгандыр. Шиһап Мәрҗани төзегән шәҗәрәдә Казаковлар түбәндәге тәртиптә бирелә: Ишбүләк — Метри — Габделкәрим — Назирмөхәммәтҗан — Шакир һәм Мостафа.

Әни үзе исә Казаков фамилиясе «качак» сүзеннән килеп чыккан дип аңлата иде.

Менә шундый тарих...

Акчаны бер әти генә эшләп тапканлыктан, өйдә һичнинди артык байлык юк иде. Без ике малайга киемнәрне дә әти-әнидән калган әйберләрдән тегеп бирәләр иде. Миңа беренче яңа костюмны бары тик 1936 елны гына, каникулым вакытында Махачкалада Дагстан дәүләт музеенда эшләп алган акчама тектереп алган идек.

Хәер, безнең гаиләдә матди байлыкка кызыгу дигән нәрсә юк та иде ул. Бар булганы — әтинең бай китапханәсе, әмма ул да рухи байлык чыганагы гына.

Әтинең хәтере бик яхшы иде. Ул барлык урыс патшаларының исемнәрен, кайсы елларда патшалык иткәннәрен белә. Мин берәр шигырьне күңелдән укырга өйрәнгәндә авырлык кичерсәм: «Кешенең хәтере — үз кулында, тырышырга гына кирәк»,— дияр иде. Үзе, хәтерен ничек күнектергәнен раслап, миңа төрле китаплардан төрле телләрдә әллә ни кадәрле өзекләр һәм шигырьләрне күңелдән сөйләп күрсәтә иде.

Урыс язучыларыннан ул А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, И. С. Тургеневларның әсәрләрен ярата. Бигрәк тә И. С. Тургеневка гашыйк, аның теленең музыкальлегенә соклана иде. Бервакыт ул миңа Тургеневның «Жизнь торжествующей любви» («Тантана итүче мәхәббәт тормышы») дигән повестеннан теләсә кайсы җөмләне ачып укырга кушты. Мин укып биргәч, яттан бер бит чамасын сөйләде дә чыкты. «Бу әсәр ак шигырь белән язылган шикелле, мин аны яшьтән үк яратып укыдым, үзем дә сизмәстән күңелемә сеңдердем»,— диде ул.

Татар язучыларыннан Гаяз Исхакыйны бик югары бәяли, аның кайбер әсәрләрен даһи әсәрләр дип исәпли иде.

1930 ел ахырыннан әти СССР Фәннәр Академиясенең Әзербайҗан филиалында эшли башлады. Шул чорда язган хезмәтләренең миңа билгеле булган кайберләрен генә китерәм: «Кыпчаклар тарихы», «Үзбәкләр тарихы», «Идел буе татарларның социаль үсеш этаплары», «Гаспринский һәм Дарданель мәсьәләсе», «Шәрекъта модернизм», «Иранда феодализм», «Мәккәдә Беренче антиимпериалистик корылтай», «Яңа мәгълүматлар буенча Мисырда милли-азатлык хәрәкә-

те», «1906 һәм 1917 елларда Россиядәге мөселман корылтайларында көрәш», «Аббасидлар — икенче гарәп-мөселман династиясе» һ. б., һ. б.

Бу хезмәтләр басылып чыкмадылар, аларның бер өлеше Әзербайжан Фәннәр Академиясенең тарих институты архивында сакланып калган, ә күбесе НКВД подвалларында череп югалган.

Кызганыч ки, утызынчы еллар башыннан НКВД дигән коточкыч куркыныч нәрсә безнең тормышыбызга да үтеп керде.

Шулай бервакыт безнең гаиләдә нииндидер яңа «дус» (инде исеме онытылган) пәйда булды. Ул еш кына безгә килеп, әти белән гәпләшеп, чәй эчәргә ярата иде. Ул үзе татар иде, НКВД киеменнән, якасында икеме-өчме шпаллары да бар. Әти-әниләр аны үзара «агент» дип йөрттеләр. Үзен ягымлы-кунакчыл гына каршы алалар, әйбәтләп сыйлап озатып калалар, кем икәнен белгәнлекләрен яшерәләр. Аңардан курыкмыйлар иде, чөнки бездә бернинди куркырлык, тыелган эш-гамәл юк дип саныйлар. Әти эшли, эшләре-хезмәтләре — күз алдында. Без укыйбыз, әни өйдә мәшгуль. Әйе шул, бездә шикләнерлек бер нәрсә дә юк, дигән ышаныч белән яши идек. Әти хәтта кайвакыт: «Әйдә, килеп йөри бирсен ул «агент», бәлки шулай яхшырактыр да әле»,— дип әйткәли торган иде. И беркатлы, тәҗрибәсез әткәм...

Без бу «агент»ка шулкадәр күнектек ки, ул кинәт кенә бер айлап югалып торгач, хәтта күңелсезләнә дә башлаган идек шикелле. Ул Әзербайжанга көньяк чикләр аша үтеп кергән нииндидер «имам» белән көрәшкә җибәрелгән булган икән. Соңыннан ул инглиз разведкасы тарафыннан безгә кертелгән «имам»ның колхозлашуга каршы крестьяннарны туплап, аларны коралландырып, совет властена каршы бунт күтәргәнлеген сөйләде. Шул чорда Бакуга да нииндидер кораллы төркемнең болайга таба хәрәкәт итүе турында хәбәрләр ишетелгәли башлаган иде. Безнең «агент» үзенең подразделениесе белән Нух шәһәрендә әлеге баш күтәрүчеләргә каршы ике тәүлек буе сугышкан, әле ярый Буденный атлылары килеп җитеп, боларны коткарган. Юкса, бетәселәр икән...

Гаиләбез өстендә болытлар куерганнан-куера бара, әтине НКВДга чакыртып тинтерәтә башладылар. Ул аннан бик борчылып, йолкынып-талкынып кайта иде. Кайткач елый, башы авырта. Әни аңа йөрәк дарулары бирә, башына юеш тастымал куя, тынычландырырга тырыша, үзе дә шыпырт кына елый иде. Без икесен дә бик кызгана идек, шомлана идек.

Еш кабатлана башлаган бу чакырып тинтерәтүләрдән түземлекләре текәнгән әти белән әни Бакудан күчеп китү турында сөйләшә башладылар. Әмма кая китәргә?

Мөмкинлекләр, бер караганда, шактый шикелле иде: әтине илнең байтак шәһәрләрендәге югары уку йортларына чакырып торалар. Шулай да якынрак китәргә карар кылынды — Пятигорскига, анда Кабарда-балкар педагогия институтында әтигә тарих кафедрасын җитәкләүне тәкъдим итәләр иде.

Шулай итеп, 1933 елның икенче яртысында әти Пятигорскига китеп барды. Уку елы тәмамлангач, мин дә аның янына күчтем. Без әти белән шәһәр үзәгендәге кунакханәдә яшәдек. Кичләрен шәһәргә йөрергә чыга идек. Әмма әтине бу матур шәһәр дә, салкынча рәхәт һава да, яшеллеккә төренгән бакчаларның хуш исләре дә шатландырмый. Аңа башлаган фәнни-тикшеренү эшләрен Бакуда тәгәлләп, аннары Ленинградка күчәргә — бай китапханәләрдә, архивларда казынырга мөмкинлек ачылырга гына торганда, бирегә килеп утыру бик үкенечле иде. Хәзер уйлап куям: баш очында җәллад балтасы тора, ә ул әле һаман да фәнни эшләре турында хыяллана...

Ул арада мин Кабарда-балкар педагогия институтының биология факультетына укырга кердем.

1933 елның җәй ахырына бөтен гаиләбез бергә иде инде. Әйбәт кенә фатир да биргәннәр иде. Ләкин азмы-күпме тынычлап без бары тик ярты ел чамасы гына яшәп калдык. Янә Бакудагы хәл кабатланды: әтине «тегендә» чакыртулар, күз яшьләре, аптыраган бер гаҗизлек, бу котылгысыз бәладән чыгу юлын таба алмау... Нәрсә эшләргә соң, нәрсә эшләргә? Янә качаргамы? Кая?

Бу юлы без Казанга кайтырга уйладык. Әтине анда күптәнге дусты, югары урында утыручы түрә Рәхмәтуллин чакыра иде. Миндә Казандагы Марксизм-ленинизм фәнни-тикшеренү институтыннан әтигә килгән рәсми хат саклана. Хатта «Профессор Г. Гобәйдуллин Татарстан тарихы буенча җаваплы эшләр башкару өчен чакырыла» дигән юллар бар.

Ярар, 1934 ел ахырларында тәялеп Казанга кайттык. Шәһәр үзәгеннән тиз генә өч бүлмәле фатир да бирделәр. Мин Казан дәүләт университетының икенче курсында укый башладым, энем — мәктәптә. Әти әлеге фәнни-тикшеренү институтында «Чит ил кешеләренең Татарстан турындагы фикерләре» дигән ике томлы китап әзерләү белән мәшгуль, шул ук вакытта педагогия институтында лекцияләр дә укый. Яшибез болай булгач! Шатлыгыбызның чиге юк: туган җиребезгә кайттык бит, үз Казаныбызга, дуслар-туганнарыбыз янына!

Әмма... кара сакалың, кая барсаң да, үзеңнән калмас, дип белми әйтмәгәннәр шул. Яңадан Бакудагы, Пятигорскидагы хәлләр кабатлана башлады. Яңадан безнең кояш сүнде... Каһәрле тоталитар режим әти белән мәче-тычкан уены гына уйнаганын, уйнап туйгач та гомерен өзәчәген без аңлый алмаганбыз икән шул...

Әти шәһәрдән-шәһәргә күчеп йөреп кенә бу афәттән котылып булмасын, бөтен ил буенча шундый «уен» башланганын, ниһаять, аңлаган иде шикелле.

Казанда бер генә ел яшәп, без янә Бакуга киттек. Анда бит әтине беләләр, анда — дус-ишләре, шәкертләре-укучылары...

Ләкин биредә дә хәл көннән-көн катлаулана бара иде. «Фәләнне алганнар икән, төгәнне алганнар икән»,— дигән чыштын-пыштын шомлы хәбәрләр йөри башлады. Кешеләр бер-берләренә ышанычларын югалттылар, элекке шикелле аралашулар-кунакка йөрешүләр бетте.

Әти кайберәүләрнең, илдә халык дошманнары күбәйде, шулар аркасында шушындый киеренке хәл туды, дип, бик беркатлы фикер йөртүләренә ышанмый иде. Тарихчы галим буларак, ул ни өчен Ленинның көрәштәшләре юк ителүенә, ни өчен сәнәгать һәм авыл хуҗалыгында ясалма корткычлыклар эшләнгәненә, ни өчен иң сәләтле-белемле зыялыларга каршы террор һәм көрәш ачылганына дөрес һәм аек бәя бирер, нәтиҗә ясар дәрәҗәгә житкән иде инде.

Ниһаять, каһәрле 1937 ел...

Бакуда танылган язучыларны, галимнәрне, партия эшлеклеләрен, карт большевикларны күпләп кулга алулар башланды. Әти көн саен яңа исемнәр ишетеп кайта торган булды.

Бервакыт ул бик моңсу халәттә мине үзе каршына утыртты да сүз башлады:

— Сәлман улым, ирләрчә сөйләшик әле,— диде.— Тиздән мине дә алачаклар. Бүген булмаса, иртәгә... Сиңа минем хакта ни генә сөйләсәләр дә, мине ничек кенә гаепләсәләр дә, син шуны бел: минем халык һәм ил алдында кәррә тамчы гаебем юк. Намусым саф һәм мин бер нәрсәдән дә курыкмыйм. Үзегез күреп тордыгыз: гомерем буе эшләдем, яшьләрне укыттым, китаплар яздым. Халык иртәме-соңмы аңлар, тиешле бәясен бирер. Дөреслек барыбер җиңеп чыгар! Сталинның үлемен генә көтәргә кирәк...— диде ул пышылдауга күчеп.— Җәмгыять демократик үсеш юлына басар. Син ышан һәм көт. Әниеңне дә алулары мөмкин. Син үзеңне сакларга тырыш. Яхшы укы! Энең Микаил да синең кулга кала. Мин сиңа ышанам, улым! Борчылма, сиңа кагылмасыннар өчен мин нык тырышачакмын. Китапханәмне Баку университетына тапшырырсың...

Бу — әтиемнең миңа васыять сүзләре иде...

Озакламый «Бакинский рабочий» һәм «Коммунист» газеталарында Әзербайҗан Компартиясенең Үзәк Комитеты беренче секретаре, соңыннан үз халкы тарафыннан каһәрләнеп, яманаты чыккан Миржафар Багировның мәкаләсе дөнья күрде. Ул «безнең фәнгә буржуаз элементлар үтеп кергән... халык дошманнары... профессорлар Гобәйдуллин һәм Чобанадзе...» дип гаеп ташлаган иде.

Әтине кулга алу өчен бу сүзләр алып ашкан иде инде.

1937 елның 18 мартында төнлә ишекне бик каты дөбердәтә башладылар. Әти: «Алырга килделәр...» — диде. НКВД киеменнән берничә кеше килеп керде. Әтигә китап шкафларын, өстәл тартмаларын ачарга куштылар. Башлыклары булса кирәк, берсе ике ярдәмчесенә китап шкафларын тикшерергә боерды, үзе өстәл тартмаларындагы кәгазьләрдә актарынырга тотынды, калганнары башка бүлмәләргә таралдылар. Тентү таңгача дәвам итте. Китапларны шкафлардан алалар да битләрен селки-селки актаралар, аннары идәнгә тотып ыргыталар. Тиздән идәндә бер тау өеме китап хасил булды. Тентү вакытында әти үзен тыныч тотты, үз хезмәтләре турында тулы-төгәл аңлатмалар биреп торды. Күрәсең, ул үзен ныклап әзерләгән иде инде. Өстәл тартмаларыннан, тумбочкалардан алынган кулъязмаларны битләп актарган булалар да, битләрен буташтырып, йә китаплар өеменә ыргыталар, йә үзләре алып килгән бишпотлы арыш капчыгына тутыралар. Әти берничә мәртәбә капчыкка рәтләбрәк салуларын үтенеп карады. Әмма — файдасыз... Башка бүлмәләрдә сандыклардагы әйберләрдә актарындылар. Күз яшьләренә буылган әни әтинең эш кабинетына керсә, аны куып чыгара тордылар. Кулъязмалар, китаплар, башка әйберләр тутырылган капчыкларны

алып чыга башладылар. Башлыклары әтигә үзләре белән барырга боерды. Әни әтинең кирәк-яракларын әзерләп куйган булган икән. Әти өстенә киде, бүреген башына батырды. Барыбыз да аның белән хушлаштык. Әни елый иде. Әтине алып чыгып киттеләр. Безгә озата чыкмаска куштылар. Берничә минуттан машина кабызганнарын һәм китеп барганнарын ишеттек.

Бүлмәләрнең асты-өскә китерелгән, аяк басар урын да юк иде. Бу тентүдән миндә жирәнгеч бер мыскыл ителү, көчсезлек хисе калды. Хәзер искә төшергәндә дә бөтен тәнем буйлап калтырану йөгереп үтә...

Әтине кулга алганнан соң йорт җиһазларын һәм азмы-күпме кыйммәте булган башка әйберләребезне конфискацияләп алып киттеләр. Сандыкларга сургуч мөһер салып калдырдылар, янәсе, рөхсәтсез ачмаска! Китапларның исән калганнарын мин, әти кушканча, университет китапханәсенә илтеп тапшырдым.

Озакламый бездән фатирны да бушатуыбызны сорадылар. Сүз уңаеннан, әтине алып китеп, әйберләребезне конфискацияләгәннән соң, ул яңгырап торган шыксыз буш бүлмәләрдә өчебез генә яшәү әллә ничек җан өшеткеч иде. Ә шулай да, без кая барырга тиеш соң? Алмаш фатир тәкъдим итмәделәр. Хосусый фатирга керергә — акчабыз юк. Алай да танышларыбыз безгә шәһәр читеннән бер фатир табарга булыштылар. Фатир дигәнебез икенче катның пыялаланган верандасы иде. Гомуми мәйданы сигез-ун квадрат метр чамасы булган веранда ике бүлемгә бүленгән. Алгы якта әни кухня әмәлләде, эчке якта үзебез урнаштык. Фатир хакын алдан түләр өчен, мөһер салып киткән сандыкларыбызның берсен ачып, әнинең туй бирнәсеннән калган борынгы ике чәй сервизын сатарга туры килде. Шулай итеп, яңа шартларда яши башладык. Без укыйбыз, әни ничек кирәк алай хуҗалык алып бара. Әмма монда да тыныч яшәргә язмаган икән.

Иң әүвәл мине комсомолдан чыгарып ыргыттылар. Берничә көннән соң университетның соңгы курсыннан да кудылар. Тормыш итәргә кирәк бит. Эшкә урнашу мәсьәләсе килеп басты. Яраткан укытучым академик А. А. Гроссгейм ярдәм итмәкче булды. Ул СССР Фәннәр Академиясе Әзербайҗан филиалының ботаник бакчасы җитәкчесе иде. Лаборантлыкка алуларын сорап гариза язарга кушты. Өметем зурдан иде, академик кадәр академикка каршы килмәсләрдер, шәт, дип уйладым. Әмма кадрлар бүлегеннән документларымны кире кайтардылар: «Ала алмыйбыз»,— диделәр. Кайда гына барып төртелмим — эш юк, имеш. Аннары миңа аңлаттылар: «халык дошманы улы» буларак, мин СССР гражданлыгыннан да мәхрүм ителгәнмен икән. Миңа республика прокуратурасына, гражданлыгымны кайтаруларын сорап, гариза язарга киңәш иттеләр.

Ул да булмады — яңа кайгы. 1937 елның караңгы октябрь төннәренең берсендә НКВДдан килеп, әнине дә алып киттеләр... Бәлки, ул төн әтине аткан төн үк булгандыр әле...

Әниемнең чәчләре аксыл-сары иде, күзләре зәңгәр, йөзе ягымлы, ул әкрен-тыныч тавыш белән йомшак кына сөйләшә, бервакытта да тавышын күтәрмәс, каты сүзләр әйтмәс иде. Ул безгә ягымлы әни, әтигә тугрылыклы, сөекле хатын, гаилә җылысын саклап торучы әйбәт хуҗабикә булды. Лагерь тормышы да, исән-сау кайтып, лагерьдан соң каңгырап йөрүләр дә аны усалландырмады, күңелен катырмады, ул тагын да яклаучысыздрак-ярдәмчесезрәк иде — еш елый торган булып китте.

Кайвакытларда ул истәлекләргә бирелә, төрмә һәм лагерь тормышының төрле вакыйгаларын сөйли иде.

Бер шулай Баку төрмәсендә хөкем көтеп ятканда, «халык дошманнары»ның хатыннары, апа-сеңелләре белән шыплап тутырылган камераларга кинәт кенә каяндыр балалар тавышы ишетелә башлый. Хәбәр тарала: кулга алынганнарның балаларын җыеп төрмәгә китергәннәр икән. Шуннан мәхшәр башлана: аналар үкереп елыйлар, камера ишекләрен дөбердәтәләр-төяләр, ялан кул белән нарларны каерып-сүтеп ыргыталар, бүрәнәләр-такталар белән ишекләрне бәреп ватарга азапланалар. Бөтен төрмә дер селкенә-гүли, бәхетсез хатын-кызларның йөрәк өзгеч әче тавышларыннан, дөбердәтү-шакылдатулардан төрмә менә-менә җимерелеп төшәр кебек тоела. Аналар: «Безне теләсә нишләтегез, балаларыбызга гына тимәгез!» — дип кычкыралар, үксиләр. Күрәсең, төрмә башлыклары да чынлап шүрләп калгандыр, «өскә» хәбәр итәләр. «Өстә» дә арттырып җибәргәнлекләрен аңлаганнар, ахрысы: балаларны өйләренә тараталар, аналарны көч-хәл белән тынычландыралар. «Болардан баш-аяк, тизрәк котылырга кирәк»,— дип-тер, озакламый хатын-кызларга «комиссия»нең хөкем карарын җиткерәләр: кемгә биш ел, кемгә җиде ел лагерь... Һәм эшелоннарга төяп, Казакъстан далаларына — Карлагка (Караганда лагеры дигән сүз) илтеп аударалар. Лагерьның исеме

бар, жисеме юк икән әле. Ачык далада хатын-кызлар үзләренә-үзләре чәнечкеле тимерчыбыклардан киртә коралар, бараклар салалар — «самообслуживание»!

Шул Караганда лагеренда әни белән бергә Тухачевскийның кыз туганнары, Енукидзеның хатыны һәм кызы да утыра. Енукидзеныкылар бөтенләй бетәшкән, шешенгәннәр, үзләре әле көтүче булып көтү көтеп йөриләр. Озакламый икесе дә шунда җан бирә...

Безнең әни дә хәлсез, аның йөрәге авырта, аны, шуңа күрәдер инде, баракта мич ягучы һәм тоткыннарга бияләй бәйләүче итеп куялар. Башка хатын-кызлар һәр иртәдә таш базларыннан таш чыгарырга китәләр, кичләрен арып-талып, чарасызлыктан гаҗиз-өметсез булып, дәшми-тынмый гына кайтып керәләр, йөзләрен соры таш тузаны баскан була.

Әнинең бәхетенә, аның белән бергә шул ук лагерьда өлкән апасы Зөләйханың кызы, Гали Рәхимнең хатыны Гайшә апа да була. Ул лагерь хастаханәсендә табибә булып эшли. Әнине авыр эшләрдән коткарып калучы да ул булгандыр, мөгаен.

Гайшә апа, исән-сау котылып кайткач, соңыннан безгә сөйләгән бер вакыйганы һич оныта алмыйм.

Мәскәү тирәләрендәге бер шәһәрдә бик әйбәт хирург эшләгән, аның кул астында бик тырыш һәм тәҗрибәле шәфкать туташы Валя да эшли икән. Хирург аңа нык ышана, барлык катлаулы операцияләрне бергәләп ясыйлар болар. Икенче бер ялкаурак та, сәләтсез дә шәфкать туташы Валядан бик көнләшә икән. Менә шул юньсез кыз үзенең йөргән милиционерына зарлана: хирург, житди операцияләр булганда, гел Валя белән генә эшли, мине якын да җибәрми, ди. Милиционер егет кызга киңәш бирә: син «Валя — акгвардияче хатыны» дип донос яз, ә мин аны хутка җибәрермен, ди. Шулай итәләр дә. Валя мескен, кияүгә дә чыкмаган яшь кыз, шушы лагерьга килеп эләгә. Ул Гайшә апа белән бергә лагерь хастаханәсендә эшли. Валяны азат иттерергә бик тырышалар: ул берничек тә акгвардияче хатыны була алмый, унсигез-егерменче елларда аңа әле нибары 8—10 яшь кенә булган, аннары — кыз кеше, гыйффәтле, дип шикаять-үтенечләр язалар. Әмма — нәтиҗәсез...

Валяны алты елдан соң гына азат итәләр.

Әниебез исә биш елдан котыла бу җәһәннәмнән. Аңа менә мондый белешмә биреп чыгаралар (тәрҗемәдә китерелә):

**Белешмә № 257159**

*Бирелә 1893 елны туган гражданка Гобәйдуллина Рабига Шакир кызына. Туган урыны — Әстерхан шәһәре. Электән хөкем ителгәнлеге хакында мәгълүмат юк.*

*СССР НКВДсы каршындагы Аерым Киңәшмә тарафыннан 1937 елның 28 декабрендә, Җинаять Кодексының фәлән статьясы нигезендә (статьясы күрсәтелмәгән. С. Г.), Ватан хыянәтчесенең хатыны буларак, Хезмәт белән Төзәтү Лагерына 5 елга хөкем ителгән (хөкем срогы шул елның 15 октябреннән исәпләнә), җәза срогын тутыргач, НКВДның Караганда Хезмәт белән Төзәтү Лагерыннан 1942 елның 15 октябрендә азат ителүе хакында белдерелә.*

*Казакъыстан ССРның Акмулла өлкәсе Молотов районына җибәрелә.*

*Белешмә тору таныклыгы булып файдаланыла алмый.*

*Югалткан очракта кабат бирелми.*

*НКВД Карлагы Идарәсе Начальнигы — Имза.*
*Исәпләү-Бүлү Бүлеге Начальнигы — Имза.*

Кем әйтмешли, менә шундый «филькина грамота»...

Ире, балалары турында да бер сүз юк...

Белешмәнең санына игътибар итегез: ике йөз илле җиде мең бер йөз илле тугызынчы! Димәк, бер Карлаг «тегермәнендә» генә дә чама белән күпме кеше «тартылган»!

Бу белешмә белән беркая да эшкә алмыйлар, ә яшәргә кирәк. Әнине күп балалы бер казакъ гаиләсе, йорт эшләрендә ярдәмче булырсың дип, үзләренә сыендыра. Иксез-чиксез далада, киез тирмәдә яшиләр. Айлы төннәрдә әни еш кына чыгып, Аллага ялвара-ялвара, балаларым белән иремне сакла дип, кайгысагышына төелеп елый. Казакъ гаиләсе бик ярлы була, ачлы-туклы яшиләр, әни төннәрен кыр-басуга барып, калган бодай башакларын җыеп кайта, уып, шуннан ботка пешерә. Аның бавыры шешә, йөрәгенең дә рәте юк... Балалары, ире турында нәрсә уйларга да белми...

Шулай ике ел үтә.

1944 елның ахырында әниебез Юдино поселогына кайта, Казанның үзендә яшәргә аңа рөхсәт ителми. Кача-поса Казанга килеп, апасыннан белешә: уллары исән, икесе дә фронтта икән, ә менә ире турында хәбәр-хәтер юк. Апасы әнигә хәл кадәре булыша, ашата-эчертә, иске киемнәрен бирә.

1957 елны, әтине аклаганнан соң гына, әниебезгә айга 700 сум күләмендә академик пенсия билгеләделәр. Шул вакыттагы акча белән бер идән юучының хезмәт хакы иде бу. Әниебез 1966 елны Баку шәһәрендә вафат булды. 73 яшендә. Иреннән калып 29 ел иза чиккәч...



*Г. Гобәйдуллинның хатыны Рабига ханым уллары Сәлман (сулда) һәм Микаил (уңда) белән. 1953 ел.*

Ә без ике бертуган егетләрнең язмышы болайрак булды.

Әниебезне кулга алгач, без япа-ялгыз калдык. Бердәнбер өметебез әтинең энесе Кадыйр абзыйда иде. Әмма аны да 1938 елның апрелендә Махачкалада кулга алалар, ул анда Дагстан музеенда фәнни хезмәткәр булып эшли иде. Ул да — «халык дошманы»... Бирелгән белешмәсенә караганда, ул 1944 елның 11 маенда төрмәдә вафат була. Монысы шиклерәк, әлбәттә, аны аткан булулары да бик мөмкин. Аклануы — 1957 елның 24 декабрендә.

Шулай... Без абыйлы-энеле икәү утырып калдык. Мин — СССР гражданы түгел, энем әле балигъ булып житмәгән — мәктәп баласы. Ничек мине дә кулга алмаганнар, утыртып куймаганнар?.. Әле дә исем китә. Хәзер безгә ни хәлләр итеп яшәмәк кирәк?! Аптырагач, мин, НКВД сургуч мөһер сугып киткән сандыгыбызны ачып, иске костюм-чалбарларны, аяк киемнәрен һ. б. чыгарып сата башладым. Бәхеткә, «барахолка» янибызда гына иде. Ләкин тиздән сатар әйберләр дә бетте. Үзем көн саен прокуратурага барып, гражданлык хокукларымны кайтармаганнармы дип, белешеп торам. Инде ярты елдан артык вакыт узды, бер төрле дә җавап юк. Соңгы әйберләр сатылып бетеп, акчасы да төкәнгәч, мин тәвәккәлләп Сталинның үзенә хат яздым: йә безне энем белән бергә төрмәгә утыртыгыз, йә гражданлык хокукларымны кайтарыгыз — эшләп яшәрлек мөмкинлек булыр иде, дигәнрәк эчтәлекле хат иде ул. Нишләтерләр? Килеп алып китәрләрме? Әллә берәр җавап килерме? Көтәм... Бер ун көннән Мәскәүдән җавап килеп төште: «Сезнең эшегез карап тикшерү өчен республика Хөкүмәт комиссиясе карамагына җибәрелде. Чакыру көтегез,» — диелгән иде. Чынлап та, тиздән Хөкүмәт комиссиясеннән чакыру кәгазе алдым. Күрсәтелгән вакытка, җыенып, үземчә кирәге чыгардай документларымны барлап, киттем мин. Коридорда сүзсез-нисез генә кешеләр утыра, башларын иеп, үз язмышлары хәл

ителәсе минутларны көтәләр. Мин дә алар янына барып утырдым. Һәр кешене чират буенча дәшеп-чакырып алалар, кемнәрдер шатланып чыга, күбесе кайгы-хәсрәт белән... Менә мине дә чакырдылар. Галәмәт зур залда озын өстәл тирәли бер уникe кеше утырышкан, алар арасында берсе — рабфакта мине укыткан, ә хәзер Әзербайҗан Мәгариф наркомы урынбасары Аллаһвердиев, икенчесе — университетта безнең факультет деканы Касумов. Калганнарын танымыйм. Минем анкетамны укыдылар, аннары Касумовка сүз бирделәр. Исем-акылым китте: Касумов мине яманлап сөйли башлады. Имеш, мин начар укыганмын, имеш, җәмәгать эшләрендә катнашмаганмын, имеш, яңадан укырга алган очракта да, мин курсташларымны куып җитә алмаячакмын... Аннары тагын кемнәрдер нәрсәләрдер сөйләде, әмма мин инде, Касумовның кычкыртып ялганлавыннан соң, бернәрсә дә ишетмәдем-аңламадым. Ниһаять, һушыма килеп, сүз бирүләрен сорадым. Ләкин миңа: «Сорауларга гына җавап бирергә хакың бар,» — диделәр. Мин кесәмнән зачеткамны алдым да, аны Аллаһвердиевка суздым. Ул аны актарып карый башлады, аннары комиссия әгъзаларының башкаларына җибәрде. Зачеткамда гел «отлично» билгеләре генә иде. Касумовның җен ачуы чыкты: «Син кагыйдәне бозгансың. Нигә зачетканны университет канцеляриясенә тапшырмадың?» — дип җикеренә башлады. Мин аңа: «Декан кеше Хөкүмәт комиссиясе алдында ялган сөйләргә тиешме?» — дип җавап кайтардым. Шул сүзләремнән соң мине коридорга куып диярлек чыгардылар: «Аллаһвердиев сүз алды: «Бу егетне рабфактан бирле беләм, ул анда да гел отличник булды, хәзер дә шулай икән. Әгәр комиссия, курсташларын куып җитмәс, дип шикләнсә, җаваплылыкны үз өстемә алам,» — диде. Ул заманнар өчен бик тәвәккәл адым иде бу. Мин ул кешегә гомерем буе рәхмәтлемен.

Комиссия карары белән миңа СССР гражданы хокукларымны һәм Әзербайҗан дәүләт университетының биологик факультетында бишенче курс студенты хокукымны да кайтардылар.

Курсташларым мине җылы кабул итте, укуда гына түгел, авыр тормышымда да ярдәм итәргә тырыштылар. Бигрәк тә курсташ кызым Елизавета Кульпина ярдәмчел иде, соңыннан ул минем хатыным һәм бердәнбер улым Әдипнең әнисе булды. Барлык доцентлар, профессорлар диярлек ярдәмнәреннән ташламадылар, күбесе әтиемнең танышлары, аны хөрмәт итүчеләр иде бит. Алай да миңа булган яхшы мөгамәләләрен бик сиздерергә тырышмыйлар үзләре. Озакламый курсташларымны куып җиттем, алар белән бергә дәүләт имтиханнары тапшыра башладым. Әмма ачлык-ялангачлык, соңгы елдагы кичерешләр, артык тырышып көн-төн уку мине бик нык йончыткан икән, үземне хәлсез сизә башладым. Тикшертеп карасам, үпкәмдә туберкулез таптылар. Укуны кичекмәстән өзәргә, калган ике имтиханымны чигереп торырга һәм берәр курортка дәваланырга китәргә киңәш иттеләр. Университет профкомы акча табып, бер санаторийга юллама да алып бирде һәм мин җәй буе дәваланырга китеп тә бардым.

1939 елның көзендә, дәваланып кайткач, мин Закводпроиз дигән оешманың проект институтында туфракларны тикшерү бүлеге җитәкчесе Владимир Родионович Волобуевка мине эшкә алуын сорап мөрәҗәгать иттем. Ул мине туфраклар белгече итеп эшкә алды. Булачак академик В. Р. Волобуев, әйтергә кирәк, минем тормышымда зур таяныч булды, эшкә дә алды, һәртөрле ярдәменнән дә ташламады, ә бәлки, кулга алынудан да саклап калгандыр әле. Аңа тирән рәхмәтлемен!

В. Р. Волобуев җитәкчелегендә мин туфраклар белгече булып киттем, гомерем буе фәнни тикшеренүләремне туфракларны эрозиядән һәм тозланудан саклау, аларны савыктыру өлкәсенә багышладым.

Калган ике имтиханымны 1940 елны уңышлы тапшырып, мин, ниһаять, биолог белгечлеге буенча Әзербайҗан дәүләт университетының дипломын алуга ирештем.

Бөек Ватан сугышы башлану хәбәрен без Төркия чигендә, Әрмәнстан тауларында туфраклар өйрәнеп йөргәндә ишеттек. Кыр эшләрен тәмамлап, 1941 елның 22 июнь кичендә экспедиция машиналарына төялеп, үзебезнең базага кайтырга чыктык. Авыл малайлары безне «сугыш! сугыш!» дигән яман хәбәр кычкырып каршы алдылар.

Экспедициябездә нигездә яшь ир-егетләр булганлыктан, без барыбыз да призывниклар, сугыш кәсафәте булган очракта, беренче сәгатьләрдә үк якындагы военкоматка барырга тиешле идек. Бер машинага төялеп район үзәге Аштаракка юнәлдек. Анда безгә үз хәлебезне Ереванга барып ачыкларга киңәш бирделәр. Киттек Ереванга. Юл тулы арбаларына хатыннарын, бала-чагаларын, йорт

кирәк-яракларын төягән, җәяүләтеп мал-туар куучы халык иде. Чик буе авылларында яшәүчеләр шулай Әрмәнстанның эчкәрге районнарына күченәләр икән.

Ереван военкоматы безне Бакуга кайтарып җибәрде. Бакуда исә: «Чакыру көтегез!» — дип әйттеләр. Минем башым тулы борчулы уйлар. Хатыным кала, әле икенче яше генә киткән улым кала, унҗиде яше дә тулмаган энем Микаил кала. Әти-әниләрем исәнме? Исән булсалар, алар кайларда? Аларны газаплыйлардыр инде...

Микаилны хатынымның әти-әниләренә урнаштырдым. Сугыш башлангач, ул Баку заводларының берсенә эшкә кергән иде инде.

Мине сугышка бары тик 1942 елның гыйнварында гына алдылар. Бу минем өчен кételгән шатлык булды. Чөнки, алмаслар, «халык дошманы улы» итеп карарлар, ышанмаслар, дип борчылган идем. Алдылар, ышандылар! Шатлана-шатлана ут эченә китеп бардым...

Кичке якта безне, эшелонга төяп, кая барасыбызны дә әйтмәстән, Бакудан алып чыгып киттеләр. Вагоннар икешәр кат нарлы, уртада — тимер мич «буржуйка», утыны да бар. Мичне ягып җибәрдек. Танышу-сөйләшүләр китте. Ут эченә — фронтка барабыз бит: кемнен кемлеген белешергә кирәк. Ачыктан-ачык, эчкерсез сөйләшә торгач, аңлаштык: без барыбыз да «халык дошманнары балалары» икән! Тиздән белдек — бөтен эшелонибыз шундый, имеш. Эчкә шом төште... Мәнә сиңа — «ышандылар!» Өйрәтелмәгән, хәрби кием дә бирелмәгән килеш кая алып баралар безне? Нишләтмәкчеләр?

Йөртә торгач, безне Керьчкә илтеп төшерделәр. Керчь бугазы каткан булса да, без чыгасы яр буе бер 100—200 метр чамасы әле катып җитмәгән иде. Аны йөзеп-җәяүләп чыктык. Кипшендек, ашап алдык. Безне алгы сызыкка илтеп, 51 нче армиянен укчы полкына куштылар, штыклы винтовкалар һәм берәр обойма патрон бирделәр. Аннары отделение, взвод, рота, батальоннарга бүлгәләделәр, командирлар билгеләделәр. Шунда ук хәрби ант кабул иттек. Аннары безне иң алгы окопларга җибәрделәр.

Рота командиры безнең бурычны болай аңлатты: һөҗүм булган очракта, батальон дошманга штык сугышына ташланырга тиеш.

Безгә күрсәтелгән «ышаныч» менә нинди икән! Автомат-пулеметлар белән коралланган фашистлар, безне, биш-ун метр үтәр-үтмәстән, чебен урынына кырып кына салачаклар бит. Бер дә болай мәгънәсезгә үләсем килми иде.

Бәхетле очрак чыкты.

Һөҗүм һаман кичектерелә килә, ара-тирә аткалаштырып торсалар да, әлегә тыныч иде.

Бер көнне безнең окопларга полк штабыннан бер командир килеп төште: штабка немец телен белүче тәрҗемәчеләр кирәк икән. Тел белүчеләр икәү булып чыктык: мин дә, тагын бер кызылармеец. Безне штабка алып китте әлеге командир. Шулай итеп, әтием өйрәнергә кушкан немец теле бик кирәк булып чыкты. Әтием мине тагын бер тапкыр үлем авызыннан тартып алгандай булды.

Полк штабында, минем югары белемле икәнлегемне дә белгәч, тәрҗемә эше өстенә штабның төрле эш кәгазьләрен язып бирүне дә сорыйлар, немецларның разведчиклар алып кайткан төрле документларын, хәрби карталарын да тәрҗемә иттереп укыталар иде. Озакламый мине Керьчкә кече командирлар курсына укырга җибәрделәр. Курслар начальнигы, югары белемле булуымны белгәч: «Сезгә монда укып, вакыт үткәреп торырга кирәкмәс. Сезне алгы сызыкта көтәләр. Хәрби уставны өйрәнегез. Өч көн срок», — дип кистереп куйды. Имтиханнар тапшырдым да, сержант дәрәҗәсе алып, алгы сызыкка китеп бардым.

Кырым тирәсендә безнең фронт хәлләре мөшкелләнгән чак булса да, мин шат идем — мин дә тулы хокуклы сугышчы, мин дә Ватанны яклап сугышам! Алай гына да түгел, әти-әнием намусын, үз намусымны яклап та сугышам! Командирларның боерыкларын тиз һәм җиренә җиткереп үтәргә тырышам. Тырышканымны күреп, мине берничә мәртәбә башта старшиналыкка, аннары офицер дәрәҗәсенә күтәрүне үтенеп «өскә» язып карадылар. 1943 елның 8 мартында язылган шундый кәгазьләрнең берсе миндә сакланып та калган. Часть командиры белән штаб начальнигы кул куйган ул кәгазьдә «административ хезмәт кече лейтенанты дигән дәрәҗәгә лаек» дип язылган. Әмма ул үтенечләр нәтиҗәсез кире борылып кайта тордылар. Сәбәбе — әлеге дә баягы «халык дошманы улы»...

1944 елның җәендә, безнең часть инде Днестр яры буена барып җиткәч, мине, алдынгы сугышчы буларак, партия әгъзалыгына кандидат итеп алу каралды. Рекомендацияләрне часть командиры белән бер офицер биргән иде. Партия

җыелышы 3 нче Украина фронтының 51 нче армия штабында, зур бер землянкада үткәрелде. Мин, әтием турында да яшерми-нитми, тәрҗемәи хәлемне сөйләдем. Сораулар күп булды. Минем белән бергә сержант Семен Черноморченконың да гаризасы каралды. Җыелыш икебезгә дә, партия әгъзалыгына кандидат итеп алырга, дип тавыш бирде. Безне котладылар, кандидатлык документлары өчен фотога төшерделәр. Шатлыгымның чиге юк иде. Ләкин бу юлы да иртә шатланган булып чыктым. Армиянең политбүлек командиры урынбасыры Бакуга минем хакта сорау җибәрәчәкләрен, аннан җавап килгәч кенә миңа кандидатлык карточкасы тапшырылачагын әйтте. Сержант С. Черноморченконы кабул иттеләр, ә мине — юк!

Шул рәвешле, мин офицер да, партия әгъзасы да була алмый калдым. Соңыннан моның өчен кайгырып та йөрмәдем. Мин намус белән, фидакарьләрчә сугыштым, күп үлемнәр күрдем, могҗиза белән генә исән калган чакларым булды. Әмма бер дә башка сугышчылардан ким-хур түгел идем. «Халык дошманы улы» дигән кара тамга миңа сугышырга артык комачауламады.

Биредә энем Микаил турында да бераз сөйләү кирәктер. Аны да 1942 елны сугышка алалар. Белмим, кемдер аңа киңәш иткәнме, әллә үз башы җиткәнме, ул армиягә заводтан «эшче улы» булып языла. Үзе хакында беркемгә дә, беркайчан да ачылып сөйләми. Махсус курслар тәмамлап, элемтәче сыйфатында фронтка озатыла, анда НКВД гаскәрләрендә (!) хезмәт итә, махсус хөкүмәт элемтәсен тәэмин итеп тора. Аңа берничә мәртәбә «Верховныйның», ягъни Сталинның, грузин акцентлы тавышын да ишетергә туры килә.

1944 елны Будапештны азат итү сугышларында Микаил каты яралана. Дәваланып, терелеп чыккач, сугыштан соң да әле ул өч елга якын армия хезмәтендә кала. Башта — Будапештта, аннары СССРда. Төньяк Кавказда Сталин дачасына махсус элемтә үткәрү эшендә катнаша. Армиядән кайткач, ул 10 сыйныфны, соңыннан Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Мәктәпләрдә география һәм немец теле укыта. Пенсиягә чыккач, Бакуда яши. (Микаил Гобәйдуллин 1995 елны фаҗигале рәвештә һәлак була. Ред.)

Үзенә пенсия юллау өчен әниебезгә әтинең үлеме турында белешмә кирәк булды. Мондый белешмәне Бөгелмә шәһәре ЗАГСы бирде. Әнинең Микаил гаиләсендә яшәгән вакыты иде. Ә Микаил Бөгелмә мәктәпләренең берсендә укыта иде.

Белешмәдә, Гобәйдуллин Газиз Салих улы 1938 елның 16 сентябрендә вафат булды, диелгән. Кайда үлүе һәм үлем сәбәбе күрсәтелмәгән иде. Нигә чын хакыйкатьне яшерергә кирәк булгандыр — әйтә алмыйм.

Бары тик 1988 елны: «Огонек» журналының 45 нче санында академик З. М. Буниятов белән булган әңгәмәне укыгач кына, без чын дөреслекне белдек. Ул 1937 елны атылган әзербайҗан галимнәре һәм язучылары арасында Г. Гобәйдуллин фамилиясен дә телгә ала.

Мин бу академикка шунда ук хат юлладым. Ул җавабында: «...мин әтиегезнең эше белән таныштым, аны укып чыктым, әтиегездән дә, башкалардан алган кебек, «өченче метод» ысулы белән сорау алганнар, ягъни аны җәзалаганнар, кыйнаганнар, шул рәвешле «гаебен танырга» мәҗбүр иткәннәр. Ул да, башкалар кебек, Хәрби коллегия тарафыннан хөкем ителгән, 20 минуттан хөкем карары чыгарыла: атарга. Ул үзе утырган бинаның подвалында, икенче көнне таң алдыннан, 1937 елның 13 октябрендә атып үтерелә.»

Әниебезне 1937 елның октябрендә «ватан хыянәтчесе хатыны» дип кулга алганда ук «тол калган хатыны» дип әйтергә кирәк булган икән... Без Микаил белән фронтка да, әтиебез исәндер, кайдадыр утырадыр, әгәр аның нинди дә гаебе булса, без аны каныбыз белән юарбыз, акларбыз, барысы өчен дә түләрбез, дигән өмет белән киткән идек бит.

Әниебез чын хакыйкатьне белмичә дөнья кичте...

Әтием Газиз Гобәйдуллинның тормыш юлын, юк, аның гына түгел, ул чордагы милли зыялыларның барысының да фаҗигале язмышларын күңелдән кичереп, мин аларга баш иям, аларны яд итәм: алар үз милләтләренең фәне һәм мәдәнияте өчен гомерләрен биргәннәр. Без аларны онытмаска, онытылганнарын халык хәтеренә кире кайтарырга бурычлыбыз.

Мин бу истәлекләремне яңа, яшь буыннарның йөрәкләрендә урын алсын өчен яздым. Әтием Газиз Гобәйдуллин иҗади-фәнни хезмәтендә бик бәхетле иде. Әйе, бәхетле иде минем мәңге онытылмас әтием...

*Мәскәү, 1989 ел.*

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әхсән Баян

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

«Казан утлары»нда чыгып килгән әдәби әсәрләрне, тәнкыйть мәкаләләрен күзәтеп барырга тырышам. Әлбәттә, төрлесе очрый. Яңалык тойгысы калдырганнары күренгәли. Әдәбиятны тулаем күздә тотып язылган мәкаләләр белән бергә, үтә дә тәбәнәк куначадан карап бәяләүләр күзгә ташлана. Шунсыз булмыйдыр, күрәсең. Бит әзерлекләр төрле, зәвыклар, ниятләр төрле. Кемнеңдер кемнәргәдер ярату хисен, ә кемнәргәдер тискәре ниятен белдерүенә гаҗәпләнмәскә туры килә. Шулай да кайбер үтә дә мөһим, принципиаль мәсьәләләргә карата субъектив бәяләр белән килешү дөрес булмас, чөнки бу киләчәк ялгышларга ярдәм итү кебек килеп чыгачак.

Әлеге мөһим мәсьәләләрнең берсе — әсәрләрнең жанрлар ягыннан төрлелеге һәм әдәби тәнкыйтьнең шул төрлелеккә игътибар итмәве. Күзәтүләр күрсәткәнчә, тикшерүгә алынган әсәрләрнең үзенчәлегенә, сәнгать дәрәҗәсенә, хәтта нинди жанрда иҗат ителүенә игътибар итмичә фикерләүләр бездә шактый нык гадәткә әйләнгән. Моның дәвамлы шаукым булуы аерымачык күренеп торганлыктан, хәлне ачыкларга тырышу шулай ук табигый омтылыштыр, дип беләм.

Тукайның «Баскыч» шигырендәге кебек, дөньяның аскы ягы өскә күтәрелгәч, күп нәрсәләргә, ә бигрәк тә фәнгә, сәнгатькә мөнәсәбәтләр капма-каршылык дәрәҗәсендә үзгәрде. Чорның афәтле җилләре әдәбиятка, бигрәк тә аның үткәненә, каты кагылды.

Бүгенге әдәбият үзе дә үзгәрә, яңа шартларга күнегергә тырыша сыман. Яңарыш, хәтта ярааклашу галәмәтләрен хәзер үк инде сизәргә, чамаларга мөмкин. Әмма бит классик әдәбият вәкилләре үз әсәрләрен бүгенге идеологиягә (бәлки идеологиясезлеккә) яраклаштыра, үзгәртә, «төзәтә» алырмыни?

Берничә ел элек әдәби тарихтан коммунист язучыларны төшереп калдыру шаукымы булып алган иде. Ул чакларда хәтта «татар әдәбиятында Галимҗан Ибраһимов дигән язучы юк», дип хөкем чыгаруга хәтле барып житүләр күзәтелде. Кайбер язучылар, тәнкыйтьчеләр гүяки сөенеч белән: «Такташ үлде!» — дип игълан итәргә ашыктылар.

Мондый атмосферада үз карашыңны булдыру өчен әдәби мирасны яңадан барларга, кабат укырга, өйрәнергә кирәк иде. Шундый ният белән мин дә күп әдипләр иҗатын яңадан карап чыктым. Бүгенге таләпләрдән чыгып карагач, бая телгә алынган инкяр итүләрнең кайбер әдипләргә мөнәсәбәттә беркадәр нигезле икәнен дә танырга туры килә. Мәгәр, шул ук вакытта, үзем өчен бер нәрсәне ачыкладым: гомумән алганда, иҗат барышында, бигрәк тә әдәби тәнкыйть җәһәтеннән, без элгәрләребез тәҗрибәсеннән бик аз файдаланабыз икән әле. Бүгенге әдәбиятның кайбер сыйфатларын тулырак аңлау өчен үткәннәрне тиргәүдән, инкяр итүдән алда, алардан сабак алырга, алар белән киңәшергә, өйрәнергә кирәк. Аерым алганда, Г. Ибраһимов томнарын укып, мин үзем өчен шундый нәтиҗә чыгардым.

Менә хәзер — күпмедер вакыттан соң — аның зур күләмле әсәрләре томанлырак булып күренә башлады. Ләкин беләм ки, ул әсәрләрдә дә халык һәм аерым кешеләр язмышы, язучы яшәгән дәвергә хас вакыйгалар рәссамнарча, тере детальләр аша тасвир ителгәннәр. Аларны юкка чыгару, инкяр итү мөмкин түгел. Шулай да, инде менә күпме вакыттан соң да, әдипнең әле генә укып чыккан кебек күз алдында саклана торган әсәрләре бар. Алары, нинди генә заманнар килсә дә, төсләрен югалтмаячак. Ышанып әйтәм. Болар — «Табигать балалары», «Алмачуар», «Карак мулла» исемле хикәяләр.

Беренче хикәядә, башка әсәрләрдәгечә үк, бик тә гади күренешләр сурәтләнә кебек. Печән өсте. Инде күпме мәртәбә, күпме язучылар тарафыннан тасвирланган! Әмма алар янәшәсендә Г. Ибраһимов хикәясе һич тә тоныкланып калмый, оригинальлекне югалтмый. Матурлык белән батырлык реаль тормыш күренеше буларак бәрләшә. Көч һәм ихтыяр үз хокукларын даулый һәм җиңүгә ирешә. Вакыйга шигъри дәрәҗәгә күтәрелә.

«Алмачуар»да авыл малаеның атка булган мәхәббәте, биткә сугылган камчы ачылыгын җиңеп, тантана итә. Нәфислек монысында да — шигърият кимәлендә.

Ә менә «Карак мулла»ның эчтәлеге әлеге әсәрләргә хәтта капма-каршы тойгылардан гыйбарәт. Әйе, бу юлы тискәре сыйфат җиңә. Авыл халкының хәзрәткә булган хөрмәте, үзе ирешкән олуг шөһрәт канәгатьләндерми кешене. Аның йөрәген бердәнбер дәрт — ат урлау бәхете биләгән. Мактаулардан, зурлаулардан ваз кичеп, ул иске һөнәренә күчә — ат урларга керешә.

Кара хис. Әмма хикәя — барыбер югары сәнгать әсәре. Шигъри әсәрләрдән һич ким түгел! Гади беллетристикадан ул әнә шул сыйфаты белән аерыла.

Мин мондый әсәрләрне «романтик проза әсәрләре» дип атар идем. Чөнки чын сәнгатьле реалистик проза белән беллетристик әсәрләрне кайчакларда кистереп кенә аеру кыенлашкан очраклар була бит.

Романтик традиция, бигүк киң рәвештә булмаса да, хәзер дә дәвам итә. Тик шунысы бар: бу юнәлешнең барлыгын тәгаен мисалларда күрсәтүчеләр, аны исәпкә, санга сугучылар юк диярлек. Ахрысы, бу битарафлык та бездә инде традициягә әйләнгән.

Г. Ибраһимовның калган әсәрләре арасында мин гомуми беллетристика жанрына карый торганнары да юк түгел, дигән фикердә калдым. Ихтимал, монысы — минем шәхси фикеремдер.

Әдәбиятта беллетристиканың үз урыны, үз хокуклары бар. Әмма бездә аның сәнгать ягыннан дәрәҗәсе дә, тоткан урыны да ачыкланмаган килеш кала бирә шул. Егерме беренче гасырга да шундый карашлар белән кереп барабыз. Вакыйгалар, баштанаяк эзлекле рәвештә тасвир ителеп, азаккача сөйләп чыгылса, шул җитә. Вакыйганың эчтәлеге хакында сүзләр күп. Фикерләре бүгенгә көн өчен актуаль икән, авторы кизү исемлеккә кергән булса, мактаулар бигрәк тә юмарт өләшенер.

Әйтерсең, сәнгать җәһәтеннән югарырак торган башка әсәрләр юк. Ләкин алар чынлыкта бар. Әдәбиятыбызда романтик жанрның — чын сәнгатьле прозаның — притчага тартым төре, шартлы алымнарга нигезләнгәннәре дә тарихта күренә килә. Якынрак тарихны алсак, бу фикерне Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле әсәре раслый алачак.

Бу язучы егерменче гасыр башыннан егерме беренче гасырга сикереш ясаган. Реаль хәл түгел. Киләчәк заманда дөньяда ике генә татар (болгар) калуын да кабул итәсе килми. Ләкин автор икенче төрле уйлаган. Җир йөзендә Җәгъфәр исемле тарихчы белән аның хатыны Сөембикә генә яшәп калган. Алай гына да түгел, үле бала табу сәбәпле терелә алмыйча, Сөембикә дә вафат булгач, тормышта бөтенләй ялгыз калган Җәгъфәр давыллы бер төндә, югалтулар хәсрәтенә бирелгән хәлдә, мәчет манарасына күтәрелә. Давыл тагын да көчәя. Һәм бервакыт манараны аударып җиргә бәрә. Җәгъфәр җимерек ташлар арасында соңгы сулышын ала. Аның үлеме белән бөтен бер халык — татар (болгар) милләте юкка чыга.

Аллегория. Уйлап кына чыгарылган вакыйга. Ә мәгънәсе? Йөрәгенә мүк үсмәгән булса, уйламыйча, куркыныч барын тоймыйча кара!

Мондый ысул белән язылган әсәрләр — башка беренче булып килгәннәрен генә атап әйтсәк, мәгъриб язучыларыннан Фр. Кафка, М. Пруст, Ст. Рэм, мәшрикътан Кобо Абе әсәрләре — бөтен дөньяга танылган. Аларны без дә таныйбыз. Ләкин Г. Исхакыйның «Инкыйраз»ын? Аны хәтта үзебездә дә белүчеләр бик тә аз түгелмени?

Шушы рәвештә язылган үзебезнең чор әсәрләре турында әйтәсе дә калмый. Ләкин әйтәсе килә: мондый әсәрләр, әгәр дә күрергә батырчылыгыбыз җитсә, безнең әдәби хәзинәбездә бердәнбер түгел.

Романтик жанрда реаль вакыйгалар үзләре сурәтләнмәскә мөмкин. Мондый әсәрләрдә автор, шул вакыйгалардан файдаланып, тормышның үзе күрергә теләгән моделен барлыкка китерә. Моның өчен реаль хәлләрне сөйләп чыгу кирәк түгел, ә фәлсәфи киңлек һәм тирәнлек кенә таләп ителә. Бездә, бәлки шуңа күрәдер, андый әсәрләр сирәк языла. Шулай булгач, аларның кадере бермә-бер артык булырга тиеш тә бит — нишлисең... Әлеге дә баягы, тәнкыйть, ни өчендер, әдәбиятның бу байлыгын күрмәмешкә салыша, хәтта аннан ояла да кебек.

Ягъни дип әйтик, без биредә проза жанрының ике төрле юнәлешен: шигърилеккә ирешкән, яки шартлы алымнарга корылган романтик прозаны (кагыйдә буларак урнашканча әйтсәк, сәнгатьле прозаны) һәм, бу жанрның киң масса укучыларга адреслана торган гадирәк төрен — беллетристика төрен искә төшердек. Чөнки хәзерге шартларда аларны аерып карау принципиаль әһәмиятле эш булып әверелде. Мәсьәләне болай куюның сәбәпләре адым саен дигәндәй күренеп тора.

Журналда «Проза турында сөйләшү» унаеннан бирелгән сорауларга җавапларның берсендә Гариф Ахуновның документаль повестена («Тимерханның яшьлеге» повесте күздә тотылса кирәк) карата катгый рәвештә шундый бәя бирелә: «Тик өлкән язучыбыз гафу итсен, «Хәзинә» янында — «Чикләвек төше», «Идел кызы», «Йолдызлар калка» янында — яңа әсәр тоныкланыбрак кала.»

Документаль әсәрне сәнгать әсәре белән тәңгәл кую... Еллар дәвамында ныгып урнашкан аяныч хәлдән бер мисал. Законлы хәлме? Корым белән карандашны чагыштыру кебек түгелме? Сәбәпне наданлык белән аңлатыргамы, әллә буталчык хәлләрне тагын да болгатырга тырышу дип карарргамы? Ихтимал, сорауларның икесе дә өлешчә нигезледер. Сәбәп тегеме, бумы, нәтиҗә бер — жанр үзенчәлекләрен исәпкә алмау ялгыш бәя бирүгә китергән. Ә ялгыш төзелгән силлогизмнан дөрес нәтиҗә көтү — өметсез эш.

Бездә еллар буе бер генә төр проза — беллетристика — өстенлек иткәнлектән, аның барча катламнарга аңлаешлы, җиңел төр булуына карамастан, укучы аннан да шактый ялыкты. Укучы хәзер күбрәк документаль әсәрләргә игътибар итә. Проза әсәрләреннән тормыш материалының яңалыгын яки моңарчы күрелмәгән, «кешесе-ние белән бергә ауган манаралар»ны эзли, тормышның хыял тудырган яңа, хикмәтле рәвешләрен эзли ул! Таба алмаса, күз йөртеп чыккач, китап (яки журнал) битләрен ябып куя.

Бүгенге көндә тормыш өчен әһәмияте зуррак булган вакыйгалар һәм идеяләр кызыксындыра укучыны.

Документаль әсәрләрнең өстенлеге — актуальлек. Аларга бүтән бурыч йөкләү мәҗбүри түгел. Шигъри, романтик алымнарга, шартлылык ысулларына — аллегория, символика, притча, метафора кебек чараларга нигезләнүгә яки, Достоевский иҗаты кебек: адәм баласының психик төпкелләрен айкаган, катлаулы, җитди, чын сәнгатьле проза сыйфатларына алар дәгъва итмиләр.

Әгәр дә Г. Ахуновның «Тимерханның яшьлеге» повестен «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнары белән түгел, аның үзенең яки башка авторларның документаль повестьлары янәшәсенә куеп карасаң, ул һич тә тоныкланып калмаячак.

Нәрсәне ни белән чагыштырасың бит! Әгәр жанрлар хасиятен ихтирам итмәгән тәнкыйтьчене фәлсәфи мәкаләләр иҗат итә торган бөек автор белән, әйтик, Сократ белән чагыштырсаң, бүгенге тәнкыйтьченең түп-түгәрәк нольгә әйләнүе мөмкин. Һәм киресенчә, аны әгәр көнкүрештә үзе аралашкан иптәшләре белән чагыштырсаң, аның ярыйсы гына, әйбәт кенә кеше булып калуы ихтимал.

Документаль әсәрләр кебек үк, соңгы елларда мемуар жанры да активлашты. Истәлек-романнар, автобиографик повестьлар дөнья күрде. Алар документаль әсәрләр төркеменә кушылырга торалар. Бәлки аларны роман яки повесть дип атау дөрес тә булмагандыр? Ялгыш таләпләр куелуга бәлки авторлар үзләре дә җай бирә торганнардыр.

Истәлекләр һәрчакта да мөстәкыйль әсәр була алмыйлар. Башлыча, ярдәмче роль үтиләр алар. Язучы тормышын (укучы моның белән кызыксына бит) һәм ул иҗат иткән әсәрләрнең чыганакларын тәгәлрәк күз алдына китерү, өйрәнү өчен, ярдәмлек була алалар. Ләкин чын сәнгать әсәрләре белән чагыштырганда, имтихан тота алмыйлар. Моны өмет итү үзе дә мәҗбүри түгел. Әлеге дә баягы, чагыштыру бер төрдән, бу очракта — бер жанрдан гына була ала.

Кыска итеп әйткәндә: Вәли үз өендә хуҗа, Гали үз өендә хуҗа.

Гел романтик әсәрләргә генә хас таләпләр куйсаң, беллетристиканың хокукларын танымау булып чыгар иде. Икенче яклап, киресенчә — әгәр дә романтик жанрга беллетристика хасиятләре мөмкинлек биргән әтрафлылык, реаль тәгаенлек, анализ ясау кебек таләпләр куйсаң, сәнгать мисалын түбән дәрәҗәгә төшерү килеп чыгар иде.

Бер нәрсә дә юктан бар булмый. Һәр яңа күренеш традицияләр җирлегендә барлыкка килә һәм яңа сыйфатларга элгәшеп, яңа чорда дәвам итә. Бүгенге әдәбиятка төпле бәя бирү өчен әдәбиятны аның тарихы белән бәйләнештә, тулаем күз алдында тотарга кирәк.

Теләкләребез чынны раслауда булса, изгелектә булса, жанрларның һәркайсын үз урынына куеп карыйк. Ышанып әйтәм: әгәр дә шулай эшли алсак, әдәби дөньябыз бермә-бер яктырып китәчәк!

Нажар Нәҗми

# ИСТӘЛЕКЛӘР

## Өч хат (Нәби Дәүли)

Нәби Дәүли белән аралашуыбыз фәкать иҗади аралашуыбыздан гыйбарәт. Без кунакка чакырышмадык (дөрес, андый очрашулар да еш очрый), шуның өчен дә аның белән өстәл артындамы, башка урындамы, күзгә-күз карашып сөйләшеп утырганыбыз булмады. Ул миңа мәшһүр «Яшәү белән үлем арасында» китабы, шигырьләре аша, бигрәк тә «Син кайда идең», «Уфа каласы ни өчен матур» дип җырланган шигырьләре аша якын иде. Аның шактый кырыс холыклы, үз фикерендә бик принципиаль, үз бәясен үзе нык белгән, хаксызлыкка бик тә рәхимсезлеген күп мәртәбәләр ишеткәнем дә бар иде. Ул ишетелгән сүзләр дөрестерме-түгелдерме, чөнки һәркем теге яки бу кешегә бәһа биргәндә үз күзлегеннән карап сүз йөртә бит. Әмма безнең арада булган бер кыска гына сөйләшү, дөресрәге, бер соравы аның нииндирәк холыклы булуын күрсәтте. Мин аның алтмышмы, җитмешме яше тулганын ишетми калдым. Берчак ул миңа үпкә катыш: «Нигә миңа котлау җибәрмәдең. Син дә җибәрмәгәч... Көткән идем»,— диде.

Менә шул кешедән, Нәби Дәүлидән, хат килеп төште. Әйтәм бит, аның белән хат та алышмый идек. Конвертны ачсам — эчендә машинкада басылган «Йөрәк» дигән поэма һәм шундый хат юлланган иде.

«Хөрмәтле Нажар!

Гаҗәпләнмә, бу синең өчен көтелмәгән хат булыр. Әлбәттә, сүземне гафу үтенеп башлыйм.

Бу поэманы моннан ун еллар элек язган идем. Яңа йөрәк кую турында беренче хәбәрләр ишетелгән чакларда.

Поэманы күпләр укыды. Берәүләр шәп, диделәр. Берәүләр начар, диделәр. Ә кайберәүләр бу фәнгә каршы протест дип тә әйттеләр.

Ә мин һаман көттем. Вакыты килер, бәлки әсәрне бастырып булыр, дип өметләнеп тордым. Вакыты да килде шикелле. (Поэмада нинди дә булса каршы фикер юк). Әмма эш барып чыкмады, «Казан утлары» да моны эшләргә алынмады. Фикер алышу өчен дип тә карадым. Булмады. Инде әсәрне мәңге архив сандыгына салып куяр алдыннан синнән дә бер укытып карыйсым килде. Син нәрсә әйтерсең икән?

Фикереңне һич кенә дә тартынмый яз. Үпкәләр яки борчылыр, дип хафаланма. Минем тире каты!

Ихтирам белән сәлам әйтеп, Н. Дәүли».

Хатны уку белән уйга калдым. Татарстанда зур-зур шагыйрьләр була торып, ә үзе миннән өлкән, минем өчен зур авторитет булган шагыйрьнең миңа мөрәҗәгать итүе бик тә сәер тоелды, хәтта уңайсызландым. Ләкин үзенең: «Фикереңне һич тә тартынмый яз. Минем тире каты!» дигәнен исәпкә алып, ни уйласам шуны яшереп-батырып тормый җавап яздым. Хатның тәүге нөсхәсен

үземдә калдырганмын — бәхәсләшергә туры килсә, кирәк булыр дигәнмендер ахры. Җавап хатым шундый:

«Хөрмәтле Нәби абзый!

Үзең язганча, хатың чыннан да минем өчен көтелмәгән хәл булды. «Йөрәк» поэмасы йөрәктән ала, поэтик эшләнеше ягыннан тетрәткеч һәм югары кимәлдә язылган, монда мин бер дә фәнгә протест күрмим. Әмма ничек кенә, нинди илдә генә булмасын, тормышта кешеләргә башка кеше йөрәген кую — фәнни һәм гуманистик башлангыч икәнен беләбез, ә поэмада исә башлангыч булып явызлык тора. Тормыштагы хәл белән (андый операцияләр бик сирәк, ә уңышлы беткәннәре аннан да сирәгрәк) поэмадагы алынган хәл арасындагы капма-каршылык укучыны бик сагайта һәм шулар, үзең үк язганча, кешеләрне төрле фикердә калырга мәҗбүр итә. Киләчәктә хәл, бәлки, синеңчә дә, поэмадагыча да булыр, синең, бәлки, алдан күрүеңдер дә (опережать факты). Ә шулай да тойгы исә бүгенгесе ягында, гуманистик башлангыч ягында кала.

Аннан соң аерым уйландыра торган бер генә нәрсә бар: чирле кешенең йөрәген кую (чирлене донор итү) мөмкинме икән?

Поэманы укып чыккач туган фикерләрем шулар, үзең кушканча ачыктан-ачык яздым.

Мине искә алуың өчен рәхмәт!

Ихтирам итеп, Нажар Нәҗми.

8.XI 86».

Хатыма җавап көтмәдем түгел, көттем, җитмәсә, пошыныбрак, ни язар икән, дип уйлана-уйлана көттем. Нәби Дәүли булсын да җавапсыз, шым гына торып калсын, ди... Хат килде.

«Хөрмәтле Нажар!

Җавап хатыңны алдым. Тау кадәр рәхмәт сиңа! Вакытыңны әрәм иткән булсам — гафу үтенәм.

Мин үзем шундый кире беткән кешемен, күрәсең. Менә син дә бит аз гына булса да шик белдергәнсең — «фәлән булмасмы, мөмкинме?» дигән сораулар белән эш итәсең, каләмне кулдан куеп торырга кирәк. Син бит үзең дә ярга басып, ташкын агымын тик кенә карап торырга ярата торган кеше түгел. Син ташкынның үзенә сикереп төшәргә яратасың. Дөньяны мин дә шулайрак хис итәм.

Дөресен генә әйткәндә, мин йөрәк күчерү уены белән күңел ачуга каршымын. Дөньяда кешегә озак яшәр өчен, хәтта ике йөз ел яшәр өчен үз йөрәге дә җитә. Моңа дәлилләр җитәрлек, ә менә шулай озак яшәр өчен җирдә шартлар тудырырга кирәк. Хәзер әле ачларга икмәк кирәк, кешеләргә саф һава кирәк, ә без йөрәк күчерү белән шөгыльләнергә керештек.

Менә ни өчен минем күңелем тыныч түгел. Минем «Йөрәк»тә бу нәрсә аңлашылмаган икән, димәк, мин яза белмәгәнмен. Хатымның соңгы юлларында сиңа бер генә сорау куясым килә: син үзең чит кеше йөрәге белән яшәр идеңме?

Мин бервакытта да! Бу бит, турысын әйткәндә, башка бер бәхетсез кеше гомере исәбенә яшәү була ич! Моны һичбер нинди гуманитарлык белән дә аклап булмый. Минем девиз: минем үз йөрәгемә яшәргә мөмкинлек булсын!

И-и бу турыда яза китсәң, бервакытта да сүзнең ахырына җитеп булмас. Гафу итә күр!

Ихтирам белән, Нәби Дәүли. Сәлам!

P. S. Мин сине һәрдаим исемдә тотам. Туып киләсе Яңа ел белән сине иң беренче булып котлыйм әле. Исәнлек, саулык сиңа!»

Котлаган яңа елы — 1987 ел иде. Аның ике хатында да аларның кайчан язылган ае, елы куелмаган. Алай гынамы, хатларда җибәрүченең адресы юк. «Казань. Наби Давли» диелгән. Болар да аның бер үзенчәлеге, холкы булгандыр, ахры.

Чит кеше йөрәге белән яшәү турындагы фикерләрдә без бик аваздаш булып чыктык. Җавап хатым белән бергә Нәби Дәүли агага 1967 елда ук язылган шигыремне җибәрдем.

## Кешечә

*«Кешең тәне ят йөрәкне кире кага»*
(Гәзитләрдән).

Табигатьнең бөек камиллеге!
Искитмәле синең биеклек:
Кеше туа — гадәти бер нәрсә,
Туу үзе нинди бөеклек!
Кеше туа үз йөрәге белән —
Бу мәңгелек гади төшенчә.
Үз йөрәге белән үлә кеше —
Табигатьчә, димәк, кешечә.
Ә тормышта табигатьчәме соң?
Кешечәме безнең кылганнар?
Үзләрен бит арыслан дип тоя
Куян йөрәк белән туганнар.
Таш йөрәген әдип йөрәгенә
Алмаштырып юкка, тикмәскә,
Үзең генә түгел, башкаларны
Интектерә күпме иптәшләр?
Мин белмимен, тормышыма фида
Кыла алдым микән җанымны?
Тик ят йөрәк түгел, үземнеке
Алып китсен минем тәнемне.

Бу хатыма җавап хаты да язмады, шигырь хакында фикерен дә белдермәде. Шуның белән безнең аралашу бетте, дип уйладым. Әмма миңа 70 яшь тулу уңае белән аннан открытка алдым. Анда язылганнарны монда күчерми булдыра алмыйм.

«5 февраль, 1988. Казан. Туганым Нажар Нәҗми! Көнләшәм, миңа да 70 кенә яшь булсын иде. Сиңа кайгырасы түгел, берзаман мине куып җитәрсең. Ә мин чын күңелдән шатланырмын. Сине шулай артымнан ияртеп барасы килә. Миңа бит тиздән 80 була. Әйдә, энем, куып җит мине! Ләкин мин сине көтеп тормам. Барасы юлың ерак әле. Озын гомер теләп, Н. Дәүли».

Аны куып җитә алырмынмы, юкмы — белмим, әмма бу аның соңгы тавышы иде. Нәби Дәүлинең вафаты турында әзрәк соңлабрак белдем.

1995. Декабрь.

### Дус
### (Мәхмүт Хөсәен)

Истәлегемне «Дус» дип исемләвем юкка гына түгел, чөнки Мәхмүт Хөсәен кебек дуслыкның кадерен белүчене үз гомеремдә мин бик сирәк очраттым. Мондый дуслык көн саен аралашып яшәмәүдән дә, тормышның вак-төяк нәрсәләренә кагылмыйча көн күрүдән дә килә торгандыр. Уфада да минем берничә дустым булды. Ике-өче белән без гомерлеккә аерылышу хәленә килеп җиттек, ә күпләре белән юк-юк та суынгалап алган чаклар булгалый иде, ә Мәхмүт Хөсәен белән беркайчан да.

Төрле-төрле мәкаләләр язганда үз шигырьләремне кыстырырга яратмыйм. «Менә мин нинди шәп шагыйрь» дигән шикелле була, әмма бу очракта дүрт юллык бер шигыремне искә алмый китә алмыйм.

Чын дуслык ул — бер-береңә
Тиңлек китергән бәхет
Тиңлек китермәгән дуслык —
Ялган патшалы тәхет.

Яшерен-батырын түгел, Казанда Мәхмүт Хөсәенне бик күпләр яратмадылар, яратмауларын миннән дә яшермәделәр: «Шул кеше белән ничек дуслашырга мөмкин?» диделәр. Янәсе, мин шагыйрь, ә ул шагыйрь түгел. Шундый ук сорауны Уфада яшәгән талантлы татар шагыйре Рим Идиятуллинга да биргәннәр икән. Ул: «Аның менә дигән шигырьләре бар. Ул хәтта бер юньле шигырь язмаган

хәлендә дә мин аның белән дус булыр идем»,— дип җавап биргән. Рим Идиятуллин сүзендә хаклык бар.

Сизәм: бу истәлекне язуыма да кемнеңдер эче кырылыр, нишлим соң, мин икенче төрле була алмыйм, үз-үземә тугры булып калуым минем өчен кыйммәтрәк. Әйе, Мәхмүт Хөсәен холкының кайбер яклары — яшәү җаен таба һәм оештыра белүе, үҗәт-әрсезлеге белән күпләр килешеп тә бетмәгәндер. Әйе, аның шундый яклары бар иде. Бер генә мисал: 1971 елда язучыларның иҗат йорты «Коктебель»дә бергә булырга туры килде. (Ул хакта аерым тукталырмын әле). Ул алданрак килгән иде. Күрешү сәгатендә үк: «Ничәнче палатада урнаштың?— диде. Мин йортны күрсәттем. Ул: «Что син?! Үзең депутат, үзең идарә әгъзасы. Хәзер үк төп корпуска күч. Әйдә, хәзер үк директорга керик. Төп корпуста яшәмичә (чынлап та ул корпус әйбәт җиһазландырылган булса кирәк. Анда күренекле язучылар, түрәләр яши иде), синең Кугультиннән (Давид Кугультинов) ни җирең ким»,— дип кыстый башлады. Мин гаиләм белән идем, бирелгән бүлмәгә риза булып калдым, ә ул үзе шул төп корпуста яшәгән булып чыкты. Берничә көннәр үткәч, Казаннан килгән тагын бер язучы белән очраштык. Ул: «Күрдеңме, Мәхмүт Хөсәен кайда яши, ә үзе союзда әгъза да түгел»,— дип ризасызлыгын белдерде. Аның ризасызлыгы юкка түгел иде, чөнки аларның (ул да гаиләсе белән) торган җирләре безнекеннән дә начаррак, хәтта түшәменнән штукатурка кубып төшкән иде. Бер карауга болар барсы да вак нәрсә кебек, ләкин яши белергә кирәклек һәркемгә дә бирелмәгән шул.

Мәхмүт Хөсәен белән кайчан ничек якынлашып китүемне хәтерләмим, әмма күрешкәнгә кадәре үк аның исеме миңа таныш иде. Без 1951 елда, Мәскәүдә яшь язучыларның икенче Бөтенсоюз киңәшмәсендә очраштык. Ул да мине ишетеп белә иде булса кирәк. Аның кара күн пальтосы, кара папаха кигәнлеге күз алдымда тора. Киңәшмә тәмамлангач, шигырь кичәсе булды. Кичәне Николай Тихонов алып барды. Миңа икенче итеп сүз бирделәр. Шигырьне укып (тәрҗемәсен Константин Ваншенкин үзе укыды), урынга утыру белән берәү минем янга килеп урнашты. Ул: «Минем фамилиям Козловский. Теләсәгез, мин сезнең шигырьләрне тәрҗемә итәр идем»,— диде. Козловский тәкъдименә, әллә ничек, битарафрак карадым булса кирәк, мине Константин Ваншенкин тәрҗемә итә бит, дигәнрәк фикер әйттем (Җәя эчендә шуны да әйтим инде: Константин Ваншенкин еллар үткәч, тәрҗемә белән шөгыльләнмәде, ә Козловский иң яхшы тәрҗемәче булып танылды. Әйтик, минем шигырьләрне, шул исәптән «Татар теле» шигырен дә, ул тәрҗемә итте). Күп тә үтми Мәхмүт Хөсәенгә сүз бирделәр. Ул шигыренең урыс теленә тәрҗемәсен үзе укыды һәм Козловский шунда ук үз-үзенә әйткән шикелле: «Не то»,— дип куйды. Чыннан да Мәхмүт бик тә коры яңгырашлы, уңышсыз шигырен укыды шул, бәлки монда тәрҗемә дә гаепле булгандыр.

Бик тә күңелгә сеңеп калган, Мәхмүт Хөсәенгә кагылышлы тагын бер хәл. 1958 елда булса кирәк, Уфада башкорт язучыларының бер җыелышы булды, шунда Мәхмүт Хөсәен дә катнашты, ләкин ул Казаннан килгән татар язучыларының делегация составында түгел иде. Җыелыш тәмамлангач, татар һәм башкорт язучыларыннан зур гына бер төркем автобуска төялеп, Сәйфи агай Кудаш яшәгән Акманай авылы янындагы Дим буена бардык. Кунакларны Сәйфи агай чакыргандыр, ахры, азактан бөтен төркемне ул үз өенә алып китте. Шунда татар язучыларының берсе (ул да мәрхүм инде, исемен әйтмим) Мәхмүт Хөсәенгә: «Нишләп йөрисең монда?!»— дигәнрәк сүзләр белән кеше алдында бик каты бәрелде һәм Мәхмүтнең чирәмгә йөзтүбән ятып, үксеп жылаганы һаман да күз алдымда тора.

Хәзер инде хәтердә нык сакланган башка бер күренеш. 1960 елның җәендә Казанга пароходта барып, урап кайту теләге туды. Казанга баргач, Бауман урамында йөргәндә көтмәгәндә Зәки Нури очрады. Нишләп йөрүемне, кайчан пароход китүен әйткәнмендер инде, пристаньга мине озатырга Зәки Нури, Илдар Юзеев, Әнвәр Давыдов, Мәхмүт Хөсәен килде. Пароходка кергәндә егетләр мине җырлатырлык хәлгә җиткергәннәр иде инде, Илдар Юзеев кайдандыр гармун табып алды — башкасын сөйләп торасы юк. Пароход кузгалды, ә егетләр бик озак торып карап калдылар. Икенче көнне пароходта миңа бер кыз сүз кушты: безнең кичәге бик үзенчәлекле саубуллашуны күреп, тыңлап торган икән. Мин аның кулындагы кечкенә китабы белән кызыксындым — ул Мәхмүт Хөсәеннең шигырьләре булып чыкты. Кичә озатучылар арасында аның барлыгын да әйтмәдем, күреп беләсезме, дип тә сорамадым, кыз кеше үзе генә: «Мәхмүт Хөсәен кызык яза»,— дип әйтә салды һәм мин дә эчемнән генә: «Димәк, Мәхмүтнең укучылары бар» дип уйлап куйдым һәм ирексездән моннан бер-ике ел элек Дим буенда үксеп ятканы күз алдыма килде.

Мәхмүт Хөсәен белән якынлашуым, дуслашуым Казанда чыккан «Сөю сүзләре» исемле китабым (1962) чыгуы белән бәйле. Ул аның мөхәррире иде. Мөхәррир белән автор арасында бертөрле дә аңлашылмаучылык булмады, тик ул бер хатында: «Нигә синең исемең «Назар», әллә чукындырылган татарсыңмы?» — дигәнрәк хат язды. Ни эшләптер, кулъязмада башкортча «Назар Нәжми» дип йөртелгәнчә киткән. «Минем тулы исемем Хәбибнажардан кыскартылып алынган»,— дип җавап алгач, нәшриятта бераз мәшәкать тудырылган икән, чөнки китапның тышлыгы эшләнгән булган һәм андагы рәссам язган исемне гадәти, типография шрифты белән алыштырганнар. Китап укучы өчен ул сизелми дә.

1976 елда Казанда чыккан «Ут күрше» исемле китабымның да мөхәррире булгач та без инде бик дуслар идек. Аңа кадәрле — язучыларның иҗат йорты «Коктебель»дә,— өстә язып киткәнемчә,— бергә яшәдек. Шунда инде мин аның иҗат лабораториясе белән таныштым, ягъни иҗат итү үзенчәлеген күзәттем. Шигырьләрне ул бик тиз яза икән. Беркөнне ул миңа бер шигырен укыды. Шигырьнең эшләнеп бетмәгәне, камил түгеллеге күзгә бик нык чагылып тора иде. Мин бик нык саклык белән: «Бу җирен шулай итеп булмасмы, бу юлларны алып ташласаң, шигырьгә зыян килми бит, бу урынын шулайрак үзгәрткәндә яхшы булмас идеме икән?» — дигәнрәк сүз әйттем.

Үземнең иҗат табигатемнән чыгып: «Мин бик күп замечаниеләр ясадым, аны башкарып чыгар өчен һич югында бер-ике көн вакыт кирәк» дип уйлаган идем, ә ул ике-өч сәгатьтән соң мине табып: «Синең сүзләрне искә алып, шигырь өстендә эшләдем»,— диде. Мин эчемнән генә аптырап куйдым. Шигырьне укыгач, ни күрәм — ул бөтенләй яңабаштан язылган шигырь иде. Шунда мин: «Шигырен язгач, Казанда кемгә укый икән, укыр кешесе бармы икән?» дип уйлап куйдым, чөнки без барыбыз да дип әйтерлек, шигырьне язгач, иң ышанган кешенә укып, үзеңне сынап карыйсың, аның тәнкыйть сүзләре булса, йә ризалашасың, йә бәхәскә керәсең. Менә әле бүген дә: «Мәхмүт үз казанында үзе генә кайнамадымы икән, ул нинди иҗади мохиттә яшәде икән?» дип үз-үземә сорау бирәм.

Аның үз мохите, мөкатдәс серләре белән уртаклашкан кешеләре булуын булгандыр, әмма үзенең язуларына караганда (мин аның хатларын күз алдымда тотам), каләмдәшләренең аңа булган мөнәсәбәте (аларның кайбер күренешләрен язып үттем инде) бик үк адәмчә булмаган шикелле. Бер генә мисал: аңа 50 яшь тулды. Ул мине үзенең юбилеена чакырды. Барырга вәгъдә иттем. Минем килү турында белгәч, минем иң ихтирам һәм башым игән кешем телефон аша әйгә шалтыратты. Сүзен шулай башлап китте: «Ты что?!» Шунда катнашуым белән мин, имеш, үземне компрометировать итәм. Өлкән агай безнең араның өзелүе белән куркытты. Мин бармадым, ә Мәхмүт Хөсәен, минем хәлемне аңлап, үпкәләмәде, әмма хәзерге көнгә кадәр, бигрәк тә аның рухы алдында үземне гаепле санап, үкенеп бетә алмыйм. Үземне куркаклардан санамасам да, бу очракта шул куркуымны гафу итә алмыйм.

Арабыздан киткән күп кенә каләмдәш дусларым, миннән өлкән агайларым хакында истәлекләр яздым. Анда миңа аларның иҗатлары хакында сүз әйтергә туры килмәде, бу очракта, ничектер, бик кыскача гына булса да Мәхмүт Хөсәеннең иҗат психологиясе, иҗатының тәүге еллары нинди, кайсы юл белән дәвам итүе хакында уй йөртмәкче булам.

Мәсәлән, аның 1942 елда, сугышның алгы сызыгында, аңа нибары 19 яшь чагында язылган шигырьләре бар. Беренчесе «Туган илем өчен җан бирсәм, юлым дәвам итәр Халисәм» (Халисә — лирик геройның яраткан кызы), ә икенче шигырь

«...Тик оныта алмый берничек тә
Сөйгәненең солдат булуын,
Аерылып, ялгыз торуын»

дип тәмамлана. Ике очракта да монда мәрхәмәтле тойгылар аша мәхәббәтнең яшәү көче һәм аның кешеләрдән кешеләргә күчүе, ягъни аның, мәңгелек сүзен кертмичә, мәңгелеге турында сүз бара. Хәзер инде алтмыш яше тулган, җилкәсендә кырык еллык иҗади гомере, тәҗрибәсе булган шагыйрьнең бер шигыреннән азаккы ике юлын алыйк (Бу шигырь бер томлык китапның «бисмилласы» булып кергән):

Җидегәннәр сипкән ямь кебек
Син, мәхәббәт, җирдә мәңгелек.

19 яшендә мәхәббәтнең мәңгелек икәнен төртеп күрсәтмәгән шагыйрь кырык елдан соң аның мәңгелек икәнен төртеп күрсәтә, ә бит аның мәңгелек икәне көн кебек ачык. Монда шагыйрь турыга ата, ә бит шигырь асылда кыек атып, туры тидерү түгелме соң? Алайга калса, мәсәлән, Зөлфәт тә «Сөю — мәңгелек» ди, ләкин ул турыдан-туры атмый, ул мәңгелекне гомернең газизлеге, бер генә булуы белән бәйли, чын шигырь тудыра: «Гомер бер генә, сөю — мәңгелек».

Ни өчен икән 19 яшьлек Мәхмүт Хөсәен белән алтмышка житкән Мәхмүт Хөсәен арасында аерма юк, ә хәтта нинди дер серле артка китеш бар? Ә бит Мәхмүт Хөсәен табигате белән тумыштан шагыйрь. Бу мисалларым һәм фикерләрем белән кешеләрне ышандыра алам микән, юк микән, ничек кенә булмасын, шагыйрьнең шагыйрь булып үсүендә тирә-як мохитнең, шигъри мохитнең зур роль уйнаганын әйтми булдыра алмыйм. Без беребез дә Пушкин, Лермонтов шартларында тәрбияләнә алмадык, ә Тукай кебек могҗизалар дөньяда берәмләп кенә санарлык. Ә шулай да Мәхмүт Хөсәен нәрсәсе белән халык арасында популяр һәм кешеләр яраткан шагыйрьгә әйләнеп китте соң? Халыкның шигъриятә акны карадан аера белмәүдә, аның шигъриятькә карата интеллектуаль югарылыгы түбән булуда, аның матурлыкны тою зәвыгы чикләнүдә дисәк, нинди зур хата булыр иде.

Мәхмүт Хөсәенне бераз кимсетебрәк «артист-шагыйрь» дип тә әйткәннәрен ишеткәнем бар. Дөрес, шигырь укуда ул кайсыбер артистларга биргесез. Татарстан филармониясе артистлары бригадасы белән Уфага килеп, аның ничек концертны алып барганын, шигырьләрен ничек укыганын күргән чакларым булды. Шәп! Ни өчен әле без аның шушы осталыгына көлебрәк карарга тиешбез. Дөрес, аның шундый шөгыле шигъриятьтә камилләшүгә бик тә комачаулагандыр. Әмма л бригада белән чыгып китәргә мәҗбүр икән, аның үзен генә гаепләргә хакыбыз бармы? Алайга китсә, ул бит үз шигырьләрен генә укымады, ә татар шигъриятe үрнәкләрен халыкка житкерде. Моңа бит сокланырга гына кирәк.

Шагыйрьнең башка бер үзенчәлеге — ул үзенең Ватан сугышы солдаты булуы белән горурланды. Татар шагыйрьләре арасында иң яшь һәм Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнүче ул бердәнбер шагыйрь, дип уйлыйм. Сугышта катнашкан кешеләр белә: андый орденга ия булу җиңел түгел, аның өчен конкрет батырлык ясарга кирәк иде һәм шагыйрьнең горурланырга хакы бар иде. Сугыш һәм яшьлек еллары аның хәтереннән җуелмады, хәтта хәрби кителен гомер буе саклады, аны киеп фотога төшүдән дә баш тартмады. Бу хәл, бәлки, аның йомшаклыгы да булгандыр, әмма «Кызыл Байрак ордены тирәсенә төрле-төрле значоклар тагып» дип язып чыгу бик килешеп беттеме икән? Минемчә, килешми, чөнки ул орден һәм медальләр сугышта кан коеп алынганнар, һәрхәлдә, Брежнев кебек, сугыштан соң өч мәртәбә Советлар Союзы Герое булу түгел.

1976 елда Тукайның 90 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә ул эш белән мәшгуль иде — минем «Ут күрше» дигән китабымны редакцияләгән чагы. Китап хакында сөйләшергә һәм Сибгат Хәкимнең баш сүзе белән таныштырырга ул мине нарат урманы арасында урнашкан бер өйгә алып китте. Без өчәү идек. Ул бер грамм да капмады, өченче кеше дә, машина рулендә утыручы буларак, бик сакланып утырды. Икенче көнне иртүк кунакханәгә кайткач, минем хәлне сораштырган кешеләргә: «Мөхәррирдә кунакта булдым»,— дип әйтүемә кычкырып көлделәр, чөнки, гадәттә, мөхәррир кеше авторның кунагы була бит...

Мин искә төшергән нәрсәләр, бер карауга, вак-төяк булып та күренәдер, ләкин миңа, Казаннан читтә яшәгән кешегә, алар бит барысы да вакыйгаларның бер чеметеме генә. Еллар буена шул «вак-төякләр»не дә үз йөрәгә аша үткәргәндә эзсез калмый торгандыр. 1983 елда аңа алтмыш яшь тулды. Юбилее булгандырмы-юкмы, истә калмаган, бәлки илле яшь тулган чагында минем килмәвемне онытмагандыр — хәбәр-хәтер булмады, ә мин шулай да аңа котлау телеграммасы җибәрдем һәм «Сиңа Мөхәммәт пәйгамбәр яшенә житәргә дә күп калмады» дигән сүзләр дә яздым. Ни өчендер, шул сүз аның йөрәгенә бик тирән кереп утырды булса кирәк. Миңа язган һәр хатында дип әйтерлек шул Мөхәммәт яшен хәтерләде, тел төбендә аңа кадәр яшәп булмас дигән уй ята иде. Ул вакытта әле аның язган сүзләренә бик игътибар белән карамадым. Менә хәзер генә уйлап куям — димәк, ул үз хәлен үзе белгәндер.

Истәлегемне «Дус» дип атадым. Язучылар арасындагы дуслык ничегрәк була, нәрсәгә нигезләнә, нәрсәгә корыла, аның үзенчәлеге бармы соң? Чыннан да, каләмдәш кешеләрнең дуслыгы гадәти дуслыктан нәрсәсе беләндер аерылып торадыр. Иң тәүге үзенчәлеге — ул иҗади зәвыкның авазддаш булуындадыр. Хәтта ул кунакка йөрешүдән дә килми, ә бер-береңнең иҗатына нинди

мөнәсәбәттә булуыннан да килә, күп кенә очракта бер-береңне макташуга да нигезләнә. Моннан бер утыз еллар элек бер иптәшнең: «Мине яратканнарны гына яратам»,— дип әйтүе әнә шул хакта сөйли. Шәхсән мин бу төр дуслыкка каршымын.

Язучылар арасындагы чын дуслык бер-береңне ихтирам итү, бер-береңнең язган әсәрләренә карата ачыктан-ачык үз фикереңне әйтә алу, хәтта рәхимсез булуга бәйле. Яшьлектә бик дус күргән, хәтта кунакка йөрешкән дуслар әсәрләренә карата үз фикереңне ярып салган өчен, тәнкыйть сүзе әйткән өчен, шушы юлларны язучыга да: «явыз», «ахмак», «Унтер Пришибеев» дигән атамалар да тактылар. Бу хәлгә ризамын да. Мондый «дуслыктан» азат булу шатлык.

Иң кыйммәтле дуслык ул, өстә шигырь белән әйткәнемчә, бер-береңне тиң күрү дуслыгы. Элекке заманнарда, СССР таралмаган заманнарда, Мәскәүдә: «Вазифасыз язучы — язучы түгел» дигән әйтем таралган иде. Бу әйтем хәзер дә үз көчендә, бигрәк тә дәүләт хакимиятчелеге тирәсендә хөкем сөрә. Вазифалы язучы белән, һәрхәлдә элекке вазифаларның инерциясе белән яшәгән язучылар белән дус булудан үзеңнең кимсетелүеңне тойгач, аннан ваз кичүемнән шатмын. Мәхмүт Хөсәен белән булган дуслык — ул бер-береңне тиң күрү дуслыгы иде. Дөрес, ул минем әсәрләремне мәкаләләрендә, хатларында чамадан тыш күккә күтәрде, хәтта миңа багышлап шигырь дә язды, әмма үзе һич ялагай булмады. Аның миңа булган мөнәсәбәте кешелекле һәм эчкерсез иде.

Бер-ике генә мисал. Өйдә телефон шалтырый. Казаннан Мәхмүт Хөсәен: «Нажар, иртәгә Уфа аша Магнитогорскига очам. Вакыт табып, аэропортка килсәң иде. Сагындым. Тапшырасы әйберләрем дә бар». Аэропортка барам. Очрашабыз. Белдем: Магнитогорскида шигърият кичәсе икән. Кулында калын китап — Кол Гали: «Кыйссаи Йосыф». Язу:

*Нажар Нәҗмигә*

Кол Гали —
сиңа, дустым,
тансык бүләк.
Кол Гали —
татар өчен
аумас терәк.
Янсак без
Кол Галидәй
ярсып-дөрләп,
Һичкайчан талмас беләк, армас йөрәк.

Мәхмүт Хөсәен. Март, 1984 ел. Казан.

Икенче мисал: «Татарча-урысча сүзлек». Мин аны югалткач, Уфада да, Казанда да таба алмадым. Аптырагач, Мәхмүткә яздым. Ул шунда ук җибәрде. Шәхси сүзлеге. Анда шундый сүзләр бар: «Нажар дус! Менә сиңа туган телебезнең сүз хәзинәсе. Ул сиңа яңа җәүһәрләр эзләп табарга, яңа офыклар ачарга рухландырсын. Мәхмүт Хөсәен. 9.V.1980».

Бу сүзлек турында язып та тормаска мөмкин иде, әмма аның бер «ләкин»е бар. Ул сүзлек Мәхмүт Хөсәеннең хәтта Казандагы каләмдәш дусларына да бик үк таныш булмаган бер сыйфатын ачып бирә. Сүзлеккә керми калган кайбер татар сүзләрен, йә булмаса татар сөйләшүендә кулланырга мөмкин булган сүзләрне өстәгән ул. Мәсәлән, сүзлектәге «Ай-ай!» дигән ымлыктан соң «Ай-мак» дигәнне өстәгән дә җәя эченә «К. Насыйри» дип куйган. Аннан соң шундый өстәмәләр бар: «Атан — печелгән дөя», «Йолдарым — гром» (Н. Чернышевский); «Кирмән — ныгытма, крепость», «Кунан — ике яшьлек куй», «Ләнәр — якорь», «Терекөмеш — кенә суы» (К. Насыйри), «филисә — чулпы тәңкәсе». Болар нәрсә турында сөйли? Үзе өстә язганча, сүз хәзинәсенә карата үтә игътибарлы, хәтта эрудит булуын да аңлатмыймыни? Күрәсез, ул К. Насыйрины да, Н. Чернышевскийны да телче булып та укыган.

Башкортстанның әдәбият җәмәгатьчелеге миңа 70 яшь тулуны билгеләмәде, төрле шау-шуларга исем китеп бармаганлыктан, үзем дә теләмәдем, ә Мәхмүт Хөсәеннең бик киләсе килгән иде. Миңа 70 яшь тулып, ай ярым вакыт үткәч, ул барыбер килде. Шулай итеп, без аны бары икәүдән-икәү билгеләдек. Бу чын дуслык иде. Аның бүләк итеп алып килгән сәгатенең арткы капкачына: «Халык шагыйре Нажар Нәҗмигә» дип язылган (Ул вакытта минем андый исемем юк иде). Ул сәгатьне һаман бәйләп йөрим.

Гөлшат Зәйнашеваның «Илле җыр» дигән китабы Тукай исемендәге бүләккә тәкъдим ителгәч, «Илле шатлык» дигән мәкалә яздым. Гөлшат Зәйнашевага бүләк бирелгәч, Мәхмүт Хөсәеннән телеграмма килде: «Зәйнашевага лауреат исеме бирелде. Бөтен йөрәктән котлыйм сине». Кеше шатлыгы белән шатлана белү — кешелеклелекнең, чын дуслыкның иң югары билгесе түгелмени?!

Соңгы очрашу... Ул да Мәхмүт Хөсәеннең кешелеклелегенә бәйле. 1991 елның декабрендә Сибгат Хәкимнең 80 еллыгы булырга тиеш иде. Хәсән Туфанның 90 еллыгына чакырылган идем, ә Сибгат Хәкимнең 80 еллыгы үткәреләме-юкмы, ә үткәрелә калса, чакырылырмынмы-юкмы, миңа билгесез иде. Шул хакта Мәхмүтнең белешүен сорадым. Ул шунда ук хат язды: үткәреләчәк, сине чакырганнар. Казанга килдем. Уфа поездын иртән иртүк Мәхмүт каршы алды. Миңа кайсыдыр кунакханәдә урын сөйләшенгән икән — шунда киттек. Анда бернинди урын булмаганлыгын белдек. Мәхмүт Язучылар союзына шалтыратып тормады, «киттек миңа»,— диде. Ул ике бүлмәле фатирда берүзе генә тора икән. Бер хатын-кыз (исемен хәтерләмим) аңа килеп, ара-тирә аш-су әзерләп, өй җыештырып йөри икән. Без өйгә килгәндә ул юк иде, кичкә таба күренде.

Мәхмүт Хөсәеннең фатиры ялгыз яшәгән ир-атныкына охшамаган — өйдә тәртип, тазалык, Шул күзгә чалынды: кием элгечләр, көзгеләр һәркайсы үз буена карап (ул тәбәнәк буйлы) кагылып куелган. Мәсәлән, миңа көзгегә карап үземне тиешенчә күрер өчен әзрәк иелергә туры килде. Безнең янга, ягъни Мәхмүт Хөсәен фатирына, Гөлшат Зәйнашева килде — бу аның үз өенә чакыруына безнең бара алмавыбызның нәтиҗәсе иде. Мәхмүтнең фатиры Казанның бер читендә, Дербышка дигән районында. Бервакыт, алдан телефоннан шалтыратып, Марсель Галиев, Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллалар шаулап килеп керделәр. Алар өчесе дә татар шигъриятенең бүгене, киләчәге. Талантлы егетләр. Алар Сибгат Хәким «кул астына» керергә өлгерер-өлгермәс калдылар. Сибгат Хәкимне ихтирам итүләре һәрберсенең сүзеннән аңкып тора. Икенче көнне, С. Хәкимне искә алу кичәсендә, Газинур Моратның чыгышында (элек укыган шигырьләрендә дә) Мөдәррисләрнең, Зөлфәтләрнең кискенрәк дәвамын күрдем. Нинди шатлык!

Өч көннән соң Мәхмүт белән Гөлшат мине Казан вокзалында озатып калдылар. Бу хәтер кичәсендә катнашуыма бик риза булып кайтып киттем — барысы өчен Мәхмүт Хөсәенгә бурычлы булуымны аңладым.

Безнең бу бергә үткәргән көннәрдә Мәхмүт Хөсәенгә 70 яшь тулырга да күп калмаган иде. Ул үз юбилеен, 1993 елның 15 апрель көнен бик дулкынланып, ничектер, ярсып көтте булса кирәк. Менә аның соңгы хатларының берсе. Ул хатларын мотлак кара кара белән яза иде. Үз карасы да беткәндер ахры, ул әллә нинди күренер-күренмәс, тонык зәңгәр кара белән язган. Хәтта караның төсе дә хатның эчтәлеген билгеләп торган шикелле иде. Хатны сүзгә-сүз күчерәм.

«Хәерле көн, ахирәт дус! Инде инандыңмы Ходайның бирлегенә, Алланың барлыгына?! Үзенең «мин-минлеген»дә Ходай тәгаләне узып, дөнья кыйратканны дөнья белми.

«Бәяң, йөрәк, кеше булып ал!
Сүнгәндә дә кеше булып кал!»

Әнә шул төпсез упкынга этсәләр дә кеше булып кал, дип юкка гына әйтмиләр. Син нәкъ шулай. Бөтен иблисләрне һәм аларның «илһамчыларын» җинеп чыктың. Шәхсәнә яктан килеп караганда — синең 1945 ел 9 май Җиңүенә тәңгәл фидакарьлек! Сине бүген авыз тутырып: шигъри каһарман, дип атыйм. Мең яшә! Ихлас котлыйм.

Миңа килгәндә, офыкта күләгә дә, «чәчән»нәр дә бик күренми: томанлы. Шул ук вакыт кояшы да бик елмаймый... Кул бирүче дә, юл бирүче дә җиде катлам болыт артында пычак кайрый. Бөтен ышаныч, бөтен өмет үз йөрәк тибешемдә... Ә йөрәккә кан сава!.. Еларга да, көләргә дә белмим... Тапшырдык бер Ходайга! Кочып Мәхмүт дип бел. 28 февраль, 1993 ел. Казан».

Бу хаттан соң аның тагы бер хаты килде. Минем юбилей көннәрендә Башкортстанда чыккан бөтен газитләрне сорап язган иде. Мин барсын да әзерләп, конвертлап куйган идем инде — хәбәр... Мәхмүт Хөсәен вафат... Хәтта Мөхәммәт пәйгамбәр яшен узып, җиде ел яшәсә дә, дусларының яшенә житә алмады.

*1995 ел, 28 декабрь.*

Рәфикъ Нәфиков

# ШАГЫЙРЬНЕ ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Соңгы елларда Г. Тукайның тәрҗемәи хәленә кагылышлы шактый гына материал табылды һәм басылып чыкты. Вакытында барысы да җыелмаган иде шул. Җыелганнарының да кайберләре юкка чыкты бит, җитмәсә 1937 елда шагыйрьнең дуслары да гаип булды, замандашлары озак елларга тынып калды. Хәзер менә шәһадәтнәмәләр туплау да кыенлашты: Тукайның чордашлары якты дөньядан китеп барды, документлар, газета-журналлар, хатлар югалып беткән.

Шулай да, булган чыганакларны игътибар белән һәм җентекле тикшерүләр фәнни эзләнүләрне бүген дә дәвам итәргә булыша. Шагыйрьнең иҗади мирасы тагын бер томга артты. Дуслары, иптәшләре турында мәгълүматлар өстәлеп тора, «Фикер» газетасының 1907 елга караган биш санын, моңа кадәр билгеле булмаган фотосурәт һәм хатларны табу мөмкинлеге бар. Татарстан Фәннәр Академиясе экспедиция һәм командировкалар оештыра, Тукайның әдәби энциклопедиясен хәзерләү бара, шагыйрьнең Казанда Фәрит Яхин җитәкләгән музее квалификацияле эшләп килә, Казан дәүләт университеты галимнәре дә фәнни эзләнүләрен дәвам итә.

Мин исә Г. Тукайның үнике ел гомере узган Уральск (Җаек) шәһәренә кагылышлылары хакында сөйләргә телим. Шагыйрьнең анда баруына йөз ел тулу уңаеннан Җаекта Тукайның фәнни үзәге оештырылган. Аны пединститут профессоры Р. А. Әбүзәров һәм доцент Н. Х. Хәлиуллина җитәкли. Кыска гына вакыт эчендә алар инде ике конференция уздырып өлгергәннәр. Шагыйрь тормышына бәйле тарихи урыннарны — Г. Тукай яшәгән йортны, укыган мәктәбен, мөгаллиме М. Төхфәтуллинның фатирын сурәткә төшереп алганнар.

Тукайга багышланган конференция Чапаево-Лбишинскида да уздырылган. Җирле тарихчы Б. Б. Пышкин — бу өлкәдә шактый яхшы белгеч.

Тукай үзәге оештырган эшләрдә миңа да катнашырга туры килде, әлеге җәмгыять мине үзенең ихтирамлы әгъзасе итеп сайлаган икән. Без телевидение хезмәткәрләре белән берлектә Тукай үз иткән Пушкин бакчасын, Хан агачлыгын тасмага төшердек. Чаган һәм Җаек елгалары кушылган урында яшь Апуш балык тотарга яраткан. Табигатьнең бу гаҗәеп почмагы әле дә булса үткәндәге матурлыкларын тулысынча җуймаган. Нәкъ менә шушында ул И. Крылов мәсәлләрен тәрҗемә иткән, үзе дә шигырьләр язган. Монда урман хуш исе, елга, дала сулышы. Монда зәңгәр күк киңлеге астында үскән йөзьеллык агачлар Тукайның шигырь аһәңнәрен саклый.

Җаекның сул ярына урнашкан Дуанга исемле бер казакъ авылында, бәлки әле, Тукай Махамбет Бөкәйханов уеныннан ләззәт алгандыр, Мостафа Күкебаев белән танышкандыр. Ул анда кымыз эчәргә, казакъ җырларын тыңларга барган.

Күкебаев дигәннән, ул үзе яратып укыган «Урал» гәзите редакциясе чыгарган рисаләне гомер ахырынача саклаган, казакъларның 1916 елгы күтәрелешендә катнашкан, бик күп шәхесләр белән якыннан аралашкан кеше. Музей хезмәткәрләре, расларлык документлар сакланмаса да, аның Тукай белән дуслыгына шик тотмый.

Тукайның сул як ярдагы Лбишенскидә булуы мәгълүм, әмма Җаекка барырга юлдаш табылмаганга, аны кире Дуанга алып киткәннәр. Тукай эзләре белән йөрергә теләүчеләр өчен кызыклы гына маршрут килеп чыккан: Җаек-Акҗаек-Дуана. Юл уңаенда гына, күлләргә тукталып, балык та тотып алырга мөмкин.

Монда, Чапаев музеена кереп, фаҗигале вакыйгалар белән танышырга мөмкин, борынгы болгарлар яшәгән Кожехарово (?), Бударино (?), Кушымга барырга була. Тукайның дуслары мөгаллимлек иткән урыннар бит алар.

Искитмәле ул Җаек, Тукай да аны матур һәм мәгърүр итеп күргән.

Җаекта Татар иҗтимагый үзәге бар һәм ул да милләтебез өчен файдалы әлеге башлангычларга үз өлешен кертә. Тукайның 100 еллыгына багышлап уздырыл-

ган конференция вакытында залда бер генә дә буш урын юк иде, бу Тукай үзгенең киң җәмгатьчелек белән актив эшләвен күрсәтә.

Җаектагы Тукай көннәреннән соң киләчәк эзләнүләребезнен кайбер җеп очлары да табылды. Җирле тарихчы Җ. Акбаев өлкә газетасында «Тукай һәм казакълар» исемле мәкалә бастырып чыгарды. Анда ул Тукайның казакъ зыялылары белән бәйләнешләре хакында яза. Шагыйрь төрле казакъ авылларына барып йөргән икән, кызганыч ки, әлегә бу фикерләрне дәлилләүче кәгазьләр юк. Безнең алда хәзер аларны табу, барлау бурычы тора.

Тукайның Җаекта танылган юрист Б. Каратаев белән аралашканлыгы билгеле. Хан тәхетенең варисы, Петербург университетын бетергән Б. Каратаев дала хуҗасы да була алыр иде, әмма аңа шәҗәрәсендә «калмык» каны агуын исенә төшергәннәр. Казакъстанның күп кенә иҗтимагый хәрәкәт эшлеклеләре нәкъ менә аның йогынтысында үскән, беренче гәзит-журналлар тууда, милли зыялылар барлыкка килүдә дә аның хезмәте бар. Кадетлар партиясенең Үзәк Комитетына керсә дә, Б. Каратаевның программ таләпләре шактый югарырак булган. Аның дәүләт думасында аграр мәсьәләләр буенча төпле чыгышлар ясавы, соңрак, әле революциядән соң да, казакъ җирләрен колонияләштерү буенча күләмле хезмәт язуы мәгълүм.

Тукай «Фикер» газетасында Б. Каратаевның дусты Гомәр Карашевның да язмаларын бастырган. Үз заманының философы, шагыйре, алдынгы карашлы укытучысы булган ул. Аның аркылы Г. Тукайның Х. Бүкәйханов белән танышуы да бик мөмкин эш.

Казакъ шагыйрәләре Маһирә Шакирҗанова һәм Газизә Шәриповага Г. Тукай иҗатының йогынтысын өйрәнү дә фәнни эшләребездә аерым бер тема булып торырга тиеш.

Тукай турында хезмәтләр язуга Х. Ямашевка бәйле материаллар да ярдәм итә ала. Студент казакълар аның Уфадагы фатирында еш булгалаганнар. Минем бу хакта архив материалларым да бар.

Гурьевта эзләнүләр үткәрсәк тә, яхшы булыр иде. Анда Тукайның якын дусты Ярулла Моради, туганнары Әүхәди һәм Әхмәди Габдулловлар яшәгән. Әле 1961 елга кадәр аларның кайбер туган-тумачаларында Тукайның хатлары да саклангын булган икән. Шагыйрьне сөймәгән Тулбаевлар да — шушы ук шәһәрнеке. Аларга бәйле материаллар табу да бик зарур.

Җәмбәйтедә туган ягы тарихын бик яхшы белүче туксан яшьлек Зәйнәп Закирова яши икән. Бәлки ул Тукайга бәйле нәрсә дә булса сөйли алыр.

Мин Җаекта бер легенда да ишеттем. Газизә Усмановaның бер хезмәтчесе бала тапканда әлеге фатирда Г. Тукай һәм аның мәдрәсә дусты Насретдин Хуҗаши да булган. Ул шул вакытта дөньяга килгән ир балага әтисе ягыннан ага туры килгән. Н. Хуҗаши үзе дә шигырьләр һәм, Тукай белән берлектә, карагруһ мөгаллимнәргә багышланган эпиграммалар язган бит.

Алар әлеге сабый хөрмәтенә икесе дә экспромт рәвештә икеюллык чыгарганнар һәм бүлмә ишегенә язып куйганнар.

Шул кадәр туры килүләр булсын әле: XX гасыр башында шул ук исем һәм фамилияле икенче бер каләм иясе иҗат иткән. Совет властеның беренче елларында Оренбургта яшәгән бу кеше адашына, чынлыкта да, туган тиешле.

Беренче Хуҗаши, туганнарының әйтүе буенча, 1906 елда тамак авыруыннан Җәмбәйтедә үлгән. «Әл-гасрел җәдид» журналында кайвакыт аның исеме белән тамгаланган икеюллыклар очраштыргалый. Ә бәлки башка мәкаләләр дә шагыйрь каләменә карыйдыр. Менә шуны да ачыкларга кирәк, минемчә.

Н. Хуҗаши Г. Тукай иҗатында билгеле бер эз калдырган кеше. Кайвакыт шигырь юлы белән, кайвакыт бергә язылган хатларда. 1906 елның 12 ноябрендә «Фикер» гәзитендә Габдулла Агишев култамгасы янында пензалы Насретдин Әл-Хуҗашиныкы да бар. Бу хәл аның вафатына бәйле датаның дөреслегенә шик уята һәм шулай ук ачыклауны сорый.

Тукайның дусты җәйләрен Уразгали исемле казакъ баеның балаларын укыткан. Миңа бу хакта С. Танабаева әйтте һәм әлеге байның туган-тумачасы исәнлеген дә хәбәр итте.

Шагыйрь Хуҗашины адашы җирләве билгеле. Мәрхүмнән калган кайбер әйберләрне, биш сум акчаны ул аның әнкәсенә Җаекка илткән.

Хуҗашиларның нәсел-нәсәбенә бәйле башка мәгълүматлар да бар һәм шуңа күрә мин киләчәктә табышларга юлыгырга да өметләнәм. Насретдин һәм Хуҗашиларны яхшы белүче Ф. Бархиевның оныгы Р. Бархиевның (Алимов) бүгенге көндә Казан университетында белем алуы ачыкланды. Анда Тукай кулъязмасы белән фоторәсем саклана.

Җаекта, Хабибуллиннар гаиләсендә, Тукай белән таныш Рәхилә Даутова карточкасы табылды. Тукай утырган кәнәфине, Тукайга хезмәт иткән дивар сәгатен алып килде ул. Рәхиләнең әтисе Фәхретдин тегүче һәм революционер булган икән. Социал-демократик юнәлештәге газетләр саклаган. Тукай аларга еш килгән, хәтта Рәхилә туташка үзенең сурәтен дә бүләк иткән. 1981 елдагы язмалардан аның Тукайның яшерен хәрәкәттә катнашуы турында сөйләве мәгълүм. Бу тема шаһадәтнамәләр туплауны таләп итә. Безгә Ф. Даутовның, хатыны Тамиләнең иҗтимагый эшчәнлеген ачыкларга кирәк. Тамилә ханымның артист буларак тәрҗемәи хәлен һәм ул йөргән драма түгәрәге узган юлны өйрәнү башка шәхесләргә бәйле нәрсәләрне дә ачарга ярдәм итәчәк.

Тукайның Казанда узган гомере дә әлегә тулысынча ачылып бетмәгән. Җентекле тикшеренүләр аны безгә торган саен ныграк ачачак.

## Уральскида — Г. Тукай үзәге

Әдәбият сөючеләребез яхшы белә: сөекле шагыйребез Казакъстанның Уральск шәһәренә кеп-кечкенә Апуш булып бара һәм аннан зуп-зур Тукай булып китә. Шул калада ул унике ел яши, белем ала һәм танылган шагыйрь, публицист, журналист булып җитлегә. Табигый ки, Уральскида Г. Тукайны хәтерләткән истәлекле урыннар да, аны хөрмәт белән телгә алучы затлар да җитәрлек. Менә шулар махсус үзәк корып, Габдулла Тукай исемен киң җәмәгатьчелеккә таныту эшен көчәйтә, аның тууына 110 ел, Уральскида яши башлавына 100 ел тулу уңаеннан, байтак файдалы гамәлләр башкара. Ул гамәлләрнең иң күренеклеләре:

1995. Декабрь. Өлкә туган якны өйрәнү музеенда Тукай залын ачу.

1996. Бу ел Көнбатыш Казакъстан өлкәсендә Тукай елы дип игълан ителә. Уральск шәһәренең Тукай яшәгән татар бистәсе «Габдулла Тукай микрорайоны» дип атала һәм шул исемдә видеофильм төшерергә карешелә. Шагыйрьнең юбилей кичәсе киң колач белән үткәрелә.

1996. Апрель. Өлкә музееның Тукай һәм Абай залларында Тукай заманы гореф-гадәтләрен, йолаларын чагылдырып, җырларын яңгыратып, халык бәйрәме оештырыла. Юбилей кичәсендә һәм халык бәйрәмендә өлкә хакимияте вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать коллективлары, күренекле башкаручылары, өлкәннәр һәм яшьләр катнаша, шәһәрнең татар җәмәгатьчелеге бу тантаналарда туган телебезгә һәм әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияләүне тормышка ашыра.

1996. Май. Уральскиның Тукай үзәге идарәсе әгъзалары Казанга килеп, Бөтендөнья татар корылтае вәкилләре белән очраша. Татарстанның фән һәм мәдәният учакларында, радио-телевидение һәм матбугат редакцияләрендә Уральск белән Казан мәдәни элемтәләрен җанландыру хакында фикер алыша, килешүләр төзи. Шагыйрьне Казакъстанда һәм дөньяда тагын да киңрәк таныту буенча Татарстан һәм Казакъстан хәбәрләндерү-мәгълүмат каналлары аша күпсанлы чыгышлар оештыра. Көнбатыш Казакъстан мәктәпләре, махсус урта һәм югары уку йортларында Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә нигез сала.

Тукай иҗаты рухи нигезләрен таныту максатында «Ислам: иман гыйлеме, әхлак, мәдәният» исемле китап бастырып чыгара.

1996. Июнь. Бөтендөнья татар корылтаеның Чымкәнт шәһәрендә уздырылган күчмә утырышында Уральскиның Г. Тукай үзәге эше хуплана, аңа булышырга тәкъдимнәр кертелә.

1997. Гыйнвар. Тукай үзәге мәшһүр шагыйребезгә багышлап, «Евразия мәдәниятенең чыганаклары» дигән халыкара конференция уздырырга карар бирә, аның эшендә әдәбиятчыларны, тарихчыларны гына түгел, фәлсәфәче, икътисадчы, эколог һәм бүтән тармак галимнәрен дә катнаштыруны күздә тота. Бу җыйналышка Татарстан һәм Башкортстан вәкилләре дә чакырыла.

*Уральск шәһәреннән алынган мәгълүматлар нигезендә бу материалны*
**Т. РАМАЗАН** *әзерләде.*

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАТЛАРЫ

**Бөек язучыбызның Садрый Максудига язган хатларының ксерокүчермәләрен безгә Гадилә ханым Айда җибәргән иде. Хатларны укуы бик авыр дию генә бу эшнең никадәр катлаулылыгын аңлатып җиткерә алмый. Гаяз Исхакыйның фикере кулыннан тизрәк йөргән. Ул кайбер хәрефләрне бер сызык белән ишарәләп кенә киткән. Ул заманда гарәп сүзләренең гаять киң кулланылуы да укуны авырайта. Соңгы хатларында моның өстенә төрек сүзләре дә күп керә башлый. Ничек кенә булса да мин хатлардагы сүзләрне бозмыйча, үзендә булганча күчерергә тырыштым. Аларны укырга миңа Габделхак ага Зәбиров та булышты. Тугызынчы дистә белән баручы бу агам революциягә кадәр башлангыч белемне мәдрәсәдә алган кеше.**

*Хатларны матбугатка әзерләүче*
**Розалина НУРУЛЛИНА.**

*16 гыйнвар, 1920. Прага.*

Садрый!

Синең хатыңны алып бик сөендем. Сине күптән бирле эзләсәм дә, һичбер йирдән хат-хәбәр юк иде. Җәй көне синең кайдалыгың хакында Япониядән Истанбулга Фаруг әфәнделәргә мәктүбләр яздым. Берничә мәртәбә телеграмма суктым. Һичбер җавап булмады. Сау идекенне, борадәр, әллә ничә кеше аркылы мәктүб белән Заһидтан кайдалыгыңны сорадым. Җавап булмады. Шуңарга күрә без сине әллә кайда большевик төрмәсендә череп ята дип исәбләп куйган идек. Шуның өчен синең табылуың миңа ләхе бәгъдәлмәүт[1] кебек тоелды. Фәукыльгадә[2] сөендерде. Инде килик андагы Себердәге, Уралдагы әхвәлгә. Беренче шул: синең гаиләң, бала-чагаң һәммәсе исәннәр. Мин аларны Казанда тугры китерә алмаенча, Уфада очраттым (былтыр). Аннан минем алдымда, әбиләреңнең киңәше берлән, Оренбургка киттеләр. Уфадагы дус-ишләренә, Акчуриннарга язган хатларына караганда, Оренбургта яхшы урынлашканнар. Аннан соң Оренбургның хәле начарланды. Бик күп кеше Тройски, Чиләбе, Петропавелга күчте. Закир әфәнде Рәмиев тә Чиләбедә калган. Соңра синең гаиләң, әбиләрең Оренбургтан чыкмый калганнар. Быел июнь числосында, бабаң гаиләсенең сүзенә караганда, алар һәммәсе калырга карар иткәннәр һәм калганнар. Исән-сау торалар да. Большевикларның соңгы айларда халыкка каршы хатты-хәрәкәтләре[3] шактый үзгәргәнгә, иншалла, хәзер дә бик тыныч иттереп, ач түгел көенчә, чәйне азрак эчеп, сыеныр затлары, дус-ишләре, кардәш-кабилә һәммәсе исән. Казаннан соңгы мәгълүмат май ахырында-июнь башында чыккан кешеләрдән. Аларның әйтүенә караганда, Һади әфәнде дә сәламәт. Әллә нинди бер мәктәптә мөгаллимлек итеп тора. Таныш-белешләрдән үлгән кеше Садыйк Галиев кенә. Казанның бөтен муллалары үз урынында. Атылу, үтерелү мөселманнар арасында бик аз булган. Булганы да безгә таныш шул кеше бер генә. Ашау-эчү Казанда ул кадәр шикле

---

[1] Ләхе бәгъдәлмәүт — гүрдән чыгарылган.
[2] Фәукыльгадә — гадәттән тыш.
[3] Хатты-хәрәкәт — тактика, тоткан юл.

түгел ди. Ләкин май аенда чәйнең кадагы өч йөз сум, шикәрнеке йөз сум булган. Икмәкне мөселман арасында һәрвакыт табып буладыр ди. Менә хәл анда фи әл-хәмидә[1] шул төстә. Үземә килгәндә, синнән аерылгач та кәкере-бөкере йөри, атлы-җәяүле мин 18 нче августта Казанга килеп чыктым. Ләкин Казанда бер кем юк өйдә. Нә Сәлах абзыйны, нә Бәдретдинне, нә Һади[2] әфәндене таба алмадым. Бер бардым, ике бардым, һәр вакытта юклар, бикле. Ахырда Һади әфәндене бикле өеннән бер хатын чыкты. Ул бик озак мине сораганнан соңында, имтиханны мин яхшы биргәнемнең соңында, Һади әфәнде бүген монда килә, ул дачада ята, йомышыгыз булса, миңа әйтеп калдырыгыз, диде. Мин аңарга үземнең кемлегемне һәм мәктүб барлыгын әйтеп, Һади әфәндене үземә чакырдым. Ул синең кодачаң Өммегөлсем ханым икән. Һади әфәнде мин көткәндә килмәде. Аннан соң килеп, мәктүбне кодачага бирергә кушып, язып калдырган. Аннан бер атнадан соң мин авылга да кайтмыйча Самарага килдем. Анда мәгълүм киңәш мәҗлесе булачак иде. Анда берни булмады. Бер-ике атнадан соң Уфага киттем. Анда Милли Идарә яңадан төзелгән. Һәммәсе эшкә керешкән. Сине көн дә-көн дә көтеп ята идек. Уфада синең гаиләңне күрдем. Һәммәсен сөйләдем. Ләкин, ник инде алып кайтмадың шунда, дип үпкәләделәр. Төрле дәлилләр белән, алып кайтмадым түгел, шулай мәслихәт булды, дип сөйләдем. Һич аңлата алмадым. Менә син кайткан, ул юк, диделәр дә тордылар. Уфада Милли Идарә янында эшли башладык. Государственное совещаниегә иштиракь иттек[3]. Анда таный башкортны гына. Татар, Төркестан мәсьәләсен аерыбрак өстерәп-өстерәп, конференцияләр ясап маташтык. Уфаның да хәле начарлана башлагач, Себергә күчәргә карар бирдек. Тройски, Чиләбедә туктау, анда куркынычлы төсле булганга, Петропавелга күченергә булдык. Һәм дә 12 октябрьдә иртә белән телячий вагоннарга төяләп киттек. Гәзитә чыгарырга уйлаганга, азрак хоруфәт[4] алдык. Анда безне шактый салкынча каршы алдылар. Имештер, ни уйлабтыр, Милли Идарәгә каршы компания. Андый хәшәрәтләрдән зарар күп. Берсе сездермәстән генә аяк чалырга маташкан. Анда барысы да бер телдә. Компанияләреннән Тарик бәк, Гомәр, Фуад сиңа бер киңәшкә дип бергә киләләр иде. Җыйнау җыелышып бер кечкенә генә гәзитә чыгарырга да берни җитми. Наборщик юк. Почтасы юк. Вакытында гәзитә чыгарып булмады.



*Гаяз Исхакый хаты үрнәге.*

Шул араларда Германиядә революция булып, анда солых мәсьәләсе туды. Мин шуны, Милли Идарәдә хәзерләнеп, гәзитәнең беренче номерына язырга тотындым. Моны бер кат аңлатып башлаган булып, фәкать бераз тарихи штрихлар да таба алып, файдаландым... (Моннан соң бер җөмлә танылмый — Р. Н.) Без Петропавел сәүдәгәрләреннән бер нәрсә оештырып акча җыйдырмакчы идек. Алар бернича ай алдап йөртteләр дә ахырдан гомумән ташладылар. Шуннан Милли Идарәнең кырык төрле мәҗлесләрен ясап, бернича кешедән мөрәккәб һәйәт чыгарып җибәрергә карар иттеләр. Берсе мин, берсе Фуад, берсе Гомәр. Миңа, әлбәттә, акча җыярга да йөкләделәр. Мин 24 гыйнварда Петропавелдан чыгып китеп, Себернең шулай бер рәттән

[1] Фи әл-хәмидә — мактарга яраклылары.
[2] Сәлах, Бәдретдин, Һади Максудилар — Садрый Максудиның агаэнеләре.
[3] Иштиракь иттек — катнаштык.
[4] Хоруфәт — хәрефләр.

акча теләнеп Харбинга кадәр ике йөз мең сум акча жыйдым. Ул акча Милли Идарә әгъзаларына фәукыльгадә зур күренгәнгә, әлләни кадәр әйбер юлларга сабышып, бик зур мәшәкатьләр тудырдылар һәм дә шулар өстенә тагы өч-дүрт кеше жибәрмәкче булдылар. Без Гомәр белән Фуадны көтеп, Харбинда бераз калдык та Солтан бәк ибне Бубины да озата барырга булганга, аларны Япониядә көтәргә булып, виза хлопотать итә торырга Япониягә киттек. Анда ун көн торыб, рәсми отказ алыб, кабат Харбинга кайтып киттек. Анда берәр атнадан соң Фуад килеп чыкты. Йөри торгач, чехлар белән инвалид булып китәргә юл ачылды. Без чехларның усрак солдатлары берлә солдат булып барырга Востокта[1] 3 нче октябрьдә пароходка утырдык. Пароход Марсельгә барырга булганга, без төрле юллар берлән Марсельдә төшеп калу ниятендә идек. Ләкин борып, Трксибтә пароходымыз Зитска[2] барырга әмер алды. Шулай итеп без чехларның мәркәзе Прага шәһәренә декабрь дүртендә килеб кердек. Шуннан бирле монда. Килгәч тә Франсиягә керү тәшәббесенә[3] тотындык. Аның өчен Фуадның паспорты юк. Минем, булса да, руслыгым көенчә торганлыгыннан, чехларның хәрби назариятының[4] киңәше буенча, безнең паспортларыбыз да бер генә еллык иде. Йөрергә керештек. Аның өстенә, безнең кулымыздагы кәгазьләрдән чехлар берәр нәрсә оештырып, аңарга заграничный паспорт төсе бирергә булдылар. Назарияттән назарияткә йөреп, кәгазьләребез бик төпле түгелгә, кичә тәмам сүзләрен рәсмиләштереп, кулымызга алдык. Инде шуларны күтәреп Франсия консулына барырга калды. Иртәгә шул консулга нәрсә илтсәк, кабул ачылыр. Файдалы бабларда гына белешеп бирәләр. Чехларның зур кешеләре, рәсмият ирләр, мәктүбләр бирәләр. Шуның берлә руслыкдан чыккач, бәлки визаны жиңел алырмыз дип уйлыймыз. Әгәр ул юл барып чыкмаса, әлбәттә, синең игътибарга калачакбыз. Син инде ничек тә тырышырсың. Эзли башлаганга бер ел тулыб әйләнгәндер-юктыр, сузылу мине шактый ялыктырды инде. Баргач, иншалла, июнь тәфсыйләтен[5] сөйләшербез. Фәкать һәрбер төбәк... (бер сүз танылмый — Р. Н.) файдаланып сине, инде һәйәтнең[6] рәисе сыйфаты берлән эшне дәвам иттерүдә бул. Чөнки безгә әүвәлдәге конференция шул вазыйфаны йөкләде. Акча мәсьәләсе шәп түгел. Курсның төшүе бик зур. Франсиядә алай ук түгел. Кулымыздагы иң ышанычлы нәрсә — алты кадак чамасындагы алтынымыз. Аны исән-сау Франсиягә алып бара алсак, иншалла, шактый гына франк алып була. Рус акчамыз да бар. Ләкин бик күбесе яшел иде. Хәзер аларны чех кронына алыштырып маташтык. Киләчәк мәктүбдә анда русның романовский акчасын алып бару файдалымы, әллә чехларның кронымы файдалыгы хакында бер мәгълүмат бир әле. Чөнки кулымыздагы чех кроны шактый күп булачак. Икесенең дә куәте хакында мәгълүмат бир. Тизрәк күрешергә теләп:

**Гаяс.**

Фуадтан бик күп сәләм. Галимдән бик күп сәләм.

Садрый!

Мин сау-сәләмәт. Яңа эш юк. Фәкать Нияз Максудидан гына бер мәктүб бар. Бүген җомга көн зиарәткә бардым. Гали-бәк, тагы бер төректән башка кеше юк иде. Безнең гаилә хәятымыз шул дип яза. Иртәгә шимбә көн. Сезне чакыруымыз хак. Фуад да килергә булды. Син онытa күрмә. Бик мәшәкатьләнеп, хафаланып кәефсезләнәчәк. Син сәгать җиде чиректән калма инде. Мин иртәгә комиссиягә барам да, аннан булып чыгып, Фуадны алып китәм.

Мәктүбләр хәерле булса, җыеп кил.

Хуш. **Гаяс**. 23 сентябрь, 1921 ел.

Адресым: *10 Мелахтон штр. Берлин. В В5, бей Брзезинский.*

*2 май, 1922 ел.*

Садрый!

Мин синең мәктүбеңне алдым. Андан элгәре генә Мидхәтне күргән идем. Ул сынакны үткән. Әллә кая Берлиннән читкә китмичә, фермәләре белән барып-

---

[1] Владивосток булырга тиеш.

[2] Трксиб, зитс — «порт-сәид, Триест» дип укылмыймы икән?

[3] Тәшәббес — инициатива, нийт.

[4] Назарият — министрлык.

[5] Тәфсыйлат — җентекләү.

[6] Һәйәт — комиссия.

килеп фигурант[1] булып тамак туйдыра икән. Бу арада бер фильмада бер актыда шау-шучылар кирәк булган икән дә, ул шаулый белгәнгә, шактый акча эшләгән. (Ягъни кәнсәнә 150 марка алган.) Шуннан бирле үзене күргәнем юк. Адресларын күндерә. Синең гаиләң килүе шәп булган. Култыкка бераз акча тәэмин итә алсаң, шуның өстенә бәлки берәр журналга Берлиндә язып торырга да айга ике йөз-өч йөз франклык эш таба алсаң, кәнең начар булмас иде. Хәзерге көндә монда тормыш, шөбһәсез, Финляндиядән очсыз. Аннан соң, Финляндиядә озак тору, үзең беләсең, кадерне киметә вә әлхасыйль[2] андый кадерле йиргә безнең ихтыяҗымыз бик зур. Монда килгәч, озын-озын сөйләшербез. Фатир мәсьәләсе хәзер ул кадәр авыр булмас. Буның 15 нче маенда өч бүлмәле бер фатир бушый дигәннәр иде. Шуны карап чыгармыз. Ул әле син килгәч тә өлгерәбез кебек. Егет ихтыярында булганда фатир табу авыр булмас. Хәбәр киткән саен ул мәсьәлә җиңеләя бара диләр. Минем карарым хәзергә монда калу. Тормышның очсызлыгы, акчаның юклыгы шулай мәҗбүр итә. Күңел белән анда торасым бик килә дә, булмагач, баш ими хәл юк. Мин монда ике йөз илле франкага (тормышлар шулай торса) тора алырмын дип уйлыйм. Ашау мәсьәләсе генә эчне пошыра. Бу мәмләкәттә ит ашамыйлар. Хафалананалар. Бер ай эчендә ашлары шул кадәр борчыды Палидрурога[3] бер мәртәбә барып ашарга әллә никадәр бирерлек хәлгә килдем. Икенчедән, монда большевизм. Большевиклар үзене бик каты хис иттерә. Халык фәкыйрь, сәләмә. Рур — большевик. Хосусән бу могаһәдә[4] тагы Рига большевиклары, тагы монда Русиядән зыяглы да күп. Үзе теләсә нәрсә эшләп ята. Кыямәт мәгънәвисе, тик куйган русның маташып ятуына табигый ачу килми хәле юк. Ләкин очсызлык. Тормышның технически ягының уңайлыгы боларның һәммәсен каплый.

Китап мәсьәләсе әле бер саглам казыкка бәйланганы юк дисәк, хәзер минем китапларымны бастыру эше кузгалды. Шул хакта сөйләшеп йөримез. Иртәгә сүз тагы озынрак, дәвамлырак сөйләшеп, бәлки, эшне бер төрле нәтиҗәгә китерермез. Дәреслекләр хакындагы мәсьәлә шактый авыр булырга охшый. Шуның өчен ул эш үзеннән-үзе... (бер сүз танылмый — Р. Н.) итә. Һәм дә ул хакта мин үзем генә хәл итә алмыйм. Акча булганда ул эшне үземез эшли алсак, бик тиз булачак икән. Ләкин бит, мөтәгассеф[5], кулда һич бер акча юк. Минем әйберемне күндерү хакындагы эшнең җиңеллегенә мин ышанып бетә алмыйм. Хәзер бит Франция (бит) хөкүмәте мәңгы[6] ителгән нәрсә чыгарылмый дип тә карый. Белгия хөкүмәте мине кечкенә мәмләкәткәр хисаплый, шул әле дип тә карый. Үзендән чуалчыклар ясый. Андан соң монда хәзер бер нәрсә кермәсен дип карыйлар. Шуңарга күрә син килгәндә поездга бер билет хакында ихтиразән[7] синең кулда акча булуны мин муафыйк күрер идем. Шуңа күрә син инде азрак түләп поездга бара торган иттерт. Ачкычлар Мостафада. Бер ачкыч берлә ике чемоданым да ачыла. Тагы бер зур йомыш. Минем адресыма «Ле темпс»ка өч айлыкка, йә алты айлыкка яздырырсың. Монда килгәч акчасын бирермен. Алты айлыкка яздырсаң шәп булыр иде. Миңа ул табигый кирәк. Моны май башыннан яисә 15 нче майдан яздырырсың (бер номеры 15 марка). Үтенәм. Моннан соң мәктүбләрне үз адресыма яз. Кайчан чыгуың да хәбәр ит. Әгәр монда берәр атна торырлык булсаң, атналап Мостафа да торган бүлмәне алып куеп булыр. Хуш. **Гаяс.**

*Кантслер, 80, бай Рюкерт, Шарлоттенбург, Берлин.*

Садрый! Синең кечкенә мәктүбеңне алдым. Син, Кадил әйткәнчә булмаса да, синдә шундый хис калдырган икән. Әхвәл рухың шундый булгандыр шул. Күңелсез дәфендә бит һәр килгән мәктүб шулай күңелсез хис калдыра. Фәкать акчалы мәктүб булса гына, кешене азрак күтәреп куя. Әйдә, бик үк төшәргә ярамый әле. Ни булса да булыр, Алла ярдәм итәр. Мин дә соңгы көннәрдә бик авыр хәлләр кичердем. Чәчемнең бик күбен агарттым. Хәзер әле әхвәл үзгәргән булмаса да, Казандан Әхмәт Хәсәндән (бисәктән-кушбака[8]) берәр йөз акча

---

[1] Фигурант — статист.
[2] Әлхасыйль — кыскасы, җыеп әйткәндә.
[3] Хәрефләре буенча шулай укыла. Берәр ресторан, ашханә исеме булырга тиеш.
[4] Могаһәдә — сүз бүлешү, килешү.
[5] Мөтәгассеф — кызганыч ки.
[6] Мәнгы — тыю.
[7] Ихтиразән — саклык йөзеннән.
[8] Бисәктән — искәрмәстән.

жибәрермез дигән бер хат алдым. (Число 12) инде хәзер барып житә булырга кирәк. Шуңарга кинәнеп тагын бер хат күндердем. Инде сезнең икътисади хәлегезгә килгәндә, минем сиңа бакый бер кинәшем бар. Ул да мондан гыйбарәт: беренче — Русиядән акча алдырту. Камилә ханым күптән түгел килгәндер, ул андагы хәлне белә. Анда хәзер аз-чук акча бар. Сезнең Гариф акча алды. Фуад да шул арада алды булырга кирәк. Тавыш бөердән чыга. Мин ала алмасам да, фәкать үземнең энем Әхмәт Хәсәннең ахмаклыгыннан гына ала алмыйм. Сезнең агай-эне дә бик үк шәп түгелдер. Ләкин бит Камилә ханымның анасы бар, сеңелесе бар. Алар, хатыннар йөрәге, бәгырьләрәк халык. Шуңа күрә дикъкать ит әле. Бу булмый торган эш түгел. Ләкин туп-туры үзеңә иттермә. Камилә ханым исеменә алдырт. Син Финляндияне бутама. Икенче бер мәсьәлә. Миңа бер төрек язучысы, Русиядә әсир булып торып, минем гәзитә-китапларны укып, мине сөйгәне хакында белдерә, Истанбулда шул арада чыгачак французча төрек гәзитәсенә француз мәкаләләрен сорый. Мин аңарга: мин яза алмыйм, бәлки Садрый бәк язар, дип яздым. Акча түләячәкбез, ди. Ул бәлки иш янына куш булыр иде. Һәм дә Истанбулда укылырга сәбәп булыб, башка эшләрегезгә дә юл ачар иде. Шуңарга бер мәкалә язып жибәр әле. Гәзитә сәяси офыкдыр, көндәлек төрек гәзитәсе исеменә Барис мәктүбләре дип тә яз. Адресы: Истанбул, Баб-гали жаддәсендә, жәмгыять китабханәсе васитасына. Кая Нури бәк. Бу тегге без белгән төрек түгел. Ижтиһад илә язучы.

Килик башка эшләргә. Муса 6 нчы февральдә чыккан. Ничек? Ләкин мәгълүм түгел. Ләкин, әлбәттә, бушлай гына чыгармаганнардыр. Аңарга адвокат яллаrга дип финләремез 20 мең фин маркасы жыеп алганнар. Әлбәттә, Агжал(?)ин күбен биргән. Петербургдагы Агжалның тегге таз тавարише Галяутдинов шул арада бик күп зарар иткән, ди. Алар анда әллә нинди Сәйфулласында бик күп фин акчасы тотып калганнар. Ул — фин акчасы, фин хөкүмәте эштән чыкты, дип игълан иткән булганнар. Мөхәммәт Синаһилар(?) да бик зур зарарга эләккәннәр, ди. Кан дус кешеләр булмасалар да, бездән акча сорамыйлар иде әле. Хәерле булсын.

Закир әл-Кадыйри Анкарага барып чыккан. Төрек кабиләсенә чыктым, дип йөри икән. Гомәр бәк кызуланып тагын Истанбулга таба хәрәкәт итмәкче була. Ләкин транзит визалары бирмиләр. Үзе дә артыннан рәтләп йөрми. Әүвәл «Гыйлме әл-виза» хакында бик надан. Шулай көтеп торып була дип белә. Валютаң булса, Франсиядә хәят очсызланып бара. Ләкин франк төшүенең мәгънәсен мин аңлый алмыйм. Бу да спекулянтка кирәк була һәм валюта шулай төшәргә тиеш микәнни? Я безнең имансыз даирә яшьнәп ята. Ләкин бу арада төркестанлылар, өстемездән большевикларга донос ясап торалар, дип төрек клубына мөрәҗәгать итделәр. Бу — Мәскәүдән алынган хатларда мондагы безнең шул эшне хәбәр биреп торуын язалар. Бигрәк вак безнең халык. Камилә ханымга, балаларга сәлам. Русиягә әһәмият бирә төшсәгез, әле бит хатлар язылса, йөри. Хуш. **Гаяс.**

*21 февраль, 1924 ел.*

Сәгадәт исбан укып ята.

*Салверништр, 14.8 бай Фаебикә, Берлин, 52.*

Синең хатыңны алдым. Агжалның мәктүбе дә кичә килеп чыкты. Бүлмәсен алыштырган булганга, хат бик озак йөргән. Үземнең әхвәл бик начар. Ягъни мәжбүри булган булмаса да, хәзер чигенә житте. Сәгадәт мәсьәләсе бик авыр. Аны нишләрмен инде. Белмим, өч айлык пансион түләнмәгән. Өч йөз илле, өч йөз алтмыш маркалар, ягъни сиксән биш доллар кайдан алырга да урын юк. Үзем бик арыдым. Әллә нишләдем. Хәтерем югалды. Бик онытам. Духтырга барган идем, мин булдыра алмый торган әллә ниләр сорыйлар. Йомырка аша... (бер сүз танылмый — Р. Н.) кыяр, һазә[1] боерыклар кыйлалар. Азис бик ябыкканмын. Ике елдан бирле бит вегитариан белән киләм. Тиешле аш атнасына бер дә эләкми. Шулар тәмам издe кәефне. Менә хәзер сиңа хат язам. Башым тонып тора. Кыйналган кебек. Вәхаләнки[2] бүген иртә торып әле бер нәрсә эшләгәнем юк. Тәмам инвалид булып каламмы инде. Минем нерваларым болай да бит бик зәгыйфь. Бу арада бик күп пошынырга туры килде. Алланың ләгънәте сукты — хуҗа хатын талап, бүлмәдән куып чыгарды. Аның белән генә калмыйча, яңа бүлмәмә барып, акча түләми, чәй эчә, төннәрен йөри, дип әллә ниләр язып ялганлаган да, анысына кертмәделәр. Дүрт-биш көн тәмам урамда калдым, эт

[1] һазә — бу.
[2] Вәхаләнки — чынлыкта.

булдым. Бәйрәм монда икегә бүленеп укылды. Гарәпләр, һиндстанлылар, иранлылар аерым укыдылар. Без төркиләр үз башымызга аерым укыдык. Хәер безнең белән бергә инглиз шпионнары, большевик шпионнары иштиракь иткәннәр [1] иде. Бик ямьсез булды. Халык бик аз иде. Бик хурлык булды. Үзем бу арада фильмга чыгарга язылып йөрим. Ләкин алырлар төсле күренми. Яшем дә карт, имештер. Белмим, ни булыр. Русиягә берничә китабымны җибәргән идем. Җавап та юк, хат та юк. Мондагы хулиганнар бик күп зур нәрсәләр язып торалар икән. Берничә көннән бирле монда җәй булды. «Совре. записки»га «Зөләйха»ның [2] тәрҗемәсен җибәргән идем. Шуны барып белеш әле. Мөмкин булса, Антиповка сөйләп, кертергә ихтыяр ит әле. Сәгадәт Бабравка кайтмады. Камилә ханымга, Гадиләгә, Наиләгә сәлам. Хушыгыз. Бу хаяттан бик туйдым. Гаяс Исхакый. 14 май 1924 ел.

Садрый!

Безнең хәл фәүкыльгадә начар бер юлга керде. Әлнәхмәнмирас [3] (?) дигән нәрсә Сәгадәтнең тәхсихатын [4] катыйгъ итәргә карар биргән. Моны бик кызуланып эшләгән. Мәгариф вәкиле бәкнең Хаккый Тарикъ бәккә вәгъдәсен ишеткәндә әмере вакигъ [5] алдында калдырырга уйлаганга охшый. Юк исә бер имтиханда муаффәккыятьсезлек [6] алтмыш шәкерт арасында һичберсе һич бер имтиханда вакигъа булмаганда, аның әрвәҗүзе [7] дәлил булудан бинаэ [8] вәсилә [9] генәдер. Хәзер буласы кадәре булган. Инде шуны тәэмин иттерергә генә кала. Хәмидулла бәк бу хосус[10]да иң соң тәкатька кадәр варачагым, дип вәгъдә биреп китте. Моны Тарикъ бәк тә шулай сөйләде. (Бер сүз танылмый — Р. Н.) мәгариф вәкиле бәк алдында да мине зур, сүзен саифлы[11] диләр. Хәзер шуларның барысына да хат яздым. Шуның өстенә Йосыфка да яздым. Боларның барысы да бер рәхим мәсьәләне тәгъмир[12] иттерү булды. Шул хосусда синнән үтенечем: беренче — Йосыфны күреп, Аннаҗан бәкне вә, кирәк булса, Гыйсмәт пашаны катырак кысрыклау. Икенчесе — Хәмидулла бәкне Гыйсмәт пашага барырга рижа итү. Хәтта Тарикъ бәкне күреп, аңардан Нәҗан бәктән мәсьәләне тәгъмир[13] иттерүен рижа итә алсаң, әлбәттә, нур гали нур булачак.

Өченче — шул мәсьәләне бераз кызулаб, миңа баштан мәгълумат бирү. Эшнең йөрүе алдан, искедән хәзерләнгәнгә охшый. Берлиндә вакытта башкаларны һичбер мәгълумат тәфтиш[14] итмәдекеләре хәлдә Сәгадәтне имтихан вакытында чакырып йөдәтеп бетергәннәр. Кырык төрле сөальләргә җавап яздырганнар. Шуның өчен бу муаффаккыятьсезлек бер әшәкелекне иттерер өчен бер вәсилә генә булган. Синдән бер рәхим — мөмкин кадәр мине тизрәк хәбәрдар итү.

Боларның тәшәббесләренең нәтиҗәсен бик көтәм. Бу эш муаффаккыятьсез чыкса, сез лязим[15] күрсәңгез, үзем дә барып чыгачакмын. Ләкин акчам бер дә юк. Без йөргәнче урын йөрер, дигән фикер берлән берлектә, әлбәттә, борчымассыз. Тагы бер фикер: сезнең доктор мәҗлесе рәисе Казым пашадан кәгазь дә булмас микән? Үзенә сөйләп кара әле. Бик зур хезмәт иткән булыр иде. Хуш. Камилә ханымлар сәламәтләр, синнән акча көтеп яталар. Гаяс. Сәгадәттән сәлам. 4 нче бәниһан 1926 ел. Адресым һаман — Кузгынчык.

Гәзитәдә Франция хозурында Габдрахман Шәфиев вафатыннан соң бик күп бастырылган хорусрат чыгып мохатарә[16] ителүләрне язалар. Дәхи[17] дә ул гаепле булып калды. Хатын бик сүзсез иде, шул тондырган икән.

---

[1] Иштиракь итү — катнашу.
[2] «Зөләйха» — Г. Исхакый пьесасының исеме.
[3] Әлнәхмәнмирас —
[4] Тәхсихат — гыйлем алу.
[5] Әмере вакигъ — чынбарлык әмере.
[6] Муаффәкыятьсезлек — уңышсызлык.
[7] Әрвәҗүзе —
[8] Бинаэ — нигез.
[9] Вәсилә — чара.
[10] Хосус — очрак, мөнәсәбәт.
[11] Сүзен саифлы — сүз иясе (остасы).
[12] Тәгъмир — төзү, төзәтү.
[13] Рижа итү — үтенү.
[14] Тәфтиш — тикшерү.
[15] Лязим — тиеш.
[16] Мохатарә — куркыныч.
[17] Дәхи — тагын.

Садрый!

Мәктүбенне алдым. Аннан бер көн генә элгәре Хакый Тарикъбәкне барып күргән идем. Ул да Фәтхи бер тыныч юклыгын белдергән вә мәсьәләне Метшар бәктә диган иде. Хәерләр, берәрсенә укытсын. Ләкин Метшар бәктә булып, анарга Йосыфның тәэсире юк түгел... Ул әле Йосыф берлә хисаплашмау дәрәҗәсенә дә менә алганы юк. Шуның өчен Йосыф шул Метшар бәкне тагы бер күреп сөйләшсә, начар булмас иде. Син анда күргәндә сөйләш әле. Бу — бер. Икенче: сезнең күрше — барымызның да дуст доктор шимбәгә мәсьәләне аңлаткан идем... Ул Кәзем пашадан... (бер сүз танылмый) сине сорарга булган иде. Ләкин шул көннәрдә булды бу, диган җаваплар килгәнгәчә мин анарга Зиннәт пашамыз юк өчен әүләдел нәфизаг [1] диган идем. Фәкать шул үтенечне яңартып китеп, фикер кәйфенә бер мәктүб язам... Син дә, үзенә мәсьәләне аңлатып, бер чара юлын кур.

Минемчә, төп сәбәбе безнең барымыз да белгән мәсьәлә. Тайибалем [2], Ләбиб бәк китте. Анарга да урлаг [3] бирмәүләре үзенчә бер интикам [4]. Киткән шәһәре берлә Измир арасында юл бик начар. Эшең (вадгуз — ?) болар гына икән. Балалар янына тагы шул арада барырга торам. Баек түгелләр. Ләбибнең Наилә [5] хакында андый сүзен һич ишетмәдем. Наилә бик кызыклы. Фәкать Ләбиб язганда авырый торган гына булган. Монда гаеп бик күп. Мин язганда бик таза иде. Гадилә [6] генә зәгыйфьрәк. Ләкин аныкы да шул мәктәбдән. Ябыклыгы гына. Чиреһмире юк. Сүз һәм тагы язам, чыгарырлар. Бастырмага алып барырмын. Я чан ахирено. Үзем Хөсәен Кәзем диган бер затның төрекчә лөгатендән шалих кыйсмен тәхвил [7] итеп ятам. (Бер сүз аңлашылмый — Р. Н.)... сәхифәле бер китапка йөз лира бирергә булды.

Хуш. Камилә ханымга сәлам. **Гаяс.**
*5 нче канун ае 1927 сәнә.*

*5.III.1927 (Варшава)*

Садрый!

Мәктүбенезне алдым. Бер никадәр вакыт кичте, яза алмадым. Монда без сау сәламәтләр. Гомәр килеп бик һәйбәт урынлашты. Әлегә әле тәртәсеннән чыкканы юк. Күпме көнгә җитәчәк, белмим. Ләкин ул минем өчен һаман бер курку булып тора. Өмидләремез юк түгел. Ләкин эшләр алай бик тиз йөрми, әлбәттә. Үзем төрекчәне бик укытам, 14 ләп шәкертем бар. Шактый маташтыра башладылар. Ләкин һичбер кулга алырлык китап юк. Һәр якшәмбе көнне мондагы мөселман колониясенең балаларыны бушлай укытам. Алары монда бик кызганыч хәлдә булган. Язу танытып җиткердем инде. Сәгадәт яз тәкъкыйленә [8] монда килде. Ләкин исәнлеге бер дә бай түгел. Дәрте бик начар. Гасабый бик күчек, вөҗүдкә [9] бик зәгыйфь. Монысында бер ай мөддәтендә[10] аз гына да алга китә алмады. Ашау-эчү хакында бер нәрсә кызганмасак та, күп нәрсә ашый алмый. Белмим, ни булып калыр. Тормышымыз начар түгел. Ләкин бүлмә мәсьәләсе монда фәүкыльгадә авыр. Бер ай эзләп, ике бүлмә таба алмадык. Айга кырык төрек лирасы түләп бер тәрәзәле кечкенә генә бүлмәдә торабыз. Әлбәттә, икемез өчен дә бик тыгыз. Варшава хәзер дөньяның иң такыр шәһәрләреннән берсе булырга кирәк. Монда шактый күп кавказ милләттәшләр вә диндәшләр бар. Шулар арасында Әхмәт Саликов та килде. «Вольный горец» диган русча гәзитәләрен монда чыгарырга уйлыйлар. Галимнәрдән... бәк дә монда килергә йөри диган хәбәр бар. Әлбәттә, калырга түгел. Болай гына, сәяхәткә. Төркиядән хат-хәбәр алмыйм диярлек дәрәҗәдә. Гәзитәләрне мыштым укыйм. Андагы әхвәлнең тышкы аратирәне, әлбәттә, беләм. Русиядән хат-хәбәр, әлбәттә, юк. Ләкин анда фәүкыльгадә фәкыйрьлек, сәфиллек[11] икәнен киткән Бари сөйли. Мәскәүдә тагын очертлар. Хатлар язгалап торыңыз вә кызыграк мәкаләләр булса, җибәргәләнез.

---

[1] Нәфизаг — сүзе үтә торган.
[2] Тайиб — яхшы, хуш
[3] Урлаг —
[4] Интикам — үч алу, үч кайтару.
[5] Наилә — Садрый Максудиның кече кызы.
[6] Гадилә — Садрый Максудиның олы кызы.
[7] Тәхвил — күчерү.
[8] Тәгътыйль — каникул.
[9] Вөҗүд — бу урында «гәүдә» мәгънәсендә.
[10] Мөддәт — вакыт.
[11] Сафиллек — түбәнлек.

Локман ике мәкаләсен җибәреп, хат та язды. Үзенең алга китүенә бик кәефләндем. Үзенә бик күп сәлам. Хушыңыз. Камилә ханымга махсус сәлам. Сәгадәттән бик күп сәлам. 5 нче март, 1927 нче. Безнең дус-ишкә сәләм. Йосыфкә[1] сәлам. Мәктүбен алдым. Җавап язачакмын. Гаяс.

Садрый! Синең мәктүбне кичә генә алдым. Мин хәзер Кузгынчылыкка[2] күчтем. Адресым: Кузгынчык, Хөсни пашаның кустекендә Гаяз Исхаки. Былтыр утырган Улын бәк каршысында. Кечкенә генә аерым өй. Көннәр суык булса да, һавасы яхшы. Бакчасы матур. Төрек Әүхәд бәк малай-салай кулына эш төшкәч, әлбәттә, бирергә уйламыйлар инде. Ул хисабның ике иллесе. Миндән «Шимал төрек әдәбияты тарихы» дип бер нәрсә язарга сораганнар иде. Шуның өчен бер өлеше бирелгән иде. Ул китабым хәзер язылып беткән, ләкин буш нәтиҗәсен борын бирмим дигән фикердә тора идем. Бу үзе бу китапка каршы. Хәмидулла бәк берлә куешымыз 300—500 арасында иде. Әгәр бирми торган булса, либеральный гәзитләрдә урын табармын дип өметләнәм. Ләкин аның артыннан тагы дүрт ай йөрергә кирәк. Хәзер Хәмидулла киләсе дип ишетдем. Иртәгә барып карыйм. Ләкин өмиде бик азайды. Кирәкмәгәнгә акча әрәм итәләр-итәләр дә миңа килгәндә ифтикар[3] ясыйлар. Имеш, акчам бер дә юк. Шул акчага хисаб иткән идем. Сәгадәт дәрелфөнүнендә[4] язылган. Тәмам мөштәни тели[5] булган. Ләкин дәресләргә язылырга тагы дәрес янына акча кирәк икән. Ул юк. Шуның өчен бу семистрда учет[6] (акча түләгәнгә генә бирәләр икән) әле алмау ихтималы бар. Нишләргә белмим. Һичбер зиһенем калмады. Үземнең дә бер нәрсәм дә юк. Кием-салым да бик бетте. Ашау-эчү дә бик тар. Җәгъфәрдән берничә лира алып күченгән идем. Ул да азагына килде. Син ничек тә миңа бу айлыгыңдан шул арада бераз акча җибәр әле. Эштән бераз тын алгансыңдыр. Аннан соң анда бурычка алып торырга йирлек тә юк түгел. Ничек тә тарсынып 30—35 лира кадәр бер нәрсә күндер әле. Бик лазем. Йосыф килгән икән. Юлда очрамады. Барып күрмәдем. Ул кеше өч мәктүбемә җавап язмады. Кирәкле сөальләрне ачык да калдырды. Хәерле булсын, бай булсак, язар әле. Гомәр миңа ике хат язды. Бик киләсе килә. Виза сорый. Мөмкин кадәр алып җибәрергә тырыш инде. Эш булу ихтималы, әлбәттә, юк. Ләкин монда икылы йирдә ач торыр.

Хуш. Камилә ханымга сәлам. Гаяс. 13 нче май, 1927 ел.

Акчаны госманлы банка аркылы җибәрмә. Я почта берлә, я башкасы аша.

**Гаяс.**

---

[1] Йосыф — Йосыф Акчура.
[2] Кузгынчылык — шәһәрнең бер төбәгенең исеме булырга тиеш.
[3] Ифтикар — ярлылык, фәкыйрьлек.
[4] Дәрелфөнүн — университет.
[5] Мөштәни тели — күнеле белән тели.
[6] Учет — зачет мәгънәсендә.

# РУХЫ НЫК — ҮРГӘ МЕНӘ

(РЕНАТ ЕНИКИЕВКӘ 60 ЯШЬ)



*Композитор Ренат Еникеевның рәссам Бакый Урманче ясаган рәсеме.*

1958 ел. Татарстан Композиторлар берлеге пленумында яңа язылган әсәрләрне тыңлау бара. Шунда Мәскәүдән килгән музыка белгече Наталия Шумская Ренат Еники әсәрен аеруча ошата. Авторының әле консерватория студенты гына икәнлеген белгәнлектән, мәйданга көчле иҗади шәхес аяк басуын тоеп, «Татар Җан Кристофы!» дип, Ромен Ролланның шул исемдәге романы баш каһарманына тиңли. Бу вакытта инде Ренат фортепиано өчен Сюита һәм Соната, квартет өчен пьесалар, хор өчен җырлар да иҗат иткән була. Аннан да кызыграгы — Ренатның унөч яшендә фортепиано өчен язган «Бию»е бик ягымлы, «чын безнеңчә милли», шул ук вакытта затлы һәм профессиональ яктан җитлеккән әсәр булып туа. Югыйсә ул чакта малай музыка мәктәбендә икенче елын гына укып йөри әле!

Мәскәү галиме сүзләре колакларга нык эленеп калган, күрәсең, музыка күгебездә яңа якты йолдыз кабынуына сөенгән зыялыларыбыз Еникидән аһ итәрлек зур эшләр көтә башлый. Еллар уза, ләкин концерт залларында, мәҗлесләрдә һаман Сара Садыйкова, Әнвәр Бакиров, Фәтхерахман Әхмәдиев кебек композиторларның гына җырлары яңгырап тора. Тамашачылар белән очрашканда Ә. Бакиров: «Өч йөзләп җыр яздым инде»,— дисә, Ф. Әхмәдиев: «Бу атнада ун җыр чыгардым, җәмәгать» — дип хисап бирә. Р. Еникинең кырык елдан ашкан иҗат гомерендә язган җырлары һәм романслары кырыкка да тулмый, аларын да теләсә кем җырлый алмый, профессиональ җырчылар башкаруын гына тыңласалар инде. Менә шунлыктанмы, бервакыт Ренатны мәҗлестә очраткан танышы:

— Күпне көткән идек синнән, өметләребезне акламадың! — дип көенечен белдерә.

— Кая инде миңа Фәтхерахманнар белән ярышу...

Шаяртыбрак җавап бирсә дә, Ренат иҗатташын чеметеп алырга һич тә теләми. Һәркем булдыра алганын бирә. Әхмәдиев әйбәт кенә җырлар иҗат итә, аларны баянда үзе бик оста башкара, сәхнәдән яңгыраттыра белә икән, бик хуп. Әмма кайберәүләр: «Фәтхерахман — татарның беренче композиторы!» дип җиңешә башласа, елмаймыйча калу кыен. Эш аның Композиторлар берлеге әгъзасе булмавында, хәтта белешмәлекләрдә телгә дә алынмавында гына түгел, билгеле. Эш — башкада.

Күптән түгел техник укымышлыларның бер мәҗлесендә утыра Ренат. Аны хуҗа кунакларына: «Атаклы композитор Еники!» дип тәкъдим итә. Күпләр:

«Композитор? Ә без аны нигә танымыйбыз? — дип гаҗәпләнә. Ренат көлемсерәп: «Аның каруы сез язучы Еникине беләсездер? — ди. — Әпсәләмовны, Хәснине?». «Әйе, беләбез!» «Чөнки сез хәреф танийсыз, укый аласыз. Ә нотаны кайсыларыгыз таный?» Мәҗлестәгеләр аптырап: «Чыннан да, шулай шул», — дияргә мәҗбүр була. Ренат исә фикерен дәвам итеп: «Балтыйк буе халыкларының, грузиннарның һәм әрмәннәрнең күпчелеге композиторларын да таный, чөнки алар мәктәптә үк башлангыч музыка белемен ала, нотаны укырга, нота буенча уйнап карарга да өйрәнә. Безнең татар җырны тавыштан гына отып ала, җырдан башка музыкага саңгыраурак!» — ди.

Уйлап баксаң, бик сәер халык шул без. Җыр яратабыз, җырчыларны телдән төшермибез, җыр иҗат итүче композиторларны да үз итәбез. Нигездә шуларны гына! Югыйсә җыр — музыканың бер жанры гына бит. Шунысы кызык, бер халыкны икенче халыкка танытуда җыр бик үк әһәмиятле урын тотмый да лабаса. Татарның да байтагы Бах, Бетховен, Верди, Григ, Моцарт, Шопен, Штраус кебек композиторларны белә, ә бит алар безгә дә, бөтен дөньяга да җырлары белән танылган дип әйтеп булмый. Музыканың төп байлыгы — җыр, диярgә инде бигрәк тә мөмкин түгел сыман! Менә шуны яшьтән төшенгәнлектән, Ренат инструменталь музыка язуга күңел салды да бугай. Туган халкының бүтән Европа халыкларыннан музыканың саф инструменталь жанрларында калышуы, бу тармакларда хәтта бушлык кына хөкем сөрүе аны борчыды, хәтта гарьләндерде дә кебек. Нәкъ менә югарыда искәртелгән 1958 елда татар музыкасы үсешенә күзәтү ясаган Яков Гиршман: «Камера ансамбленең мавыктыргыч сәнгате — соната, трио, квартет һ. б. әле тиешенчә үсмәгән, хәтта тәмам онытылган хәлдә кала бирә», — дип белдерде ич. Ренат канәгатьләнеп хәтерли: эскрипкә, альт һәм виолончель өчен Триосын ул шушы елны тәмамлады!

Башкалар тарафыннан салынган юлдан атлау уңайлы, чөнки беренчеләр инде хәтәр упкыннарны кичү, тарлавыкларны имин узу ысулларын ачкан була. Аяк астыннан очлы ташлар алып атылган, юл кырыйларына маяклар кадалган. Әмма үзен көчле санаган шәхесләр ачылмаган яңа киңлекләрне эзли, яңа биеклекләргә күтәрелергә хыяллана. Ренат та шундыйлар токымыннан, күрәсең. Аның ашкынулы омтылышы ничек барлыкка килүен белер өчен, бала һәм үсмер чагына күз салырга кирәктер.

Ул үзенең иҗат дөньясына ничек кереп китүен Татарстан радиосы аша тапшырылган бер әңгәмәсендә болай дип тасвирлаган иде:

— Беренче тапкыр музыка белән тәэсирләнүем балалар бакчасы белән бәйләнгән. Анда без уенчык музыка коралларында уйнап, хорда җырлый идек. Соңрак төрле музыка коралларында уйный башладым — бигрәк тә гармунны яраттым. Малай чакта ук атаклы музыкантлардан Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккинин, Оркыя Ибраһимова, Гайса Билаловларны тыңлаганым булды. Аларның үзенчәлекле уены мине таң калдыра иде. Аларга ияреп берзаман үзем дә бормаларны сиземләргә, көйләрне төрләндереп уйнарга тырыша башладым. Музыка коралын тоткан һәркем музыкант, һәр җырлаган кеше чын җырчы була алмый. Бу һөнәрләр кешедән таныш көйләрнең яңа, әле бүтән башкаручылар тапмаган ямен эзләүне таләп итә. Композиторлык ялгысы да, күрәсең, шул киң таралган көйләрне үзенчәлекле итеп уйнадан башланадыр.

Минемчә дә шулай. Ренат Еникинең музыка дөньясына килеп керүе язмышына туганчы ук язылган булган, күрәсең. Чөнки аның атасы гармун уйган һәм көчле тавышка ия булган. Әнисе инде өйдә яки мәҗлесләрдә генә түгел, радиога барып та җырлар яңгыраткан. Төскә-биткә чибәр, сәнгатькә һәвәс ханымны профессиональ белем алыр өчен Мәскәүгә җибәрергә теләгәннәр, әмма әнисе моңа юл куймаган. Профессиональ сәхнәгә аяк баса алмаса да, аны үзешчәннәр бергәләп спектакльләр куярга чакырган. Әнисе моңлы итеп «Сак-сок»ны сузып җибәргәндә нәни Ренат еламыйча түзә алмаган. Музыкага сизгер бала башта үзе курайга ия булган, аннары аны әти-әнисе кечкенә гармунлы да иткәннәр. Остара төшкәч, Ренат сәхнәгә дә күтәрелә башлаган, хәтта смотрларда катнашып, бүләккә дә лаек булгалаган. Бервакыт Республика олимпиадасында аның чыгышын тыңлап торган жюри рәисе Фәйзулла Туишев сөенеп: «Менә безне кемнәр алыштырачак!» — дип әйтеп куйган икән.

Музыка яратучы гаиләдә байтак патефон тәлинкәләре була, Ренат шулар аша күп кенә татар-башкорт җырларын ишетеп үсә. Җәйләрен авылга кайту аны табигатькә тагын да якынайта. Монда ул бакча казу, утын яру, иген игү һәм башка эшләргә дә тартылып китә, аннары, аңлашыла ки, яшьләрнең кич утырулары, җыр-биюле уеннарда катнашу, халыкның рухи байлыгын табигый рәвештә күңеленә сеңдерү башлана.

Ренат Казанның уникенче мәктәбендә укый, аның аскы катында исә педучилище урнашкан була. Педучилищедә музыка дәресе дә керә, менә шуның музыка укытучысы мәктәп балалары хорын оештыра, монда инде Ренат та җәлеп ителә. Әнә шулай малайның музыкага һәвәслеге һаман үстерелә бара. Гармун уйнаганда ул инде халык көйләренең үз вариантларын чыгарырга тырыша, чынлыкта бу — композиторлык иҗатының ялкынсы була, әлбәттә, ләкин әле малайга үзе чыгарган көйне язып куярлык нота белеме җитми. Шуңа да карамастан, ул мәктәпнең гармунчылар ансамблен оештыра һәм аның үсешенә җитәкчелек итә. Бу шөгыль үсмернең һәвәслеген тагын да кыздырып җибәрә — күңел ихтыяҗы аны ирексездән музыка мәктәбенә сукмак салдыра. Әмма Ренатка инде 11 яшь тулган, ул яшьтәшләреннән шактый соңга калган булып чыга.

Тик бу юлы да аңа бәхет елмая — музыка мәктәбендә ул талантлы педагог Нина Николаевна Карукес кулына килеп эләгә. Шанхайда дипломатик хезмәттә булып кайткан Карукес киң эрудицияле, дөнья музыкасын яхшы белә торган зыялы икән, ул укытуда үз методикасын сынап караган. Музыканы өйрәнүгә шулкадәр сусаган Ренатның табигый сәләтен һәм тырышлыгын абайлап алгач ул малайны шулкадәр ошаткан, хәтта уллыкка алырга да әзер булган. Шундый оста кулына килеп эләгү Ренатка 7 еллык музыка мәктәбе программасын дүрт елда узарга мөмкинлек биргән, ул имтиханнарда хәтта җиде ел буе гадәти курс үткән укучыларны да узып, иң югары билгене казанган.

Музыка мәктәбе!ндә укыганда Ренатның күзләре янадан ачылгандай була — классик музыка үрнәкләре белән танышканнан соң, ул анда татар милли музыкасында очрамаган, үзенә таныш түгел әллә нинди формалар, жанрлар барлыгын белеп, чын-чыннан гаҗәпләнә.

Ренат Н. Карукесның бай ноталар китапханәсеннән иркен файдалану аркасында, бик яшьли музыка җәүһәрләре белән таныша, дипломат ханым чит илдән СССРда тыелган музыка ноталарын да алып кайтканлыктан, «тимер пәрдә» тышындагы бай хәзинә дә аңа килеп җитә. Остазы аны пианист итеп үстерергә омтыла, әмма Ренат инде шул чакта ук үзе музыка иҗат итү белән мавыга, мәктәп елларында төрле пьесалар иҗат итә, соңрак ул фортепиано һәм оркестр өчен язган концертын сөекле остазы Н. Карукеска багышлый. Нәкъ менә шушы остазы аңа композитор булу өчен белемен тагын да тирәнәйтү кирәклеген дә аңларга булыша.

Казан музыка училищесендә ул Ю. В. Виноградов җитәкчелегендә композиция сабакларын ала (1952-1956). Тәҗрибәле, җитди педагог сәләтле шәкертен төрле яктан үстерер өчен аңа төрле жанр һәм формада иҗади күнекмәләр ясата. Бу эш һәр жанрның үзенчәлеген тоярга, аның табигатен аңларга булыша. Виноградов яшь егеткә профессиональ белем бирүдән тыш, нык ихтыяр көче булдырырга да ярдәм итә — чигенмәскә, каршылыкларны җиңәргә рухландыра. Еники фикеренчә, Ю. Виноградов аның профессиональ үсеше өчен ныклы нигез сала.

Казан консерваториясендә Ренат А. Леманның композиция классында укый. Бу дәвердә ул полифония буенча төпле белем биргән профессор Генрих Литинскийдән аеруча зур ярдәм ала. Литинский аңа полифонияне милли җирлек белән тоташтыру серләрен ачыкларга булыша.

Без композиторлар тормышын һәм эшчәнлеген гадәттә яхшы белмибез. Язучылар әнә үзләре хакында үзләре яза, бер-берсе хакында да матбугатта мәгълүмат чыгарып тора. Композитор халкы андый һәвәс түгел, аларга биш сызыклы дәфтәр бирегез дә шунда алар без аңламый торган ниндидер койрыклы төрткеләр төшереп, дөньяны онытачаклар. Югыйсә алар тормышында да җәмәгатьчелек игътибарын тартырлык кызыклы вакыйгалар, көенечле яки сөенечле хәлләр күп булырга тиеш. Иҗат ул утырып шәп көй язу, аны тамашачылар алдында яңгыратып, алкышларга күмелү генә түгел. Моны барыбыз да аңлый, билгеле, ә менә Ренат Еникинең иҗат юлы ничегрәк дәвам итүен күпләр, мөгаен, белмидер.

Ренат тормышы (ул 1937 елның 13 июнендә Казанда укытучы гаиләсендә туа) һәм эшчәнлеге илдә тоталитар идеология тантана иткән дәвергә туры килә. Дөрес, музыка теле шартлырак булганлыктан, цензура кысымы аларга, язучыларга караганда, йомшаграк кагыла. Әмма татар музыкасы хәяте бик озак тоталитаризм эчендәге тоталитаризмга дучар була ич. Нәҗип Җиһанов — талантлы, республикабыз мәдәнияген үстерү өчен гаять күп көч түккән олы шәхес булса да, аның яшь сәләтләрне җитештерү, аларның иҗатын оештыру тырышлыгын бары уңай яктан гына бәяләп булмый. Казан консерваториясе ректоры, Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе вазыйфаларын дистә еллар буе өзлексез

башкаруы, шул ук вакытта РСФСР, СССР композиторлар берлекләре идарәләре әгъзасе, Татарстан, РФ, СССР парламентлары депутаты, Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре комитеты әгъзасы булып сайлануы, өч мәртәбә СССР Дәүләт премиясен казануы аркасында (аның дәрәҗәле вазыйфаларын һәм бүләкләрен санап бетермәдек!) ул искиткеч зур абруй казана, аның фикере теге яки бу татар композиторы иҗатын бәяләүдә, аңа уңайлы иҗат микроклиматы барлыкка китерүдә хәлиткеч шартка әйләнә. Аның тәэсире беренче адымнарыннан ук зур иҗади потенциалга ия икәнлеген күрсәтеп өлгергән Ренатка да тими калмаган.

Карукес хәзинәсендәге дөнья музыкасы классикасын, Көнбатышта дан казанган замандашлары җәүһәрләрен фортепианода уйнап танышу Ренатның зәвыгын һәм тоемын байтак иҗатташларыныкыннан өскәрәк чыгаруы табигый. Шуңа күрә аның иҗади эзләнүләре кыюрак һәм-аларныкыннан күпмедер аерылыбрак торуы да гаҗәп түгел. Әмма консерваториядә моңа гаҗәпләнүчеләр, хәтта өнәмәүчеләр дә табылган, эш аңа «формалист», димәк, данлы совет сәнгатенә ят, дошман бәндә ярлыгы тагуга, консерваториядән куып чыгаруга кадәр барып житә язган. Бу гауга, шөкер кыенлык белән булса да басылган, консерватория дипломы кесәгә салынган. Әмма ул да түгел, яңа чуан тулган: Еникине Композиторлар берлегеннән чыгарып атырга кирәк, имеш! Сәбәпләре дә үтә житди: гаиләсен таркаткан, язмый да! Ренат башына ишелеп төшкән мондый бәлаләрне киң җәмәгатьчелек кайдан белсен? Аларны Ренат ялгыз башы гына күтәрергә мәҗбүр. Менә шундый шартларда Еникинең Беренче сонатасы языла. Аны тасмага язып алырга килгән Мәскәү бригадасы житәкчесе И. Дудкевич: «С. Прокофьевныкыннан соң мондый әсәрләр язылганы юк иде әле!» дип авторны котлый.

РСФСР Композиторлар берлеге рәисе Г. Свиридов Казанга килгәч жирле иҗатчыларның әсәрләре белән танышырга тели. Аңа байтак музыкаль язмаларны тәкъдим итәләр. Мәшһүр композитор, Еникинең Беренче сонатасы яңгырый башлагач ук, җанланып китә, аннары ихлас күңелдән хуплап, авторның кулын кыса. Г. Литинский исә шәкертенең бу әсәрен Мәскәүгә, яшь композиторларның Бөтенсоюз конкурсына алып китә. Монда да бу соната зур уңыш казана: жюри рәисе А. Хачатурян аны тәүге турда ук беренче урынга куя. Бу хәбәр үзенә килеп ирешкәч, Н. Җиһанов гадәттән тыш «кайгыртучанлык» күрсәтә. Автор яшь әле, янәсе, көтелмәгән уңаштан башы әйләнеп китәр дә үсештән туктар, аны артык калкытмау файдалырак булыр! Мондый «кайгыртуның» нәтиҗәсе билгеле инде — Беренче соната конкурс программасыннан төшереп үк калдырыла. Еникинең Кыллы квартеты Мәскәүдә шулай ук мактала, ләкин Татарстан ләм-мим дәшми. Яшь композиторны уңышлардан башы әйләнеп китүдән «саклыйлар!»

Ренат шундый «кайгыртучан» мөнәсәбәттән «илһамланып», «М. Җәлил истәлегенә» вокаль-симфоник поэмасын язгач, үҗәт егеткә карата үсендерүнең яңа алымы кулланыла: әлеге әсәрне биш ел буе яңгыраттырмыйлар! Хәсән Туфан юбилеендә аның шигыренә нигезләнеп иҗат ителгән музыканы уйнатмыйча калдыру читен булганлыктан, теш кысып, риза булалар, әмма юбилей кичәсен декабрьдән гыйнварга күчерттерәләр. Уяу «кайгыртучылар» яхшы белә: гыйнварда студентлар хоры каникулга таралачак, әсәр ансыз башкарыла алмый. Кайгыртырга булгач, кайгыртырга кирәк инде!

Бераз музыкаль грамотасы булган кеше чамалый: башкаручылар тарафыннан яңгыратылмаган шартта автор әсәренең ничек килеп чыгуын анык белми, шунлыктан аның җитешсезлекләрен бетерүгә дә керешү читен. Иҗатың лаеклы бәясен алмаса, ничек үсәсең? Укучы, тыңлаучы, тамашачы тәэсирләнүен күрмәсә, ишетмәсә, язучы һәм композитор, рәссам һәм артист яңа эшләргә ничек илһамлансын? Мондый шартларда инде Жан Кристоф булырга туган илаһи затның да, сәләте йомылып, гадәти миллионнарның берсе булып кына калуы хак башында. Бәлки кемгәдер үзенә көчле көндәш булырлык иҗатчы үсүе кирәкмәгәндер дә? Тоталитаризм иҗат кешесен әнә шулай буа, имгәтә ала. Ләкин Р. Еники бирешергә теләми, агуга каршы дәваны совет тоталитаризмының атасыннан эзләп табарга — В. И. Ленин хезмәтләрен укырга керешә, үзенә бик кирәк җирләрен исә ятлап ук ала. Үзен хөкем итәргә багышланган җыелышларда тиздән ул акыл өйрәтүчеләр авызын Ленин сүзләре, фикерләре белән генә яба башлый. Демогоглар тәмам аптырашка кала. Сүздә генә ленинчы булса ярар иде, иҗатында да тәмам дагаланган сәясәтче икән ләбаса Еники: Икенче сонатасын Ленин тибындагы беренче ортодоксаль татар большевигы Х. Ямашевка багышлый! Аннары — «Партия турында җыр», «Ленин яшь», «Кокушкино ягы» китә! «Җәлил истәлегенә» вокаль-симфоник поэмасы исә «Җир әйләнә, Коммунизм ягына әйләнә!» дип тәмамлана.

Еники әсәрләрен «ни өчендер» (!) Д. Шостакович югары бәяләвен, берничә тапкыр аларның авторын якларга тырышуын да белгәнлектән, ниһаять, Н. Җиһанов бервакыт: «Еникидә инструменталь башлангыч бар, тыңларга кирәк»,— ди. Тагын бер ыгы-зыгы булып ала әле бу елларда — күренекле режиссерыбыз Нияз Даутов Ренатны опера яки балет язарга җәлеп итмәкче була, аны потенциаль автор исәпләп, бергә эшләргә тели. Н. Җиһанов исә Еникине опера, балет язучылар исемлегенә кертергә ашыкмый. Камера музыкасын белсә дә, Еники симфонист түгел, янәсе. Театр тирәсендәге интригаларны яхшы чамалаган Ю. Виноградов шәкертенә урынлы киңәшен бирә: «Опера, балет язып маташа күрмә, вакытыннан элек инфаркт алырсың»,— ди.

Дөнья тар күңелле кешеләрдән генә тормый, билгеле. Уфа музыка фестивалендә Еникинең фортепиано һәм оркестр өчен Концертын (1987) тыңлагач, атаклы башкорт композиторлары З. Исмәгыйлев белән Х. Әхмәтев аңа югары бәя бирәләр. Соңгысы: «Дөньядан бу әсәрне тыңламыйча китү минем өчен зур югалту булган булыр иде!» ди.

Бу әсәрнең беренче варианты консерваторияне тәмамлаганда (1961) диплом эше итеп языла. Бу жанрда Р. Яхин, А. Леман, татар халык көйләрен файдаланып, беренче әсәрләрне инде иҗат иткән булалар. Еники исә тулысынча үз хыялы нигезендә генә иҗат итәргә тели. Концертын милли музыкабыз традициясендә һәм рухында язырга омтыла. Аны тыңлаган Д. Шостакович әсәрнең материалы әйбәтлеген, образлары, музыкасы күңелгә ятышлы булуын әйтеп хуплый, әмма анда әле техник җитешсезлекләр дә булуын искәртә. Еники аның яңа редакциясен тудыру өчен күп эзләнә. Әсәрнең соңгы варианты Казанда, Уфада, Мәскәүдә И. Шерман, Ф. Мансуров, Н. Рахлин, В. Есипов кебек дирижерлар җитәкчелегендә уйнала. Аның Уфада уңыш казануына пианист Марат Сиражетдин да оста уены белән өлеш кертә.



*Сулдан уңга ирләр: Әмирхан Еники, Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Ренат Еникеев.*

1981 елда Ренат СССР Композиторлар берлеге идарәсенә сайлана. Ренатка якташларының әсәрләрен Мәскәүдә уза торган рәсми концертлар программасына кертер өчен күпме үҗәтлек күрсәтергә туры килә. Югыйсә шулар әле кичә генә Казанда типкедә йөргән Еникинең Мәскәүдә күтәрелеп алынуын аңлый да, кичерә дә алмый. И бу иҗат дөньясының сәерлекләре!

Хәер, татар композиторларының һәммәсен дә тар күңеллелектә гаепләү гадел булмас иде. Ф. Әхмәтев, М. Яруллин, Р. Билалов, музыка белгечләребездән З. Хәйруллина, Й. Исәнбәт, Н. Әлмиева, Г. Касаткина һ. б. Р. Еники иҗатына югары бәя бирәләр, матбугатта һәм радио-телевидениедә аның иҗатын

җәмәгатьчелеккә таныту өчен җылы фикерләрен әйтәләр. Еники иҗатын яратып һәм тирән анализлап чыгыш ясаучы Галина Касаткина белән Наилә Әлмиева хезмәтләре миңа аеруча кыйммәтле тоела, шунлыктан бу очерегымны язганда мин бик рәхәтләнеп алар фикеренә дә таяндым.

Еники иҗаты белән тәфсиллерәк танышуны аның сонаталарына тукталудан башлау хәерле, чөнки татар фортепиано сонатасының ныклы нигезгә утыртылуы һәм чәчәк атуы нәкъ менә Ренат әсәрләренә бәйләнгән.

Соната — бер яки ике уен коралы өчен языла торган инструменталь әсәр, гадәттә, ул уртак сәнгати фикер берләштергән үзара капма-каршы өч-дүрт өлештән укмаша.

Р. Еники фортепиано өчен Беренче сонатасында (1967) ашкынулы заманыбызның каршылыкларын гомумиләштереп, аны егерменче йөз музыкасының матур традицияләре белән куша һәм, милли колорит белән сугарып, яңа юлдан атлый. Соната каһарманы тормышка актив ургылып керә, көрәш кайнарлыгын һәм матурлыкка чуму шигъриятен җитә тоя. Аның яшәвенең бөтен мәгънәсен якты идеалларга омтылу тәшкил итә.

Соната өч өлештән гыйбарәт. Аның кабатланмас үзенчәлеге яңалыгы традицион кысаларга ничек тулуында, шәкелләнүендә үк чамалана. Гармония, фактура һәм башкаларның заманча сурәтләү чараларын файдалану, әсәргә ачык милли буяулар иңдерү, сонатаның буеннан-буена үтәли сузылган бердәй аһәңнәр яңгырату тыңлаучыны әсәр уйналып беткәнче үз әсирлегендә тота. Менә шул сыйфатлар Г. Свиридов, Дм. Кабалевский, А. Хачатурян кебек күренекле композиторларның игътибарын җәлеп итә һәм алар Р. Еникинең Беренче сонатасына югары бәя бирә. Казанда пентатоник музыка мәсьәләләренә багышланган халыкара конференция барышында әлеге әсәрне тыңлаган Мажарстан музыка белгече Ласло Викар исә: «Бу соната, шөбһәсез, авторның зур уңышы, бары шуны тыңлар өчен генә дә Советлар Союзына килүем аклана!» — дип белдерә.

Мәгълүм ки, бер халыкның композиторы әсәре башка милләт тыңлаучылары күңелен дә били алсын өчен, аның гомум кешелек кыйммәтләренә милли төсмерне тиешле нисбәттә сеңдереп бирә алуы сорала. Ул әсәр заманча музыкаль сурәтләү чараларын урынлы кулланып язылырга, мәгълүм фикерләрне һәм хисләрне куе буяулар белән үзенчәлекле һәм оста чагылдырырга тиеш. Р. Еникинең Беренче сонатасын телгә алганда кайбер музыка белгечләре аның аерым сыйфатлары дөньяның мәшһүр композиторлары әсәрләрен хәтерләтә, ләкин Еники аларның өйрәнгече, мөрите хәленә төшми, җитлеккән оста буларак үз юлыннан бара, дип басым ясыйлар. Беренче сонатаның башкаручылар һәм тыңлаучылар кызыксынуын даими уятып, аның Мәскәү, С.-Петербург, Балтыйк буе, Кыргызстан, Башкортстан, Төньяк Осетия һәм башка якларда уйналып торуы, уку йортлары программасына кертелүе авторның зур иҗади уңышы хакында сөйли. Бу фикерне сәнгать фәннәре кандидаты Г. Касаткинаның «Советская музыка» (1970, № 10) журналында Беренче сонатаның үзенчәлекләрен, кыйммәтен әтрафлы анализлап мәкалә бастыруы да, сонатаның Мәскәүдә «Советский композитор» нәшриятендә дөнья күрүе (1971) дә раслый.

Р. Еники 1971 елда — Икенче (Х. Ямашевка багышланган), 1972 елда Өченче сонатасын иҗат итә. Икенче сонатасын тыңлаганнан соң матбугатта: «Бу әсәр сәнгатьчә ниятне ачык контрастларда эзлекле һәм ышандырырлык итеп сурәтләве белән аерылып тора. Еники фольклор һәм композиторлык башлангычын, заманча һәм традицион милли чараларны кирәгенчә синтезлауга ирешкән, шуның аркасында аның Икенче сонатасы чын-чыннан заманыбыз рухына авазлаш яңгырый һәм тыңлаучыга эстетик канәгатьләнү һәм шатлык китерә», дип билгеләп узылды.

Икенче соната халык җыры «Анам кабере янында»га нигезләнгән. Композитор кыска һәм кырыс көйнең потенциаль мөмкинлекләрен ачып, аның төрледән-төрле вариацияләрен иҗат итә. Әсәр, әлбәттә, әлеге көй җирлеге белән генә чикләнми. Анда әлеге көйгә капма-каршы моң да яңгырый. Татар язмышында афәтле эзен калдырган ике башлы каракош образы матурлыкка омтылу, яшәү дәртен чагылдыручы мотивлар белән көрәшкә ташлана. Яшәү омтылышын гәүдәләндергән милли моң ят аһәңнәр тарафыннан кысрыклана. Финал өлешендә каракош образы аеруча калку сурәтләнә. Шул ук вакытта автор киеренке музыкасы белән батырлыкның үлемсезлеген, кадерле идеаллар өчен көрәшнең котылгысызлыгын да тасвирлый.

Өченче сонатасында композитор кеше тормышы дәверләрен гәүдәләндерә. Әсәр полифоник (күп тавышлы) формада язылган, аңа психологик тирәнлек, сонатаның буеннан-буена сузылган драматизм үсеше хас. Әсәрнең якты, күтәрен-

ке рухта тәмамлануы кеше гамәлләренең мәгънәле һәм үлемсез икәнлеген басым ясап раслый.

Татар халык музыкасы — бер тавышлы, күп тавышлы әсәр язу аның милли җирлеген юкка чыгара, дигәнрәк караш яши иде бездә. Р. Еники фикеренчә, полифония табигатьнең үзендә, татар да шул ук табигать кочагында яши. Күккә карасаң, айны һәм йолдызларны күрәсең. Бу инде — полифония. Кеше тормышы да ике башлангычтан (ир һәм хатын) гыйбарәт, димәк, полифоник. Мәскәүдә Илһам Шакиров концертын тыңлагач, атаклы музыкант М. Растропович: «Карурман» җырында яшерен полифония бар, ике тавышлылык сизелә»,— дип белдерә.

Р. Еники полифония татар музыкасының миллилеген бетерә дигән фикер белән мотлак килешми.

— Полифониясез музыка бертөрлерәк була,— ди ул.— Сәнгатебезне баетыр өчен күптөрлелек кирәк. Төрне үзгәртү, күчешләр ясау исә теманы төрле яктан ачарга булыша. Мин дә милли үзенчәлекне саклау тарафдары, милли сыйфаты юк икән, миңа андый музыка кирәкми. Әмма миллилекне полифониядә дә сакларга мөмкин. Ул гармонияне ничек эшләүгә бәйләнгән.

Белгечләр әйтүенчә, полифония Р. Еники иҗатының органик өлешенә әйләнгән, ул полифония алымнарын яшьтән үк, аның принципларын яхшы белеп файдалана. Еники шул ук вакытта татар милли композиторы да булып кала, чөнки ул әсәрләрендә тулы канлы татар мелодик интонациясен саклый, аның иҗатында моңыбызның сулышы өзелми.

Белгечләрнең тагын бер мөһим сөземтәсе: Еникинең сонаталары да, башка жанрдагы әсәрләре дә бер-берсенә охшамаган икән.

— Безгә Бетховенның һәм башка классикларның барлык сонаталары таныш,— ди ул.— Бетховенның даһилыгы да шунда — ул башкаларны да, үз-үзен дә кабатламый. Мин яңа әсәр язганда элгәреләрне кабатламас өчен, шул жанрдагы классиклар мирасы һәм тагын бик күпләрнең әсәрләре белән тулаем танышам. Бездә алай «җәфаланмыйча», бары язу белән генә шөгыльләнүче талантлар да бар. Мин, игезәк әсәрләр тумасын өчен, киң һәм тирән хәбәрдарлык кирәк дип исәплим. Дөрес, иҗади сәләтең юк икән, мәгълүматлы булу гына уңышсызлыктан коткара алмый. Әмма тапталмаган юлдан атларга шул нәрсә бик нык ярдәм итә.

Ренатның күп нәрсә белән кызыксынуы, даими эзләнеп яшәве исә балачагыннан ук килә. Әнисе аңа башлангыч сыйныфта укыганда ук Г. Тукай китабын бүләк итә. Малай аны укып кына калмый, байтак өлешен ятлап та ала, соңрак шагыйрьнең тулырак басмалары белән дә таныша, әмма балачак дәвере бүләген ул әлегәчә кадерләп саклап килә.

Тагын шунысы кызык, Ренат шәһәрдә туса да, аның татарлар гына тупланган бистәсендә яшәгәнлектән, балачагында урыс телен начар сукалый, хәтта училищегә кергәндә шул фәннән икеле дә ала. Әмма шул кимчелеге аны татар мәдәнияте өчен саклап та кала: ул иҗади шәхес, сәнгатькә хезмәт итәрлек эшлекле шәхес төсендә җитлегүнең иң хәлиткеч баскычында татар җирлегендә нык басып тора, туган мөхите һавасын сулап, гореф-гадәтләрен, әдәбиятын-сәнгатен, гомумән, бөтен милли рухын һәр күзәнәгенә сеңдереп үсә. Мәктәп китапханәсендә ул укымаган бер генә татарча китап та калмый. Мин беләм: кайбер татар язучылары «Казан утлары» журналын да даими алдырып укып бармый. Р. Еники язучы түгел, әмма ул бу журналны «Совет әдәбияты» дип аталган дәвереннән башлап бүгенгәчә җыеп, шуның белән азыкланып килә. Училище елларында ул инде урыс телен дә яхшылап өйрәнә, бөтен дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән танышуга да зур әһәмият бирә. Күпчелек язучыларның төшенә дә кермәгән «Советская музыка» журналы да аның даими танышып бара торган басмасына әйләнә. Менә шунлыктан ул Л. Толстой, А. Чехов, И. Крылов яки Ф. Хөсни, Ә. Еники, Н. Фәттах кебек танылган язучылар иҗаты хакында гына түгел, әле аз билгеле шагыйрь һәм әдип хакында да иркенләп фикер йөртә ала. Тегеяки бу шәхесне, язучымы ул, композитор яки галимме, күпбеләмлеген күрсәтер өчен генә түгел, фикерен тулырак ирештерер өчен телгә ала Ренат. Әгәр сүз аның идеал иткән Бах, Моцарт, Чайковскийларга кагыла икән, ул инде бу бөек шәхесләрне, аларның әсәрләрен инәсеннән җебенә кадәр сурәтләп бирә ала. Билгеле, иҗат кешесе әнә шундый тирән белемле, киң карашлы булырга тиеш, ләкин һәммәбездә бармы соң мондый асыл сыйфатлар? Бетховен, Чайковскийлар үз заманы фәлсәфә гыйлемен яхшы белгән икән, дип кайсыларыбыз дөнья философлары мирасын төпле рәвештә өйрәнеп ята? Санаулы затлар гына. Әнә шул санаулылар исәбенә Р. Еники дә керә. Чөнки инструменталь музыка — очраклы рәвештә генә төзелгән авазлар кушылмасы түгел, аның һәр үрнәгендә мәгълүм фәлсәфә ята. Әсәр шунсыз туа алмый!

Җыр чыгаручы композиторлар исә шагыйрь фикеренә генә ияреп бара...

Р. Еникинең иң зур уңыш казанган әсәрләре арасында «М. Җәлил истәлегенә» (1981) дигән вокаль-симфоник поэма да бар. Аның ничек тууы хакында композитор үзе болай сөйли:

— Хәсән ага Туфанның шигырьләр җыентыгын укыганда мин аның «Җир әйләнә» әсәренә тап булдым. Ул шигырь мине фашизмга каршы нәфрәт хисе белән тетрәндерде һәм аңа музыкаль чишелеш табу хыялы туды. Бу әсәрне язганда шагыйрьнең идеясен музыкада тулы чагылдыру өчен катлаулы музыкаль форма таләп ителүе, моның өчен башка чыганаклар да кулланырга кирәклеге ачыкланды. Шактый күп чыганакларга мөрәҗәгать иттем. Аеруча Рафаэль Мостафинның «Герой-шагыйрь» эзләреннән» исемле китабы бик нык булышты. Әсәр язылып беткәч, Хәсән ага музыка белән үтә кызыксынып танышты һәм хуплавын белдерде. Бу минем өчен бик зур шатлык иде, билгеле.

Туфанның нәни шигыреннән этәргеч алып, Еники милли музыкабыз тарихында якты эз калдырачак әсәрен әнә шулай иҗат итә. Ышанып әйтергә мөмкин: шагыйрь һәм композитор нияте, идеясе туры килсә дә, ул ниятне гамәлгә ашыру чаралары икесендә ике төрле. Еники шаулы музыкасы аркылы корал көченә — рух көчен, диктатурага каршы художник ихтыярын куя. Музыкаль образлар саран чаралар белән сурәтләнә: бәрмә кораллар ритмик салкын яңгырап, вакыт агышын саный, шулар фонында тромбон исә кеше тормышының нәзберекләгән чагылдыра. Фашист документының битараф рухы шагыйрьнең кайнар хисләре белән давыллы музыка яңгырашында кара-каршы очраша. Күп тавышлы орган вакыйгаларга галәми колач бирә, хорның дулкынландыргыч елавы фаҗиганең тирәнлеген аңлата. Шагыйрьнең үлеме аның иҗатының үлемсезлегенә китерә, көчле симфоник тавышлар тантанасы талантның диктатура эскәнҗәсен тишеп, иреккә чыгуын күзаллата.

Ренат Еники 1983 елда шушы вокаль-симфоник поэмасы һәм кайбер камера әсәрләре өчен Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Композиторның симфоник оркестр өчен язылган «Рапсодия»се (1987) дә тыңлаучылар яраткан әсәрләр исәбенә керә. Ул анда туган җире язмышын, заманнар агышында халкы тормышы ничек дәвам итүен сурәтли. Оркестрның бай яңгырашында борынгы заман һәм бүгенге көнкүреш күренешләре җанландырыла. Халык чичәне телгә килгәндәй, «Рапсодия»нең беренче авазлары архаик рухта яңгырый. Башта ук түбән тынлы кораллар авазыннан ерак гасырлар чагылдырылуын тоясың. Эпик рухтагы көчле башламнан якты сәхифәле вакыйга үсеп чыга — бөтенесе нурда коена, оркестр барлык буяулары белән чәчәк ата, әмма бәхетле тормыш агымына хәвеф бәреп керә. Ватан куркыныч астында! Бу чакыру баһадир куәтләрне уята — оркестр төрки каһарманлык дастаннары рухында яңгырый — һәр гасырдагыча, яшьләр ватанны сакларга кузгала. «Рапсодия» халыкчан аһәңнәр рәвешендә агыла — музыка сокланырлык дәрәҗәдә милли яңгырый.

Әсәрнең икенче бүлегендә оркестр кораллары сөйләшә, хәрәкәт көчәя, темптизлек арта, музыкада күп кеше җыйналу күренеше ачыла — чуар, шаулы халык төркеме гөр килә. Автор бу өлешне сабантуй бәйрәме тәэсирендә иҗат итә. Халык традицияләре җыйналмасы әсәрдә әнә шулай калку гәүдәләндерелә — бу күренешләрдә халыкның көч-куәте, яшәү энергиясе дөрли. Әсәрдә вакыт-заманалар бәйләнеше гаять тәэсирле һәм матур чагылдырыла. Шундый сыйфатлары белән бу «Рапсодия» ерак-еракларда да игътибар казана — аны Белоруссия академия оркестры да үз репертуарына ала.

Иҗат эше — катлаулы процесс, безнең өчен инструменталь музыка туу барышы аеруча серле тоела. Еники симфоник оркестр өчен музыка язу хакында үз төшенчәсен һәм тәҗрибәсен менә болай аңлата:

— Һәр теманың үз тембры бар,— ди ул.— Мәрмәрдә, агачта, бронзада төрлечә: агач — җылырак, мәрмәр — салкынрак. Сынлы сәнгатьтәге кебек, музыкада да теманың үз тембрын табу әһәмиятле. Музыкаль образ үз тембры белән туа. Оркестровканың асылы да шулай. Фактура һәм гармония мәгълүм тембр сайлап алуны таләп итә. Бу процесс эчке тоем белән үк хәл ителә. Тембр төгәл сайлап алынмаса, музыка образлылык көченнән мәхрүм кала. Дөрес сайланмаган тембр хәтта бөтен планны, идеяне үтерергә мөмкин. Җыеп әйткәндә, музыканың һәр компоненты үзара ярашып торырга тиеш.

Шушы таләпләрне Еники башка әсәрләрендә ничек гамәлгә ашыра соң?

Аның Икенче кыллы квартеты (1972) халык тормышының төрле күренешләрен гәүдәләндерә. Анда күп бизәкле, күп тавышлы җанлы тормыш агышы ачыла — бу әсәрнең милли йөзен билгеләүдә уңышлы хезмәт итә. Шунысы со-

кландыра: Ренат дөнья классик музыкасы хәзинәсен татар композиторлары арасында тирән белүчеләрдән булса да, шуның куәтле йогынтысында космополитка әверелми, киң эрудициясен ул милли көйләребезнең төрле яңгырашларын, вариантларын табуда файдалана. Шунлыктан аның бу кыллы квартеты тыңлаучыны әсәрләндерә, ачышлары белән гаҗәпләндерә — аның өч кисәге дә кызыксынып һәм сокланып кабул ителә. Халык көйләре — композитор хыялын илһамландыручы һәм кабызучы, аның үсешенә һәм чәчәк атуына этәргеч бирүче көч. Йодрык кадәрле җепшек кар йомарламы колач җитмәс шарга, аннары кыш бабайга яки кар кызына әверелсен өчен балаларның уртак тырышлыгы кирәк. Бер яки берничә көйнең аерым өзекләреннән бөтенләй башка, кабатланмас яме һәм тәме булган яңа әсәр үсеп чыксын өчен дә талантлы иҗатчы булу сорала. Әйтергә кирәк, Ренат мәгълүм бер көйдән этәрелеп, әлегәчә колак ишетмәгән авазлар дөньясына кереп китә һәм шуннан үзен дулкынландырган, алгысыткан хисләренә тәңгәл ритмнар, моңнар байлыгын сөзеп чыга. Аның шул табышында замандашларыбызның катлаулы, каршылыклы рухы, аларның эзләнүләре, югалтулары һәм табышлары куе тойгылар, тирән фикерләр рәвешендә чагыла. Классик принципларга таянып барлыкка китерелгән, җанынннан сыгып чыгарылган музыкаль шәкелләр, аларда яңгыраган оригиналь, тәэсирле бормалар, кичерешләр байлыгын түкми-чәчми җиткергән авазлар ярашуы төрле ил, төрле милләт тамашачыларын әсир итә. Бу әсәрне Казаннан еракта да, шул исәптән, Алмания һәм Япониядә дә уйнаган эскрипкәче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шамил Монасыйпов, нәүбәттәге бер гастроленнән кайткач, болай дигән иде: «Чехословакиядә Ренат Еникинең квартетын башкардык. Югары профессиональ дәрәҗәдә иҗат ителгән әлеге әсәрдә хис тә, интеллект та бар. Андый Квартетны теләсә кайсы аудиториядә уйнасаң да, йөзең кызармаячак».

Музыка белгечләре бу квартетта кардәш халыклар музыкасы гонсерләренең дә табигый үрелеп китүен, әсәрнең тематик яктанербөтенлеген, фактурасының күпкырлылыгын, музыкаль материалның полифоник үсешен, квартетның аз күләмдә күпне сыйдыруын да мактап телгә алдылар. Русия Федерациясе Композиторлар берлеге рәисе, СССРның халык артисты Родион Щедрин бу әсәрне тыңлаганнан соң, мәсәлән, болай ди: «Аның формасы камил, жирлеге милли, автор исә хәзерге заман сурәтләү чараларын яхшы белеп һәм иркен куллана, хисләрне зәвыклы гәүдәләндерә, аның профессиональ осталыгы югары». Мәскәү филармониясе сәнгати җитәкчесе Р. Еникинең бер үк концертта башкарылган Икенче кыллы квартетын, эскрипкә һәм фортепиано өчен язган «Романс»ын һәм «Вальс-скерцо»сын халыкка киңрәк таныту максатында тиз арада бастырып чыгарырга тәкъдим итә.

Әйе, камера музыкасына караган зур әсәрләр белән бергә, композитор кыллы уен кораллары һәм фортепиано өчен кечерәк күләмле әсәрләр дә иҗат итә: аның Бакый Урманчега багышланган эскрипкә һәм фортепиано өчен «Романс»ы (1979) нәкъ менә әнә шундыйлар исәбеннән. Белгечләр фикеренчә, бу әсәргә күтәренке рух, лирика һәм драматизмның бергә үрелүе, музыканың ритмик яктан төгәл һәм камил оешуы, милли лад-гармоник теленең ачыклыгы хас. Автор эскрипкә табигатен, фактураны яхшы белеп, авазларны үзенчәлекле тезеп, куе яңгырата һәм әсәрне романтик рухта иҗат итә. Шуңа күрә ул беренче тапкыр башкарылуында ук тыңлаучыларның югары бәясенә лаек була һәм, «Вальс-скерцо» белән бергә, эскрипкә миниатюраларының иң әйбәт үрнәкләре сафына баса. Казан эскрипкәчеләр квартеты һәм халыкара конкурслар лауреаты, эскрипкәче Зариус Шәехморзаева репертуарында даими урын ала.

Бу кыска гына әсәрне тыңлаганда минем күңелдә сынлы сәнгатебезгә нигез салган Урманченың бөтен драматик язмышы җанлана — күз алдына аның күп төсләр бәйрәме шикелле «Салтык болынында» картинасы (яшьлекне сагыну!), «Сөембикә» уйма-сыны (гүзәллек һәм үкенеч!), «Сагыш» уйма-сыны (фани дөнья гыйбрәтләрен җыйган аксакалның гомер азагындагы фәлсәфи уйлануы!) килеп баса. Эскрипкә әле сагыш, җәбер-золым елларының хәсрәте, әле талгын сабырлык, әле бирешмәс рух һәм көрәшләрдә ирешкән җиңүләр хакында сөйли кебек — бу моңнар ачыну, нәфрәт, теләктәшлек хисләрен оета, шундый кичерешләрдә, төрле гаммәләрдә узган гомернең барыбер татлы булуын искә төшерә һәм яшәргә өнди. Әсәрне тыңлагач: «Бу музыка мине нәкъ булганымча чагылдыра», ди Бакый Урманче. Романс Б. Урманченың яки авторның үз тормыш юлын, бәрелешләрдә узган чыныгуларын гына түгел, татарның милләт буларак яшәешен дә сурәтли кебек. Әйе, бу язмыш катлаулы, ләкин өметсез түгел, чөнки бу «Романс»ның кайнар рухы, йомшак лирикасы, фәлсәфилеге үзе үк безнең яралы күңелгә дәва булып туган.

«Вальс-скерцо» (1971) — виртуоз уенчыга исәпләп эскрипкә һәм фортепиано өчен язылган әсәр. Автор монда да үзе яраткан контраст алымын куллана — заманның давыллы ритмнары аша бирелгән тормыш күренешләрен борынгы милли хәят күренешләренә каршы куя. Эскрипкә партиясендә йөгәнсез фантазия, бик тиз үзгәреп тора торган «очышлы» фактура әсәрнең баш һәм ахыргы өлешләрендә җиңелчә көлемсерәү белән ачылган халык тормышының шактый искерә төшкән, катыбрак калган көнкүреше сурәтләрен мәзәк хәлдә күзаллата. Лад-гармониясе җәһәтеннән сәер, үзенчәлекле фактурага ия гәүдәләндерүнең капма-каршы чараларын файдаланып, һич тә берләшә алмастай күренгән өлешләрне бербөтенгә укмаштыру, әсәрнең формасын нечкә тою авторга бердәм стильдәге тоташ әсәр барлыкка китерергә мөмкинлек биргән. Еники шатлык тулы, дөньяны якты-нурлы итеп күрсәтә торган җәүһәр иҗат итеп, тыңлаучыларга яшәү дәрте өсти. «Вальс-скерцо»дан чәчрәп торган шаяру, мыскыллы елмаю, наян үртәү, биюче картларны якын итеп, яратып гәүдәләндерү җылы аһәңнәр көлтәсе рәвешендә сибелә. Монда да Ренатның кыска, кечкенә күләмгә күп күренешләрне сыйдыра алуы, музыка чараларын эшкә бәрәкәтле җигүе күз алдында. Чын талантларга хас сыйфат бу. Матбугатта юкка гына «Вальс-скерцо»ның нечкә юморга, интонацияләргә-төсмерләргә байлыгы һәм башка уңай сыйфатлары хакында күпләр язып чыкмады шул!

Композиторның эскрипкә һәм фортепиано өчен язылган «Ариетта»сы (1976)да тере хисләргә бай, үтемле, моңлы, матурлык һәм рухи мәгънәлелек символы буларак яңгырый торган әсәр. Автор анда хатын-кызларга хас нәфислекне, мөлаемлекне, йомшаклыкны сурәтләргә омтыла, шул ук вакытта хатын-кыз матурлыгы белән табигать гүзәллеген тәңгәлләштереп гәүдәләндерергә тели. Бу әсәр җанга якынлыгы, рухыбызга аваздашлыгы белән бәгыребездән сытылып чыккан музыка шикелле булса, икенче яктан, үзенең колачлы булуы белән галәми киңлеккә чыга, безне дә җир шары тирәли очышка алып китә сыман. Аның саф авазлар ташкыны, нәфислеге йөрәкне җилкетә, хыялларны канатландыра, моңнар тобасына батырып, чынбарлыкның ят, тирән катламнары белән таныштыра, адәм баласының белгесезлекне ачыклауда зур мөмкинлекләре барлыгын, аны алда әле бик күп табышмаклар көткәнен искәртә сыман. «Ариетта»ны һәркем үзенчә кабул итеп, үзенчә аңлатырга мөмкин, тик шунысына шикләнмәскә мөмкин: аны тыңлау рәхәт һәм кызыклы!

Р. Еникинең һәр әсәренә җентекләп тукталу мөмкин булмаганлыктан, аларның кайберсен санап китү белән генә чикләнергә туры килә. Әйтик, җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп иткән И. Крылов мәсьәләләре темасына язылган миниатюралар татар симфоник музыкасында яңа жанр — сатира барлыкка килүен хәбәр итте. Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал», Н. Фәттахның «Кол Гали» пьесаларын сәхнәләштерү өчен язылган музыкасы Еникинең төрле жанрда уңышлы эшли алуын раслады. Ниһаять, аның «Үрләреңне менгәч» (С. Хәким сүзләре), «Ак дулкыннар», «Ләйсән» (М. Хөсәен сүзләре), «Синең эзләр» (Роб. Әхмәтҗан), «Язмышым» (С. Хәким), «Һәр кич саен» (Ә. Баян), «Сүрелмәс җырым син» (Р. Вәлиева) кебек җырларын кем генә белми икән? Аларга моңда сыгылмалылык, тавыш интонациясендә ачыклык, гамониядә затлылык, фактура төрлелеге хас.

Үз эшенә гаять таләпчән караганлыктан, Ренат арзан танылу эзләми, җыр язуны башкалар шәбрәк булдырыр, дипме, үзе музыканың катлаулырак жанрларында көчен сыный, шул тармакларда Европа осталары белән ярышырга йөрәкләнә.

Еникинең тирән милли аңлы шәхесләргә хас бик кыйммәтле бер сыйфаты — туган сәнгатебездәге ниндидер бер бушлыкны тудырырга тырышуы. Бу гамәл аңа авторлык шөһрәтен китерми, әмма ул татарның гармоник үсеше өчен кирәк. Мәшәкатьле, күп көч һәм вакыт сорый торган ул шөгыльнең үз әсәрләрен язуга киртә генә булачагын белсә дә, бүтәннәр шуңа алынмагач яки алынырга әзерлекләре дә җитмәгәч, нишләмәк кирәк? Мисалга, республикабызда музыка мәктәпләре байтак, ләкин аларда укытыр өчен милли репертуар әлегә юк дәрәҗәсендә иде. Татарстанда татар көйләрен уйнамыйча гына музыкантлар тәрбияләү сәер түгел идемени? Ренат шуңа күптән борчылып йөргәнлектән, С. Сәйдәшев көйләрен фортепиано өчен эшкәртергә алына һәм шуңа ел ярым гомерен багышлый. Бик катлаулы бурыч була бу, чөнки ул көйләрнең фортепиано ачкычын табу, көйне уен коралларына дөрес күчерү зур теоретик әзерлек һәм иҗади сәләт таләп итә. Ниһаять, егерме көйне эченә алган «Яшь пианист дәфтәре» әзер.

Ренатның фидакарьлеген исбатлаган икенче эш — татар халык җырларын баритон һәм фортепиано, оркестр өчен эшкәртү, «Карьят батыр», «Бик еракта

идек без», «Син сазынны уйнадың» һәм башкалар нәкъ менә аның зәвыклы, тылсымлы кулы кагылу аркасында этнографик бизәкләрдән чын җәүһәрләргә әверелеп яңгырый башлады. Әйтергә кирәк, «Син сазынны уйнадың» көе 24 такттан тора. Илһам Шакиров аның 8 тактын гына көйләп бирә, калган 16 тактны исә Ренат Еники үз уйлап «бетерергә» мәҗбүр була!

Татар музыкасы профессиональ яктан үсеп, инде күптән республикабыз чикләрен атлап узды. А. Монасыйповның сонатасы Парижда, М. Мозаффаровның эскрипкә концерты Чехиядә, З. Хәбибуллинның кайбер җырлары күрше республикаларда башкарылуын, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, Н. Җиһановның «Алтынчәч» һәм «Җәлил» опералары ерак чит илләрдә дә куелган, соңгы дәвердә исә яшьрәк буын композиторларыбызның инструменталь әсәрләре Азия һәм Европа сәхнәләрендә яңгыравын горурланып телгә алабыз. Бу казанышларда өлеше барлыгын искәрткеч, Р. Еники:

— Уңышлар юк түгел,— диде.— Әмма мин үсешебездән һич тә канәгать түгел. Чит илләрдә «Шүрәле» дә, «Алтынчәч» һәм «Җәлил» дә куелмый ич хәзер. Инструменталь әсәрләребез тегендә-монда яңгырый икән, үз музыкантларыбыз гастроле нәтиҗәсе алар. Бу әле халыкара күләмдә чын танылу түгел. Финнәр әнә: «Симфониябез бар, ләкин операбыз юк», диләр. Югыйсә Финляндиядә ел саен ике-өч опера языла, ләкин алар үз илләрендә генә куела икән. Ә Я. Сибелиус симфонияләре барлык илләрдә уйнала. Сибелиус фин симфоник музыкасын киң мәйданга алып чыга. Ягъни халыкара танылу ул әсәреңнең күп илләрдә репертуарга керүе дигән сүз. Без әле менә шуна һаман ирешә алмыйбыз. Билгеле, милли музыкабызның беренче бурычы — татарның рухи ихтыяҗын канәгатьләндерү. Әмма татар музыкасы ни өчен әле зуррак киңлекләргә чыкмаска, халкыбыз шәһрәтен ерак-еракларда да җәймәскә тиеш? Димәк, без туктаусыз эзләнергә тиеш. Биектә очасы вакытта без әле бүген башкалабызның бердәнбер музыка театрын, күп кенә талантларны берләштергән коллективны татар репертуарын уйнарга мәҗбүр итә алмыйбыз. Дәртебез күп, дәрманыбыз чамалы, ахры! Димәк, «офыкларыбыз киңәйде!» дип күкрәк кагарга бик иртә әле.

Р. Еники пессимист түгел, юкса ул төрле аяк чалулардан инде күптән сөрлеккән булыр иде. Аның фикеренчә, халкыбыз зур һәм затлы интеллектуаль байлыкка ия, ләкин аны тиешенчә бәяли, күрсәтә һәм сата белми.

Билгеле, Ренат үз эшчәнлегеннән дә канәгать түгел. Сәләтенең һәм көченең шактый өлеше тормыш вaклыклары белән көрәшкә исраф ителгән. И. Ганди әйтмешли, «кеше елап туа, ләкин бу дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк ки, аннан киткәндә, сине югалтуның ачы хәсрәт икәнлеген аңлап, башкалар еларлык булсын». Еники фикеренчә, күпләр күңелен тетрәтерлек даһи әсәрен ул әле язмаган, имеш! Килешүе кыенрак, әмма композиторның үз иҗатына шулкадәр таләпчәнлек күрсәтүен хупламыйча да мөмкин түгел. Күңелендә дәрт тә, дәрман да бар, өметләребез зурдан әле.

Тагын шунысы йөрәгенә юаныч бирә: хатыны Нәркис белән алар — фикердәшләр. Нәркис ханым — Татарстан радиосының музыка тапшырулары редакциясе хезмәткәре, консерватория тәмамлаган фольклор белгече. Уллары Надыйр да ата-аналары эзеннән атлый — Казан мәдәният академиясе студенты, мандолинаchы булырга җыена.

Р. Еники Казанда һәм Мәскәүдә унөч китап — музыка әсәрләре җыентыгын чыгырган автор да ич әле. Аннары ул гомер буе саф иҗат эшенә генә күмелеп яши алмады — театрда һәм филармониядә хезмәт итте, фольклор экспедицияләрендә йөрде, укыту белән шөгыльләнде, җәмәгать эшләреннән дә читтә калмады. Иҗатташы Рафаил Билалов әйтмешли, «эш бит күп язуда гына түгел, сыйфатлы язуда. Менә соңгысы җәһәтеннән инде Еникигә дәгъва белдерү мөмкин түгел, ул татар музыкасын яңалык алып килгән гаять үзенчәлекле, тирән хисле фәлсәфи эчтәлекле әсәрләр белән баетты».

Ренатның атасы Башкортстан Каргалысыннан, язучы Әмирхан Еники белән бер нәселдән. Анасы Татарстанның Арча төбәгеннән, Тукайга кан-кардәшлеге бар. Тамыры тирән, кәүсәсе нык агач давылларга да бирешмәгән шикелле, Ренат та тормыш юлында калыккан киртәләрне исән-аман атлап уза алган һәм онытылмаслык әсәрләр барлыкка китергән. Шуңа күрә аңы әдәбият-сәнгатебезнең Бакый Урманче, Сибгат Хәким кебек аксакаллары үз иткән. Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Ренат Еники үзе дә әнә шундый күренекле иҗатчылар токымыннан, ул әле киләчәктә дә яңадан-яңа иҗади табышлары белән безне күп мәртәбәләр шатландырыр. Без исә аңа бары уңышлар гына телибез!

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**

# ФАКТЛАР НӘРСӘ ДИ?

Татарстан китап нәшрияты 1996 елның башында, зур кыенлыклар булуга карамастан, минем күп эзләнүләр нигезендә табылып төзелгән «Татар шәҗәрәләре» җыентыгының беренче китабын дөньяга чыгарды. Бу китабыма игътибар итеп, татар әдәбияты буенча күренекле белгеч Мәсгуд Гайнетдин «Казан утлары» журналы битләрендә (1996, № 8) рецензия-бәяләмә дә язып чыкты.

Бәяләмә гомумән уңай язылган. Әлбәттә, анда кимчелекләр булуы да күрсәтелә. Сүз дә юк, кимчелекләрне күрсәтү кирәк, ләкин мин аларның күбесен кимчелек дип санымйсым килми. Шунлыктан биредә кайберләренә карата фикерләремне язарга булдым. Тарихи фактлар буталмасын өчен.

Мәсәлән: 38 биттәге «ятар» сүзен «йотар» дип үзгәртергә бер нигез дә юк. Кара: Башкирские шеджере.— Уфа.— 1960.— Б. 27, 233.

55 биттәге «Иман каласы» шәҗәрә текстында Өфе (Уфа) дип күрсәтелгән. Бу атамага искәрмә соралмый да. Ул М. Гайнетдин теләгәнчә «Яман кала» дип язылмаган. Орски атамасы да монда кирәкми.

84 биттә «Шаһи Озынның кулы буенча» дигән җөмлә бар. Шаһи Озын — реаль кеше исеме һәм кушаматтан гыйбарәт сүздер. Бу очракта ул «шаһлар рөхсәте» дип тәрҗемә ителми. Шаһи Озынның әдәби псевдонимы — Шаһиәхмәт Мәнгәри. Ул — тарихчы, 1930 еллар тирәсендә үлгән.

88 биттәге «Тау иле янында» сүзен «Тау иле ягында» дип укырга нигез юк. Чөнки монда «Тау иле» — авыл исемен белгертә (хәзерге Тат. Ходаш авылы).

3 биттә дә бәяләмә авторы минем фикеремне бозып «Татар халкы бүген дә Дәшти Кыпчакта яши» — дип яза. Минем хезмәтемдә исә: «Татар халкы нигездә бүгенге көндә дә үзенең тарихи ватанында, ягъни халык булып формалашкан әүвәлге Дәшти Кыпчак җирендә яши», диелгән.

5 биттәге «пырак булды» сүзе (тузанга әйләнү мәгънәсендә) татар теле сүзлекләрендә дә бар. Кара: (Татар теленең диалектологик сүзлеге.— Казан.— 1993.— Б. 254).

24 биттәге Алтын Урда ханнарының мөселман Көнчыгышына карата тоткан кыйблалары турындагы мәсьәләгә рецензент фикерен төшенеп булмый. Ул ниндидер халыкларның «яшәү хокукы, хөрмәт» һ. б. турында яза. Минемчә, сүз бары Ислам дине өйрәтүләре нигезендә идарәчеләрнең үз билгән урыннарын изгеләштерергә омтылулары турында гына бара, һәм аның масштабы гына арттырыла.

38 бит. Рецензент мине Исмәгыйль исемен Шәйбаниләргә ябыштыра, ди. Минем искәрмәдә андый фикер юк. Сүз бары шәҗәрәдәге буталчык факт турында гына бара.

«Аеры Калбак»ны «калмык» белән бәйләргә дә бер урын да юк. Калмыклар Җаек буйларына фәкать 1600 еллар чамасында гына килеп чыгалар. Татарлар, гомумән, төркиләр калмыкларны гел үз исемнәре белән атаганнар.

40 биттәге «Ата» терминын М. Гайнетдин суфыйлар шәҗәрәсенә тартып кертергә өнди. Бездә суфыйлар шәҗәрәләре бар, ләкин аларда «ата»лар юк. Татар шәҗәрәләрендәге «Коркот ата» кебек исемнәр дә суфыйларга түгел, нәсел башларына карыйлар. Суфыйлар нәселләренә караган шәҗәрәләрдә шәех, суфый кебек терминнар күренә.

Рус телендә басылган «Татарские шеджере» теоретик хезмәтемдә мин шәҗәрәләрне тикшерү, аларга тәнкыйди якын килү ысулын бәян иттем. Тарихчылар шул ысулдан файдаланып татар халкы кулында XX гасыр ахырынача сакланган шәҗәрәләрне тәфсилләп өйрәнерләр, җитмәгән, югалган буыннарын ачарлар, яңа мәгълүматларга баерлар.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.



# БЕЗНЕҢ КЫЗЛАР — САЛАВАТ КҮПЕРЕ!..

Кем генә яшьлегеп сагынмый икән!

Менә балачак хатирәсе булган фоторәсемнәрне карап утырам. Аларның берсендә туган авылым Арташның «Кирмән очы» дип аталган урамы буйлап, күлмәк итәкләрен җилфердәтә-җилфердәтә, өч кыз йөгерә: Нәзифә, Гөлфәния, Миннебикә... Кошлар кебек канатланып оча яшүсмер кызлар! Бер читтә, исе китеп, ак кәҗә бәтие янәшәсендә, авызын ачкан авыл малае карап тора...

Әлеге рәсем моннан кырык ел чамасы элек, Сабан туе вакытында, классташыбыз — ул чаклардагы сирәк очрый торган һәвәскәр фотограф Николай Степанов тарафыннан төшерелгән иде...

Еллар томанына күмелеп артта калган балачакның, яшьлек елларының кабатланмас бер мизгеле булган әлеге фоторәсем инде әллә кайчан Нәзифәләрнең Мәскәүдәге иркен фатирында, һәркемнең күзе төшәрлек дәрәҗәле урында тора. Хуҗабикә үзе, күптәннән ике бала анасы булуга карамастан, Балачак илендә калган елларын һаман да сагынып яши. Үзе өчен кадерле булган шул рәсемгә карап, ул яшьтәшләрен, авылдаш дусларын, якын күршеләрен, кызыклы хәлләрне, мавыктыргыч уеннарны хәтерендә яңарта. Җыеп кына әйткәндә, бу рәсем аңа дәрт-илһам, Тукаебыз әйтмешли «язар өчен азык» бирә.

...Авылдашым һәм сабакташым Нәзифәнең күңелендә әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт уятуда, мөгаен, аның тапкыр сүзле, җыр-шигырь чыгарырга оста әнисе Мәүҗидә апа, әтисе — моңлы күңелле Харис абый, аларның терәлеп торган ут күршеләре — ике сугыш ветераны, авылның данлыклы гармунчысы һәм чичәне Борһан ага Сәләхов сәбәпче булгандыр. Гаять кызыклы, үзенчәлекле шәхес иде Борһан ага. Заманында ул берадәран Кәримовларның Казандагы типографиясендә эшләгән, бөек шагыйребез Габдулла Тукай белән якыннан аралашкан. Шуның тәэсире булса кирәк, Борһан ага үзе дә сатирик-юмористик рухтагы шигырьләр иҗат итәргә маһир иде — авылыбыз халкы аны, бик тә хөрмәтләп: «Үзебезнең Тукай!» — диеп йөретте...

Җор телле, шигъри күңелле, җырга-моңга гашыйк кешеләр арасында яшәү Нәзифәнең дә күңелен җилкендереп җибәрә, күрәсең: «Тукта әле, мин дә, Борһан абый кебек, шигырьләр чыгарып карыйм әле!..» Тырыша торгач, максатына ирешә Нәзифә. Кызның бу сәләтенә Урта Кирмән сигезьеллык мәктәбенә (Мамадыш районы) Алабуга педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп җибәрелгән дипломлы яшь белгеч, Нәзифәләрнең класс җитәкчесе Әнисә Касыйм кызы Галиева да игътибар итә. Үзе дә шигырьләр язу белән мавыккан Әнисә апалары балаларны, шул исәптән Нәзифәне дә, тылсымлы-серле Шигърият дөньясына алып керә.

Берзаманны алар класслары белән шигырь яза башладылар. Тора-бара без дә — күрше класслардагылар да — әкренләп аларга иярдек. Ул чакта мәктәптә иҗади рух хөкем сөрде. Әдәби түгәрәк утырышларында тикшерелгәннән соң, иң яхшы дип табылган «әсәрләр»не туплап, кульъязма газета-журналлар да чыгардык хәтта. Нәзифәнең дә беренче шигырьләре әнә шуларда урын алды...

Сигезьеллык мәктәптән соң, Алабугадагы мәдәни-агарту училищесын уңышлы тәмамлап, Минзәлә районы үзәгендәге мәдәният йортында методист, директор булып эшләгәндә дә, Мәскәүдә эстрада сәнгатенең Бөтенроссия иҗат мастерскоенда ике еллык курсларда укыганда да (бирегә ул Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оештырган иҗади бәйгедә җинеп чыгып, үзен нәфис сүз остасы, биюче итеп таныткан өчен җибәрелә) Нәзифә күңелендә иҗат ялкыны сүнми-сүрелми. Башкалада яшәүче әдәбият-сәнгать әһелләре белән дә якыннан аралаша ул. Шул чорда «Литературная Россия» атналык газетасы журналисты, язучы-тәрҗемәче — күренекле шагыйрь Мостай Кәримнең улы Илгиз белән танышып-дуслашып, соңыннан аңа кияүгә чыга. Әдәби-мәдәни мохит аны яңадан каләмгә тарта. Һәм ул көчен проза жанрында — аның иң авыр төре саналган балалар әдәбияты мәйданында сынап карарга була. Балалык елларында үзе күргән-кичергән хәлләр турында шигъриятле итеп яза Нәзифә. Һәм, ниһаять, аның хикәяләре, парчалары бер-бер артлы Татарстан матбугаты битләрендә дә күренә башлый. Балалар язучысы Ләбибә ханым Ихсанова да моңа игътибар итә һәм 1975 елда «Социалистик Татарстан» газетасында, Нәзифәнең тәүге чор иҗатын анализлап, «Юл башы» дип исемләнгән язмасын бастыра. Шуннан бер өзек китереп үтәсебез килә:

«...Казан утлары» журналында һәм «Яшь ленинчы» газетасында Нәзифә Кәримованың балалар өчен язган хикәяләре күренә башлауга бер генә ел әле. Сан ягыннан күп тә түгел үзләре. Әмма даими алып барган темасы һәм яратып язган нәни геройлары белән шактый җылы тәэсир калдыралар.

Нәзифә балаларны тоташ хәрәкәттә бирә... Автор балаларның шаянлыгын белә, шуны күрсәтерлек сүзләр таба... Тагын шунысы куанычлы: яшь автор күп сүзле түгел. Кайсы яшьтәге балалар белән эш иткәнен белеп яза, артык детальләр кулланудан, вакыйгаларны катлауландырудан саклана. Шуңа күрә аның хикәяләре җыйнак, кыска языла... Шунысы сөендерә, Нәзифә Кәримованың иҗат юлына шактый җитди әзерләнеп чыкканы күренә...»

Әлбәттә, мондый бәя яшь язучының иңнәренә канатлар куя. Тагын да дәртләнебрәк иҗат итә башлый ул. 1976 елда Нәзифәнең рус теленә тәрҗемә ителгән хикәяләре «Запах мяты» («Бөтнек исе») дигән күмәк җыентыкта дөнья күрә. Җыентыкны төзүче — әдәбият белгече Галия Хантимерова китапка язган кереш сүзендә Нәзифәнең хикәяләренә дә тукталып үтә, яшь прозаикның гадәти авыл тормышын шигъри итеп сурәтли белүенә соклана...

Нәзифә исә, үз осталыгын тагын да камилләштерү, аң-белем офыкларын киңәйтү максатыннан, Башкорт дәүләт университетының татар теле-әдәбияты бүлегендә читтән торып укый. Китап сөючеләр җәмгыятенең Россия Федерациясе идарәсендә, Мәскәүдә Чит телләр әдәбияты китапханәсендә җаваплы вазифалар башкарганда да, аннары Щепкин исемендәге театр училищесының татар студиясендә булачак артистларга татар телен һәм әдәбиятын укытканда да язучылык эшен онытмый ул. 1986 елда Татарстан китап нәшриятында Нәзифәнең балалар өчен язган «Җәнлекләр кайта» исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. «Казан утлары», «Сөембикә» журналлары, «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасы битләрендә дә еш күренә аның чәчмә әсәрләре, төрле дәреслекләргә дә кертелә. 1991 елда исә Нәзифәнең «Казан утлары»нда дөнья күргән «Урманнан чаккан юлчылар» повесте татар әдәбиятында вакыйга буларак кабул ителә, әдәби тәнкыйть тарафыннан югары бәяләнә. Соңыннан, 1993 елда, әлеге әсәр Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Өермә» дигән повестьлар җыентыгында да дөнья күрде.

Бер үк вакытта тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлары бар Нәзифә Кәримованың. 1992 елда ул, күренекле төрек язучысы Газиз Нәсиннең сатирик-юмористик әсәрләрен туплап, «Эт койрыгы» дип исемләнгән җыентыкны, Татарстан китап нәшрияты аша, татар укучысына җиткерде. Хәзерге вакытта Нәзифә танылган чуваш язучысы Ева Лисинаның «Синьял балалары» исемле күләмле әсәрен татарчага тәрҗемә итеп, нәшриятка тапшырды.

Быел Нәзифә Кәримова, драматург буларак та, үз тамашачысын тапты. Аның «Үп мине, Зәйтүнә!» исемле ике пәрдәлек лирик-музыкаль комедиясен Чаллы татар дәүләт театры коллективы (режиссеры — Ринат Әюпов-Шәлә, Нәзи-

фәнең Щепкин студиясендәге шәкерте) сәхнәләштерде, 10 мартта исә аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында сәнгать сөючеләргә дә күрсәтте. Көчле алкышларга, чәчәкләргә күмделәр бу көнне Нәзифәне!..

* * *

Шушы елның 24 маенда, Мәскәүнең Зыялылар клубында, Нәзифә ханымның илле яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсе үткәрелде. Аны Татарстаннан һәм тугандаш Башкортстаннан килгән күп кенә дуслары, әдәбият-сәнгать әһелләре кайнар котлады. Ире Илгиз, юрист булып эшләүче кызлары Айгөл, Мәскәү дәүләт университетының журналистика бүлегендә укучы уллары Нияз да әниләре өчен горурланып утырдылар бу кичәдә.

1993 елдан башлап, «Азатлык» радиосының Россия башкаласындагы үз хәбәрчесе, Мәскәүдәге Татар-башкорт зыялылары клубы директоры, Бөтендөнья татар хатын-кызлары «Ак калфак» берләшмәсенең идарә әгъзасы буларак та, гаҗәеп зур эшләр башкара якташыбыз. Купкырлы асылташ яисә салават күпере кебек балкып, күңелләргә якты нур сибүче бу ханым — үзенең тапкырлыгы, уңганлыгы, җитезлеге белән! — халыкара «Киленбикә» бәйгесендә дә җиңүчеләрнең берсе булды.

Язучы буларак, Нәзифәнең әдәбият өлкәсендәге уңышлары күренекле әдип Шәйхи Маннур исемендәге премия белән билгеләп үтелде...

...Безнең яшьлектәге фоторәсемне тагын кулыма алам. Балачакта бергә-бергә бәбкә үләнле урамнардан ялан тәпи йөгереп узган, олы Тормыш мәйданына Сабан туе көнендәгечә чәчрәп килеп кергән, халкыбыз файдасына инде күп кенә игелекле эшләр эшләп өлгергән сабакташым бүген дә зур иҗади омтылышлар, гамьле уй-ниятләр белән янып яши.

Салават күпере бер кабына икән, аңардагы төсләр балкышы күпләрнең күңелен нурга күмә, Табигать һәм Тормыш манзарасын матурлый. Безнең кызларны — татар кызларын салават күпере белән чагыштырырга тырышуыбызның төп мәгънәсе әнә шунда.

Тормыш Сабан туе дәвам итә...

**Шаһинур МОСТАФИН.**

## Музыка сөючеләргә

«Курай» радиосы II Бөтендөнья татар конгрессына багышлап халык арасында иң популяр җырларны ачыклау максатында хит-парад үткәрә. Анда катнашу өчен түбәндәге купонны тутырып мондый адрес белән җибәрергә кирәк: 420036, Казан, а/я 38.

Исем, фамилиягез ______________________
Яшегез ______________________
Һөнәрегез ______________________
Яраткан җырыгыз ______________________

Конкурс 31 июльгә хәтле дәвам итә, ә 1 августта туры эфирда катнашучылар арасында лотерея уйналачак. Җиңүчеләрне кыйммәтле бүләкләр көтә.

**«Курай» радиосы.**

# «ТАТАР ПЬЕСАСЫ» КОНКУРСЫ

**Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге 1997—1998 елларда драматургия жанрларын үстерү һәм баету максатында «Татар пьесасы» конкурсын игълан итәләр.**

Яшьләрне һәм балаларны театр сәнгатенә җәлеп итү, үсеп килүче буыннарга эстетик, әхлакый һәм милли тәрбия бирү, шулай ук балалар өчен хәзерләнгән спектакльләрнең профессиональ дәрәҗәсен үстерүне һәм балалар драматургиясенең жанр төрлелеген баетуны күздә тотып, «Татар пьесасы» конкурсы кысаларында балалар өчен язылган драма әсәрләре (пьеса, әкият, мюзикл һ. б.) бәйгесе дә үткәрелә.

Конкурста драматурглар, язучылар, шагыйрьләр белән беррәттән, язучылар берлеге әгъзасы булмаган иҗат яшьләре дә катнаша ала.

Пьесалар өч нөсхәдә кабул ителә, кульязмалар каралмый. Һәр нөсхәнең титул битендә әсәрнең исеме, жанры, авторның девизы күрсәтелә. Авторның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, өй адресы, телефоны, әсәрнең исеме, жанры, девизы ябык конвертта җибәрелә.

Конкурска моңарчы басылмаган һәм куелмаган сәхнә әсәрләре кабул ителә. Конкурска җибәрелгән әсәрләр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Конкурска катнашкан авторларның исемнәре, лауреатларныкыннан кала, матбугатта игълан ителми. Әсәрләр конкурска 1998 елның 1 апреленә кадәр кабул ителә.

Конкурска кабул ителгән сәхнә әсәрләрен бәяләү өчен составына күренекле театр эшлеклеләре, режиссерлар, актерлар, театр тәнкыйтьчеләре кергән жюри төзелә. Аның составы Татарстан Республикасы мәдәният министры тарафыннан раслана.

Иң яхшы дип табылган әсәрләрнең авторларына лауреат исемнәре һәм акчалата бүләкләр бирелә:

**I премия — 1 данә**
**II премия — 3 данә**
**III премия — 5 данә**

Балалар драматургиясе конкурсы аерым йомгаклана, җиңүчеләргә шулай ук лауреат исемнәре һәм акчалата бүләкләр бирелә:

**I премия — 1 данә**
**II премия — 2 данә**
**III премия — 3 данә**

Оештыручылар тарафыннан ике кызыксындыру премиясе (аларның берсе балалар пьесалары конкурсы йомгаклары буенча) бирү мөмкинлеге карала. Жюриның нинди дә булса премияне бирми калдыру һәм файдаланылмый калган премия фондын үз карамагы буенча бүлеп бирү хокукы бар.

Йомгаклау утырышы һәм конкурс нәтиҗәләрен игълан итү 1998 елның 7 маеннан да соңга калмый уздырыла.

Дәүләт, җәмәгать, коммерция предприятиеләре һәм оешмалары үз премияләрен һәм призларын билгели алалар, бу очракта премия хуҗаларының фикере жюри фикере белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин.

Конкурс лауреатлары булып билгеләнгән, шулай ук премия алмаган, әмма жюри тарафыннан уңышлы дип табылган әсәрләр республика театрлары сәхнәләрендә куелу өчен тәкъдим ителәчәкләр.

Әсәрләрне түбәндәге адрес белән җибәрергә кирәк: 420014 Казан, Кремль, III подъезд, Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы, сәнгать бүлеге, «Татар пьесасы» конкурсына. Белешмәләр өчен телефоннар: 32-07-26, 32-64-73.

## ПРЕЗИДЕНТ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

16 майда Татарстан Президенты М. Шәймиев Казан Кремлендә республикабызның матбугат һәм радио-телевидение житәкчеләрен кабул итте. Анда газета-журналлар редакцияләре, «Татарстан» телерадиокомпаниясе тапшырулары эшчәнлеген тагын да яхшырту-камилләштерү юллары турында житди сөйләшү булды. Татарстанның үз Матбугат һәм мәгълүмат көнен 19 майда үткәрергә дигән карарга киленде.

Очрашуда ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, вице-премьер И. Хәйруллин, ТР Матбугат министры И. Әхмәтҗанов катнашты.

## ҮЗ ШАГЫЙРЕН ОЛЫЛЫЙ ВАТАН

28 апрельдә К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында бөек шагыйребез Габделҗаббар Кандалыйның тууына 200 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Олуг шагыйрьне искә алырга, аның иҗатына баш иярга Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Татарстан Фәннәр академиясе президенты — язучы М. Хәсәнов, башка рәсми затлар, депутатлар һәм Мәскәүдән, Башкортостаннан, Төркиядән кунаклар килгән иде.

Чын мәхәббәт шагыйре булып ил елъязмасына, халык хәтеренә кереп калган классик шагыйребезнең үзенчәлекле тормыш юлы һәм иҗаты хакында иң элек Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев сөйләде. Рухи туганы һәм тәбәктәше турында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р. Харис үз фикерләре белән уртаклашты.

Аннары сәнгать осталарыбыз Г. Кандалый тормышын һәм иҗатын гәүдәләндергән әдәби-музыкаль тамаша күрсәттеләр.

## КҮҢЕЛЛӘРНЕҢ ТУРГАЕ СИН, ТУКАЙ!..

Халкыбызның бөек улы Г. Тукайның туган көнендә — 26 апрельдә — башкалабыз Казанда һәм республикабызның күп кенә төбәкләрендә шигърь бәйрәмнәре гөрләп узды. Ә шулай да аның аеруча киң колачлысы, халыкны үзенә иң күп туплаганы мәркәзебезнең Ирек мәйданында — олуг шагыйребезгә салынган һәйкәл янында булды. Биредә быел да Татарстанның күп кенә шәһәр-авылларыннан, Россиядән һәм БДБ илләреннән, чит мәмләкәтләрдән кунаклар, шигърият сөючеләр байтак килгән иде.

Шигъри митингны Татарстан Югары Советының даими комиссия рәисе — танылган шагыйрь Р. Миннуллин ачып җибәрде һәм 1997 ел өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләген бирү турында ТР Президенты Указын игълан итте. Лауреатлар өчәү — рәссам Абрек Абзгильдин, җырчы Венера Ганиева, шагыйрь Ренат Харис... Көчле алкышлар астында, алар бер-бер артлы сүз алып, үзләренә күрсәтелгән шундый зур хөрмәт өчен, халыкка һәм житәкчелеккә ихлас рәхмәтләрен белдерделәр. Аннары мөнбәр шагыйрьләргә, сәнгать осталарына бирелде. Әлеге шигъри бәйгедә Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзиев, Тукай бүләге лауреатлары Г. Зәйнашева, М. Әгъләмов, фронтовик-язучы К. Латыйп, урта буын шагыйрьләрдән Л. Шагыйрьҗан, Р. Гаташ, Зөлфәт, И. Гыйләҗев (Азнакай), Р. Газизов (Мамадыш), Н. Сафина, яшьләрдән Илгөлем, Эльмира Җәлилова... — барлыгы дүрт дистәдән артык кеше чыгыш ясады. Килгән кунаклардан төрек шагыйре Айхан Инал, Башкортостан шигърияте илчесе Муса Сиражи, мәскәүле Игорь Ляпин чыгышларын халык аеруча яратып кабул итте.

* * *

27 апрельдә Тукай бәйрәменә килгән кунаклар һәм Җөмһүриятебез шагыйрьләре, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев житәкчелегендә, Арча районының Кушлавыч авылында булдылар — олуг шагыйребезгә җан иңдергән, иҗатына илһам биргән әлеге төбәктә хәзер Тукаевларның музей-усадьбасы эшли. Арча педагогия училищесында һәм Тукай-Кырлайда да очрашулар җылы үтте.

* * *

7 май көнне «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, КДУ профессоры, язучы-академик Тәлгат Галиуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрәфҗанов, Татарстан Җөмһүрияте милли китапханәсе директоры Разил Вәлиев, Балтач районының Сасна Пүчинкәсе авылында булып, Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстай җирләнгән каберстанга зыярат кылдылар. Зират янындагы мәчет тирәсенә күрше авыллардан да байтак халык җыйналган иде.

Шул ук көнне Казан кунаклары Субаш авылы мәдәният сараенда авыл халкы һәм мәктәп укучылары белән очраштылар.

Тукайга бәйле урыннарны мәңгеләштерү һәм халыкка мөмкин кадәр күбрәк билгеле итү юнәлешендәге бу күркәм эшләр Балтач районы хакимияте башлыгы урынбасары —

шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин тырышлыгы белән оештырылды.

* * *

Чаллы шәһәрендә дә Г. Тукайны зурлап искә алып үттеләр. Бөек шагыйребез исемен йөрткән клуб янында уздырылган шигъри митингта Нәҗип Мадияров, Мәхмүт Газизов, Фәкил Әмәк, Әхмәт Дусайлы, Мирһади Разов, Шамил Шәйдуллин, җырчылардан Фән Вәлиәхмәтов, Гөлдания Хәйруллина, Асия Әхмәтшина, Дания Сибгатуллина һ. б. чыгыш ясадылар. Аннары бәйрәм «Энергетик» мәдәният сараенда дәвам итте. Татарстан дәүләт телерадиосының Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге симфоник оркестры һәм халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллинаның концерт төркеме, танылган җырчылардан Рафаэль Сәхәбиев, Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтов тамашачыларга бәхетле минутлар бүләк иттеләр.

*ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫНДА

15 майда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Утырышта Казан ханлыгы чорының күренекле шагыйре Мөхәммәдьярның тууына 500 ел тулу уңаеннан үткәреләчәк олы юбилейга хәзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Әдәбиятыбызның горурлыгы-мактанычы булган Мөхәммәдьяр белән Г. Кандалый исемнәрен республика күләмендә мәңгеләштерү зарурлыгын әйтеп, Татарстан Президенты М. Шәймиевка һәм Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаковка ачык хат кабул ителде. Идарәдә Татарстанның Әлки районында туып-үскән атаклы чуваш язучысы Педер Хузангайның 75 еллык юбилеен июнь аенда Казанда үткәрү, татар әдәбияты классигы Ибраһим Газиның 90 еллык юбилее уңаеннан, аның туган ягында — Кама Тамагы районында әдәби очрашулар уздыру турындагы мәсьәләләр дә каралды. Бирәдә шулай ук «Татарстан язучылары» дигән китап-белешмәнең тулыландырылган яңа басмасын хәзерләү турында да сөйләшү булды һәм бу басманың редколлегия рәисе итеп өлкән язучыбыз Р. Даутов билгеләнде.

## ӘДӘБИЯТ ФОНДЫ ТЕРНӘКЛӘНӘ

Элекке СССР һәм Россия Әдәбият фондларында матди яктан һәм җитәкчелектә җитди кыенлыклар килеп чыгу сәбәпле, Татарстан язучыларының Әдәбият фонды да соңгы елларда шактый авыр хәлдә яшәгән иде. Ниһаять, безнең Әдәбият фонды тернәкләнә башлады! Фонд идарәсенең 23 апрельдә булып үткән чираттагы утырышында әнә шундый фикер әйтелде. Идарә рәисе Әхсән Баянов, фонд директоры Данил Салихов, баш бухгалтер Диләфрүз Вахитова язучыларга соңгы айларда рухи һәм матди ярдәмнең сизелерлек яхшыруын билгеләп үттеләр. Аеруча мохтаҗларга акчалата һәм әйберләтә дә булышлык күрсәтелгән. Яңа ел, Халыкара хатын-кызлар бәйрәмнәре уңаеннан, язучыларны һәм аларның балаларын түгәрәк өстәл янына — чәй мәҗлесенә чакырып, ихластан котлаганнар, бүләкләр тапшырганнар. Иҗат йортларына бару өчен арзан бәягә юлламалар (путевкалар) алу мөмкинлеге тудырылган. Мәрхүм язучылардан 10 кешегә һәркайсы 12 миллион сум торган кабер ташлары эшләтелгән. Фондка «УАЗ» маркалы җиңел машина алынган...

Бу өлкәдә матди яктан Әдәбият фондына Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы, Татарстан китап нәшрияты (җитәкчеләре — язучы Рәфкать Кәрами, Харис Әшрафҗанов) аеруча зур булышлык күрсәткән — идарә утырышында аларга рәхмәт әйтелде.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘЛӘРЕ

Татар әдәбияты классигы — күренекле прозаик һәм драматург, күренекле җәмәгать эшлеклесе Мирсәй Әмирнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, 25 февральдә Казанда, Актерлар йортында, искә алу кичәсе булып үтте. Язучылардан Р. Мөхәммәдиев, Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, Р. Харис, Р. Мостафин һ. б. олуг әдип турында истәлекләре белән уртаклаштылар. Кичәдә аның магнитлы тасмада сакланып калган үз тавышы да яңгырады, якыннарының да чыгышлары тыңланды. Г. Камал театры артистларыннан Р. Таҗетдинов, Р. Шәрәфиев, Х. Җәләлов, Н. Әюпов, З. Зарипова һ. б. Мирсәй аганың «Миңлекамал», «Агыйдел» спектакльләреннән өзекләр уйнап күрсәттеләр, сатирик-юмористик хикәяләре белән таныштырдылар. Җырчылардан З. Сәхәбиева, Ф. Сөләйманова, З. Нурмөхәммәтов, М. Сөнгатуллин һ. б. язучы араткан җырларны башкардылар. Әдәби-музыкаль кичәне З. Шакирҗанова алып барды.

* * *

М. Әмирнең туган ягы булган Башкортстанда да әдипне зурлап искә алдылар. 13 мартта Мәләвез районы мәдәният йортында, 21 мартта туган авылы Җиргәндә «Саф күңелләр җырчысы» дигән исем астында хәтер кичәләре үткәрелде.

---


*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, рәссам Абрек Абзгильдинның «Дәрдмәнд» триптихы.



Газиз Гобәйдуллин
(1887—1937)

Индекс 73210



Шагыйрь Нажар Нәҗми.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)